


# КАЗАН УТЛАРЫ

9
СЕНТЯБРЬ
1982

# КАЗАН УТЛАРЫ

**9**

СЕНТЯБРЬ
1982

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга


СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ


Х. ӘЮПОВ. Бәйрәмнәр. Шигырь . . . . . . . 3

М. ХӘБИБУЛЛИН. Суләр үргә акса да. Роман . . 4
Н. АРСЛАНОВ. Ана сөте белән. Шигырьләр . . 66
З. МӘҖИТОВ. Яңа шигырьләр . . . . . . 74
Ф. ЯРУЛЛИН. Йөрәп тора хатлар гына. Шигырьләр . . . . . . . 76
Г. ӘДҺӘМОВА. Үкенечкә калмасын. Кечкенә повесть . . . . . . . . 80


ДУСЛАР ИҖАТЫ


Д. КУГЕЛТДИНОВ. Моабит тоткыны. Поэмадан өзекләр . . . . . . . . 117
А. КАПУСТИН. Тозлы чык . . . . . . 121


МАЙ ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!


М. РАФИКОВ. Чаптар туктамый. Очерк . . . . 133


КАЗАН АЛАРНЫ МӘҢГЕ ОНЫТМАС


Р. САБИРОВ. Бөек юлның башлангычы . . . 138
Беренче марксист . . . . . . 142
Ике даһиның университетлары . . . . 145


ЯЗУЧЫ УЙЛАНУЛАРЫ


Т. МИҢНУЛЛИН. Кызыл тышлы дәфтәрдән . . 148


НУРИ АРСЛАНОВКА 70 ЯШЬ


З. МАНСУРОВ. Үзгәрде рух, китте җан уянып . . 161


БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ


Л. ИХСАНОВА. Сабыйлыкта кунакта . . . 168
Р. ЯГЪФӘРОВ. Дәү китап . . . . . 172
М. ӘГЪЛӘМОВ. Нәниләрне онытмагыз! . . . 174



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

СӘНГАТЬ

Э. ШӘРИФУЛЛИНА. Җанга шифа . . . . . 177
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Бер йолдызың миннән булыр 181

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН. Барый Тархановның тууына 90 ел . . . . . . . 185

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Телдән-телгә күчә көлке сүз . . . . . . . 187
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . 190

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ *(баш редактор урынбасары)*, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

---

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63; сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 21/V-1982 ел. Басарга кул куелды 20/VIII-1982 ел. ПФ 04229. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65.049 экз. Заказ Ю-215. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.



# СССРның төзелүенә 60 ел

## Харрас Әюпов

### Бәйрәмнәр

Кешелекнең үзе шикелле үк
Борынгыдан килә бәйрәмнәр,
Шатлыкларын бәйрәм итә кеше,—
Бәйрәмнәрдә олы ямьнәр бар.

Җир шаулатыр бәйрәмнәрең булсын...
Бәйрәме бар халык — бай халык:
Гасырларның бәйрәм җилләрендә
Җыры кала,
Байраклары бара чайкалып.

Бәйрәмнәрдә — бәхет тантанасы,
Җан сафлыгы, күңел яктысы.
Гомер буе озатып бара безне
Бәйрәмнәрнең керсез ак төсе.

Тар күңелдә була алмый бәйрәм...
Бәйрәмнәргә кирәк мәйданнар:
Борынгылар җаннар матурлыгын
Мәйданнарга,
Гасырларга җәеп салганнар.

Дулкынланып бара ал байраклар,
Илдә — хөрлек, илдә — бәйрәмнәр;
Бәйрәмле дә, җырлы да син, халкым,—
Киләчәккә иңәр ямьнәр бар!..

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# СУЛАР ҮРГӘ АКСА ДА

РОМАН

## 10



Декабрь аеның чатнама суык бер көнендә Зөлфияләргә Барый килеп керде. Зөлфия баянда уйнап утыра, әнисе кухня ягында аш пешерә иде. Ишек тавышына Зөлфия уйнаудан туктады, коридорга чыкты. Кыска тун кигән Барый әнисенә тотлыга-тотлыга нидер сөйли, әнисе биленә бәйләгән алъяпкычны кулларына ураган да шаккатып тыңлый.

— Сәлам, Барый!

— Исәнмесез, Зөлфия.

— Чишен.

— Кәримә Алабугада укый икән бит,— диде Барый.

Гөлбикә белән Зөлфия бер-берсенә мәгънәле генә карашып алдылар.

— Син әле яңа белдеңмени, Барый? — диде Зөлфия аны мыскыллап.

— Минем анда барып кайтырга исәп бар. Шуңа киңәшкә килгән идем. Ул анда милиция мәктәбендә укый булса кирәк.

Гөлбикә Барыйга беравык сынап сүзсез карап торды.

— Алып кайт син аны Казанга. Булдыра алсаң, алып кайт. Бирелә дә бар түгелме соң ул мәктәп, һич югы монда укыр, янымда булыр...

Ана бу сүзләрне гүя Барыйга түгел, аны күрмичә, аның аша кемгәдер мөрәҗәгать иткәндәй эчке бер сагыш белән әйтте. Кухня ягына кереп, әнисе пешереп маташкан коймакны яндыра төшеп, Зөлфия май исе чыгарды, ана моны да сизмәде, күңел күзе белән ул Кәримә кызы белән сөйләшә иде.

— Өсте дә юкадыр. Формалары бик юка бит... Әй, бала, бала...

Барый тунын салмады, чишенмәде, түргә узмады, китәргә ашыкты.

— Мин китим инде, Гөлбикә апа. Аэропорттан билет аласым да бар. Яңа ел алды бит, билет булырмы әле.

— Ай аллам, әллә коймагыңны яндырасың инде, Зөлфия!

Гөлбикә кухняга кереп китте. Зөлфия, бераз чытлыкайланып, ефәк халатын җемелдәтеп, Барый янына чыкты.

— Китми тор. Китмә дим! Кияү...—диде ул кинәяләп.—Хәзер ышандым, чын кияү син. Ә ул кияүгә чыккан булса, Борька?

— Нәрсә анда шыпырт кына сөйләшәсез? Зөлфия, әйт үзенә, китмәсен әле. Чәй эчкәч китәр.

---

Ахыры. Башы 7—8 саннарда.

— Ашыга ул, билет аласы бар,— диде Зөлфия.

— Тукта инде алай булгач,— Гөлбикә янә коридорга әйләнеп чыкты.— Әйт үзенә, кайтсын. Хатка язып кына аңлатып булмады инде. Гел бишлегә укыган бала медицина институтына да керә алган булыр иде дә бит. Я аллам, нигә шундый үзсүзле булды икән бу бала! Әйт үзенә, бераз әниеңне кызган, диген. Бик милициядә эшлисе килсә, врач булгач та эшли алган булыр иде дә бит... Язганы, кылганы шулдыр. Кайтсын, кайтмаса бәхиллегем юк, дип әйтеп әйтте диерсең.

— Хушыгыз.

— Чао, Борау, ак юл сиңа! — дип калды Зөлфия.

## 11

Алабуга шәһәренә Яңа ел алдыннан юлга чыкты Барый. Юлга чыкты дип, самолет белән бер сәгатьлек ара инде ул. Дөресен әйтергә кирәк, Кәримәнең милиция мәктәбенә китүен гөманлап кына белә иде ул. Элемтә техникумында укуы ярап куйды. Кызның адресын бик тиз тапты. Сортировочныйда практика үтүче кызларга: «Азатова Кәримәгә яисә Азатова Кәримәдән нинди дә булса хат күзегезгә чалынса, зинһар адресын язып алыгызчы»,— диде. Адресны тапкан кызга бер тартма шоколад вәгъдә итте. Һәм аңа озак та көтәргә туры килмәде, кулына Кәримәнең адресы килеп керде. Кыз хатны Казан шәһәрендәге бер егеткә язган иде. Бу хәл Барыйны борчымады. Берәр классташыдыр дип кенә юрады.

Барый шат иде. Күңелендә нинди дә борчылуга хас шигәю бар барын, чөнки Кәримә нинди дә егеткә хат яза, Барыйга түгел, әмма эшнең бу ягына бик үк игътибар итмәскә тырышты ул. Иң мөһиме, Кәримә югалмаган да, кемгә дә кияүгә дә чыкмаган, Алабуга шәһәрендәге милиция мәктәбендә укып йөри.

Әле булса хәтерендә Барыйның: беренче тапкыр озата баргач, ул аның кулыннан алды һәм сизелер-сизелмәс кенә үзенә табарак тартып китергәндәй итте, шул вакытта кыз яшьлеге, наивлыгы беләнме, карусыз аның кочагына керә язган иде. Барый шунда гүя күккә ашты, ул моны гелән көтмәгән иде. Дөрес, егеткә тартылу белән, кыз шунда ук читлеккә эләккән кош кебек бәргәләнергә тотынды, әмма беренче адым ясалган иде инде, ике арадагы киеренкелек кисәк эреп, юкка чыккан иде. Шул көннән алып Барый өчен ир-егет дуслар бетте, күңелендә гел Кәримә дә Кәримә.

Самолет һавага күтәрелүгә, Барый түбән карады.

Кыш. Түбәндә кар каплаган кырлар, ә тирә-юньдә иксез-чиксез зәңгәрлек диңгезе. Аның күңеле дә бөтен дөньяны иңләр кебек иде бүген. Ниһаять, ул Кәримәсен күрәчәк һәм, ниһаять, бераз гына тынычланачак. Ярата бит ул шул Каракүзне, ярата. Ә бит Барый табигате белән гаять горур егет иде. Әнә нишләтә икән кешене мәхәббәт. Кәримә аңардан ике-өч яшькә кече булса да, олыларча фикер йөртә белә. Барый хәтта үзен аның янында бала итеп хис иткән иде. Ни өчен шулай? Башта ул моның асылына төшенә алмый йөдәде. Ә инде кисәктән кыз югалгач, аңа чын мәгънәсендә юксыну килде. Сагынды, юксынды, аның юкка чыгуын ни дип аңлатырга да белмәде. Кәримә аңа тагын да кадерлерәк булып китте. Дәрестә булсынмы, юлда булсынмы, Кәримәнең мөлаем, бераз гына самими сөйкемле карашын күз алдына китерер иде дә, сагышланудан йөрәге кысылып куяр иде. Менә ни өчен кулына Кәримәнең адресы төшүгә, юлга җыена башлады ул. Яңа елга ике көн кала китүе дә имтиханнарын алдан бирүе дә шуннан иде. Ул тырышты, ул сабакташлары көнләшердәй итеп яхшы укый башлады. Котбый мыскыллы елмаеп йөрде, әмма сабакташының кәефен

бозарга теләмәде. Чөнки үзе дә шуңа охшашлы ук гашыйк, гыйшык дулкынында йөзә иде.

Техникумга кергәндә гел бергә йөргән егетләр теге хәлдән соң һәммәсе үз дөньясына кереп бикләнде, һәммәсе үз кайгысы белән яши башлады. Кемдер әйткән бит: кешене кеше итү чараларының иң хикмәтлесе, иң кадерлесе, иң заруры — аның тәүге тапкыр чын-чынлап киләчәк тормыш турында уйлана башлавындадыр, дип.

Китәр алдыннан Барый янә Гөлбикәләргә килде, Алабугага очуы турында әйтте.

Кәримәнең әнисе, күз яшен сөрткәләп алды һәм, юмартланып китүен раслау өченме, Барыйга егерме биш сум акча сузды.

— Мәле, һич югы шул акчаны бирерсең үзенә. Өстенә рәтле кием дә алмаган иде, юп-юка формадан йөридер...

— Рәхмәт, минем акчам бар, кирәксә, үзем бирермен,— диде Барый, сузган акчаны алмый торды.— Кием өчен кайгырмагыз, формалары җылы аларның.

— Ал, ал. Һәм әйт, колагына киртеп әйт: ялга кайтсын, әниең гафу итә, диген. Нишлисең, язмыштан узмыш юктыр, күрәсең. Гафу итми кая барыйм, кайтсын...

— Язмышны күп вакытта үзебез ясыйбыз шул, Гөлбикә апа.

Ана кеше сәерсенеп, хәтта бераз аптыраштарак калып, бер мәл егеткә карап торды, әмма берни дә әйтмәде.

— Ярый, хуш! Исән-сау йөреп кайт...

Барый Кәримәне ике сәгать буена милиция мәктәбе каршында каравыллады. Тулай торакка барырга нигәдер оялды. Мәктәпкә кереп, дәресләр барганда кемнәрнедер борчып йөрисе дә килмәде. Аннары ул Кәримәгә үзенә күрә бер сюрприз ясамакчы: син миннән качып киттең, ә мин сине барыбер таптым, диясе килә иде егетнең. Ихтимал, йөргән егете дә бардыр инде, дигән газаплы һәм шомлы уй да килгәләде башына. Ахыр чиктә барыбер алай уйлыйсы килми иде. Мәктәп ишегеннән кереп-чыгып йөргән халыкның күбесе — ир-егетләр, хатын-кыз сирәк күренә. Барысы да бер төрле формадан булгангамы, кинәт кенә тануы да кыен иде. Шуңа күрә Барый капка янынарак күчте.

Ачык һавада озак торгангамы, эчкә салкын төшә башлады, җылы ботинканың гүя олтаны юкарды — яланаяк карда басып тора сыман, тун исемен йөрткән пальто кисәге дә бер дә җылытмый — аркага кар тәңкәләре коелып эри-эри дә тәнне куыра-куыра түбән тәгәри кебек. Өшүе тәмам җитте, аякны аякка суккалап, кулны-кулга каккалап торуның да файдасы әллә ни юк. Ә капкадан керүче һәм чыгучыларның Барыйда ник бер гамьнәре булсын. Кәримә һаман күренми.

Суык тәмам эчкә төште, аяклар, ни суккаласа да, бер-берсен тоймый башлады.

Ул гына да түгел, төньяк тарафтан салкынча җил исеп, җәяүле буран купты. Шул җил, шул буран Барый күңелендәге мәхәббәт ялкынын сүрелдерергә тели сыман тоела башлады.

Капка каршында гына юан тупыл үсеп утыра, ахыр чиктә Барый шул агач янына килде, бәйдәге эт сыман, шул тупыл тирәли әйләнә башлады.

«Мин түзәргә тиеш. Тагын биш минут. Нибары биш минут». Шул мәлдә капкадан чыр-чу килеп, күксел-зәңгәрсу-яшькелт төстәге форма кигән яшьләр чыга башлады. Барый аны күргәч тә таныды һәм чак кына кычкырып җибәрмәде, кычкырды да бугай хәтта, мәгәр тавышы гына бик зәгыйфь чыкты. Бу, әлбәттә, аның тетрәнүле дулкынлануыннан һәм ахыр чиккә җитеп өшүеннән иде. Кәримә дә аны шунда ук искәреп алды. Чөнки яшьләрнең барысы да юан тупыл янындагы егеткә (күрер күзгә ыспай егеткә) игътибар иткәннәр иде.

— Барый!

Кыз башта аңа таба ташланды, аннары исенә килде бугай, әйләнеп, сабакташларына карады, сабыррак атлап китте һәм килеп житүгә:

— Барый, жүләрем, туңгансың бит! — диде.

Юк, үз итеп кенә әйтмәде, әнисе баласына дәшкән кебек кызганып, жәлләп дәште. Барыйның күзенә яшь йөгерде, ул моны гел көтмәгән иде, ләкин шунда ук читкә борылып, перчаткасының сансыз бармаклары белән, күз яшен сөртеп алды.

— Жил,— дигән булды.

Кыз башка сүз катмады, килде дә егетнең күкрәгенә башын төртте.

— Рәхмәт, Барый. Мең-мең рәхмәт сиңа!

— Ни өчен? — дигән булды Барый.— Ни өчен, Кәримә? — диде кызның аркасыннан кочып, тамак төбендәге каты төерне йотып жибәрә алмый торды.— Ни өчен!

— Килүең өчен, синең дөньяда булуың өчен...

Кыз башын күтәрде, егетнең күзләренә карады.

— Мин сине бик озак көттем, Кәримә.

— Син тәмам туңгансың ич, Барый.

— Кәримә! — дип дәште булачак милиционерлар арасыннан берсе.— Житте. Хәйригә әйтәм.

— Әйтмәгәең,— диде аңа кыз, үзе һаман Барыйдан күзен алмады.

Кызның да күзләрендә яшь иде.

— Син мине чынлап та көттеңме, Кәримә?

— Белмим. Миңа синсез кыен булды, Барый. Үзем дә белмим, нигәдер бик кыен булды... Әйдә тулай торакка, туңгансың ич...

Гел күптәнге, бик күптәнге танышлар кебек ягымлы итеп, үз итеп дәште ул. Кызның бу сүзләре Барый күңеленә сары май булып ятты, йөрәге дәртләнеп, ашкынып тибә башлады, туңган аяклары кызышып китте.

— Әйдә, мин чынлап та бераз өшедем бугай шул. Суык икән сезнең бу Алабугада.

Кәримә егетнең терсәген кысты. Аның иптәшләре күздән югалганнар иде инде.

Кәримә иптәш кызы белән бер бүлмәдә яши икән, классташы янына егет килеп керүгә, теге шунда ук каядыр чыгып та югалды. Бүлмә жылы иде, Кәримә аны чишендерде һәм, хәзер чәй эчәбез, дип, электр чәйнеген утка тоташтырды.

— Өшегәнсең ич син, Барый, жүләрем.

Егет дигәнең шундый сүзләрдән эридер инде. Кәримәнең бу сүзләреннән Барыйның эченә генә түгел, аякларына чаклы эссе коелды. Бераз иялләнгәч, бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Алты-жиде квадрат метрлы бүлмәгә ике карават куелган, ишек катында чаршау сыман нәмәрсә, шунда Кәримә чәй хәзерләп йөри. Түр якта, ул утырган өстәл янында өч урындык. Икесенә хужалар утырса, бер урындык кунак өчен, бу очракта минем өчен, дип уйлады Барый һәм үз уйларыннан үзе үк көлемсерәп куйды.

— Әй, гел онытып жибәргәнмен. Менә моны киеп жибәр әле. Менә шул жылы оекбашларны. Хәтимәнеке ул. Күршем минем шундый: кырык беренче размер кия. Сиңдәй егетләрне бер итек кунычына тыга да куя. Кайбер егетләр хәтта якын килергә дә куркалар үзенә. Менә бу журналларны караштыра тор. Мин хәзер.

Кәримә каядыр чыгып китте. Бераздан ул (буфеттандыр инде) кочагына тутырып, ризык-нигъмәт алып керде.

— Хәзер, хәзер, әз генә сабыр итсәң. Син иртәннән бирле ашамагансыңдыр әле?

Барыйның эченә тәмам жылы төште. Иң курыкканы: Кәримәнең

аны ничек кабул итүе иде. Ә ул... күз тия күрмәсен, гелән аны күтәп торган сыман кылана. Әй, шуларның барысы да чын булса икән! Бәй, чын бит инде, чын-чынлап Кәримәнең бүлмәсендә утырасың, ә ул ду килеп, сиңа табын әзерләп йөри. Барый тәмам тынычланып китте, эреп таралгандай булды.

— Хәзер чәй эчәбез,— дип килеп керде Кәримә.

Табын янында ул тартынып тормады, кат-кат көйләтеп чәй эчте. Үзе кырын күзе белән генә Кәримәне күзәтте. Рәхәт иде аңа Кәримә белән шулай утырулары.

— Мин синең монда китүеңә ышандым да, ышанмадым да,— диде Барый.

Кәримәнең бит очлары алланды, озын кара керфекләрен еш-еш каккалап, ясап куйган куе чәйгә карап тора башлады, гүя кыз шунда тагын кемне дә булса күрергә тели иде.

«Мин аны яратам икән бит,— дип уйланып утыра башлады кинәт кенә Барый.— Яратам. Әнә шул нәни баланыкыдай бармакларын, кара чәчләрен, туры төз борынын яратам, җәядәй иреннәрен...»

Кәримә өстәл янына милиция формасын салып килеп утырган, шуңамы, тагын да чибәрләнеп киткән сыман, аның озынча каратут йөзенә моңсулыкка кушылып шатлык кунган иде. Ак чәчкәләр төшкән кызгылт төстәге фланель халатын кай арада киеп алгандыр.

— Минем монда килүем очраклы түгел, юкка түгел, юкка түгел,— дип авыз эченнән көйләп алды Барый.

Кәримә ике кулы белән иягенә таянган да, елмаеп, Барыйга карап тора. Гел-гел шулай карап торсын иде ул. Әй, җүләр булган да икән... Кайчан?.. Кайчан булсын, бер ел элек кенә. Котбыйның коткысына бирелеп, әллә ниткән каратэ алымнарына өйрәнеп... ә бит аның янында гына алиһә йөргән икән ич, гүзәлләрнең гүзәле — Кәримәкәй-Каракашкай-Каракүзкәй.

— Ә син шундый-шундый чибәрләнгәнсең, Кәримә.

— Көләсең, Барый!

— Билләһи менә. Шундый-шундый чибәрсең...

— Оялтма, Барый. Синең килүеңә мин шатмын, бары тик шул гына... Я, юк-бар сүзләр сөйләп утырганчы, әнә чәең суынды, эч тагын берне, кайнарлап бирәм.

— Яса, син көйләгән чәйне агу булса да эчәчәк Барый.

— Барый-Барый, җүләрем. Чынлап кылануларыңмы?..

— Ышанмыйсың инде. Телисеңме, коридорыгызга чыгып кычкырам.

— Ни дип? — сәерсенеп, шул ук вакытта бераз кызыксынып сорады кыз.

— Кәримәне яратам, дип.

— Тилекәй, яратканны шулай кычкырып йөриләрме. Миңа калса,— дип җитдиләнеп китте Кәримә,— яраткан кеше яратуы турында кычкырып йөрми. Чын-чынлап яратсаң, әйтми генә сиздер син аны, Барый.

Кәримә торды, Барыйның чәчен туздырып ташлады.

— Ә мин барыбер яратам,— егет кызның кулыннан эләктереп алды. Һәр бармакның битен укып чыкты.— Яраткан өчен гаепләмиләр. Яраткан — җан аткан.

— Әллә нинди син, Барый. Элек алай түгел идең.

— Анда, сирәк кенә булса да, син күз алдымда идең. Бердәнбер көнне син юкка чыктың. Һәм миңа курку килде. Инде сине беркайчан да күрмәм кебек тоела башлады. Аннары, төннәр буена уйланып ята торгач, тәгаен бер карарга килдем: табам икән, барысын да әйтәчәкмен, теге вакытта оялып йөргәнем өчен үкенгәннәремне белсәң икән син, Кәримәкәй-Каракүзкәй. Хәзер менә таптым һәм күзеңә карап, мин сине яратам, дип әйтергә булдым. Күзеңә карап, чөнки чыны шул.

Кәримә кисәк кенә аның алдына тезләнде, башын егетнең тезләренә төртте.

— Чынлапмы, Барый? Дөньяда шундый ярату да буламы, әллә без аны китаплардан гына укып беләбезме? Әйт әле, әйт, кабатла әле тагын бер шул сүзләреңне!

Барый кымшанырга да кыймыйча, кызның әллә ниткән хуш исләр, нәкъ менә кызларда гына була торган хуш исләр килгән чәченнән сыйпарга тотынды. Аннары үзе дә идәнгә тезләнде дә учлары белән кызның битеннән алды, күзләренә карады.

— Әйдә Казанга минем белән, Кәримә. Анда да милиция мәктәбе бар. Анда без гел-гел бергә булырбыз. Минем сиңа өйләнәсем килә. Әнием минем риза булыр, сине күрү белән риза булыр...

Кәримә аңа текәлеп карады, егетнең сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмичә текәлеп карады.

— Ю-юк, Барый, монда минем әтием укыган, кайчандыр шушы мәктәпне тәмамлаган. Аннары монда аның иң якын кешесе эшли. Син бернәрсә дә белмисең ич, Барыйҗан.

— Кем ул, кем?

Икесе дә аякка бастылар.

— Сиңа барыбер түгелмени. Ә ул әле булса аны ярата. Әтине күмгәннән соң ул бирегә килеп эшкә керә. Ул мине үз кызыдай күрә. Ә инәки мине беркайчан да аңламады. Аның үз куанычы, үз юанычы бар иде...— «Зөлфия апа», дип әйтергә теле бармады Кәримәнең.

— Менә нәрсә,— диде Барый, кызны кочагына алды.— Әйдә киного, аннары мин Шишкин музеен күргәнем юк, күрсәт әле шул музейны миңа...

Кәримә тыгыз күкрәкләре белән үзе үк егеткә сыена төште. Барый аның иңнәреннән сыйпады. Аңарда үзе дә аңлап бетермәгән хис ташкыны дөрли иде, гүя Кәримә изге җан, үз сеңелесе, нәфесен сузарга ярамаган бер зат иде. Кәримә сизелер-сизелмәс кенә читкә тайпылгандай итте, Барый кызның кулыннан алды.

— Мин киеним, Барый. Музей сәгать жиделәрдә ябыла, соңга калуыбыз бар.

— Минем шагыйрә Марина Цветаева каберен дә күрәсем килә.

— Анда да барырбыз,— дип, Кәримә чаршау артына керде.— Ул ерак түгел, тау башындагы зиратта гына.

Барый ут яктысында Кәримәнең халат салуын, зифа сынына күлмәк киюен чаршау аша сизеп, сокланып торды.

## 12

Музейда бөек рус рәссамы Шишкинның табигать манзараларын сәгатьләр буе карап йөрделәр. Рәссамның цоколь бүлмәсенә кергәч, Барый Кәриманең кулыннан алды, кызның кул кайнарлыгын тою һәм гаҗәеп картиналарны карау аңа тиңсез рәхәт иде, болай да ашкынулы йөрәге тагын да дулкынланыбрак тибә башлады.

Музейдан чыккач, тау башындагы зиратка мендeләр. Бик борынгы заманнарда ук ихаталап алынган зиратка кергәч, кабер ташларын укый-укый, шагыйрә Цветаева каберенә җиттеләр. Тимер чылбыр белән уратып алынган кабер өстендә тере чәчәкләр ята. Димәк, алар килер алдыннан гына биредә кемдер булган һәм, шагыйрәне искә алып, аның кабер ташына тере канәфер чәчәкләре салып киткән иде. Чәчәкләр кышкы салкында, күксел мәрмәр ташка язылган алтын хәрефләр өстендә яталар. Барыйга да, Кәримәгә дә бу чәчәкләрне күргәч, моңсу булып китте. Кәримә әтисен искә төшерде. Ул, күңеле тулышуын тоеп, Барыйга дәште.

— Барый,— егет аны ишетми тордымы, уйга чумуы идеме,— Барый дим,— дип пышылдады Кәримә, гүя аны биредә, тын зиратта, кояш баеп килгән мәлдә тагын кем дә булса тыңлап тора иде.— Барый дим, Казанга кайткач, зиратка барырбыз, яме. Әтиемнең каберенә канәфер чәчәге салырбыз, яме, Барый.

Кызның күзләрендә яшь иде, яшь бөртекләре аның тутсыл йөзе буйлап ирennәренә кадәр тәгәрәшеп төшәләр, кыз аны гүя күрми дә, сизми дә, ул уйга чумган, ул, мөгаен, бу минутта әтисе кабере янындадыр.

— Барырбыз, Кәримә. Тик син елама гына.

— Нигә без бирегә чәчәкләр алып килмәдек, Барый? Моңа мин гаепле. Минем монда беренче килүем генә түгел. Килгән саен үкенү тоям. Гүя миңа шагыйрә рухы рәнҗидер, миңа үпкәлидер сыман.

— Ул бер дә алай уйламый, Кәримә. Ул шатлана безнең монда килүебезгә. Ә хәзер...

Кинода Кәримә аңа елышып ук утырды.

— Карале, Барый. Нигә шулай икән, әйтерсең лә мин сине күптән, бик күптән беләм һәм инде без бергә торып караганбыздыр шикелле. Син дә шулайрак хис кичермисеңме?

Кино кино булмады, алар аны карамадылар да, Барый белән Кәримәнең күңеле экранда түгел иде. Барый кызның кайнар учындагы һәр сызыкны тоя, гүя ул аның йөрәк серләрен шуннан эзли иде. Вакыт-вакыт Кәримә аңа елышып, кайнар сулышы белән битен пешереп алды, зәгыйфь бер чәчәкне сындырудан, имгәтүдән курыккандай, егет аны ирексезләмәде. Кинонь әллә карадылар, әллә карамадылар, аларның үз дөньялары дөнья иде бүген.

Кинодан чыккач, алар бер адымнан атлап, тулай торакка кайттылар. Җил туктаган, тып-тын, салкынча, әмма түзмәслек түгел, рәхәт салкын иде.

Барый үз-үзенә шаккатты: нигә ул дөньяда шушындый ярату, дөресрәге, яратышу булуын белә торып, бер ялгызы каңгырап йөргән икән? Кәримәгә булган мәхәббәте янында дөнья мәшәкатьләренең барысы да күмелеп калды. Иртәгә ул Казанга кайтып китәр, Кәримә биредә калыр. Ничек аерылышырлар? Мөмкин хәлме бу! Барыйның беркая да китәсе килми. Шул ук вакытта биредә кала да алмый бит инде. Онытмасмы аны Кәримә?.. Юк, онытмас. Күрә бит ул, күрә, кыз да аңа карата битараф түгел. Хак анысы, башта бигүк шаккатмаган кебек иде, хәзер юк, ярты көн эчендә, әйтерсең, Кәримәне алыштырып куйдылар, ул гүя ямьле җәйдә иртәнге чык төшкән чәчәккә кунган бал корты бүген.

Барыйның Кәримәгә нindидер изгелек эшлисе килде. Әйтсен иде ул аңа мин риза дип, ул аны Казанга кадәр кулына күтәреп алып кайтыр иде.

Бүлмәгә кайтып кергәч, Кәримә аш пешерергә әзерләнә башлады.

— Мин дә булышам, беләсең килсә, ир-ат пешергән аш тәмлерәк була ди, минем инәй.

— Тилермә, Барый, үзем.

— Юк, үзем дигәч үзем. Мин түгел, син — минем кунагым.

— Ай, Барый, Барый. Мә инде алай булгач.

Кыз аңа бер савыт бәрәңге, пычак тоттырды.

Бүлмәләрдән төрле музыка, шау-шу килеп торган коридорга килеп чыккач, Барый икеләнә калды. Әмма кире чигенмәде, аяклары аны беренче катка алып төшеп киттеләр. Кухняны аш исе, таба мае исе буенча эзләп тапты. Шөкер, кухняда адәм заты юк иде. Бәрәңге әрчергә кереште.

— Кәримә,— дип кайтып керде ул бүлмәгә.— Тоз бир, суган. Аннары, ни, кая синең бүлмәдәшең?..

— Ул бүген кайтмастыр, кайтса да бик соң кайтыр. Чаллыга китте. Анда аның йөргән егете бар, шофер булып эшли. Тиздән өйләнешергә җыеналар.

— Ә-ә...— Барый тотлыгып калды. Кыз аның ни әйтергә теләвен тел төбеннән үк аңлап алды бугай, көлемсерәп аңа килеп сыенды.

— Без,— диде кыз,— безме, Барый,— егетнең күзләренә карады.— Укып бетерү белән. Ышанасыңмы син миңа?

— Мин кая йоклармын соң?

— Аның караватында. Юк, син минем караватта, ә мин аныкында,— дип төзәтте Кәримә һәм янә егеткә сыена төште.

— Юк, Кәримә, өн түгелдер бу, төштер сыман миңа. Синме бу?..

— Мин, мин, Барый.

— Ә син миннән курыкма, Кәримә.

— Җүләрем. Нинди кеше син. Нигә дип мин милиционер булырга укыйм, сиңдәйләрдән куркып торгач...

Барый көлеп куйды:

— Чынлап та, сезгә монда самбо алымнарын да өйрәтәләрме?

— Өйрәтәләр.

— Ә мин сине элеккечә сабыр, карусыз итеп күрәсем килә.

Барый аны кочаклап алды, сулышы капканчы үпте, бөтен тәне буйлап тетрәнү узды, башына кайнар кан йөгерде.

— Мин сине яратам, Кәримә. Мин сине бик тә, бик тә яратам.

Кәриманең кайнар сулышы аның иреннәрен өтеп алгандай итте, Барый аны сак кына кулына күтәрде, тар һәм кечкенә бүлмәдә зырылдатып әйләндерә башлады. Аннары ул кызның янә ике битен учына алды һәм күзләреннән, битләреннән үбәргә, сөяргә тотынды. Ул кызның чәчләреннән килгән ландыш исенә гүя исерде, гүя татлы иреннәрендәге балга тәмам иләсләнде. Шул вакыт кемдер ишек шакыды.

— Кәримә, бәрәңгең кайный, пешкәндер инде! — дип кычкырды.

Тынып калдылар, күккә ашканнар иде сыман, кемдер дәшеп, капылт икесен дә җиргә төшерде, күтәреп, бүлмәгә кертте — айныдылар.

— Ай,— диде кыз.— Барый, нишлибез без, җүләрләр!

Кыз чәчләрен тарый-төзәтә чыгып китте, ә бераздан ул кастрюльне күтәреп килеп тә керде.

Табыннан кузгалгач, Кәримә китапларын барлый башлады.

— Иртәгә минем соңгы имтиханым, Барыйҗан. Хәзер без икебез ике почмакка утырып, укып утырырга тиешбез. Тып-тын гына.

— Мин риза. Миңа бирәр китап бир дә. Ә күршең?..

— Кайтмый инде, кайтмый. Ул да имтиханга хәзерләнә. Имтиханымны бирсәм, мин дә синең белән Казанга кайтам.

— Чынлапмы, Каракаш?

Үз янына атылып килгән егетнең кулына Кәримә тастымал тоттырды.

— Чәшкәләрне сөртә тор.

Шунысы хикмәтле: Барый өчен биредә гаҗәеп бер күчеш булды. Алабугага килеп төшкәндә ул җир кешесе иде әле. Ә менә Кәримәне тапкач, җитмәсә аның белән бер бүлмәдә калып, бер өстәл янына утыргач, дөнья аның өчен күчеш ясады — ул үзен җирдә түгел, ә башка бер планетада итеп хис итә башлады. Хикмәтле тойгы иде бу, мондый тойгыны аның гомер-гомергә дә кичергәне булмаган иде әле.

Кәримә китабын, лекция дәфтәрләрен алды да караватына менеп утырды. Аннары нидер исенә төшеп, Барыйны үз караватына күчерде.

— Мин сиңа урын җәеп бирәм. Арыгансыңдыр. Ят, йокла. Мин имтиханга хәзерләнәм.

Барый кыз әйткән һәрнәрсәгә карусыз буйсынды, кисәк кенә ул үзен кечкенә бер бала итеп хис итә башлады. Ул — бала, ә Кәримә — гүя аның әнисе...

— Минем йокым килми.

— Китап укып ят. Я бетте, сөйләшмибез. Менә сиңа урын да әзер, чишен дә ят. Мин сиңа карамыйм.

Башта йокы килми кебек иде, китапны мавыгып укыды, әмма тора-бара Барыйның күзләре йомыла башлады. Йомшак караватъ, Кәримәнең чәч исе килеп торган мендәр, мамык юрган — барысы да йокыга китүгә сәбәп булды, күрәсең. Ул башын чайкап та карады, күзләрен дә угалады, йоклап китмәскә теләп, кырын күзе белән генә Кәримә ягына күз төшереп алгалады. Әмма йокы барыбер үзенекен итте. Кәримә дөньясын онытып, имтиханга хәзерләнә, гүя анын өчен бүлмәдә Барый юк иде. Ул аны гаепләмәде. Имтиханын бирә алмаса, ул Барый белән Казанга кайтып китә алмаячак. Дәшмәскә, игътибарын алмаска. Һәм йокламаска. Мин аны яратуым турында тагын бер тапкыр әйтергә тиешмен. Шунсыз йоклап булмас. Ишетәсезме, күзләр, йомылмагыз, ярамый...

Төшендә ул хикмәтле хәлләр күрде. Имеш, алар күккә ашканнар икән. Һәм ни могҗиза: оҗмахка керергә чират торалар. Кәримә дә шунда. Тик хатын-кызлардан бик азлары гына оҗмахка эләгәләр. Ишек янында торучы сакчы, инде үз яныннан үтеп барган кайбер хатын-кызны кинәт туктата һәм бөтенләй икенче якка — дөрләп янган учак ягына кертеп җибәрә. Гаҗәбе шул: анда таба китүчеләр ник бер сүз әйтсеннәр, барысы да карусыз буйсыналар. Шунда Барый түзмәде, кычкырып сакчы өстенә ташланды, ләкин барып җитә алмады, аны ниндидер яман көч бер якка алып атты, нәкъ менә гөнаһлыларны ташлый торган якка атты.

— Барый, Барый дим. Саташасың ич, уян...

Барый уянып китә, һични аңламаган хәлдә бер тын селкенми, күзен ачмый ята.

— Әй, Барый дим, кияү егете, уян!

Ниндидер ят хатын-кыз тавышыннан сискәнеп, Барый күзләрен ачты. Караватъ янында Кәримәнең бүлмәдәше басып тора иде.

— Хәтимә мин. Нигә алай карыйсың, юан кызлар күргәнең юкмы әллә?! Менә тамаша. Исең китмәсен, Кәримәң имтиханга китте. Миңа төштән соң. Тор, юын. Мин чыгып торам. Әй саташып та карады берәү... Бакырасың прәме, суярга алып баралар идеме әллә үзеңне?

— Гафу итегез. Бик яман төш күреп ята идем. Карале, мин соң шулай бер дә уянмыйча...

— Сәгать сигез инде, кияү егет... Мөгаен, төнне йоклап уздыргансыңдыр әле?

— Хак шулай. Уянып та карамадым ичмасам.

— Әйбәт кияү. Сөйгән кызы янында йоклап ята, уянып та карамый.

Хәтимә чыгып китте, ишек ябылуга, Барый сикереп торды, киенде, чаршау артыннан сөлге алды да коридорга чыкты.

— Булдың дамы. Солдат кебек үзең, күз ачып йомарга да өлгерми калдым.

Ул юынып кергәндә Хәтимә караватны җыештырган иде инде.

— Йомшак булдымы соң сөйгән кызың караваты?

— Шайтан күтәреп алып китсә дә уяна алмаган булыр идем, шул хәтле аруым җиткән булган икән.

— Күтәреп алып, күрше бүлмәгә чыгарып куярга исәп иткән идем дә, Кәримәдән яхшысынмадым. Кайттым, дөбер-шатыр йөрим, һаман йоклыйсың, мәрткә киткән диярсең. Кәримәне күптән беләсеңме соң үзең?

— Бергә үстек диярга була, балачактан ук...
— Яраттың, өйләнәсең, димәк?
— Кем белә, өйләнеп тә куюым бар, Кәримә риза булса, әлбәттә...
— Менә нәрсә, кияүкәй, мин хәзер имтиханга китәм. Кәримә ул отличница, имтихан бирер дә кайтып та керер. Булдыра алсаң, аш сал. Ит әнә форточкадан бауга таккан. Үзең чамала. Бәрәнге, суган әнә...
Сәер кеше икән бу Хәтимә дигәннәре. Барый авыз ачып сүз әйтергә өлгергәнче чыгып та китте. Ул бертын бүлмә уртасында басып, уйланып торды да эшне караватны җыештырудан башлады. Күр әле бу Кәримәнең мендәрен. Тышына, зәңгәрсу җирлеккә роза чәчәге төшерелгән. Төшерелгәнме, әллә кулдан чигелгәнме?.. Кулдан чигелгән. Гүя тере чәчәк. Үзе чикте микән?.. Чәчәк Барыйны тәмам сихерләде, ул караватны үзе белгәнчә җыештырды да, мендәрнең роза чәчәкле ягын өскә каратып, мендәрне күпертеп, кабартып куйды. Аннары аш хәстәрләргә керešте. Ярый әле итне бер салырлык итеп турап куйганнар иде. Кастрюльгә ит салып, янә кухняга чыгып китте. Коридорда тәмәке тартып басып торган ике егет аңа сәерсенеп карап калдылар. Итне куйгач, ул янә бүлмәгә керде, бәрәңгеләрне бер савытка салып, янә кухняга чыкты.
Коридорда инде аңа беркем дә очрамады, тулай торакта тып-тын иде.
Бүлмәгә килеп керүгә, ул иң әүвәл кырынып алырга булды. Портфеленнән кырыну машинкасын алды, шул вакыт кемдер арттан килеп аның күзләрен каплады.
— Кәримә!
— Каян белдең?
— Сине дә белмәгәч...
Кәримә милиция формасыннан иде, Барыйда тик бер мизгелгә генә үзе дә аңлап бетермәгән ятсыну кебегрәк хис туды, әмма кыз елмаеп җибәрүгә, барысы да юкка чыкты.
— Ә мин имтиханны биреп тә кайттым,— диде Кәримә һәм чаршау артына кереп китте.— Бу якка карама. Аш пешереп йөрисеңме?
— Каян белдең?
— Хәтимә әйтте. Синең ул Барыең повар булып эшлиме әллә,— ди.
— Повар булып булмады шул, Кәримәкәй. Үзеңә иң-иң тәмле ашлар гына ашатып торыр идем. Тукта, мин кырынып бетерим инде. Аннары ашны чыгып карарга булыр.
— Хәзер, мин үзем. Кәк-никәк мин хатын-кыз. Һәм минем аш пешерерлек кенә сәләтем бар, Барыйкаем.
Кәримә чаршау артыннан чыкты, итәгенә нәкъ мендәр тышындагы сыман роза чәчәге чигелгән зәңгәрсу күлмәк кигән һәм тагын да сылуланып киткән иде ул.
— Ә сиңа форма да килешә,— диде Барый кызның күңелен төшермәскә тырышып.— Бу күлмәгеңнән бигрәк тә матурсың.
— Нәрсә инде бу, мактавыңмы, Барый?
— Имтиханыңны ничек бирдең?
Кәримә нәни балалар кебек бармагын тырпайтты.
— Молодец син. Миңа ул бишле дигән билге бик сирәк кунакка килә.
— Ә син аның янына үзең бар, чакырма. Менә минем янга килгән кебек, көтмәгәндә.
— Син мине гел көтмәгән идеңме, Кәримә?
— Чып-чынын әйтимме?
— Әйт.
— Мин сине гел онытып бетергән идем инде, җүләрем. Мин,— кыз егеткә күз сирпеп алды.— Мин, Барый, Казандагы бер егет белән хат алышам. Ю-к, мин аны... рәтләп белмим, мин аны кызганам. Ә инде

хатын-кыз кызгандымы, Барый, ул кешене өзелеп сө н егетеннән дә якынрак күрәчәк. Кызгану хисе безнең табигатькә үк салынган, күрәсең.

— Мин аны кем дип сорамыйм. Бары тик бер нәрсәне генә беләм: минем бу дөньяда синнән дә якын кешем булганы булмады, булмас та...

— Беләсең килсә, Барыйҗан, сагындым мин Казанны. Әнине дә, Зөлфия апаны да...

Барый дәртләнеп, Казандагы хәлләр турында сөйли башлады.

— Мин шуңа аптырыйм, Барый, неужели Зөлфия апа шул Котбыйны ярата икән?

— Ә нигә?..

— Күзләре әллә нинди аның.

— Әйе, син хәзер криминалист, белгеч, күзгә карап кына кешенең кем икәнен билгелисең...

— Мин болай гына, бәлкем, аңарда Зөлфия апа мин күрмәгәнне күреп алгандыр.

— Алгандыр...

— Син дә бит әнә килдең дә, бер тәүлек үтмәде, Кәримәне бөтенләй үз итеп бетердең...

— Кәримә,— дип янә кыз янына кузгалды Барый.— Кәримә...

— Я-я, утыра бир, начармы-яхшымы, мин — бу өйнең хуҗасы, шулаймы?! Шулай булгач, утыра бир утырган урыныңда. Менә тиздән аш өлгерер, аннары билетлар барып алырбыз.

— Караватың миңа ошады. Мендәреңнән хуш исләр килеп тора. Роза чәчәген үзең чиктеңме?

— Үзем булмый.

— Матур. Ә син молодец. Кулыңнан килмәгән эш юк.

— Минем хыял бар, Барый: университетка керү. Заочно булырмы, мин аны барыбер тәмамлаячакмын. Минем әти дә анда укыган, Василә Хаковна да. Алар бергә укыганнар. Башта әти өйләнгән, аннары ул кияүгә чыккан. Ләкин озак тора алмаган, аерылышканнар. Ничәмә еллар бер учреждениедә эшләп, әтигә ул мәхәббәте турында беркайчан да белдермәгән. Ул миңа бу турыда үзе сөйләде, Барый. Күрсәң иде син аны сөйләгәндә. Үзе сөйли, үзенең күзләрендә мөлдерәп яшь тулган. Шулай ярата алсаң икән ул,— дип офтанып куйды Кәримә.

Бераз тынычлана төшкәч, Барыйда тәүге күтәренкелек үтте, акыл хисе эшкә керешге. Ул кызга сынабрак карады һәм үз-үзенә шаккатты: белми икән бит әле ул аны, бөтенләй белми. Хәзер инде Барыйга Кәримә кичәге кебек чәчәктән-чәчәккә кунып очынган унҗиде-унсигез яшьлек кыз булып түгел, ә дөньяның ачысын-төчесен татыган тәҗрибәле хатын-кыз булып күренде.

Барый килеп төшкән вакыттан башлап, Кәримәгә бик тә сәер бер тойгы килде: әйтерсең аны үзе иң-иң яраткан бер затлы әйбер белән бүләкләгәннәр иде, һәм ул шул бүләкне алырга ояла, имеш, аның моңа хакы юк икән. Бу сәер хис, бу серле тойгы аны тәмам әсир итте. Төнлә белән ул рәхәтләнеп йоклап яткан Барыйга ачуы килеп чыкты. Нигә йоклап ята. Бер караганда Барыйның аны борчымавы әйбәт иде, ул имтиханга хәзерләнә. Шулай дисә диде, әмма йоклап ятуын барыбер килештереп бетермәде. Укый-укый башы катып киткән араларда ул, китаптан аерылып, Барыйга карап торды. Менә ничәмә-ничә сәгать инде аны сәер бер тойгы биләп тора. Ул әле, үз-үзен сынамакчы булып, иртәгә үк Барыйны, куып кайтарып җибәрергә дигән фикергә килгән иде. Ә икенче бер мизгелдә аның янына барып уятасы, сөеләсе, назланасы килде. Ләкин тегесен дә, монысын да эшләмәде. Кичә үбешкәннән соң аның иреннәре ут булып янып тора. Кәримә хәтта чаршау артына кереп, иреннәрен салкын су белән сүрелдергән иде. Әмма үбеш-

кәннән соң янып, гүя утта өтелеп калган иреннәр алай гына сүрелмәде, киресенчә, иреннәрдәге ялкын битләренә, колакларына хәтле күчте. Ахырда дулкынлануы шул чиккә җитте ки, ул күзләренә яшь тулуын сизми дә калды. Ярый әле хәйләсен тапты: суган әрчергә кереште. Чаршау артына кереп, көзге кисәгендә йөзен күргәч, Кәримә аһ итте. Бит алмалары, колаклары ут кебек яна, күзләрендә яшь. Нидән булыр бу?! Шулай ук ярата микәнни ул аны?..

Ярый әле ул мизгелләр узды, Кәримә әкрен генә үз хәленә кайтуын тойды. Барыйга ул бүген, бер төн бер бүлмәдә йоклагач, бөтенләй икенче күзлектән карады.

— Барый, биш минутка гына коридорга чыгып торчы.

— Баш өсте, син дигәндә, мин идәндә,— дигән булды Барый һәм, чыга-чыгышлый, Кәримәнең битеннән үбеп алды.

«Нигә соң, әллә ниләр уйлыйм, мин аны яратам бит. Ул — кичәге Барый». Шулай дип Кәримә үз-үзен юатса да, хәзер генә туган шиге күңеленә гүя шырпы булып кадалды, гел борчып, бимазалап тора башлады. Моның нидән кисәк кенә шулай булуын да белмәде ул, ләкин уйлана торгач, кинәт куркып китте. Бүген аңа Бәхтиярдан хат бирделәр. Хатны укырга вакыт тимәде, тизрәк Барый янына кайтасы килде, ә менә кайтып керүгә, Барыйны күрүгә, әллә нишләде шунда дөньясы. Аның Барые кичәге Барый түгел кебек тоелды. Имеш, бөтенләй башка берәү. Әллә соң шулай тоела гынамы?.. Ни язган икән бу Бәхтияр?

Хатны алды, тиз-тиз укып чыкты. Бераздан, онытылып, яңадан укырга кереште. Ул Барыйның ишектән кергәнен дә, янына килеп басканын да күрмәде, ишетмәде, ул бөтенләе белән хат тәэсирендә иде. Бәхтиярны тиздән Мәскәүгә олы хирургларның берсенә алып барасылар икән. «Бәхтияр, бичаракай... Мин кайтам, Бәхтияр, кайтам. Һәм мин сине Мәскәүгә киткәнче күрергә тырышырмын».

— Хат алган берәүләр,— диде Барый һәм аның кулы хатка таба үрелгәндәй итте, әллә шулай күренде генәме?

— Кеше хатын укырга ярамый, Барый.— Кәримәгә кинәт оят булып китте. Барый аның янәшәсендә түгел, өстәл янында ук утыра, ә Кәримәгә ул кулындагы хатны алырга үрелгән сыман тоелган иде.

— Нәрсә?! — диде Барый.— Әллә имтиханнан соң үзалдыңа сөйләшә башлады инде бу...

— Хак әйтәсең. Төнозын йокламадым, шуңадыр...

Бераздан:

— Арыдым, Барый,— дип Кәримә егет янәшәсенә килеп утырды, аның иңенә башын салды. Рәхәт иде шулай тын гына утырулары. Иреннәр сөйләшә, ә күңелләр әллә-әллә кайларда.

— Билетка соңга калабыз, Барый,— диде кыз.— Киен дә коридорга чыгып тор. Мин хәзер.

Һай бу коридорны. Чыкты, чыкмый кая барсын. Караса, коридор буйлап бер егет килә. Спорт костюмыннан, Кәримә кебек үк каратут йөзле, кавказ халкыдай үткен, утлы карашлы.

— Сәлам, кияү егет!

— Сәлам.

— Беләсеңме мин кем?

Барый: «Белмим, беләсем дә килми!» — дип әйтүдән чак кына тыелып калды.

— Белмисең,— диде егет киная белән.— Мин Хәйдәр булам, дускай. Ишетәсеңме, Хәйдәр,— ул Барыйга якынрак килде.— Әгәр дә мәгәр син Алабугада тагын бер күренәсең икән, кара аны, егет...

— Шундый усаллар яши мени биредә? Мин бит Алабуганы цивилизацияле шәһәр дип уйлаган идем. Ә монда, күрәм...

— Тел үзеңдә, брат.

— Тел синдә дә аллага шөкер.
— Шулай да белеп тор.
— Шул кеше дә милиционер булырга җыенсын инде. Мин бу хәлне мәктәп дирекциясенә җиткерсәм, ә?!
Дирекция сүзе егеткә шундук җитте, ул килешсез генә елмаеп:
— Анда барып җитәрлек хәлең калса,— дигән булды.
Ул арада Кәримә бүлмә ишеген ачты, ике егетнең әтәчләнеп басып торуларын күреп:
— Барый, кер, китәбез,— диде.
— Бигайбә,— дигән булды Хәйдәр.
— Бигайбә, бажай, бигайбә. Гаепләмә инде... Мине, күрәсең, чәй эчәргә дәшәләр. Алай да кайгырма, без әле очрашырбыз.
— Боерган итсә, абизәтельны. Тик вәгъдәңне оныта күрмә!
— Юк инде, онытып буламы.
— Хәйдәр,— диде егеткә Кәримә.— Бу ни дигән сүз инде тагын!
— Юк, Кәримә, болай гына, менә кияү егете белән туйга чакырышу турында сөйләштек. Ул үз туена, мин үз туема чакырырга вәгъдәләштек...
Хәйдәр шулай диде дә сызгырына-сызгырына китеп барды.
— Игътибар итмәсәнә шуңа,— диде Кәримә, Хәйдәр китеп баргач.
— Ә ул шактый тупас кеше. Я, ярый, барысы да әзерме. Инде киттекме?..
Аэропортта Кәримә: «Мин хәзер киләм»,— дип, кай тарафкадыр китеп барды. Барый зал уртасындагы баганага сөялде дә юлчыларны күзәтә башлады. Кемнәр генә юк иде бу вокзалда. Таякка таянган әбекәйләр дә, сынын төз тотарга тырышса да гомер капчыгы иңендә яткан урта яшьләрдәге ир-ат та, бала-чага да, чәчрәп торган яшь-җилбәзәк — барысы да каядыр баралар, кабаланалар, билет хәстәрен күрәләр, ә инде билетлары кулларында булганнары тыныч кына самолет көтәләр иде.
«Тукта, иртәгә Яңа ел түгелме соң! — Кинәт айнып китте Барый.— Нигә дип монда гына Яңа елны каршыламыйбыз?..» Ул арада кассалар ягыннан Кәримә килеп чыкты, кулында билет. Аның кулында бер билет күрүгә, Барыйның эче жу итеп китте.
— Менә,— диде Кәримә аның янына килеп туктауга,— бер билет.
Барый, Кәримәгә караган килеш, ачкан авызын яба алмый торды.
— Бу?..
— Мин китә алмыйм, Барый. Яңа елдан соң кайтырмын. Бүген мине директор чакырып алды. Мәктәпнең комсомол секретаре бит мин.— Барый, барысын да аңлыйм дигән сыман, баш кагып куйды.— Директор кал дип торганда ничек китим инде мин. Аңла мине, кер хәлемә, Барыйҗан!..
Кәримә ничек кенә ышандырырга тырышмасын, Барыйга кисәк кенә кыен, бик кыен булып китте. Күз алдына Хәйдәр килде: «Боерган итсә, абәзәтельны очрашырбыз, тик вәгъдәңне оныта күрмә»,— дигән сүзләре янә колакны ярып үтте.
— Ул китмәскә куштымы? — диде Барый, Кәримәнең күзләренә туры карарга куркып. Куркуы шуннан иде: уйлаган уе чын булыр, Кәримә әйе дияр кебек иде.
— Кем ул?
— Хәйдәр.
— Җүләрем,— дип, Кәримә егеткә сыенып алды. Аның күзләре ихласлык белән мөлдерәп тулган иде, Барый, теләсә-теләмәсә дә, елмаеп җибәрде.
— Нигә аны кайтмыйм дип башта ук әйтмәдең?.. Ә бәлкем, мин дә калган булыр идем. Хәзер инде билет кулда.
— Сиңа китми ярамый, Барый. Безгә сине барыбер кертмәсләр

иде. Аннары,— диде кыз, әйтимме икән, әйтмимме дигән сыман, бер тын уйланып алды.— Аннары миңа да уңайсыз булыр.

— Ярый соң,— диде Барый үпкәләвен сиздермәскә тырышып һәм күзләрен читкә алып.— Кайчан көтим сине? Кайтырсыңмы?..

— Кайтмый буламы, Барыйҗан. Өчесендә мин өйдә. Сагынмады дисеңмени Казанымны. Әнине, Зөлфия апаны, Юлия Борисовнаны, ишегалды малайларын.— Кәримә тирә-ягына каранып алды.— Әйдә әле, самолет килгәләгәнче һавага чыгып торыйк.

— Карале, Кәримә, нигә бүген китмәскә булдың? Яшермә генә әйт әле. Чынлап та директор чакырдымы, яисә анысы бер-бер хәйлә генәме?..

— Барый,— дип гаҗәпләнә калды Кәримә.— Бу ни дигән сүз инде тагын?

— Үзем синең белән басып торам, ә үзем инде сине сагына да башладым, Кәримә. Ышансаң ышан, ышанмасаң — юк. Үзем китәм, йөрәгем монда кала, Кәримә.

— Житте ул турыда, кадере китүе бар. Әйдә, регистрация башлангандыр, керик. Өчесендә өйдә булырмын, хәбәр итәрмен...

Регистрация башланган иде инде, монда да Кәримә үзе керепкитте һәм, күп тә үтмәде, әйләнеп тә килде.

— Менә. Әйдә, я утырта башларлар.

— Кәримә, чынлап та өчесендә көтимме сине?

— Истән чыгып киткән, без бер атнага практика үтәргә Чаллыга барабыз. Безнең группа...

Барый дәшмәде, аңа кисәк кенә күңелсез булып китте. Әле генә өчесендә кайтам дигән иде, хәзер практикага китә...

Диктор Барый кайтасы самолетка утырта башлаулары турында хәбәр итте. Кәримә аңа карады.

— Я, Барый, исән-сау кайтып жит.

Халык капкага таба кузгала башлады. Кәримә аңа кулын бирде, әмма Барый аны үзенәрәк тартып китерде һәм үбеп алды.

— Хуш, Кәримә. Кайту белән хат язармын,— колагына иелә төште.— Онытма Барыйны, ишетәсеңме, оныта күрмә.

— Син үзең онытма Кәримане.

— Минме!..

— Я, бар инде, әнә китеп беттеләр.

— Гражданин, сез очасызмы? — дип сорады капка янында кертеп торучы кыз.— Очсагыз, керегез,— диде ул, Кәримәгә күз ташлап.

«Бәлкем аның йөргән егете юктыр, шуңа усал итеп карыйдыр»,— дип уйлады Барый әлеге кызга карап.

Самолетка таба атлаганда ул тимер койма янында кул болгыйболгый озатып калган Кәримәгә берничә тапкыр әйләнеп карады. Аннары, бер җай китереп, үзләрен озата барган аэропорт кызына:

— Сезнең бәхетле булуыгызны телим. Яңа ел белән! — диде.

— Рәхмәт,— диде кыз һәм, зәңгәр күзләрен елтыратып, елмаеп куйды, дустанә итеп елмайды.— Сезне дә котлыйм!

Самолет күтәрелеп киткәч, Барый күзен йомып уйга калды. Ул менә бүген генә, хәзер генә яшәү мәгънәсенең асылына төшенде. Аны яратучы бар һәм бүген, мөгаен, аңардан да бәхетле кеше юктыр. Шушы көннән аңарга якын кешесе турында кайгырту хисе килде.

## 13

Юлия Борисовна астагы катның мәйданында йөри көтеп торды. Зөлфия өске каттагы тәрәзә төбендә егете белән утыра иде. Беравык

тынып торалар да күгәрченнәр кебек гөрләшә башлыйлар. Кыз шунда егетнең чираттагы мәзәгеннән тыенкы гына көлеп куя. Пенсионер карчык үз яшьлеген күз алдына китерә. Аңа бирелә суык түгел, иңендә мамык шәл, ә яшьләрнең гөрләшүен тыңлау үзе бер гомер икән. Күңелгә истәлекле хатирәләр тула. Ул шулай сәгатьләр буена да басып торыр иде. Ләкин халык төшә-менә йөри, күрсәләр, яшьләрне тыңлап тора, дип үртәүләре бар. Пенсионер карчык Зөлфиянең гел бер егет белән генә йөрүен хуп күрә иде. Ләкин... егетнең исеме бик сәер — Котбый. Татар исемнәре болай да аның хәтерендә озак сакланмый торган иде, ә бу Котбый дигәне каядыр төшә дә югала, төшә дә югала.

Ниһаять, Юлия Борисовна өске катка күтәрелде.

— Зөлфия,— диде карчык үтешли,— әниең эшкә китте. Чәй эчәргә миңа керерсең, егетеңне дә калдырма...

— Ярый, Юлия Борисовна.

Ишекне ачканда пенсионер карчык кире уйлап куйды: «Егетен чакырмаган булсам да яраган булыр иде, мөгаен...»

Хикмәт шунда, Котбыйны аның күргәне бар иде инде. Дөресен әйтергә кирәк, ошатып бетермәде ул егетне, әмма беренче тәэсирнең ялгыш булып куюы бар. Чүлмәкнең тышыннан белеп була, диләр дә, кеше чүлмәк түгел бит. Шул ук вакытта ул: «Керсен әле, сынап карыйк»,— дип уйлады.

Яшьләр кергәч, Юлия Борисовна аларга өсләрен салырга, кулларын юарга, түр якка узарга кушты. Керә-керүгә, ачык итеп егетнең исәнләшүе аңа ошады, ләкин пенсионер карчыкны аның болай чәчрәп чыгуы гына канәгатьләндерми иде әле. «Әйдә, әйдә, түрдән уз»,— диде Юлия Борисовна, гомумән, кешеләргә бик озаклап ияләшә иде.

Кулларын юарга кереп киткән яшьләр ваннада пышык-пышык көлештеләр, тынып калгаладылар.

Карчык сырлап-бизәкләп ясалган борынгы өстәл янында утыра, ваннада яшьләр... кул юалар... Юлия Борисовнаның хәтеренә беренче мәхәббәте килде. Әле булса хәтерендә: бер тапкыр аларны әниләре базга бәрәңге алырга төшереп җибәрде. Иреннәре авырткачы, башларын боргалый-боргалый үбешкәннәр иде шунда. Бәрәңге турында да оныттылар. Бер мәлне баз авызыннан әниләре аваз салды: «Юлия, нигә озак, суым кайнап бетте инде».

Баксалар, бәрәңге алырга алып төшкән чиләкләре буп-буш. Тизтиз генә бәрәңге тутырдылар да бер-берсенең күзләренә карарга да ояла-тартына баздан чыктылар. Әниләре егет кулыннан чиләкне тартып алды да китеп барды. Шунда күргән иде Юлия: Володяның бит очларына гүя ут капты.

Володя ул вакытта аларда квартирда тора иде, Котбый кебек үк заводта эшләргә укыды. Бер сүз белән — эшче. Ә Юлия — Казан кызы, училищега керергә йөри иде. Тиң идеме эшче егет җырчы буласы кызга, юкмы? Юк, дип уйлады ул вакытта Юлия. Ә хәзер, еллар үтеп, гомер кичкәч, алай дип әйтәсе килми. Теге вакытта, син эшче үк димәсә дә, шуңа сылтап егетне читкә кагуына әле булса үкенү тоя Юлия Борисовна. Кем белә, Володяга кияүгә чыккан булса, бәлкем бала тапкан булыр иде. Хәзер әнә берүзе калды. Ярый әле күршесе Гөлбикә бар, үз кызыдай күргән Зөлфия бар. Юлия Борисовна Кәримәне дә бик сагынып искә ала, хәтта соңгы вакытта аны Зөлфиядән дә якынрак күрә башлады. Ул кызда Юлия Борисовна тәвәккәллек, үз-үзенә ышанганлык сыйфатлары күрә, ә бу сыйфатлар аның үзенә җитмәде бугай. Кеше дигәнең яшәү дәверендә якын иткән кешеләрендә үзенә җитмәгән сыйфатларны эзли ләбаса.

Юлия Борисовна уйларыннан арынып, өстәлгә күз төшерде. Табынны ул борынгы рус гаиләләренә хас муллык белән хәзерләде.

— Рәхим итегез, Котбетдин, син менә моннан утыр.

Котбый аңа, исемен тутырып, картларча әйткәнгәме, керфекләрен каккалап, карап алды.

— Бер дә шаккатма, Котбетдин, Юлия апаңның хәтере саерак булса да, татар исемнәрен әйтә белә. Хәтта Котбетдин үк булмаса да, Шиһабетдин атлы егет белән дуслашып та йөргән идек яшьлектә.

Котбыйның өстендә күн пиджак, запорожье казаклары сыман ике якка сәлендереп мыек җибәргән. «Мыек җибәрү — житдилек галәмәте, бәлки начар егет түгелдер»,— дип уйлады Юлия Борисовна чәй ясый-ясый.

— Үткән гомер үтә менә, Зөлфиякәй, әле кайчан гына укырга кергән идең, инде менә диплом яклар вакытларың да житеп килә.

— Мин дә быел бетерәм,— диде егет.

— Бик әйбәт. Шуннан нишләргә исәп инде?

— Производствода эшләргә. Аннары өйләнергә исәп...

— Өйләнергә! — Юлия Борисовна чәшкәсенә төртелеп диярлек чәй эчүче Зөлфиягә күз төшереп алды.

«Ә минем бер дә кияүгә чыгарга исәбем юк әле»,— дип уйланып утырды Зөлфия. Бу уен аның Юлия Борисовна да сизгәндәй үзалдына елмайды. «Житдилек житми шул әле сезгә, балалар»,— дип уйлап куйды. Ләкин күңел дигәнең шушы яшьләр арасында булган мәхәббәт җебенең күңелләргә сузыла башлавын күрүгә дә куанучан икән.

— Артисткага тормыш алып баруы жиңел түгел инде ул,— диде Юлия Борисовна.

— Нигә, җырчылар арасында ике-өч бала үстерүче аналар да бар бит әле,— дип каршы төште Котбый.

— Генийларның да менә дигән семьялары булган,— диде Зөлфия, егетен якларга тырышып булса кирәк.

— Анысы хак, генийларның семьялары булгалаштырган...

— Генийлар арасында, Юлия Борисовна, атказанган артисткалар була, ашказанганнары да бар, ягъни казан һәм аш тирәсеннән уза алмаганнары. Вә ләкин, миңа калса, алар да генийлар. Иренә аш пешереп, аны эштән көтеп алу, итәк тутырып балалар үстерү — ул хәзерге көндә бик сирәк күренеш була башлады,— дип сөйләп куйды Котбый.

— Ә бәхет? — диде кинәт Зөлфия.— Бәхет бала үстерүдә геенәме? Баланы күп аналар үстерә ала, ә менә барча хатын-кыз да артистка була алмый.

— Бәхет ул — шатлык, Зөлфия. Шатлыкны баладан башка нәрсә бирә алыр микән анага!

— Ә сәхнә! Минем зал тулы тамашачы алдына чыгып басудан да зур бәхет тойганым юк әле, Котбый.

Егет дәшмәде, үпкәләвен сиздереп, башын түбән иде.

Котбый өчен сәер көннәр башланды. Юлия Борисовналарда Зөлфиянең «минем өчен зал тулы тамашачы алдында чыгыш ясаудан да зур бәхет юк» дияюе, аның егетлек тәкәбберлегенә нык кына кагылган иде. Шул турыда уйланды. Уйлана торгач, Зөлфияне үзләренә китерергә дигән нәтиҗәгә килде. Килсен, күрсен, өйрәнә, гадәтләнә торсын. Тик менә әнисенә ничек шул турыда әйтергә? Аңлармы аны әнисе?.. Син, малай актыгы, эшли башламадың, өйгә кыз-кыркын җыя башладың дисә?!

Хак анысы, аның эшли башлавына да әле ике-өч ай гына. Ләкин Котбыйны эшендә хөрмәт итәләр, шул ике-өч ай эчендә ул кая җибәрсәләр шунда барды, кушкан эшне эшләде. Иң мөһиме — тиешле чаклы хезмәт хакын әнисенә кайтарып бирде. Улының бу адымын әнисе бик ошатты, аркасыннан сөя-сөя: «Кирәккәндә сорап алырсың»,— дигән булды. Хак анысы, егет кеше булгач, акчаның да кирәге чыга

икән. Зөлфә конфетлар ярата. Ул суга кер дисә — суга керәчәк Котбый, утка дисә — утка ташланачак. Тик ул гына әллә ни шунда. Әле аңа тартыла, әле чит-ят кеше шикелле кылана. Бер сүз белән әйткәндә — артистка. Тукта, бит Котбый да артист була ала. Әйтик, әнисен әбиләренә авылга озатырга да Зөлфияне үзләренә чакырырга. Шунда аңлашырлар. Музыка, берәр шешә вино...

Кинәт кенә башына килгән бу план Котбыйга шул хәтле ошады ки, әнисе эштән кайтуга, ул планны тормышка ашырырга да керешге.

— Инәй,— диде ул, әнисенең каршына утырып.— Синең күптән әбекәй янына кайтканың юк. Кайтып килер идең бер. Минем беренче хезмәт хакымны бүләк итәр идең. Куандыр әле шул әбекәйне бер...

Гаҗәп тә соң ана кешеләр, нишләргә белмәде әнисе, куанычыннан сүз табалмый аптырап калды.

— Балакем,— диде ана, ниһаять,— ай балакаем, мин бит сине... атаң юлынннан китәрсең дип котларым алынып йөридер ием. Киләсе ялга ук барып кайтырмын,— дип тәмамлады сүзен.

— Барып кына кайтмассың. Ял алдыннан китеп, янында берәр кич кунып та кайтырсың,— диде Котбый.

— Әйе шул, улым, күптән кайтканым юк.

Ул көнне Котбый көтеп ала алмый интекте. Үзләренә кунакка алып барырга теләге булуы турында ул Зөлфиягә һәр көн әйтә килде. Ә инде иртәгә әнисе китә дигән көнне тәгаен өзеп: «Зөлфә, иртәгә безгә кунакка барабыз»,— диде. Кыз аңа шикләнебрәк карады. Имеш, яхшы булырмы, әниең ни уйлар? Ул бу сорауны кызның күзләреннән үк аңлады. «Әни минем бик әйбәт кеше, синә ошар ул»,— дип котылды. Бу изге ялган иде. Әнисе китәчәк, ә Зөлфәгә бу үзенә күрә бер сюрприз булыр, дип уйлады егет.

Ниһаять, көткән көн дә килеп җитте. Эштән кайтуына, әнисе аны күчтәнәчләр тутырган ике сумка белән көтеп тора иде.

— Син мине, улым, автовокзалга чаклы гына озатып куй инде.

Озатмый буламы. Котбый аннан-моннан гына капкалады да ике кулына ике сумка тотып, автобус тукталышына юнәлде.

— Кая бу хәтле йөгерәсең? — диде әнисе улыннан артта кала башлагач.

— Я автобус китеп барыр.

— Автобус сәгать өчтә генә була, өлгерәбез әле. Карале, улым, ишекләреңне бикләргә онытма. Этне җибәреп йокла. Кеше-фәлән китермә. Ипи-сөт алып куйдым. Теләсәң, аш пешереп ашарсың. Кискән токмач мич каршындагы шкафта, бәрәңгене беләсең. Ит холодильникта.

— Ярый, инәй, минем өчен кайгырма, җаен табармын.

— Уйнаткычыңны бик кычкыртма, күршеләрдән яхшы түгел...

— Ярый, инәй. Син анда әбекәйгә миннән сәлам әйтергә онытма. Диплом алды, заводта эшли, яхшы гына акча төшерә, менә беренче хезмәт хакын сиңа җибәрде, диген...

Әнисен автобуска утыртып җибәргәч, Котбый такси алды. Консерватория янына ул сәгать дүртләргә генә килеп җитте. Әбиләр чуагымы, көн җәй көннәрендәге кебек эссе. Котбый, күн тужуркасын салып, җилкәсе аша ташлады. Аның исәбе буенча, Зөлфия ярты сәгатьләрдән консерватория ишегеннән килеп чыгарга тиеш иде. Аның Зөлфияне беренче каршы алуы түгел, шуның өчен соңга калырмын дип бер дә курыкмады.

Консерваториянең ишеге рәтләп ябылмый да — керәләр, чыгалар, ә Зөлфия һаман юк та юк. Ул сөялеп торган юкә агачының яфраклары саргая башлаган, кытыршы кәүсәсе җилкә башын авырттыра. Эссе, сентябрь ае димәссең. Котбый, киҗү майкасын тартып, тәнен җилләтеп алды. Дулкынлануданмы, тик торганда тирләтә. Тыгыз джинсы чал-

бардан тән бөтенләй сулыш алмыйдыр сыман. Сәгать дүрт булды, бишенче китте. Урра, әнә ул Зөлфә, әнә чыгып килә!

— Һәлло, Зөлфә, мин монда.

Зөлфия бер кыз белән тротуарга баскан гына иде, үзенә дәшүче Котбыйны күреп алды.

— Һәлло, Котбый. Мин хәзер,— диде ул, янәшәсендәге кызга нидер әйтте, Котбый ягына ым кагып күрсәтте.

«Минем турыда гайбәт сата,— дип уйлады Котбый.— Я мактый, я күләгә кебек артымнан йөри, дип мактана».

Урам аша каршыдагы өйнең күләгәсе сузылып яткан, шул күләгә эченнән Зөлфия аңа таба килә. Менә аның ярты гәүдәсе кояш нурларына эләкте һәм Зөлфия киң читле зәңгәр эшләпәсен маңгаенарак тартып куйды. Чибәр иде Зөлфия. Кызның вак-вак атлап, үзенә таба килүе, сылу гәүдәсе, зифа сыны, мөлаем итеп елмаюы Котбыйны тәмам әсир итте. Гел шулай: ул аңа нидер әйтергә тели, Зөлфия аңа шундый иттереп карый, Котбый югала да кала, әйтер сүзен әйтә алмыйча аны тыңлый, кыз ни әйтә, кая барабыз ди, шуңа буйсына. Бүген Зөлфия елмайса да, шул елмаюы белән Котбыйны сихерләсә дә, егет үзенеке итәргә ниятләде. Кыз килеп җитәр-җитмәс үк ул:

— Син инде оныткансыңдыр да, бүген миңа кунакка барабыз. Юк-юк, теге көнне вәгъдә иттең — бетте. Туры безгә китәбез,— диде.

— Ә минем өйгә кереп чыгасым булса?

— Нигә? Әниең эштә...

— Сумканы күтәреп йөримме?

— Үзем күтәрермен.

— Рәхим ит, алайса.

Зөлфия, килеп җитәр-җитмәс, сумкасын аңа таба селтәп җибәрде. Котбый җай гына аны тотып алды.

— Киттекме?

— Карале, Котбый, Чыңгыз поселогы бик ерак бит ул!

— Үзем китереп куярмын.

— Үзең,— дип ирәеп карады Зөлфия.— Сиңа ышанып буламы соң?

— Зөлфия,— ул аңа Зөлфия дип бик сирәк әйтә иде, исемен тутырып әйткәч, Котбый үзалдына елмаеп куйды.— Зөлфә, мин шундый ышанмастай кешемени соң?..

— Я, бетте-бетте. Киттек. Беренче автобускамы?

Зөлфия белән сөйләшүе аңа кайчак бик кыен була. Котбый сәнгатьне аңлавы белән аңардан калыша, шуның өчен куп очракта рухи яктан фәкыйрь халәтендә кала. Нәкъ менә шул хәл аны вакыт-вакыт куркуга сала. Зөлфия аның белән җитди рәвештә йөрми, вакыт кына уздыра сыман тоела башлый, Зөлфия аны гүя җепкә бәйләп тота, ә теләсә ул аны җибәрер һәм бер аңа ияләшеп киткән Котбый кай тарафка да юл таба алмый иләсләнеп йөрер, хәтта акылдан шашар шикелле. Бу курку аңа күптән түгел килде. Бер көнне алар Зөлфияләргә килеп керделәр. Котбыйның аларга беренче тапкыр керүе иде. Кулга кул тотынышып кермәсәләр дә, иңгә-иң килеп ишек төбендә басып торгач, Зөлфиянең әнисе бу егетнең кем булуы турында шундук аңлады булса кирәк. Котбыйны ошатмадымы ана, ирен чите белән генә елмаеп куйды.

— Инәки, мин сиңа сөйләгән Котбый шул инде,— диде Зөлфия.

— Исәнмесез,— диде Котбый.

— Әйдүк, егет,— диде Гөлбикә.— Түрдән узыгыз...

Ләкин Зөлфиянең әнисе бу сүзләрен шундый иттереп әйтте ки, Котбый өшеп китте. Гөлбикәнең аскы ирене бүселеп чыкты, салкын бер караш ташлады да сүзсез генә үз бүлмәсенә кереп китте. Котбый Зөлфияләргә бүтән бармады. Хәер, әнисенең ничек каршы алуын күреп калган Зөлфия нигәдер дә аны өйләренә чакырырга атлыгып тормады.

Бу хәл өчен Котбый Зөлфиягә үпкәләмәде. Аның ни гаебе булсын ди! Киресенчә, шушы көннән соң Зөлфиядә ул самимилек, ихласлык сыйфатлары туа башлавын күрде. Ә бер тапкыр хәтта: «Котбый, инәкигә ачуланма син. Безнең инәки бөтен дөньяга үпкәле кеше. Кемне генә күрмәсен, аның бәхетен урларлар кебек кылана ул», диде. Әмма эш моның белән генә бетмәде. Көннәрдән бер көнне, звонок биреп, Зөлфияне чакыргач, ишек артында торучы ана, Котбый ишетсен дип, юри кычкырып: «Тиң түгел бит ул сиңа, балакай, күзләрендә өмет юк»,— диде. Шул көнне өйгә кайткач, Котбый озак итеп көзгегә карап торган иде. Нишләп аның күзендә өмет булмасын ди. Гомумән, нәрсә ул өмет?!

— Нәрсә син уйга калдың? — диде кыз автобуска утыргач.— Күр әле, көз дә җитте... Композиторларның күбесе көзге манзараларга карап музыка язганнар. Беләсеңме, Пушкин да нигәдер көзне яраткан, Есенин да, Такташ та...

Котбый аны тыңлады да, тыңламады да. Зөлфия аңа гаҗәпләнеп карады, сул кашы югары сикерде, чибәр йөзендә кызыксыну чалымнары биеште. Кыз шулай туры караганда, Котбый әллә ниткән уңайсызлану тоя, бу уңайсызлану аның җанын айкый, ачуын чыгара. Бу халәттән ул бик озак арына алмый йөди.

Автобустан төшкәч, алар җәяү киттеләр. Котбый кызны култыклап алды һәм үткән-сүткәннәр белән исәнләшә барды. Ул горур, шат, бәхетле иде бүген. Аны, карсак буйлы, юантыграк гәүдәле, кечкенә күзле, киң яңаклы Котбыйны, сылуларның сылуы култыклап бара.

— Су эчәсе килә,— диде Зөлфия автобустан төшкәч.

— Әнә мороженый саталар.

— Миңа ярамый.

— Хәзер кибеткә керәбез, сок эчәрбез.

Кибеттә сок булмады, аның каравы Котбый бер шешә «Рислинг» виносы алды.

— Бу нигә? — дип сорады Зөлфия.

Котбый җилкәсен генә җыерып куйды.

— Сусаганда сухой винодан да әйбәт су юк.

— Апа,— дип мөрәҗәгать итте сатучыга Зөлфия.— Сок юкмыни сездә?

— Нигә булмасын, бар. Әнә банкасы белән утыра. Өч литр.

— Әйдә киттек,— диде моңа каршы Зөлфия Котбыйга.— Ерак торасызмы?

— Монау үрне менгәч тә сулдан өченче йорт.

— Әниең ни әйтер?

— Инәй өйдә юк, авылга китте... Беләсеңме, мин Алла Пугачеваның өч дискасын таптым. Уйнатырбыз...

— Нигә әниеңнең өйдә юклыгы турында шәһәрдә үк әйтмәдең?..

— Килмәссең дип курыктым.

— Беләсең килсә, мин көтелмәгән хәлләрне яратам. Әниең юк икән, бигрәк әйбәт...

Капкалары бикле иде, Котбый кулын тыгып җай гына кече капканы ачып җибәрде һәм Зөлфиягә алдан юл бирде.

— Рәхим ит, Зөлфә!

Кыз ишегалдына атлады, төрле төскә буялган болдырга карап торды. Аннары:

— Матур! — диде.

— Үзем буядым,— дип мактанды Котбый, гәрчә болдырны әнисе буяган булса да.

— Ә син молодец,— диде кыз, чын-чынлап гаҗәпләнә калып.—Карале, нинди зур эт. Бәйдәме?.. Мин этләрдән куркам.

— Курыкма, бәйдә.
— Исеме ничек?
— Актырнак.

Өйгә керделәр, Зөлфия инбашына элгән сумкасын диванга ташлады, челтәрле «чабаталарын» салды да түр бүлмәне тутырып җәйгән келәмгә аяк бөкләп утырды. Котбый өтәләнеп аңа салкын су китерде.

— Виноңны кемгә эчерәсең? — диде аңа кыз, суны эчкач.
— Сиңа.
— Рәхмәт, мин су эчтем инде.

Зөлфиянең бераз гына кинаяләп, ирәебрәк сөйләшүеннән Котбыйга тәмам канатлар үскән кебек булды, ул кабаланып уйнаткычны кабызды, Алла Пугачеваның пластинкасын куйды.

— Бетховенның пластинкалары бармы синдә?
— Юк, классиканы кабул итмим.
— Арыганда яратам мин аны тыңларга. Бетховен музыкасында шул хәтле хис, сагыш... Син беләсеңме сагышның ни икәнен?.. Әйтик, синең иң кадерле кешеңне үтерделәр, ди. Я булмаса сине сөйгәнең ташлап китте ди, үлеп-үлеп сөйгәнең...
— Вино эчәбезме?
— Тагын нинди пластинкаларың бар? Куй әле берәм-берәм...

Котбый пластинканы алыштырды да келәмгә газета җәйде, бокаллар китереп куйды, «Рислинг» виносын ачты.

— Ә мин эчмәсәм? — диде аның һәм хәрәкәтен дикъкать белән күзәтеп торган Зөлфия.— Эчмәсәм нишләрсең?..
— Егылып үлмәм үлүен, шулай да, әйдә, эчик инде, Зөлфә?..
— Куй әле шул виноңны, миңа болай да әйбәт.

Котбый бер кап «Кош сөте» конфеты китерде, капны ачып, Зөлфиягә сузды.

— Куй. Үзем дә җитешәм. Син еш эчәсең ахры?
— Нигә алай дисең?
— Теге вакытта... Әйт әле, Котбый, сез аны нигә кыйнадыгыз?
— Кемне?
— Белмәмешкә салынма инде. Мин ул егет белән Казанка буенда гулять итеп йөридер идем. Сез килеп аңа бәйләндегез, мин качып киттем. Беләсең килсә, мин аның исемен дә белми калдым. Ә сез, тиләр, килдегез дә тиктомалга бер гаепсез кешегә бәйләндегез. Беләсең килсә, миңа ул егет ошаган иде.

Зөлфия беркайчан да, беркемнән дә курыкмады. Котбый аңа бергә үскән күрше малае кебек кенә иде. Күрер күзгә әрсез, тәвәккәл булса да, Зөлфия алдында ул югалып кала, миңгерәүләнеп калгандай йөри иде. Ни өчен бик күп егетләр арасыннан нәкъ менә шушы Котбыйны сайлап алды Зөлфия? Ул аны үзе дә тәгаен генә белми. Зөлфия ярату дигән сүзнең төп мәгънәсенә төшенергә теләп, кулындагы вино тулы бокалга карап утты. Мәхәббәт сүзен кыстырасы килмәде аның. Ул аның ни икәнен белми иде. Минем беренче мәхәббәтем, мин аны яратам, әгәр дә мәгәр ул мине яратмаса, суга ташланачакмын, минем өчен яшәүнең мәгънәсе калмаячак, дип лаф орган, кем өчендер янган-көйгән кызларны аңламады ул. Котбыйны яратмый ул, ләкин егетнең үз артыннан бер тотам калмыйча йөрүе аңа ошый. Гомумән, аңа кемдер кирәк, кемдер аңа ияреп, аңа буйсынып йөрергә тиеш. Ә Котбый әнә шундый егет.

«Бүген кунарга кайтмасам, әни борчылыр инде борчылуын. Борчылмагае,— дип уйлады Зөлфия, гәрәбә төсендәге винога карап.— Инәкидә Хәлил кайгысы. Тегене эчүдән туктатырга исәбе, врачлардан врачларга йөртә, әмма ул ташбаш һаман үзенекен итә».

Бик тиз эңгер инде, караңгы өйдә бөркү иде, Зөлфия Котбыйга фор-

точканы ачарга кушты, егет утны кабызырга теләгән иде, каршы төште.

— Ут кирәкми. Мин караңгыда утырырга яратам.

Зөлфия винаны һаман эчмәгән иде әле. Ни сәбәпледер винога Котбый да кагылмады. Алар идәнгә сузылып яткан килеш музыка тыңладылар, рәхәт иде идәнгә сузылып ятып музыка тыңлавы. Зөлфия күзләрен йомды. Шул мәлдә ул үз янәшәсендә Котбыйның сулышын тойды.

— Мин сине... Әйдә, эчик инде, Зөлфә.

— Ә-ә, әйдә соң,— Зөлфия торып утырды, кулына бокалын алды. Винаны ул иренәнә генә тигерде. Эчкелтем вино тәмле түгел, әллә ниткән чүпрә исләре килә иде. Котбый винаны эчеп бетерде.

— Беләсеңме нәрсә,— диде ул буш бокалын куеп, сузылып яткач.— Мин сине бик күптән үзебезгә китерергә хыялланып йөри идем.

— Гитараң бармы синең, Котбый.

Котбый торып утырды, Зөлфиянең иңенә кулын салды. Ялкау гына, иренчәк рәвештә генә салды кебек, әмма Зөлфиянең бөтен тәненнән ток үткән кебек булды, чирканып китте.

— Гитара бар ла ул...

— Ал әле кулыңны, Котбый. Яратмыйм мин озын куллы кешеләрне. Китер гитараңны.

— Бер иске гармун кисәге бар. Тальянка.

— Шулаймыни! Китер әле. Чыгарып булмасмы икән шуңарда берәр көй?..

— Минем әни уйный аңарда. Бабайдан калган гармун, хан заманындагы. Бабай минем гармунчы булган...

— Син уйный беләсеңме соң?

— Тальян да булдымы гармун...

— Хәсрәт син, Котбый. Татар халкында, музыка коралы буларак, тальян гармун революциягә кадәр беренче урында торган. Син миңа бер дә ошамый башладың әле, Котбый. Җырчы кыз артыннан йөрисең, ә үзең гармунда да уйный белмисең. Ә менә әниең белә, бабаң да белгән. Кая, бир әле гармуныңны...

Зөлфия гармун каешын иңенә ташлады, нечкә бармакларын телләр буйлап йөгертеп алды. Их, уйнап та карагандыр Котбыйның бабасы көмеш телле шушы гармунда. Ә хәзер тыңла инде, Котбыйҗан... Һәм, Зөлфия «Сарман» көен уйнап җибәрде.

— Әтиең уйный идеме? — дип сорады Зөлфия, бармаклары белән икенче көйне гармун телләреннән эзләгәндә.

— Әтиме? Юктыр. Мин аны хәтерләмим.

— Ә-ә,— диде Зөлфия. Өйдә караңгы булса да, күз өйрәнгәч, барысы да ачык күренә иде. Зөлфия бераз гына башын кырын салган да көй табарга маташа, нечкә нәфис бармаклары ак телләр буйлап йөгерешә.

«Нишләп хәтерләмим,— дип уйлады Котбый, кисәк кенә әтисе исенә төшүгә.— Хәтерлим мин аны, Зөлфия, хәтерлим. Ул вакытта миңа ничә яшь булды икән? Биш-алты, ә бәлкем, сигездер? Юк, сигез түгел... Аның турында әнисе Котбыйга сөйләргә яратмады, һәрчак нервыланды, юк белән башымны катырма әле дип, тизрәк чыгып китү җаен карады. Үсеп балигъ булгач, Котбый әнисеннән атасы турында сорап йөдәтмәде. Себердә эшли, ди ич, эшли бирсен, кайтыр әле бер».

— Котбый, Котбый дим, йокыга киттеңме әллә? Әйдә озат мине, кайтам,— диде Зөлфия, аны уйларыннан бүлдереп.

— Җибәрмим мин сине, Зөлфә. Кун бирерә...

— Тиле,— диде Зөлфия, гармунны келәмгә куеп, торып басты. Котбый да күтәрелде.— Мин кайтам.

— Иртә бит әле, Зөлфә,— диде Котбый һәм сак кына кызга кагылып алды, биленә кулын салды, кочаклады, үбәргә үрелде. Зөлфә башын читкә борды.

— Мин уйныйм, син йоклап ятасың... Обидно...

— Мин синең жырыңа соклана беләм, Зөлфә. Син жырлаганда, мин күккә ашам, бер мәлгә рәхәт-рәхәт булып китә. Әллә соң жан чынлап та бармы икән ул, Зөлфә?.. Жырла әле үзең яраткан борынгы жырларыңны.

Дөресен әйтергә кирәк, Котбыйның моңа кадәр беркайчан да шулай бирелеп милли жырлар тыңлаганы юк иде әле. Кисәк кенә аның бөтен тәне буйлап, чымыр-чымыр дулкыннар йөгерешә башлады. Түзмәде, Зөлфия жырлап туктауга, кыз каршына тезләнде.

— Син минем күңел сандугачым, син...

Котбый аның иреннәреннән үпте, ләкин шундук сизеп алды, жавапсыз, кайтавазсыз үбә иде. Зөлфия бер дә исе китмәгән рәвештә басып тора, үзен үбәргә рөхсәт итә, әмма иреннәрендәге бер генә кузәнәк тә селкенми иде. Бераздан ул читкә тайпылды.

— Узынма, Котбый!..

Түр якка урам баганасындагы лампочкадан тоныкк кына яктылык төшә. Яктылык идәнне урталай ярып үтә. Зөлфия шул яктылыкка эләккән. Ул да түгел, Котбый йөгереп чыгып китә һәм бакчадан ике роза чәчәге кисеп кертә. Һәм горур төстә чәчкәләрне Зөлфиягә суза.

— Их, Котбый, Котбый, кызларга беркайчан да ике чәчәк бүләк итмиләр. Кабер өстенә генә ике чәчәк салалар. Кызларга я бер чәчәк, я өчне бирәләр...

Котбый ачкан авызын яба алмыйча Зөлфия каршында басып тора, аннары янә борылып чыгып йөгерә, күп тә үтми ул өч роза чәчәге тотып керә.

— Жүләр син,— ди аңа Зөлфия.— Чәчәкләрне үзең үстерәсенме?

— Юк, инәй үстерә.

— Синнән булмас иде шул. Чәчәкне аны якты күңелле кешеләр генә үстерә...

Шулай дисә дә, Зөлфия чәчәкләрне рәхәтләнеп иснн, бүлмәгә роза чәчәкләре исе тула.

— Киләсе елда, сиңа багышлап, менә дигән розалар үстерәчәкмен, Зөлфә.

— Я, бир берәр ваза, суга утыртыйк... Бар чәй куй әле...

Ут алгач, Зөлфия пәрдәләрне тартып куйды. Бераздан кара-каршы утырып чәй эчтеләр.

— Менә чәрсә, Котбый. Син хәзер, дускаем, мине илтеп куясың.

— Юк, Зөлфә, син бүген бездә кунасың. Куркасың икән, мунчага барып йоклыйм.

— Мунчага! — дип гажәпләнде Зөлфия һәм рәхәтләнеп көлеп жибәрде.— Үтердең бит, Котбый... Күр әле, син кызык кына кеше икәнсең бит... Болай булгач, калмый да булмас...

Зөлфия «Кош сөте» конфетын капты да, авызын очлайтып суырасуыра, Котбыйга карап тора башлады.

— Мин хәзер табынны жыям, Зөлфә. Син бар, музыка тыңлый тор. Аннары бер тилереп алырбыз...

— Ни ул?..

— Ну, поп музыка куеп...

— Аңлашылды. Жый табыныңны.

Зөлфиянең бүген ирәйгәннән ирәясе килә иде. Котбыйның ул ни әйтсә шуны эшләргә торуы, үтә гади кылануы аңа кызык иде. «Тормыш — сәхнә уены» дигән иде аңа кемдер. Кем әйтүен Зөлфия хәтерли алмады, бәлкем, кайда да булса укыгандыр. Котбый начар кеше түгел. Түгелдер, дигән фикергә килде ул.

Ул арада табынны жыештырып, түр якка Котбый керде. Керү белән утны сүндерде.

— Шулай яхшырак, нигә музыка куймыйсың?

— Куй әле шунда берәрсен,— диде Зөлфия.

Котбый пластинка куйды һәм тәрәзә янында басып торучы Зөлфия янына килде. Сак кына, курка-тартына гына кызның иңенә кулларын салды: «Мин бәхетле бүген, Зөлфә, бик тә, бик тә бәхетле. Рәхмәт сиңа килгәнең өчен»,— дип ул кыз алдына тезләнде, итәк чабуына битен терәп, тын калды. Зөлфия аның чәчләренә бармакларын батырды. «Җүләр, тор!» — диде. Котбый торып басты, кызны күкрәгенә кысты. Кызның тән җылысы аның йөрәген тетрәндереп җибәрде. Шушы мизгел өчен генә дә Котбый гомерен бирер иде. Тәрәзәдән төшкән ут яктысында ул кызның чибәр йөзен күрә, кыска, юан бармаклы кулы белән Зөлфиянең битеннән сыйпый. «Син нигәдер калтыранасың?» — ди ул һәм шунда гына үзенең дә калтырануын тоя, гүя салкын иде аңа.

— Зөлфә,— дип ярым пышылдый ул.— Ишетәсеңме, Зөлфә, мин сине яратам. Я-ра-там...

Егетнең пышылдап әйтүе Зөлфияне гүя сихерли, чарасыз итә, ихтыярсызландыра һәм ул үзе үк Котбыйның кочагына сыена бара. «Нәрсә бу, нишлим мин, тиле»,— дип уйлый Зөлфия, әмма үз-үзе белән берни кыла алмый.

— Зөлфә, ишетәсеңме?..

— Китеп тор әле. Зато мин сине яратмыйм. Ишетәсеңме, Котбый, мәнә шулай кыланууыңны яратмыйм. Оят түгелме сиңа?!

Зөлфия аның кочагыннан шуып чыга да барып пластинканы алыштыра. Котбый аның артыннан килеп янә кочаклый.

— Карале, Зөлфә, син миңа...

Кыз кинәт аңа таба әйләнә, Котбыйның авызын каплый.

— Әйтмә алай. Әйтмә, Котбый. Кирәкми.

— Нигә, Зөлфә?

— Әйдә музыка тыңлыйбыз... Җибәр дим... Бисемек килми минем, Котбый... Утыр әле идәнгә, утыр, менә шулай. Тик кенә утыр, яме...

Котбый бүген җырдан тәмам сихерләнде, әйтерсең моңа кадәр аның колагын томалап торганнар да менә хәзер генә ачып җибәргәннәр иде. Пластинка бетте, ә җыр һаман яңгырый. Күрче, Зөлфия шулай нәкъ Пугачева булып җырлый икән бит! Хикмәт, Зөлфия кинәт татарча җырлый башлады, Котбыйның күңел кыллары тибрәлеп китте. Ул тәмам юкка чыкты, чык тамчысы кебек кояшта парга әйләнде, өйдә бары Зөлфия һәм аның моңлы җыры калды.

Җыр тәмамлангач та Котбый бер тын сүз әйтергә кыймый торды.

— Зөлфә, син сандугач икәнсең бит, син...

Кинәт ул яшәү мәгънәсен шушы бер җырда күрде. Хәзер ул Зөлфиянең кем икәнен белә, ул аны беркайчан да рәнҗетмәс, ул аны ярата, кыз риза була икән, Котбый аңа иртәгә үк өйләнәчәк. Зөлфия тагын җырлый һәм Котбый тәүге уйларының бары тик матур хыял булуына, җырлаган саен Зөлфиянең үзеннән ерагая баруына инана бара.

Җыр бетүгә, кыз Котбый янына келәмгә килеп утырды. Күпме вакыт шулай үткәндер, йокылы-уяулы Зөлфия һау-һаулап эт өргәнгә сискәнеп китә.

— Котбый! — дип кычкырып җибәрә Зөлфия.— Котбый, нишләп мин монда кунып ятам?! Озат мине өйгә, хәзер үк озат!..

Котбый аңа елыша, бер сүз дәшми.

— Кит әле, Котбый. Кит дим янымнан!

— Мин сиңа өйләнәм,— ди аңа Котбый.— Әйдә иртәгә ук гариза бирәбез?..

— Мин сиңа кияүгә чыкмыйм. Кит дим янымнан!..

Котбый кызны кысып кочаклаган да җибәрми. Ниһаять, ул егет кочагыннан ычкына һәм диванда яткан сумкасын эләктерә, туфлиләрен кулына ала да йөгереп ишегалдына чыга. Ләкин ни сәбәпледер, урам як капкага түгел, ә бакчага таба йөгерә. Мунча янынннан уза, инеш буендагы таллыкларга җиткәч, кинәт туктый, кая, ни өчен, кемнән качып

йөгерүенә аптыраган бер рәвештә тирә-юненә карый. «Уф,— ди ул, тирән сулап.— Нишләде ул? Нигә кунып калды биредә? Нигә аңа бу Котбый?..»

Зөлфия инеш буендагы сукмактан түбән таба төшеп китте. Шул якта олы юл, шул якта машиналар гүләве ишетелә. Таң атып килә икән бит инде. Ә ул, җүләр, Котбыйда йоклап ята. Ни өчен, нигә кирәк ул аңа? Яратмый бит ул аны, яратмый!..

Олы юл янына житәрәк ул инешкә төшкән басма күрде. Басмага керде, аякларын салындырып утырды. Су салкын иде, алай да аякларын юды, туфлиләрен киде. Аякларын салкын суда югач, аңа ничектер жиңелрәк булып китте. Биредә инеш тын гына ага, су өстеннән сыек томан күтәрелә. Томан әле тал араларына кереп китә, әле инеш өстенә сузылып ята. Зөлфиягә томан эченнән кемдер, каядыр аны чакыра сыман тоела башлый. Зөлфия үзенең бил тиңентен судан баруын күрә, аръякта кемдер аңа дәшә кебек. Тукта, чынлап та кемдер дәшә түгелме соң аңа?.. Әйе шул, Котбый. Димәк, ул аның инеш буена таба китүен күрми калган, хәзер дөнья бетереп эзли. Зөлфиягә кинәт җүләр бер уй килә: суга ташланырга. Котбый килсен дә аның батып ятуын күрсен. Әмма алай итми, чөнки ул шундук үзен мәет рәвешендә күрә. Имеш, аны судан күтәреп алып чыгып киләләр, чәчләреннән шарлап су ага, куллары салынып төшкән. Моны күргәч, халык аһ итә! Күр бу сабыйны, япь-яшь бит әле, дип кызганучылар табыла. Кызык, су анасы дигән әкәмәт чынлап та бармы икән бу дөньяда?.. Элек яшь кызлар таң атканда су буена кер чайкарга төшмәгәннәр, су анасы алып китәр дип курыкканнар.

Зөлфия тиз-тиз чишенде, сак кына басмадан төште. Су башта гына салкын тоелган икән бит. Күрче, нинди җылы, май кебек. Менә су аның күкрәкләренә житте, тәнен рәхәт кытыклый-кытыклый муенына якынлашты. Су эчендә торуы рәхәт иде. Шул чакта ниндидер кош чутылдап алды. Ә Котбый һаман кычкыра. Менә җүләр, нишләп сиңа Зөлфия җавап бирсен, ди. Житәр, дускаем, йөрдек, узынмыйк. Юлия Борисовна дөрес әйтә, ул миңа тиң түгел. Инәки дә кабул итмәде үзен. Күрдең ич теге вакытта ничек каршы алды: күзе-кашы җимерелгән, әйтерсең кызын урларга килгән берәү...

Зөлфия судан чыкты, басмага менеп басты. Шунда бөтен тәне калтырап китте. Тиз-тиз генә киенде дә йөгерә-йөгерә олы юлга юнәлде. Менә ул олы юл. Хәзер уң якка чыгасы да беренче машинага кул күтәрәсе. Кем дә булса утыртыр әле, дөньяда рәхимле кешеләр бетмәгәндер.

## 14

Зөлфиянең олы юлга чыгуы булды, беренче жиңел машина ук, ул кул күтәрүгә, аның янына килеп туктады. Машинада сакаллы ике ир-ат утыра, рульдәгесе үрелеп, Зөлфия ягындагы ишекне ачты.

— Әйдә, алга утырыгыз!

Зөлфия утырып ишекне япканда, шоферга карамыйча гына рәхмәт әйтте. Сары төстәге «Москвич»ның эче дә сары иде. Машина кузгалып, тизләгеч арттыра башлагач, Зөлфия тынычлана төште. Ул кырын күзе белән генә рульдәге кешегә карап алды. Күрсәткеч көзгесеннән арт урындыктагы ир-атка да күз ташлап алды. Ирләрнең икесе дә сарыкызгылт сакаллы, икесе дә яланбашлар, хәтта бертөрлерәк киенгәннәр дә иде.

— Шәһәргә кайтасызмы? — дип сорады рульдәгесе.

— Әйе.

— Кай тирәдә торасыз?

— Вишневский урамында...

— Юл өстендә икән,— диде машина йөртүче һәм уң кулын рульдән ычкындырып, сакалын сыпырып куйды.
— Курыкмыйсыз тагын үзегез?
— Иптәш кызыма барган идем.
— Хәлләр... — диде артта утыручы ир-ат.
Бик иртә булгангамы, юлда машиналар очрамый диярлек. Арттагы кеше текәлеп, Зөлфиянең иңнәренә карап бара. Күзләре Зөлфиянең иңнәренә төбәлгән дә каткан. Зөлфия кофтасының өске сәдәфләрен элэктерде, өшеп киткәндәй, җилкәсен җыера төште. Артта утыручы, аның калтыранып китүен сиздеме, күзләрен йомды, йокымсырагандай утыра башлады.
— Сакалбай, миңа калса, ул монда кайтмас,— диде ул бераздан.
— Хак анысы, тиз генә кайтмас. Ләкин аның монда малае, хатыны бар. Туган ягы. Ә аның кебекләр туган яктан аерыла алмый.
— Теге вакытта ук атарга тиешләр иде аны.
— Ләкин атмаганнар. Унбиш ел, от звонка до звонка утырырга тиеш бит...
— Теге картны әйтәм, исемен ишеткәч, күзләре акайды.
— Малаен теге дөньяга озатсын да... Күзең акаер... Болай таза күренә әле карт... Килеп чыгуы бар, күз-колак булыгыз дигәч, кулны кысты — кыскыч белән эләктерде дип торам...
— Шеф безгә бер атнадан артык югалырга кушмады.
— Юк, торабыз әле, Сакалбай. Күңелем сизә, кайтачак ул ашаган җиренә, кайтачак... Ну, бу юлы инде аңа каюк...
— Это точно. Ә син кызын күрдеңме? Ай сылу, зур кара күзле, йомры балтырлар, сын тагын үзендә. Чибәр, чукынган.
— Куй,— диде артта утыручы.— Кызык та соң бу өйләнмәгән халык, билләһи... Юкны күрә дә йөри.
Арткы урындыкта утыручы кеше үзе сөйләшә, үзе һаман күзләрен ачмый иде. Зөлфия аларның сөйләшүен тыңлады да, тыңламады да. Ул арада машина шәһәргә килеп керде. Арча кырын узуга, Зөлфия сумкасын ачты, бер сум акча чыгарды.
— Менә шунда туктатыгыз әле, рәхим итеп. Әйе, әнә шул биек өй каршында...
Зөлфия бер сум акчаны шоферга сузды. Шофер аның кулын этеп җибәрде.
— Мороженый яратасыңмы?.. Яратмасаң, конфет алып ашарсың. Хуш! Ә акчаңны сумкаңа сал...
— Хуш, чибәркәй,— диде артта утыручы.— Әйе, бер киңәш, болай иртә йөрмә, дөнья хәлен белеп булмый. Нигә дип, төрмәдән бер кеше качкан...
— Рәхмәт сезгә...
Зөлфия машинадан төште дә юл аша йөгерде. Сакаллы агайлар көлемсерәп, аның артыннан карап калдылар.
Өй ишеген ул үз ачкычы белән ачты. Шым гына, аяк очларына баса-баса үз бүлмәсенә узды. Ни сәбәпледер, аның бөтен тәне калтырый, няк асты дерелди иде. Бүлмәсенә кергәч, ул бер тын салкынча стенага аркасын терәп, ашкынып типкән йөрәген тыңлап торды. Битләре ут яна, ә бөтен тәне калтырана иде аның. Әллә соң салкын тидеме үзенә? Тиле дә соң, нигә дип суга керде соң әле ул?.. Суга кереп баруы күз алдына килүгә, аркасы чымыр-чымыр итеп китте. Их, Котбый, Котбый! Ярый, Котбый белән бетте. Онытачак ул аны. Әйе, әйе, онытачак!
Шунда тыштан ул ниндидер тавыш ишетте, әйтерсең лә, кемнедер сөйрәп баралар иде. Эче жу итеп китте. Күрче, аны бит теге ике кеше?.. Я, җүләр дә соң үзе...
Тиз генә чишенде дә караватына ятты, башыннан ук юрганын бөркәнде. Ябынды, әмма колак түрендә һаман да әле астан, тротуардан килгән тавыш иде. Түзмәде, торды, юрганга төренгән килеш, тәрәзәдән

тышка карады. Зөлфия шым булды, йөрәк тибеше бөтен тәненә тарала башлады. Тротуардан аякларын сөйрәп, ярым өстерәп, ярым сөйрәп, исерек кеше сыман, стенага тотына-тотына күрше инвалид егет килә иде. Аны күрде дә, Зөлфиянең йөрәге убылып китте, колак төбендә нидер чынлап тора башлады.

Кинәт егет күтәрелеп карады, Зөлфиянең аркасына гүя салкын су койдылар, ул чытырдатып күзләрен йомды һәм шундук Казанка буендагы хәл күз алдына килде. «Инәки!» — дип сыкранып куя Зөлфия.— Инәки!».. Аның тавышы шундый әчке сыкрау белән чыга, ул һичничек ала алмый идәнгә сыгылып төшә.

— Ни булды сиңа, бала. Кайда болай төне буе йөрдең?..

Зөлфия күзләрен ачты. Әнисенең күз төпләре кызарган, чәчләре тузган, халат сәдәфләре эләктерелмәгән. Зөлфия әнисенең карашыннан ук тойды: әйдә аны көткәннәр, төне буена рәтләп йокламаганнар. Әнисенең әрнүле карашы, кызарынган күз кабаклары, тузган чәчләре Зөлфияне әллә нишләтте, кисәк тез буыннары йомшап китте. Күз алдыннан Котбыйның кайнар сулышы, әрсез куллары, сихерле итеп пышылдавы узды.

— Инәки!..

Зөлфия әнисенең күкрәгенә капланды да үксеп-сыкталып елап җибәрде.

Йокы бүлмәсеннән өстенә буй-буй сары-күк сызык төшкән пижама кигән Хәлил килеп керде. Үги атаның чәчләре тузган, күз төпләренә капчыклар салынып төшкән иде.

— Ни бар, ни булды тагын?

— Ни дә булмады, бар әле, чык та ят,— диде Гөлбикә һәм тәртеп диярлек ирен чыгарып җибәрде.

— Аңлашыла! — дип кычкырды күрше бүлмәдән Хәлил.— Аңлашыла... Чык аннан, үтәр. Кемнән үтмәгән ул!

— Тыясыңмы син анда теленне, юкмы, Хәлил. Әллә чыгып...

— Инәки, мин чирлим. Миңа салкын...

— Әйдә әле, ят әле, кызым. Менә шулай. Төренебрәк ят. Я, хәзер әйт. Ни булды? Кем булса рәнҗеттеме әллә үзеңне?

— Инәки, мин бүген бер кешене күрдем. Тан096дым мин аны...

— Кемне?..

— Ярый, инәки, арыдым. Бар, чык инде, йоклыйм мин... Әйтәм бит, арыдым...

— Я, чык диләр сиңа! — дип кычкырды күрше бүлмәдән Хәлил.— Чык дигәч, чык! Бала арыган, йокысы килә. Төне буена биегәннәрдер.

— Акыл өйрәтеп утырма әле анда, бүрәнә аша бүре куып. Менә хәзер чыгармын да... Кысылма хатын-кыз эшенә!..

— Инәки, бар чык, минем чынлап та йокым килә. Куркудан ул, үтәр. Әйтәм бит, йөгердем...

Әнисе шикләнүле йөз белән торды да, бөкрәя төшеп, ишеккә таба юнәлде. Халатының бер җиңе сыдырылып беләгенә төшкән, шуңамы, Зөлфия аны канаты сынган кошка охшатты. Кызның күңелендә әнисенә карата әрнүле кызгану хисе уянды.

— Инәки, китмә!..

Зөлфия моны шул кадәр өзгәләнеп, сагыш-кызгану тонында әйтте ки, әнисе ишек янында туктап калды, аннары кисәк борылды да караватн янына килде, тезләнде, юрган аша кызын кочаклады. Ана күзләрендә яшь күреп, Зөлфиянең йөрәге кысылып куйды.

— Син, инәки, җылама, яме... Мин җыламыйм бит...

/ — И-и, бала, үткән гомерләрне кайтарып булса икән ул, атаң белән яшәгән бәхетле вакытларны...

Кайчан йокыга китүен ул хәтерләми. Күзләрен ачып җибәрсә, бүлмә тулы кояш. Зөлфия стеналарга, рәсемнәргә күз йөгертеп алды. Үз

булмәсендә йоклый, өендә. Зөлфиянең эченә җылы йөгерде. Аның белән берни дә булмаган һәм ул исән-сау. Өйдә шылт иткән тавыш юк. Зөлфия кулларын, аякларын сузып җибәрде, оеп киткән буыннарын кузгатып алды. Аннары урынын җыйды да радионы эләктерде. Ниндидер музыка бирәләр иде, ничек булдыра ала, шулай бөгелә-сыгыла зарядка ясап алды. Бөтенләй чишенеп ташлады, сак кына ваннага керде. Җылымса су рәхәт итеп тәнне оета. Зәңгәрсу төстәге су эчендә аның ап-ак тәне мәрмәрне хәтерләтә, ниндидер мизгелдә бу гәүдә аныкы түгел, ә музейларда күргән бөек скульпторлар ясаган гүзәл сын кебек тоела иде.

*

* *

Кәриманең хыялы тормышка ашты. Алабуга милиция мәктәбен тәмамлагач, аны үз үтенече буенча Казанга эшкә җибәрделәр. Бу мәсьәләдә аңа Васил̆ә Хакова ярдәм итте. Озын колаклар ишеттерделәр, имеш, Кәримә Азатованы Казанга җибәрү мәсьәләсендә өлкән укытучы Васил̆ә Хакова үзе директор янына кереп сөйләшкән. Кулына юнәлеш кәгазе эләгүгә, Кәримә беренче булып Бәхтиярга телеграмма сукты, аннары Барыйга. Барый аны каршы алырга тиеш иде, Бәхтиярга ул үзе керер. Китәр алдыннан Кәримә өлкән укытучы Хакова янына сугылып чыгарга булды. Хакова кабинетында берүзе утыра иде, Кәримәне күрүгә торды да аңа каршы китте.

— Я, уз әйдә, утыр. Беләсеңме, башта мин бит сине Чаллыга направление сорарсың дип уйлаган идем. Мин сине әтиең кебек үк тикшерүче булырсың дип ышанам, ә моның өчен, әлбәттә, университет белеме кирәк.

Ул һәрчак формадан булыр, үз итеп елмаер, үткәндә дә, сүткәндә дә Кәриманең аркасыннан сөеп китәр иде. Бүген исә Васил̆ә Хакова аның янәшәсенә утырды. Өстендә чия төсендәге алсу йон күлмәк — Васил̆ә Хакова илле яшендә дә чибәр иде әле. Кәримәне ул үз кызы кебек якын күрә. Еш кына өенә чәйгә дәшә. Озаклап, үзенең үткән гомерен сөйли. Кәримә аңа шул вакытта үзенең университетка укырга керергә хыялы барлыгын сөйләгән иде. Ул мәлдә Хакова аңа бер сүз дә әйтмәде. Әйтмәде, әмма Кәримәне Казанга җибәрү мәсьәләсен хәл иткән. Кәримә аңа Бәхтияр турында да сөйләгәне бар. Аны кыйнаган егетләрне тотып бирергә вәгъдә итүе турында да әйткән иде. Хакова, башта аның бу вәгъдәсен көлемсерәп тыңласа да, соңыннан гаять җитди итеп:

«Вәгъдә биргәнсең икән, үтәргә кирәк. Тикшереп кара. Бәлкем, университет өчен ул синең диплом эшең булып куюы бар»,— диде.

Чыгып киткәндә Васил̆ә Хакова аны кочаклады һәм бер тын гүя кызның йөрәк тибешен тыңлап торды — җибәрмәде. Кәримә аның күзләрендә яшь күргән иде шул вакытта.

Университетка Кәримә кайткан елны ук керде. Милициядә эшләү һәм уку аңа җиңел түгел иде, җиңел булмаячагын да белде ул. Ә бер көнне бабаларына күчеп китәргә булды — әнисенең икенче ире Хәлилне яратмады, аның исерек гәүдәсен күрсә, җен ачулары чыкты. Шуннан әнисенә янә әйтеп тормыйча Гата бабаларына күчеп китте. Әнисе артыннан килмәде, аның каравы озын итеп хат язды, кайнагасына, ягъни Гата картка, аннары Кәримә кызына. Ни генә булмасын, Кәримә бабаларында калды, Чыңгыз поселогыннан Вахитов районына эшкә йөрде, кич белән университетка чапты. Кайчак ул йөгереп Юлия Борисовна янына, өйләренә кереп чыккалады. Әнисе аны: «Утыр, бала, чәй эч,— дип якты йөз белән каршы ала иде. Кәримә, тәүге үпкәләүләрен онытып, әнисен гафу итте, әмма барыбер кире әйләнеп кайтмады. Ул бабасы белән әбисе янында яшәргә өйрәнгән иде инде.

Милиция мәктәбендә укыганда бер хакыйкатьне аңлаган иде ул: эчке халәтеңне башкалар сизмәскә тиеш. Ләкин башкалар сизмәсәләр дә, синдәге үзгәрешне әниең сизми буламы! Бәхтияр янына кергәли башлагач, әнисе аңа бер тапкыр болай диде: «Инвалид янына керәсең, әниеңнең хәлен белергә вакытың юк». Шуны истә тотып, буш вакыты булганда Кәримә еш кына әнисе янына кергәли башлады. Бүген ул көпә-көндез килде. Әнисе өйдә юк, Зөлфия апасы бүлмәсендә йоклап ята иде, күрәсең. Кәримә аяк очларына гына баса-баса апасы бүлмәсенә таба узды.

— Ку-ку, кем бар монда?

Ваннадан яңа чыккан Зөлфия фен белән чәчен киптереп маташа, озын чәчләре биленә хәтле сибелеп төшкән. Кәримә килеп керүгә ул фенын сүндерде, чәчен бөтереп, артка чөеп куйды.

— Сәлам, апа!

— Сәлам-сәлам. Нинди җилләр ташлады?

— Инәки сукранды, сирәк керәсең, ди. Аннары бүген, беләсеңме, нинди көн?..

— Шимбә.

— Әтинең туган көне.

— Чынлап та. — Зөлфия караватына утырды. — Гел онытып җибәргәнмен. Инәки кайтуга берәр нәрсә пешереп булмас микән, Кәримә?

— Әйдә бәлеш пешерәбез. Әти бәлеш ашарга яраткан ди бит.

— Әйдә! Туктале, бүген төнлә мин бабайлар ягында булдым.

— Котбыйлардамы?

— Каян белдең?

— Күзләреңнән күренеп тора.

— Беләсеңме, Кәримә, мин аның белән араны өздем. Да-да, житте. Йөрдек, булды.

— Ничәмә еллар йөргәчме?

— Дүрт ел артымнан килеп сара инде ул минем.

— Шул гомер йөрешкәч, нигә дип инде бозылышырга?

— Беләсеңме, надоел, скучный ул какой-то.

— Ә ул сине ярата иде.

— Перебьется. Тиң түгел ул миңа. Юлия Борисовна была права. Кәримә, син теге күрше өйдә торучы инвалид егетне күргәнең бар идеме?.. Шул-шул... Кичә мин аның безнең тәрәзә каршына таба килүен күрдем. Таң атып кына килә, ул стенага тотына-тотына безгә таба килә. Килеп житәр-житмәс кире борылды. Шунда инде китәргә борылгач, беләсеңме, безнең тәрәзәгә күтәрелеп карады бу. Күрдем дә үзен, эчем җуу итеп китте.

— Чынлап та безгә таба килә идеме ул? Исеме Бәхтияр аның. Бәхетсез ул, һәм аны бәхетсез итүчеләр әле булса иректә йөриләр. Кыйнаганнар аны, умыртка сөяген имгәткәннәр, шуннан бирле әнә шулай калган.

— Кыйнаганнар? — дип әллә нинди бер халәттә тынып торды Зөлфия. — Кем, кайчан?..

— Биш ел элек, көз көнендә, Казанка буенда...

Зөлфия агарынып китте, тел очына нинди дер сүз кунды, әмма авызын ачып сорарга курыкты.

— Я, бәлеш пешерергә итсәк, әйдә, магазинга чыгып керик.

— Әллә оныгыз да юкмы?

— Юк шул.

— Әйдә соң... Юлия Борисовнаны да дәшәрбез. Хәлил генә кайта күрмәсен...

— Аны айныткычка алып киткәннәр... Кайтмаячак ул... Инәки шуның артыннан керәм, дигән иде.

— Алып кайтмаса гына ярый инде үзен...

Магазиннан азык-төлек алып кергәч, Кәримә, күлмәген салып, әни-

сенең халатын киеп алды һәм бәрәңге әрчергә кереште. Бераздан ул бу эшне апасына тапшырды, үзе ит турарга тотынды. Барысы да әзер булгач, Кәримә камырны җәйде, бәрәңге турап, ит белән аралаштырды да суган турап салды, борыч, тоз сипте. Табаны плитәгә куеп җылытты да камыр салды, эчлекне тутырды, өске камырны каплап, бөтерә-бөтерә ефәк бау кебек ишеп китерде. Ул бу эшне шул хәтле оста башкарды ки, Зөлфия шаккатып карап торды.

— Каян болай өйрәндең син бәлеш салырга?

— Әбекәй өйрәтте. Ипи дә сала беләм әле мин.

Кәримә бәлеш камырын майлап, өстенә ак кәгазь каплап, духовкага тыкты.

— Бу кәгазь ни өчен? — дип сорады Зөлфия.

— Көймәсен өчен. Сәгатькә кара. Сәгать ярымнан бәлеш әзер булачак... Вәт шулай, апа җаным, мин кияүгә чыксам, иремне ашата белермен, син нишләрсең?..

— Ашханәгә йөрербез.

— Шулай итәрсез. Хәзер менә нәрсә, бар син берәр торт алып кер. Чәй янына. Инәки торт белән чәй эчәргә ярата.

— Инәкинең исендәдер дисеңме әтинең туган көне?

— Белмим. Иң мөһиме безнең истә. Беләсеңме, Зөлфия, мин аның җилкәсендә утырып йөрүемне хәтерлим. Яхшы кеше булган безнең әти. Ятканнар үзен... Милициядә әле булса исләренә төшереп сөйлиләр...

Әниләре кайтып керде, кухняда уралучы кызларын күрде дә елмаеп җибәрде

— Һәй, нишлиләр болар монда?.. Исәнме, кызым!

— Исәнме, инәки!

— Бабаларың исән-саулармы?

— Дөбердәтеп яшиләр.

Әниләре өстен салды, кухняга кереп өстәл янына утырды.

— Бәлеш пешереп яталар инде әллә?.. Бәлеш үкме? Кәримә, синең эшең дер инде, Зөлфиянең кулыннан килмәс. Рәхмәт, кызым. Атаңның туган көнен онытмаганың өчен рәхмәт.

Кызлар күзгә-күз карашып алдылар.

— Сизеп торам, инәки әтинең туган көнен дә оныткан, дип уйлагансыздыр әле. Их, балалар, балалар, яратып гомер иткән ир онытыла димени!.. Менә монда ул минем, күңел түрендә, йөрәгемдә. Соңгы көнем өчен үкенепләр бетә алмыйм да бит, нишләмәк кирәк, язмыштыр инде, үлгән артыннан үлеп булмый... Юлия Борисовнаны дәштегезме соң әле?.. Зөлфия, бар алып кер, сөйләшә торырбыз.

— Юк, Юлия Борисовнаны мин үзем чакырам, апа торт алырга чыга,— диде Кәримә.

Дүртәүләп табын янына утыргач, Юлия Борисовна Кәримәгә карап торды-торды да:

— Синдә барыбер әтиең чалымнары күбрәк, Каракүзкәй. Көннән-көн чибәрләнә барасың тагын үзең. Бигрәккенәләр сине ярата иде шул мәрхүм. Кайтыр иде дә: «Каяле, каяле минем Каракүзем» дип әүвәл синең арттан керер иде. Син, сабый, әтиеңне күргә, үрле-кырлы сикерер иең. Әттә кайтты, әттә кайтты, тәтәй алып кайтты, тәтәй алып кайтты дип такылдар иең... Урыны тыныч булсын инде, теләк шул бездән...— Табын янындагыларның өчесе дә шыңшый башлады. Гөлбикәнең күзләре мөлдерәп яшь белән тулган, ул бер ноктага текәлгән дә уйга чумган Кәримә борын тартып утыра, Зөлфия елый ук башлады.

— Карале дим, Каракүз! Нишләвегез инде бу, Гөлбикә! Җырла әле бер, Зөлфия! — дип, сүзне икенчегә борырга тырышты карчык. Хәзер ул мәрхүмне исенә төшерүенә үкенеп бетә алмый иде.

— Әйе шул,— диде Юлия Борисовнаны яклап Гөлбикә.— Җырла әле, кызым, берәр яңа җырыңны. Үткәннәрне кайтарып булса икән ул.

Юлия Борисовна, җаным!.. Халык тикмәгә генә: «Яшь гомерләр кире кайтмас, сулар үргә акса да»,— дип җырламагандыр. Без синең белән яшисен яшәдек инде, Юлия апа. Менә балалар без ясаган хаталарны ясамасыннар иде, ходайдан бар сораганым шул...

— Әй, ул яшь чакларны! Ул чакта бит бу дөньяга мәңгегә килгән кебек йөрисең. Бактың исә, үтә дә китә икән ул яшьлек дигәнең. Я инде, Зөлфия. Күр әле моны, нигә алай боегып киттең әле?

Зөлфия берничә җыр җырлады да, үз бүлмәсенә кереп китте. Кәримә китап алды, Зөлфия янына керде.

— Апа, син Котбый белән чынлап та араны өзденме?

— Ул минем бишектән үк вәгъдәләшкән егетем түгел, нигә алай дисең?..

— Каракүз, син кая киттең? Кил әле бире,— дип дәшеп алды Кәримәне Юлия Борисовна.— Кил әле, кил,— Кәримә кире залга әйләнеп керде.— Карале, Каракүз, теге этиеңне үтергән дошман төрмәдән качкан диләр, хакмы шул?

— Белмим, ишеткәнем булмады,— диде Кәримә һәм кухняга чыгып китте. «Күр инде боларны,— дип уйлады ул.— Каян ишеткәннәр диген син аны»

Кәримә бүген иртәнге якта, бик иртә хәтта, бабасына килеп кергән сакаллы кешеләрне күз алдына китерде. Кәримә уянган иде инде, аларны тәрәзәдән күреп торды. Бабасы кулындагы көрәгенә таянган да аларны тыңлый, тыңлый-тыңлый да башын чайкап куя. Аннары сакаллы кешеләр аңа ниндидер рәсем күрсәттеләр. Бабасы рәсемдәге кешене таныды булса кирәк, ияк кагып куйды. Кәримә тиз генә өстенә халат салды, чәчен рәтләштергәләде һәм ишегалдына чыкты, бакчага таба юл тотты. Сакаллылар яныннан ул исәнләшеп үтте. Сакаллыларның икесе дә аңа карап баш иделәр. Бабасы аларга нидер әйтте һәм шул сүздән соң аларның үтеп барган кыз белән кызыксынулары тагы да артты бугай. Кәримәдән күзләрен алмас булдылар. Кәримә моны әйләнеп карамаса да сизеп торды. Сакаллылар киткәч, бабасы Кәримәне чакырып алды һәм Серыйның фотосын күрсәтте. Бабасы Серыйның кем булуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Серый — Сиражи Яһудин икән. Чыңгыз кешесе. Биредә йорты, семьясы бар. Малаеның исеме Котбетдин диде. Башта моңа Кәримә игътибар итмәгән иде, соңыннан гына зиһене ачылып, Котбый түгелме дигән шиккә калды. Шул ук вакытта алай дип уйларга да курыкты. Бабасы: «Серый төрмәдән качкан, сакаллылар шуны эзлиләр», диде.

— Юлия Борисовна,— диде Кәримә кире әйләнеп кергәч.— Сез ул турыда каян ишеттегез?

— Ил хәбәрсез, җир икмәксез булмас, дигәннәр борынгылар, бабаң килгән ие, шул әйтте...

— Ятыйк инде, инәки,— диде Кәримә.

— Хәзер, балам. Син булмаса залга, диванга гына ятарсың...

— Ярый. Тыныч йокы сезгә, Юлия Борисовна.

— Тыныч йокы, Каракүз. Әйт әле, Каракүз, кайчан кияүгә чыгасың инде?

— Университетны тәмамлагач.

Пенсионер карчык килеп, Кәримәнең аркасыннан сөйде һәм чыгып китте. Кәримә урын җәйде, ятты, баудан тартып кына утны сүндерде. Күзләрен йомарга да өлгермәде, күз алдына Барый килеп басты. Кызык та соң бу Барый. Беркөнне автобус тукталышында дүрт сәгатькә якын көтеп торган. Утырып кына каршы алырга китәр иде, аймыл булырмын дип курыккан. Җитмәсә көн салкын иде, төньяктан салкын җил исә, ә ул, бичара, юка плащтан. Кәримәнең автобустан төшеп килүен күрде дә, бала-чага сыман үрле-кырлы сикергәләнергә тотынды Барый. Кәримә, ихтыярсыздан, аның салкын битеннән үбеп алды. Әй тотынды шуннан сөйләргә, имеш, шул бер үбү өчен ул шушы тукталыш

та төн кунарга риза. Ике үбүгә, әлбәттә инде, ике төн куначаксыңмы, дип шаяртты Кәримә...

Йоклап китәр алдыннан ул шомланып тагын теге качкын турында исенә төшерде. Миллионлы шәһәрдән Серыйны табып алулары җиңел булмаячак. Бәлкем әле ул Казанга кайтмас та, бер ара төрле шәһәрләрдә йөрер. Саклык кассалары басу буенча исеме илгә таралган каракка яшәргә урын табар, ил зур. Әмма барыбер эләгер, барыбер табарлар. Һәм аны Кәримә үз күзе белән барып күрер. Кәримәдә каракка, этисен үтерүчегә карата чиксез нәфрәт, җирәнү хисе уянды.

## 15

Зөлфия бик озак йокыга китә алмый интегеп ятты. Котбый һәм Казанка буенда булган вакыйга исенә төшүгә миен гүя утлы кисәү көйдереп ала. Шундук теге егет күз алдына килә: урта буйлы, чибәр, итагатьле, тыйнак егет. Ни дип качты ул аны ташлап?.. Юк, йоклап булмастыр бүген. Ахырда, ул санарга кереште. Күпмегә хәтле санагандыр, бераздан өне төшкә, төше өнгә әверелде бугай. Имеш, мәктәптә укый икән, беренче класста. Укытучы апа санарга куша. Зөлфия саный. Меңгә җитә, миллионга. Кинәт укытучы апалары юкка чыга һәм аның урынына Бәхтияр килеп баса. Имеш, ул мәктәптә директор булып эшли икән. Һәм, ни сәбәпледер, Зөлфиягә текәлеп карап тора. Янына ук килә һәм «Я, нигә санаудан туктадың?» — дип сорый. Зөлфия, кимсенеп, елап җибәрә. Шунда Зөлфия, куркынып, уянып китә. Колакларында зыңлау, йөрәк тибеше тамак төбендә үк, күзләрендә яшь, мендәрен капшап караса — мендәре юп-юеш. Төшеңдә еласаң — шатланырга, диләр. Ләкин Зөлфиянең моңа ышанасы килми, ул урыныннан тора, юрганына төренә һәм тәрәзә каршына барып баса. Таң атып килә икән инде. Зәңгәр күккә таба алтын кояш нурлары сузылган. Нурлар түгел, алтын төсендәге ефәк җепләр диярсең, ул да түгел, җепләр бенгаль утлары сыман яна башлый һәм күк гөмбәзе яктырып китә. Зөлфиянең мондый манзараны беренче тапкыр күрүе иде, ул бер мәлгә таң калды. Соклануы хәттин ашкан рәвештә, сулыш алырга куркып торды. Ул, атна кичтә күк капусы ачылганны күрергә чыккан берәүдәй, үз-үзенә теләкләр тели башлавын сизми дә калды. Алтын кояш нурлары, җемелдәп янган бенгаль утлары, зәңгәр күк гөмбәзе — таң аткандагы күренеш аны тәмам әсир итте, сихерләде. Зөлфия хәйран калып карап торганда, аның колагына янә кичәге тавыш ишетелде, янә йөрәге җу итеп китте. Шундук зәңгәр күк гөмбәзе, бенгаль утлары, алтын, ефәк җепләр юкка чыкты, аның бөтен игътибарын кичәге тавыш кабат биләп алды. Зөлфия түбән карады һәм стена буеннан алар тәрәзәсенә таба килүче Бәхтиярны күрде. «Инәки!» — диде ул куркынып. Ул аны әчтән генә әйткән кебек иде, ләкин әнисе ишеткән икән: «Кызым, саташасың, ахры, икенче ягыңа әйләнеп ят»,— диде.

Зөлфия шым булды, тиз генә урынына ятты. Хәзер киенәм дә янына чыгам, дип уйлады ул. Чыгам да әйтәм, гафу ит, дим. Алдына ук тезләнермен, ул мине гафу итәр, ул мине онытмагандыр.

Ләкин шулай дип күпме генә батыраеп, үз-үзенә сөйләнеп ятмасын, урыныннан кузгалмады. Шул турыда уйлый торгач, тәмам алҗып һәм күз кабаклары авыраеп, йокыга китүен сизми дә калды...

## 16

Кәримә йөгереп урамга чыкты. Бүген аңа гүя канатлар үскән иде. Әйе, Бәхтиярга биргән вәгъдәсенең, ниһаять, җеп очын тапты. Хәзер ул аны җибәрмәячәк. Апасы барысын да сөйләп бетермәде, сөйләр әле.

вакыт бар. Туган шәһәр, үзең яшәгән өй, урам, таныш ыгы-зыгы. Троллейбус, автобуслар үтеп-сүтеп тора, шалтыр-шолтыр трамвай уза, ике як тротуардан тегe якка да, бу якка да кешеләр агыла. Ирек мәйданында аны Барый көтеп торырга тиеш иде. Кәримә бер ара җәяү атлады һәм мәйданга килеп чыгуга, Барыйны күреп алды. Кәримә, йөгерә-атлый, чаттагы офицерлар йортына җитте, дәү багана артына посты. Ниһаять, Барый офицерлар йорты өстендәге электрон таблога карады. Кәримә аңа нәкъ сәгать тугызда Ирек мәйданында булам, дигән иде, менә ике минутка соңга да калды. Хәер, ике минутка гына түгел, ярты сәгатькә соңарса да Барый аны барыбер көтеп алыр иде. Сәгатенә карый-карый арлы-бирле йөри башлагач, Кәримә аны кызганып куйды, яшеренгән җиреннән чыгып йөгерәсе һәм Барыйның кочагына керәсе килде. Һәм шушы уе аны җинде: ул җәһәт кенә багана артыннан чыгып, йөгерә-атлый Барыйга таба баруын сизми дә калды. Хәзер инде ул туктый алмаячак, чөнки Барыйга сәгать унга эшкә барып җитәсе, ә ул өченче көн: «Кәримә, сине срочно күрәсем бар, кайда очрашабыз, кайчан?» — дип шалтыраткан иде. Кәримә үзе атлады, үзе бары тик бер Барыйны гына күрде, ул кемгәдер орынып китте, гафу үтенде, мәгәр бәрелеп киткән кешегә күңел күзе белән карамады.

— Кәримә, — диде аңа таныш тавыш.— Кәримә, кая болай чабасың!

Шунда гына Кәримә артына әйләнеп карады һәм күзләре дүрт булды, аның каршында Васылә Хакова басып тора иде.

— Василә апа! — дип аның кочагына ташланды Кәримә.— Василә апа, нинди җилләр белән?..

— Кинәшмәгә килдек менә...

— Василә апа, Василә апа, мин шундый, шундый сагындым сезне!

— Тегe егет кем? — дип сорады Василә Хакова. — Ә-ә, ярый. Белдем. Әйт, килсен безнең янга, таныштыр мине дә.

— Барый,— дип дәште егеткә Кәримә.— Кил бире. Кил инде, Барый.

Барый тартына-ояла гына якын килде.

— Исәнмесез!

— Исәнме-саумы, егетем! Шул егетме инде, Кәримә, сине Алабугадан урлап алып китәргә килүче?

— Үзе,— диде Кәримә, күзләрен түбән төшереп.— Барый, таныш бул, Василә апа бу, минем укытучым.

— Я, ярар, мин ашыгам, Кәримә. Бәхетле булыгыз.

— Сау булыгыз!

— Кәримә,— диде Василә Хакова.— Мин «Татарстан» гостиницасында, килеп кит. Килеп китегез.

Икәүдән-икәү генә калгач, Барый Кәримәне бер читтәге эскәмиягә әйдәде.

— Беләсеңме,— диде ул кызны янәшәсенә утырткач.— Синең бит бездә бөтенләй булганың юк, әнинең сине күрәсе килә.

— Шулаймыни, Барый! Әниеңнең күрәсе киләмени! Алай булгач, бармыйча да булмастыр. Тик кайчан?.. Хәер, кайчан да ярый...

— Мин аңа өйләнәм дип әйтеп әйттем...

— Барый, бу ни дигән сүз инде тагын?! — дип үпкәләгәндәй итте Кәримә, үзе егеткә елыша төште.

— Кайчан безгә киләсең?..

Кәримә аңа каш астыннан күз сирпеп алды.

— Үзем әйтермен, яме?..

## 17

Иртән бабаларында уянгач, үзендә сәер бер үзгәреш тойды Кәримә: тәне белән ул Барыйга тартылса, җаны белән Бәхтиярга тартыла иде. Бәхәссез аксиомалар була: үз башына төшкән кайгы-хәсрәтне дә,

бәхет-шатлыкны да кеше бары тик үзе генә ихластан кичерә ала, башкаларда моның чагылышы гына булырга мөмкин. Кәриманең бу ике егеткә булган мөнәсәбәте аны тәмам самимиләштерде. Әллә инде аның күңелендәге Бәхтияр Барыйда булган чагылыш кынамы югыйсә?

Бабасы иртән торган да йорт себерә, әбисе мич каршында коймак пешерә. Рәхәт тә соң бабаларында. Әйе, әйе, аның иң-иң якын кешеләре әбисе белән бабасы, аннары Барый, аннары гына Бәхтияр.

Ул, эшкә барышлый, әнисе янына кереп чыгарга булды. Хәер, аңа бүген эшкә бармаска да була, практикада санала. «Шунда беррәттән Бәхтияр янына да сугылып чыгармын»,— дип уйлады. Әнисе яңа торып килә икән, апасы йоклый иде әле. Өстенә япон плащы, башына күннән тегелгән берет кигән кызын күргәч, әнисе беравык сүзсез генә карап торды.

— Кая булса җыендыңмы әллә?

— Юк, Бәхтияр янына кереп чыгармын дигән идем.

Әнисе, миләш капкан кешедәй, чыраен сытты:

— Ни калган синә анда? — дип сорады.

— Мин аны кыйнап имгәткән, гарип калдырган егетләрне табарга телим. Шул турыда эш кузгатачакмын,— дип өстәде Кәримә.

— Таптың, ди ул егетләрне, көтеп торалар, ди алар синдәй диплом язучыларны. Күптән җилләр искән, ничәмә кат кар каплап, ташу сулары алып киткән инде аларның эзләрен.

Кәриманең ачуы чыкты, әмма ул тыелып калды, бер сүз дә катмады. Бер тапкыр аңа укытучылары әйткән иде. Имеш, хәзерге ата-аналар балаларына гаять дәрәҗәдә таләпчән киләләр һәм бу бик тә табигый хәл, моның белән алар кайчандыр үзләре ясаган хатаны балаларыннан ясатмаска тырышалар. Әлеге таләпчән ата-аналар заманында үз-үзләренә дә шул дәрәҗәдә таләпчән булган булсалар, без күптән инде идеал җәмгыять төзегән булыр идек, дигән иде. Мәгәр алай булмый, матди дөньяга килеп, балигъ булган һәммә кеше үз акылы белән яшәргә тырыша. Чөнки аңа яшисе бу матди дөньяда, аңа дөнья көтәсе. Иң мөһиме, ул үзе яшәгән җәмгыятьнең тулы хокуклы гражданины. Олылар ясаган үгет-нәсихәтне, нотык-өйрәтүне я кабул итә ул, я — юк, чөнки замана кешесе буларак ул да үз акылы белән яшәргә тели. Кылган эшләренә җаваплылык хисе аңа тормыш тәҗрибәсе, укыган китаплар, күргән кинолар, ишеткән гыйбрәтләр аша килә.

— Син, балакай, гарип кеше күңеленә әллә ниткән өметләр сала күрмә тагын, күңелен дә гарип итәрсең. Рәнҗетүең бар берәүне.

— Инәки, мәхәббәт — кешегә бирелгән табигать бүләкләренең иң изгесе, иң кадерлесе, иң гүзәле, диләр. Кимсетмә кызыңны алай. Аны да. Егет кеше ул, акыллы, читтән торып университетта укый.

— Кайда, нинди факультетта?

— Тарих факультетында.

— Бөтен хикмәт тә шунда — гарип ул, балакай. Ә гарип кеше — ким кеше ул. Ким кеше үпкәчән, көнче булучан.

— Инәки, алай дияргә синең хакың юк. Ул үзе теләп гарип калмаган.

— Сугышкандыр әле?

— Кыйнаганнар аны.

— Кем белә, әллә кыйнаганнар, әллә үзе бәйләнгәч тукмаганнар. И-и, әлеге яшьләргә ышансаң... Ә син уз, өстеңне сал, чәй эчәрбез... Сал плащыңны. Күлмәгең матур булган, кемнән тектердең?.. Зрә киләшә үзеңә... Ә инәкәң әйткәнгә үпкәләмә.

Ул кызының зифа буй-сынын күздән кичерде. Анада нindидер бер мизгелдә кызыннан көнләшү кебек бер хис узды, ләкин бу көнләшү түгел иде, кызының чибәрләнеп китүенә ананың соклануы иде. Әнисе текәлеп караганда Кәриманең озын керфекләре күбәләк канатларыдай

җилпенеп китте, ул чәч каптыргычын алып, кара чәчләрен иңнәренә сибеп җибәрде. Сылу гәүдә, тутсыл йөз, иңнәренә төшеп торган чәчләр, әнисе текәлеп караганга булса кирәк, алсуланып киткән бит очлары — барысы да камил иде кызда.

— Ичмасам, кызым, син генә апаң хәленә кала күрмә инде.

— Инәки,— дип чәчрәп килеп чыкты үз бүлмәсеннән Зөлфия.— Ни сөйлисең син, миңа ни булган?! Үзең соң, үзең, ундыңмы... Хәлилеңнән.

— Замолчи! — әниләре шул тиклем каты иттереп идәнгә типте ки, кызларның икесе дә дерт итеп киттеләр.— Оят түгелме сиңа, Зөлфия?! Узындың тәмам, кызый. Беләм дә, беләм. Чыгарырмын мин сине моннан ары, чыгармаган ни!..

Өчәүләп, сөйләшмичә генә чәй эчтеләр. Аннары Кәримә киенде дә, саубуллашып чыгып китте. Әнисе дә, апасы да табыннан тормый гына баш кагып калдылар. Кәримә баскычлардан акрын гына түбән таба төшә башлады. Иртәнге күңел күтәренкелегенең эзе дә калмаган иде. «Әллә авырый микән безнең бу инәки?» — дип уйланды ул подъезддан чыгып барганда.

Бәхтияр аны подъезд төбендәге эскәмиядә каршы алды. Егетнең чәче гадәттәгечә шома итеп ике якка тарап куелган. Өстендә күксел костюм, аксыл күлмәккә сары галстук таккан, йөзе дә аксыл-сары, һич галстук төсеннән аермалы түгел. Күзләрендә назлы караш.

— Исәнме, Бәхтияр!

— Сәлам, Кәримә!

Ул култык таягына тотынып, аягүрә басты һәм чайкалып китте, Кәримә аны тотарга ымсынды, әмма егет аны күз карашы белән туктатты.

— Кирәкмәс, Кәримә. Менә бу чәчәк сиңа.

Һәм егет Кәримәгә бердәнбер канәфер чәчәге сузды. Чәчкә ап-ал таҗларын киң итеп ачкан, гүя соңгы тапкыр кояшка, зәңгәр һавага карап калырга теләгәндәй, томыраеп күккә төбәлгән иде.

— Рәхмәт инде, Бәхтияр.

— Ә хәзер, әйдә, безгә керәбез. Әти дә, әни дә өйдә юклар. Аулак бездә. Мин сине көттем, Кәримә. Мин барысын да сөйләп бирергә булдым. Эшне сиңа тапшыруларына мин бик шат.

Бәхтияр, стенага елыша-елыша, бик кыенлык белән баскычтан менә, ул үзенә ярдәм итәргә кушмый, ярдәм итә башласаң үпкәли, рәнҗи, ачулана.

Ниһаять, менә аларның ишеге. Бәхтияр җилкәсе белән ишек яңагына сөялде дә кесәсеннән ачкыч чыгарды, ишекне ачты. Аның куллары җиңелчә калтырый иде. Янә кызганып куйды егетне Кәримә. Бусаганы атлап керүгә, Бәхтияр аны түргә узарга кыстый башлады.

— Монда мин хуҗа. Әйдә үт, залга кер. Мин хәзер.

Кәримә плащын, туфлиләрен салды һәм ниндидер йомшак эчле чүәк элдектереп, залга узды. Күп тә үтмәде, дүрт тәгәрмәчле арбага ризыкнигъмәт тезеп, Бәхтияр килеп керде. Ул арбага тотынган да сак кына атлый иде. Кәримә аңа ярдәм итәргә кузгалмакчы иткән иде, Бәхтияр янә карашы белән аны туктатты.

— Әйтәм бит, үзем. Менә шулай. Бу юлны мин көненә ун-унбиш тапкыр узам. Өйрәндем инде. Хәзер якынрак кил, күчебрәк утыр, тартынма. Кофе эчәбез...

— Рәхмәт, Бәхтияр, мин яңа гына чәй эчкән идем.

— Аш аш башына, дигәннәр картлар. Җитеш әйдә...

— Ә син бераз үзгәргәнсең димме, ябыгып киткәнсең кебек, Бәхтияр...

— Укулары җиңел түгел. Тарих хикмәтле фән бит. Менә мин болгар дуслардан бер китап соратып алдым. Хикмәтле китап булып чыкты. Авторы мөхтәрәм болгар тарихчысы.— Бәхтияр бармак калынлык бер китап алды.— Менә ни яза ул, Кубрат ханның ике улы була. Хазар

лар Болгария илен басып ала башлагач, Кубрат ханның олы улы Аспарух, үз кешеләрен алып, күптән билгеле юл белән Дунай ягына китә, ә икенче улы Батбай үзенең кешеләре белән төньяк-көнчыгышка юнәлә. Шушы ике туган халык турында татар халкында Сак белән Сок бәете туган, шундый ук бәет Дунай буе болгарларында да бар икән. Димәк, Сак белән Сок бәетенең мәгънәсе бик борыннан килә һәм бөтенләй башка икән ич... Шул турыда, Болгар халыкларының борынгы бабалары бер булуы турында минем курс эше язарга исәп бар.

— Бәхтияр, син миңа тагын нидер сөйлим дигән идең.

— Анысы — башка. Эч әле тагын бер чәшкә кофе... Мин сиңа, гомумән, ышанам, Кәримә. Беләсеңме, сеңлем кебек күрә башладым мин сине. Гафу итә күр, ни...

— Рәхмәт, Бәхтияр. Хикәятең кызык. Ләкин мине борынгы бабаларыбыз гына кызыксындырмый, Бәхтияр. Мине синең белән булган вакыйга да кызыксындыра. Онытма, мин тикшерүче һәм мин ул кешеләрне табам дип, сиңа вәгъдә дә иткән идем.

Бәхтияр җайсыз гына күтәрелеп урыныннан кузгалды. Кыен иде аның хәрәкәтләренә карап торуы. Кәримә кулына журнал алып, актарырга кереште.

— Мин «Син сазыңны уйнадың» дигән җырны яратам. Күпме моң ул җырда.

— Мин дә яратам аны.

— Синең нигәдер кәефең юк кебек, Кәримә.

— Кәефем чынлап та бик шәптән түгел, кызыгырлык түгел, дим.

— Дөрес булса, башта кешегә кызыгу килгән, диләр бит. Яши-яши, зәвыгы үсә төшкәч кенә, соклану сыйфаты килә адәм баласына. Кешене кеше итүче сыйфат — соклану хисе, дияр идем мин. Минем берәүдә яшьлегем яши, сокланыр таза чагым, ул миңа килсә, мин аңа һичкайчан авырлык китермәс идем.

Бәхтияр пластинканы куйды, бүлмәгә тыенкы-тымызык кына моң тулды.

«Әйе, соклана белү кешенең иң матур сыйфаты,— дип уйлады Кәримә. — Ләкин каян килә адәм баласына явызлык? Бу сыйфат аңа алла тарафыннан бирелмәгән, бусы — бәхәссез. Син бит, Бәхтияр, беркемгә дә явызлык кылмадың. Ә шулай да сине имгәткәнче кыйнаганнар. Һәм алар бүгенге көнгәчә вөҗдан газабы кичерми иректә яши бирәләр. Юк, Бәхтияр, һәр очракта да, явызлык җәза алырга тиеш... Явызлыкны гел изгелек белән генә җиңеп булмый икән шул, аңа каршы еш кына көч кулланыла, көч һәм һәр кешегә бирелгән хокук. Синең дә, Бәхтияр, хокукың бар, һәм шуны саклый торган кагыйдәләр бар. Бүген син миңа ул кызның исемен әйтергә тиешсең. Иртәгә дә түгел, бүген, хәзер үк...»

Бер гаепсезгә гарип калган егетнең гаять горур булуын, кайчандыр җәбер-золым күрүенә карамастан, анда яшәү рухы көчле булуын белә иде Кәримә. Бәхтияр үзендә яшәүгә генә түгел, хәтта укырга көч тапты. Үзен гарип калдырган кешеләрдән үч алу теләге белән яшәми, шул ук вакытта үзен гарип калдыручыларны оныта да алмыйдыр ул. Шул еллар эчендә аның яссы такыр маңгаен сырлар кискәләде, ул язмышы белән килешкән сыман иде инде, менә һич көтмәгәндә, йөрәген ярсындырып: «Мин аларны табам»,— дип, аның тормышына бер кыз килеп керде. Башта Бәхтияр аңа ышана алмады, кызның хыялын җәберләмәс өчен генә килешкән иде. Хәзер исә, еллар үтеп, кыз янә шул мәсьәләгә әйләнеп кайткач һәм җитди эш итеп берничә ел элек булган фаҗиганы ачырга җыенгач, ышаныч һәм өмет белән бер мәл Кәримәгә карап торды ул. Хәзер менә музыканы җибәрүе дә күңеленә гайрәт, таяныч алу өчен генә иде. Музыка Бәхтиярның халәтен җиңеләйтмәде, киресенчә, тагы да кискенләштерде, сагышландырды гына. Ул лып итеп

диванга утырды һәм ике кулы белән йөзен каплап бер тын дәшми торды. Егетнең үтә күренмәле юка бармаклары җиңелчә дерелди иде.

Кәримә аңа туры карамаска тырышып, журнал актаруын дәвам итә. Ул аны гүя күрми, ләкин белә: егеттә гаять зур эчке көрәш бара. Моңа кадәр ул кешедән генә түгел, хәтта үз-үзеннән дә кемнеңдер исемен яшереп килгән. Хәзер аңа барысын да сөйләп бирергә кирәк. Кирәкме бу хәл аңа, җөйләнеп барган җәрәхәтләрен генә кузгатып җибәрмәсме?..

Музыка туктады. Бәхтияр, хатирәле истәлекләреннән аерыла алмыйча, бүлмәдәге һәммә нәрсәгә күз йөртеп чыкты. Күзләре белән бүлмәсенә кайтса да күңеле белән ул һаман теге чакта, Казанка буенда иде әле, күрәсең. Әмма карашы Кәримәгә җитүгә, ул тәгаен реаль дөньяга кайтты.

— Беләм, Бәхтияр, сиңа бу турыда сөйләү түгел, искә төшерүе дә кыендыр. Сиңа үткән белән түгел, бүгенге белән яшәргә кирәк. Ул кызга әле булса ихтирамың зур икән, мин сине аңламыймы, Бәхтияр, аңлаудан баш тартам. Син аның исемен әйтергә теләмисең, ә ул... Син аны әлек тә белгәнсең, Бәхтияр. Шулай бит?..

— Юк-к, Кәримә,— дип башын чайкады Бәхтияр.— Мин аны бүтән күрмәдем... мөнә бирегә күчеп килгәч... Мин аны һич тә гаепләргә теләмим.

— Ул сине иң-иң авыр минутта ташлап качкан. Ни бу, Бәхтияр, куркумы, я булмаса рухи фәкыйрьлекме?.. Ул кыз бәлки әлеге егетләрне дә беләдер...

— Тимә, кагылма минем үткәнемә, Кәримә. Калдыр. Тимә ул кызга. Ул бәхетле, аның киләчәге бар. Бу хәлнең ачылуы аны бәхетсез итүе бар... Син дә үкенерсең...

— Бу ни дигән сүз инде тагын, Бәхтияр!

— Ал башка бер эш, Кәримә. Беткәнме, бетәсеме хәвефле хәлләр. Беләсең килсә, мин аны хәзер һәр көн диярлек күрәм. Күргән саен күңелем бөтәеп, җиңеләеп киткәндәй була. Мин бер тапкыр үлеп карадым инде, Кәримә. Икенчесеннән курыкмыйм. Ул җиткергәнне беләләр, хулиганнар аны гафу итмәсләр...

— Бәхтияр,— диде Кәримә түземен җуеп.— Бәхтияр, аңла, ниһаять, җәмгыятьтә төрле шәхесләр була. Бер үк агачта аны корытучы кортлар да, шул кортларны ашаучы кошлар да яши. Битарафлык ул җинаять кылу белән бер. Җәмгыять агачын корытмыйм дисәң, син аның исемен әйтергә тиешсең, Бәхтияр. Явызлык кыла белгәч, җәзасын да алырга тиешләрдер бит?!

Бәхтияр авырлык белән аның янынарак күчеп утырды, тезенә кулын салды һәм кызның күзләренә карады. Кәримә әллә нишләп китте. Тез өстендәге кул гүя авыр ташка әверелде, әмма кыз аягын кузгатмады, егетнең кулы тезенә ятуга, капыл сискәнеп китүен сиздермәскә тырышты.

— Бик тә беләсең киләме, Кәримә?

— Бәхтияр...

— Ә мин сиңа ул кыз — синең апаң иде дисәм!

— Зөлфия апамы?! Юк, Бәхтияр, мин синнән чынлап сорыйм...

Апасының исеме чыгуга, Кәримәнең йөрәге дерт итеп куйды, әмма ул сер бирергә теләмәде. Дөресе шул иде: ул аңа Бәхтияр әйткәч тә ышанган иде, мәгәр алай булмавын теләде. «Зөлфия апамы?!» — дип кайтарып соравы да, куркынып, шомланып китүеннән иде.

— Гариплек кешене бөтен нәрсәдән дә мәхрүм һәм бәхетсез итә алмый, Кәримә. Мин университетта укыйм, мине анда хөрмәт итәләр. Зөлфия ни... Зөлфия үзенчә бәхетле, мин үземчә. Аны гаепли дә алмыйм.

Кәримә аны әллә ишетте, әллә ишетмәде, тезендәге кулны сыпырып төшерде дә әкрен генә күтәрелде һәм ишеккә таба кузгалды. Аның дәшми-тынмый ишеккә таба уңайлавын егет бертын карап торды да

кузгала башлады, әмма күтәрелә алмады, сыгылып, кире диванга утырды.

Кәримә чыгып китте.

Ишегалдында шау-шу иде. Малай-шалай туплы уйный, кыз-кыркын бер-берсен куыша. Кәримә уйланып әкрен генә бара. «Мөмкин хәлме бу, апа җаным, мөмкин хәлме!» — дия-дия ачыргаланды ул, кай тарафка барырга, ни кылырга белми гаҗизләнүдән. Ләкин аны аяклары туры өйләренә, өченче катка алып менде. Ишеккә җиткәч, бераз стенага сөялеп торды. Зиһене чуалган, исен җуйган бер халәттә иде ул. Иң кыен моментта Бәхтиярны ташлап качкан кызны ничәмә-ничә еллар тиргәде ул, аны кайчан да булса фаш итү хыялы белән яшәде. Һәм менә тапты. Ул аңа әллә ниләр әйтергә җыенган иде. Һәм менә Кәримә бүген, ниһаять, ул кызның исемен белде. Әйе, Бәхтиярны инвалид иткән егетләр табылыр, Кәримәнең моңа иманы камил, аннары аларны хөкем итәрләр. Ә менә апасын... Нигә ул, нигә башка берәү түгел!..

Кәримә стенага сөялгән килеш, башын як-якка чайкады, йөрәге әрнешүдән ни кылырга белмәде. Апасының бу хәле өчен ул гарьләнде, гарьләнүдән тамагына төер тыгылды, күз яшьләре тып-тын идәнгә тамды. Нишләргә, нишләргә тиеш ул хәзер?.. Моңа кадәр ул бөтен булганы белән гаделлеккә омтылды, кирәк икән тапты, гаеплене фаш итте. Менә хәзер, хәзер нишләргә тиеш ул?! «Их, апа, апа... Соңгы арада син аны һәр көн булмаса да көн аралаш күреп йөргәнсеңдер... Танадыңмы икән үзен?.. Танымыйча үтеп-сүтеп йөрдеңме? Ә бит ул сине һәркөн күтеп алган...»

Кыңгырау төймәсенә басты, эчтән энисе: «Ишек ачык!» — дип кычкырды. Керде, ишек төбендә туктап калды. Энисе идән юа, Зөлфия апасы түр бүлмәдә пианинода уйный һәм тыенкы гына җырлый иде:

> Яшь гомерләр кире кайтмый,
> Сулар үргә акса да...

— Зөлфия апа, чык әле бире...

— Әйдә, аягыңны сал да түргә уз,— диде энисе.— Ишетми ул, күрәмсең җырлый... Туктале, тукта, ни булды сиңа, гелән төсең качкан? Куркыттымы әллә берәрсе?..

— Берни дә булмады, инәки. Зөлфия апа кирәк миңа, вакытым тар...

— Зөлфияү, чык әле бире, кил әле дим! Ә син өстеңне сал да чәй куеп җибәр. Кызым, бәбкәчем, әллә мәйтәм бу эшеңнән китәсеңме?.. Бетәсеме Казан кадәр Казанда хатын-кызга эш... Атаң, мәрхүм, шул эштә башын салды, инде хәзер син. Милиция машинасының тавышын ишетәм дә, котым алынып уянып китәм...

— Инәки, без синең белән бу турыда сөйләштек бугай бит инде. Миңа үземнең эшем ошый.

Кәримә кухняга узды, чәй куйды.

— Нигә тиктомалга бәйләнәсең әле, инәки, шуңа. Тик эшләсен. Каракларны, хулиганнарны тотар,— дип түр яктан килеп чыкты Зөлфия.

Әниләре хәтта игътибар да итмәде, һаман Кәримә белән сөйләште.

— Кызым, Хәлил әләккән бит. Чыгара алмассың микән үзен?..

— Юк, инәки. Теләсәң нәрсә сора, моны эшли алмыйм. Телисеңме, дәваларга озатам үзен?

— И ходаем, чирле бит ул, болай күрер күзгә генә таза күренә. Үлеп калса шунда. Бахырның бер дә анда барасы килми шул, бәбкәем...

— Ни пычагым булсын аңа,— диде Зөлфия.

— Әй, бала-бала. Син ни сөйләгән буласың инде тагын. Начармы, яхшымы, ул минем белән тора бит... Исән-сау чыксам, яңадан авызыма да капмас идем, ди.

— Тукран тәүбәсе...

Кәримә апасына туры карарга кыенсынды.

Чәй әзер булгач, тезелешеп өстәл янына утырдылар.

— Инәки,— диде Кәримә, шоколад конфетны иреннәренә тигезми генә вак-вак тешләп, чәй эчеп утырган апасына күз төшереп алгач.— Инәки, Зөлфия апа бездән нидер яшерә. Моннан берничә ел элек, августның бер көнендә ул Казанка буена бер егет белән йөрергә төшә.

Әнисе дә, апасы да чәй эчүдән туктап, Кәримәгә текәлделәр.

— Ни булды тагын, балакайлар?..

— Безнең күршедә Бәхтияр атлы инвалид егет яши. Аны нәкъ шул көнне Казанка буенда дүрт хулиган умыртка сөяген сындырганчы кыйныйлар. Аның янында бер кыз да була...

— Синме, балакай, Зөлфия дим, дәш, нигә телең йоттың?!

Зөлфиянең йөзендә кан әсәре калмады, ул берара ни әйтергә белми сеңлесенә карап торды, аннары кисәк өстәлгә капланды да елап җибәрде.

— Син каян белдең соң моны, Кәримә балакай?! — Кәримә җавап бирмәгәч, ана Зөлфиягә иелде.— Чынмы бу, балакай? Зөлфия дим?!

— Хәзер генә күз яшең түкмә,— диде Кәримә тора башлап.— Синең гаебең үз намусыңда. Бер киңәшем бар сиңа: барысын да язып милициягә китер...

— Тукта әле, балам, Кәримә. Бу ни дигән сүз инде,— дип өзгәләнә башлады әниләре.— Кем алып бара ул эшне, синме, башка берәүме?..

— Мин, инәки.

— Син,— дип гаҗәпләнде әниләре хәттин ашып.— Син! Туктат, апаңны адәм хуры итмә, җуеп кал...

— Булмый, инәки. Мин моңа бара алмыйм. Аннары, мин туктатсам, аны барыбер башка берәүгә бирәчәкләр. Без капчыкта ятмый.

Зөлфия башын күтәрде, кара сөрем тарткан керфекләреннән эреп буяу катыш яшь тама, әмма күзләрендә ачу иде аның.

— Барый белән арагыз ничек әле, әйт!

— Инәки, кара әле тилене.

— Миңа нәрсә, сеңелкәем, ул егетне кыйнаучылар арасында синең Барый да бар иде...

Кисәк булган бу хәбәрдән Кәримәнең аяк астындагы идән убылып киткән кебек булды. Әмма бу халәте озакка бармады, ул шундук исенә килде. «Апа ялганлый»,— дип, үз-үзен юатып алды. Ул үзен кулга алырга теләде, әмма апасына туры каравы булды — барысына да ышанды — апасы ялганламый иде.

— Бу мөмкин түгел, апа.

Зөлфия аягүрә басты һәм ашыга-кабалана, тотлыга-ярсына барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Котбый янында Барыйның да булуы, ул гынамы, алар янында тагын ике егетнең уралуын әйтте. Бәхтиярне ташлап китүенә үзенең әле булса үкенеп йөрүләре, әле булса аны оныта алмавы, әмма күрше өйдәге егетне һич тә ул булыр дип уйламавы, гомумән, аның төс-йөзен рәтләп хәтерләмәве, чөнки танышуларына да бер сәгатьтән артмавы, аны әле шушы көннәрдә генә таныган сыман булуы, әгәр дә мәгәр, ул чынлап та күрше өйдә яшәүче инвалид егет икән, алдына тезләнеп гафу үтенәчәге турында әйтте. Кыскасы, берсен дә калдырмады. Хәтта, мөмкин булса, ул аны Мәскәүнең иң зур профессорларына алып барып күрсәтергә дә әзер булуын белдерде.

Шуннан, ерактан йөгереп килгән берәүдәй шымып, кире урындыгына утырды.

Кызлары аңлашкан арада исенә килә алмый торган ана ике кулы белән битен каплады да бермәл як-якка авып-түнеп торды, аннары Зөлфиясен килеп кочты, аны калдырды да Кәримәнең күкрәгенә килеп капланды.

— Бәбекәем, син моны эшләмәссең бит, әйт, эшләмәссең бит! Сез бит бер туганнар, бер анадан туган балалар!

— Юк, инәки, апага барыбер вөжданы каршында җавап тотарга туры килер,— диде Кәримә һәм китәргә дип ишеккә таба кузгалды.

Аны әнисе дә, Зөлфия апасы да туктатмадылар. Урамга чыккач, Кәримә тирән итеп сулыш алды. «Эмоцияләр артык күплектән бу, кислород җитмәүдән»,— дип уйлады ул, нигәдер бер лекторның сүзләрен исенә төшереп. Моңа кадәр аңа дөнья болай ук катлаулы түгелдер кебек тоела иде.

Барый... Кәримәнең йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Барый исеме аны әллә кайларга алып китте. «Барый, бәгырь, мөмкин хәлме бу, синме моны эшләүче?!» — дип ярсынды ул милиция үзәгенә таба атлаганда.

Башта ул бу хәлнең чын булуыннан коты алынып курыкты, соңыннан янә үз-үзен юата башлады. Юк, апасы ачуы чыккач кына әйткәндер. Барый андый буламы соң... Котбый — әйе, булгандыр, сугышкандыр. Барый — юк. Бер гаепсезгә кешегә кул күтәрә торган егетме ул! Юк, тагын бер тапкыр юк. Моны хәтта күз алдына китерүе дә кыен.

Янә апасының Казанка буенда булган хәлне тәфсилләп сөйләве күз алдына килә, янә Кәримәнең күңеленә шик төшә. «Бу хәл чын-чынлап дөрес булып чыкса? Дөрес булып чыкса нишләрсең, җүләрем?!.»

Гел ышанмаслык хәлләр. Барыйның хулиганнар компаниясендә булу мөмкинлеге тууга, Кәримәгә рухи хәлсезлек килде. Милициягә килеп керүгә, ул икеләнә калды. Алай да, кабинетына кереп, өстәл янына килеп утыргач, тынычлана төште һәм барысына да повестка җибәрергә дигән фикергә килде. Барыйга да. Шунда ачыкланыр — катнашканмы, юкмы. Гаебе юк икән... Ике көн инде Кәримәнең аны күргәне юк. Башка чарам калмагач, повестка белән чакырып китерергә мәҗбүр булдым, дияр. Ә инде Бәхтиярны кыйнауда катнашкан икән... Ул вакытта... Ул вакытта Кәримә ни эшләргә тиешлеген белми иде әле...

Милициягә килү белән ул майор Хикмәтулла Хаков кабинетына юнәлде. Заманында әтисе белән бергә эшләгән майор Хаков, дуадак каз кебек, һаман бер ялгызы яши: ул Кәримәне шул хәтлѐ якын күрә, кызым дип кенә дәшә. Милициягә килгәч тә ул Кәримәне үз кул астына эшкә алды.

Бусаганы атлап керүе булды, формадан йөрергә яраткан майор Хаков аңа таба кузгалды.

— Ә-ә, Кәримәкәй, рәхим ит, үт әйдә, утыр. Ярый әле кердең, чакырып сөйләшергә дип тора идем... Беләм, телефоннан сөйләшә торган сүз түгел,— Хаков аның янәшәсенә утырды.— Әниең килгән иде, яңа гына китте. Теге явызы тагын эләккән. Ну, чыгарыгыз, дип үтенә. Үтенә генәме, ялвара. Ә минем әүвәл синең белән сөйләшәсем килде. Әллә мәйтәм, сине кыерсытамы, исерек баш. Юкмы. Хәзер анда тормыйсыңмы?.. Алай булса ярый. Язуны язып бирдем, ә эчне әллә ни тырный.

— Беләсезме, Хикмәтулла абый, мин дә шул турыда сезгә кергән идем. Инәки үтенепләр сорады. Башта ризалык бирмәдем, ачуланып чыгып киттем, соңыннан...

— Чыкты инде ул. Күз-колак булып торырга әниең вәгъдә итте. Бикләп кит үзен, дидем. Гаҗәп хәл, яратуымы шулай?.. Ярый, куеп торыйк аны, Серый турында ничегрәк уйлыйсың? Тегеннән дә егетләр килгән, эзлиләр, безнекеләр дә кушылды. Синең бабаңда булганнар. Бу якларга кайтса хатынына керми китмәс, дип баралар.

Хикмәтулла торып, өстәл янына күчеп утырды, терсәкләрен шома өстәлгә җәеп салды да карашын Кәримәгә төбәде. Алар бер-берсен күзәтәләр, бер-берсен сыныйлар кебек иде.

— Хикмәтулла абый, теге кыйналган егетнең материалы турында иде... Куркам мин. Әллә нигә куркам. Ачып җиткерә алмам кебек... Алар арасында... — Кәримә бик авырлык белән генә Барый хакында сөйләп бирде.

Майор Хаков кузгалды, ишекле-түрле йөреп килде, кулын кесәгә тыгып, бер тын тәрәзәдән урам якка карап торды.

— Суыта башлады. Җир туңды. Кыш якынлашып килә. Көннәрнең рәте юк. Көзе көз түгел, кышы кыш дигәндәй. Барысы да буталды, чуалды. Миңа калса, кеше табигать сферасына артык нык басым ясый башлаудандыр бу. Егетең турында сөйләшү өчен әүвәл миңа кереп дәрес эшләгәнсең... Беләсеңме, күптән түгел кем килде миңа? Белмисең. Вәсилә апаң. Ике сәгатьләп ресторанда утырдык һәм ике сәгать буена диярлек синең әтиең турында сөйләштек. Мәгъфүрә апаң дөнья куйгач, син анын, бик төче сүз дип уйламасаң, кулын сораган идем. Бер сүз белән: «Юк!» — диде... Менә шундый безнең хәлләр, Кәримә. Егетеңнең гаебе бар икән, йомып калдырырга тырышма. Әйбәт кеше тик торганда кеше кыйнамас. Яшь чакта да, ир-ат булгач та, минем кебек картайгач та...

— Аны утыртып куйсалар?..

— Кеше үз язмышын үзе ясый. Менә минем кебек. Вәсиләдән башка миңа беркем дә кирәкми. Куанычым да, юанычым да ул. Әйдә, риза булмасын. Ләкин ул бары минем йөрәгемдә.— Хаков Кәримәгә таба борылды.— Әйе, егетеңне утыртып куюлары да бар. Бик мөмкин хәл. Явызлык җирдә ятмый, явызлык кылган кеше җәзасын да алырга тиештер бит, ә? Без ни өчен монда?.. Явызлыкны булдырмау өчен, булганын җәзасыз калдырмау өчен... Гаепле икән, егетеңне коткарырга маташма.

— Ю-у-к, бәлкем әле ул гаепле дә түгелдер. Ул шундый әйбәт, Хикмәтулла абый...

— Әйбәт,— диде Хикмәтулла һәм янәдән өстәл янына килеп утырды.— Безнең төп эш, Кәримә, кылган явызлыкларны фаш итү.

Кәримә аяк очларына карады, күзен күтәреп карарга оялып торды. Тәҗрибәле карт тикшерүче кызның халәтен шундук сизеп алды.

— Ә син нәтиҗә ясарга ашыкма. Башта тикшер. Гаепләнүчеләр дүртәү була. Икесе каялар?..

— Чаллыда эшлиләр. Берсе мастер, икенчесе техник.

— Чакырт. Тикшер. Син беләсеңме әле Яһудин дигәне әнә шул этиеңне үтергән Яһудин Сирайның улы булуы турында. Белмәсәң бел. Котбый Яһудин Сирай Яһудинның улы. Алма агачыннан ерак төшми, диләр, күрәсең, хак булган борынгылар...

«Юатты,— дип уйлады Кәримә майор Хаковтан чыккач,— юатты, янәсе». Кәримәдә олылар әйткән һәр сүзгә карусыз буйсыну, нәкъ алар кушканча гына эшләү гадәте юк иде. Шуның өчен кабинетына кайтып кергәч, ул бер тын уйланып утырды. «Юк, хаклы түгелсең син, Хикмәтулла абый, хаклы түгелсең, төрмәдә утырган бар кеше дә әшәке була алмый. Күбесе аннан акылга утырып кайта, яңабаштан яши башлый. Бәлкем әле аның Барые гаепле дә түгелдер. Нишләп гаепле булсын ди. Ул шундый әйбәт кеше, этисе-әнисе дә әйбәтләр. Ә шулай да повесткаларны җибәрми булмас, китә торсыннар».

Кәримә кисәк күтәрелде дә повесткаларны секретарьга кертеп бирде.

*
* *

Эшкә килеп, урынына утыруга, Кәримә кабинетына күз йөртеп чыкты. Барысы да үз урынында иде. Ул бүген беренче тапкыр сорау алачак. Һәм кемнән? Апасының йөргән егетеннән. Кәримәнең карашы тәрәзә төбендәге роза гөлендә тукталды. Кәримә уч төбе хәтле гөнә көзгесен чыгарды, йөзенә карады. Бүген ул формадан түгел иде, аның өстендә кызыл күлмәк, муенында сары гәрәбә төймә, күлмәк ес-

геннән түше ачык калын йон кофта кигән, кофтаның сәдәфләрен ул юри эләктермәде.
Ишек шакыдылар.
— Мөмкин,— диде Кәримә. Ишектән майор Хаков килеп керде.
— Кәримә, бер фикер әйтимме үзеңә?.. Сорау алганда беркайчан да бу кеше гаепле дигән фикер белән сорау ала башлама. Гаебе юк бу кешенең дип уйла. Хәтта гаебе булган очракта да нәтиҗә ясарга ашыкма. Я, уңышлар сиңа...
Майор Хаков чыгып китте. Хаковның сәбәп юктан сәбәп табып килеп керүе, нотык укуы Кәримәне бераз аптыраштa калдырган иде. Майор Хаков киңәшмәләрдә дә, оперативкаларда да сүзен әйтергә ашыкмас, барысын да тыңлап бетерер, мөмкин булганда сүзен иртәгә калдырыр, ә инде вакыт тар икән, тәнәфес кебек нәрсә белдерер, шуннан соң гына үз фикерен әйтер иде.
Кәримә шулай уйланып утырганда ишектән Котбый килеп керде.
— Пр-ривет!
— Исәнмесез! — диде Кәримә һәм ым белән генә стена буендагы урындыкка күрсәтте.
— Менә,— дип Котбый повестканы өстәлгә ташлады.— Сез җибәргән повесткамы бу?.. Сез, димәк. Ни ямарга телисез инде бездәйләргә?.. Беләсеңме,— дип башка тонга һәм «син»гә күчте Котбый.— Ишектә таныш фамилия күргәч, теге, ни, аптырап калдым. Ба-а, мин әйтәм, балдыз янына килер көннәр дә бар икән. Апаңа ул-бу эшләгән дисәң, ялгышасың, балдыз. Без аның белән мирно разбежались. Тәк что, балдызкай, апаңа әйтә аласың, Котбый Яһудин моннан ары аның тирәсендә чуалмас... Исәндер бит үзе?..
— Апа исән-сау. Иптәш Яһудин, сезне бирегә ни өчен чакыруыбызны бераз абайлыйсыздыр кебек миңа калса...
Котбый урындык артына терәлебрәк утырды, өстәлдә яткан повесткага, беркетмәгә күз төшереп алды. «Белгәнме, белмичәме шулай үзүзен тыныч тота бу? — дип уйлады Кәримә. — Белгән булса бер хәл, белмичә шулай тыныч кабул итсә, җиңел булмас моңардан сорау алулары. Әгәр тана икән, Котбый Яһудин потенциаль җинаятьче...»
— Бусы сезгә нигә кирәк инде?
— Моннан биш ел элек, хәзер инде алтынчы ел китте, егерменче август көнне, сез, дүрт кеше, Бәхтияр атлы бер егетне имгәткәнче кыйнагансыз. Шул хәлдән соң егет өч айга якын больницада ятып чыга. Аны инвалид итүче сез, Яһудин.
Котбый янә өстәлдә яткан повесткага күз төшереп алды, аннары, ни тели бу кыз миннән дигәндәй, Кәримәгә карады һәм, авыз чите белән генә елмаеп: «һә»,— дип куйды.
— Биш ел элек түгел, биш көн элек булган хәлләрне дә оныта башладым мин хәзер. Склероз... Хәтер юк, иптәш тикшерүче.
— Ярый. Димәк, егерменче августта сез Казанка буенда булмадыгыз?
— Юк, булмадым. Хәтерләмим.
— Үзегез белән бергә булган егетләрнең фамилияләрен дә хәтерләмисезме?
— Кабат әйтәм, мин егерменче август көнне, моннан биш ел элек Казанка буенда булмадым.
Котбый Казанка буенда булган хәлне сөйләргә теләми иде. Кәримә сорау алуны туктатырга булды, ни файда, иптәшләре стенага китереп терәгәч, барысын да сөйләр, сөйләми кая барсын.
Кәримә язылган беркетмәне Котбый ягына таба этәрде.
— Менә монда кул куегыз да, китә аласыз.
Котбый моны көтмәгән иде, күрәсең. Утырган җиреннән кузгалыр-кузгалмас бер кавым уйланып торды. Ул хәзер Кәримәнең йөзенә, күзләренә туры карарга тырыша иде. Аңардан беренче тапкыр сорау ала-

лар, сорау алу болай тиз булмыйдыр, дип уйлавы идеме. Аны үгетләргә, аңа ялварырга тиешледер бит инде. Алай да ул өстәл янына күчте, беркетмәдә язылганны укып чыкты һәм кул куйды.

— Дөрес язгансыз, ничек сөйләдем шулай язгансыз. Мин чынлап та андый хәлне хәтерләмим.

— Менә монда да кул куегыз...

— Әй шулай да, булган булсам, нишләтергә исәбегез инде, иптәш лейтенант. Лейтенант бугай бит сез?..

— Повесткада төгәл әйтелгән, Яһудин. Ялганлау, дөрес күрсәтмәләр бирмәү, суд органнарын ялгыш юлга җибәрергә маташу фактлары табыла икән, хөкем сезнең файдага булмаячак. Шул гына, Яһудин, нибарысы шул гына. Кстати, әйтегез әле, Яһудин, Сирай Яһудин сезнең әтиегезме?

— Әйе, дисәм ни әйтерсез?

— Кул куегыз! — дип тавышын күтәрә төште Кәримә.— Кул куегыз! — диде ул эчке бер тетрәнү тоеп.

Котбый әкрен генә торды, мәгәр ишек тоткасына кулын салгач, бер ара уйланып, туктап калды. Кәримәнең күңелендә бу кешегә карата ачы нәфрәт уты дөрли иде. Шушы кеше белән Зөлфия апасы күпме йөрде, ә аның әтисе безнең әтине үтерүче. Белде микән бу турыда Котбый? Мөгаен, әнисе әйтмәгәндер...

— Сезгә китәргә мөмкин. Икенче тапкыр чакырганда булган хәлләрне хәтерегезгә төшереп килерсез дип уйлыйм. Да, да, Яһудин! Анналы менә нәрсә, бусы протоколга язылмас. Зөлфия апа анда булган хәлләрне бик яхшы хәтерли. Күрәсез, Яһудин, сезнең хәтерләмим дигән сүзләрегез дөрес үк булып чыкмады.

Яһудинның күзләре шар ачылды, ишек тоткасына салган кулын кире алды, өстәл янына таба ымсынып куйды. Кәримә аңа шул кадәр нәфрәт тулы күзләре белән карады ки, Котбый кисәк күн тужуркасының сәдәфен боргаларга кереште, ул да түгел, яшькелт-сары күлмәгенең якасын рәтләде.

— Ә-ә...

— Минем вакытым юк, Яһудин.

Шул вакыт ишектә милиция хезмәткәренең башы күренде.

— Азатова, летучкага!

Кәримә тиз-тиз өстәлдәге кәгазьләрне җыештырды, ул юри Яһудинга күтәрелеп карамады, гомумән, күрәсе килми иде аның бу кешене. Котбыйның кисәк икеләнә калуы, китми торуы Кәримәгә көч өстәде. «Куркасың, Котбый, куркасың»,— дип уйлады ул летучкага җыенганда.

— Миңа летучкага, Яһудин, сезгә иртәгә хәтле уйларга вакыт бирәм. Мәгез повесткагызны, эшегездә кая булдыгыз дип сораулары бар.

Кәримә ишеккә юнәлде, Котбыйны алдан чыгарып, кабинетын бикләде.

## 18

Үз-үзен гаять дәрәҗәдә горур тоткан Зөлфия апасы аның янына үзе килде. Летучкадан соң кабинетына юнәлгән Кәримә, коридорда боегып кына басып торган апасын күрде дә, аптырап китте. Зөлфия күп сөйләшмәс, бер-бер нәрсә турында сорасаң: «Оныткanмын, кайчан булды соң ул хәл?» — дип сорар, әмма җыр текстларын җиде төн уртасында уятып сорасаң да төп-төгәл әйтеп бирер иде.

Кәримәне күрү белән ул сеңлесенә ияреп кабинетка керде.

— Мин хәзер генә Бәхтиярда булдым,— диде кабинетка керер-кермәс апасы. — Ул, бичара, читтән торып университетта укый икән бит. Диплом язып ята. Ул мине шундук таныды.

Кабинетка керүгә, Кәримә өстәл өстендәге кәгазьләрне тартмага

салды. Зөлфиянең карашы иң элек тәрәзә төбендәге роза гөленә, аннары стена буендагы артлары шомарып беткән иске урындыкларга төште. Апасына кабинеттагы җиһазлар ошамадымы, шундук аскы ирене бүлтәеп чыкты. Боларның барысын да искәреп торган Кәримә үз алдына елмаеп куйды һәм апасына шул урындыкларның берсенә утырырга ишарә ясады.

Апасының йөзендә, нәзек-зифа гәүдәсендә, коңгырт-яшькелт күзләрендә, өстендәге ак свитрында, алдан сәдәфләр белән эләктерелгән ерык джинси юбкасында — гомумән, үз-үзен тотышында ниндидер ясалмалык бар иде. Зөлфияне бер күрмәгән кеше аны нәкъ менә шулай дип табигый кабул итәр иде. Ләкин апасын Кәримә артыгы белән белә. Зөлфия балалар бакчасыннан ук сәхнәләргә чыгып җырлады, аңа гөр килеп кул чаптылар, ул һәрчак халык игътибарында, халык күз алдында булды. Ул, гомумән, үз-үзен бик иртә артист итеп тоя башлады. Артистлану аның канына сеңгән иде инде. Кай вакытта Кәримә шикка кала иде: уйныймы апасы, я булмаса аның белән чын-чынлап сөйләшәме? Бәхтиярга кергән, җитмәсә...

— Хәзер генә мин кемне күрдем дип беләсең?

— Котбыйнымы?

— Әллә инде чакырып сораулар да ала башладың? Беләсең килсә, миңа бер грамм да җәл түгел ул... Ә, ни, Бәхтияр болай ничего. Күзләрен күрсәң син аның. Шундый итеп елмая, бит очларына мәхәббәт чокырлары куна. Әнисе кайтып керде, бергәләп утырып чәй эчтек. Сабый чакларын искә төшереп алдылар. Ә минем күз алдымнан Казанка буенда булган хәл китмәде. Күзләренә карыйм да тәнем чымыр-чымыр итеп куя. Ә бит мин аның алдында гаепле.

— Апа, Котбыйның әтисе Сирай Яһудин безнең әтине үтергән кеше икәнен беләсеңме әле син, юкмы?..

Зөлфия күзләрен зур ачып, бер мизгелгә тәмам телсез калды.

— Кит аннан! Әйтәм аны, әтиең кая дип бер тапкыр сорагач, Себергә вербоваться ителеп китте дигән иде, әнә ничек икән ул,— Зөлфия торды, башын чөя төшеп басты.— Мин аның белән араны күптән өздем инде, апаем... Кара син аны, ялганчы...

— Ул синең белән йөргәндә әтисенең безнең әтине үтергәнен белгән иде микән?..

— Юктыр, юктыр... — диде Зөлфия.

Кәримә апасына кайтарып дәшмәде, аңа ачулы күңелен бушатырга вакыт бирде. Бәләкәйрәк, карсак гәүдәле, киңчә җилкәле, бер-берсенә якын утырган кечкенә күзле, әрсез карашлы Котбый биредә үзе булса нәрсә әйтер иде икән апасы?..

— Ә хәзер, апа, бар кайт. Минем эшем бар. Миңа тагын бер шаһит киләсе.

— Барыймы?! Димәк, синең дә...

Кәримә апасына шундый иттереп карады ки, Зөлфия ачкан авызын яба алмый тотлыгып калды.

— Бар инде, кайт. Ишетәсеңме, апа!

— Беләсең килсә, Хәлилне зрә чыгардың.

— Мин чыгармадым аны, майор Хаков рөхсәт биргән. Инәки үзе килеп үтенгән.

— Беләсеңме ни ди шул Хәлил миңа беркөнне. Юлия Борисовна байлыгын кемгә калдырыр икән, ди. Билләһи менә. Казанда берәүдә дә юк аңардагы кебек байлык, ди.

— Кем әйткән, каян белгән. Юк сүз бит бу. Дөрес, Юлия Борисовнаның әти-әнисеннән калган алтын әйберләре бар, ләкин...

— Мин дә әйтәм бит, нигә кирәк ул аңа. Җен ачуларым чыкты үзенә. Нәрсә ди бит әле, сиңа байлыгын васыять итеп калдырса, миңа да өлеш чыгарырсың әле, Зөлфия кызым, ди. Шул сүзен ишеттем дә җир

тишекләренә керeп китәрдәй булдым. Бер дә бүтән түгел, бу турыда аңа инәки сөйләгән, тел төбеннән шуны аңладым...

Болай да күңелен болгатып торган бу хикәят Кәримә күңелендә үги әтисенә карата коточкыч чиркану хисе уятты, ләкин хәзер ул турыда сөйләшәсе килми иде аның.

— Барысын да яздыңмы?

— Әйе, Барый турында да.

— Бар инде, кайт!

«Менә ачыла да башлады,— дип уйлады Кәримә, өстәл янынnан торып, апасын ишеккә кадәр озата килде.—Хәзер Барый килеп керер». Зөлфия артыннан ишекне япкач, Кәримә бер ноктага карады да уйга чумды. Уйлары әкрен генә үз урыннарына утыра бара иде. Кәримә балачагында кубикларны тезеп төрле җәнлек сурәтләре чыгарырга ярата иде. Кубикларны дөрес җыймаганда куян койрыгына я төлке койрыгы эләгә, я арслан башы. Ә инде барысы да тәгәл җыелганда шундый куанып иде. Хәзер дә ул гүя күңелендә шундый кубикларны тезеп ниндидер ачык сурәт табарга тырыша иде. Бәхтиярны кыйнаучыларны ачыклавына Кәримә шикләнми иде. Менә апасы барысын да язып китергән, Котбый булып китте, хәзер Барый килеп керер. Ул нәрсә әйтер, Котбый кебек үк барыннан да танса?.. Юк, ул андый түгел, Барый танмас. Ул барысын да сөйләп бирер. Әмма нәкъ менә шул хәлдән курка иде Кәримә. Ул һаман ниндидер могҗизага өмет итә: йөргән егете ул компаниядә булмагандыр кебек иде. Их, Барый, Барый!.. Ярый, хәзер офтанудан ни файда. Әдәп саклау йөзеннән мин аңа башта ни өчен чакырылуы турында әйтмәм... Кәриманең Барыйга булган мәхәббәтен тиз генә югалтасы килми иде. Күңелеңә шулай якын булган кешедән ничек сорау алмак кирәк. Сине ихлас күңелдән эчкерсез яраткан, сиңа карата гаять дәрәҗәдә игелекле, тыйнак һәм сөйкемле булган Барыйдан...

— Мөмкин булырмы?

Кәримә ялт итеп артына әйләнеп карады, ишектән Барый керeп килә, иреннәрендә, күзләрендә Кәримәгә генә аңлаешлы булган үз итеп елмаю. Кәримә дә ихтыярсыз аңа елмайды.

— Әйдә, уз, утыр!

— Утырырга кушкач, утырырбыз, нигә утырмаска,— диде Барый һәм стена кырындагы урындыкларның берсенә чүмәште.— Повесткалар белән генә чакыра башлады бераү.— Үрелде, кул бирде, кызның кулын җибәрми торды.— Бер-бер хәл булдымы әллә, Кәримә? Кичә Котбыйның әнисе кергән, инәйгә әллә ниләр сөйләп бетергән. Эштән кайтып керүем булды, инәй миңа ябырылды. Имеш, мин сине рәтле кешеләр белән йөрисең дип торам, син анда кеше кыйнап йөрисең икән, ди. Кемне кыйнадың, иблис токымы! дип бәйләнде. Барысы да кылт итеп исемә төште. Булган иде андый хәл... Бик күптән бит инде ул — яшьлек җүләрлеге...

«Булган иде,— дип авыз эченнән кабатлады Кәримә.— Булган иде. Бүгеннән соң, Барыйҗан, син безнең арадагы мәхәббәтне «булган иде» дип сөйли башларсың. Явызлык кылгансыз икән, ул беркайчан да җирдә ятмый, Барыйҗан, көне белән аякланып, халык арасында йөри башлый, синең шәүләңә әверелә»

Барый сөйләде, Кәримә аны тыңлады да, тыңламады да. Аның күз алдына бөтенләй башка нәрсәләр килде. Бер тапкыр аны Барый йөз метрга якын кулында күтәреп барган иде. «Уф,— диде Барый аны кулыннан төшереп.— Авырсың икән бит син, Кәримәкәй». Кәримә аңа шунда: «Яраткан кешең авыр буламы, җүләрем»,— дигән иде. Барый аны кочагына алды һәм җил-афәттән сакларга теләгәндәй тынып калды. «Бөркет кара карлыгачын канат астына алды»,— дигән иде ул. Шул чактагы куанычны, бәхетне кире кайтарып булса икән. Кәриманең хә-

теренә шигырь юллары төште: «Нишләтим инде сине, эх, йөрәк, йөрәк, йөрәк?!»

— Барый,— дип урыныннан кузгалды Кәримә.— Син беләсеңме моның ни белән бетәсен?! — Кәримә Барыйга туры карарга курыкты.

— Мин үз хәлемне яхшы аңлыйм, Кәримә. Мин гаепле. Яшьлек хатасы.

— Ә бит хатасыз яшьлекләр дә була, Барый. Бит сине хөкем итәчәкләр, өмет итмә гафу итүне, Барый!

Тавышы сабыр, басынкы, йөзе җитди иде Кәримәнең. Ул Барыйга туры карамады. Шул вакыт ишекне кактылар. Кәримә җәһәт кенә өстәл яныннан кузгалды, барып, ишекне ачып кем беләндер сөйләшеп алды. Әйләнеп өстәл янына килде, кәгазьләрне җыештыра башлап, Барыйга күтәрелеп карамый гына:

— Мине чакыралар, ничек булган, барысын да язып, иртәгә сәгать дүртләргә китерерсез, иптәш...

Кәримә исенә килеп, күтәрелеп Барыйга карады. Егет аңа гаҗәпләнеп карап тора иде. Ул моңа ышанмый, хәер, ышанырлык хәлме. Аның бу карашын күргә, әрнүле ярату хисләре дулады Кәримәнең күкрәгендә, әмма һични кыла алмады. Иң яхшысы Барыйның күзләренә туры карамау, чыгып китсен, Кәримә менә шулай өстәлдәге кәгазьләрне җыештырып маташканда, тизрәк чыгып китсен иде.

Ишек ачылып ябылды. Кәримә авыр сулап куйды. Эчендә әрнүле хафа уты яна. Аның йөгереп чыгып Барыйны туктатасы, туктатасы да кире алып керәсе, мин хәзер әйләнеп керәм, дип кабинетында калдырасы килде, шул ук вакытта аның бу бинадан тизрәк чыгып китүен дә теләде.

## 19

Озын буйлы, көрәк сакаллы, коңгырт чәчле, җылы тире белән эчләтелгән плащ кигән Себер егете майор Хаков кабинетында утыра, Хаков үзе юк.

— Гафу итә күрегез, коллега, эшегезне бүлдердем бугай, саумысез! — кул бирде, күрештеләр.— Утырыгыз, Азатова. Минем алдан кул бирүемә шаккатмагыз. Гадәт. Мин Себер кешесе, безнең якта кем алдан кул суза, шул сине каршы ала, кунак итә. Менә шул. Кунак итеп булмас, вакыт тар. Хикмәт менә нәрсәдә, Азатова. Серый Казанда. Кайтып җиткән. Серый эзне җуя белә ул. Серыйның Дербышкида яшь хатыны булган, ләкин Серый төрмәдә утырганда ул кияүгә чыга, бер баласы бар инде. Миңа калса, әйбәт кенә яшәп яталар. Хатын үткәне өчен үкенә, яшь иренә әйтергә кушмады. Килеп чыкса-фәлән, хәбәр итәргә булды. Килештек. Бу турыда, әлбәттә, Серый ишеткәндер, я кем аша булса белгәндер. Аңа бердәнбер чара кала: беренче хатыны. Беренче хатыны бер үзе тора, малае зур инде, эшли. Исеме Котбый бугай.

— Ул кеше кыйнаган, без аның өстеннән эш кузгаттык. Мин алып барам ул эшне.

— Димәк, алма агачыннан ерак төшмәгән. Бу мәсьәләдә безгә бабаң ярдәм итәргә булды. Яһудин хатыны янына кайтмый булдыралмас. Кыскасы, бабаң Яһудиннар өен күздән яздырмаска булды. Сез дә аңа ярдәм итсәгез иде. Беренчедән, бүгеннән коралсыз йөрмәгез, икенчедән, Серый күренү белән безгә хәбәр итәргә тырышыгыз. Сезгә йомыш шул иде, коллега.

*

* *

Тәрәзәгә кагыла
Акрын гына...
«Кем икән бу!» — дисәм,

Җил икән,
Йомышы бардыр, бәлки?
«Әйтим микән... юкмы?..» ди микән.

Кәримә күптән түгел олы шагыйрьнең автор кичәсендә булды. Ап-ак чәчле, күрү белән үзенә карата ихтирам уята торган, җил чыкса, очып китәрдәй чандыр, юка гәүдәле сиксән яшьлек өлкән шагыйрь үзенең самими, мөлаем кыяфәте белән генә түгел, ә йөрәкне тетрәтердәй шигырьләре белән әсир иткән иде. Кичәдән соң Кәримә аның җыентыгын сатып алды һәм кайту белән әбисенә, бабасына шагыйрьнең шигырьләрен кычкырып укыды. Әбисе күз яше белән елады, бабасының күзләре яшь пәрдәсе белән томаланды. Кәримә үзе дә шул халдән соң менә танга кадәр йоклый алмый ята. «Әллә ничек үтте гомер: туйганчы күрешмәдек тә...» Әнә бит ничек әйтә олы шагыйрь, эх, Барыйҗан, Барыйҗан.

Таң атып килә. Башта һаман шул бер уй. Бүген, ниһаять, Бәхтиярның эше төгәлләнде. Дело начальник өстәлендә ята, тиздән ул аны прокурорга тапшырыр, тегесе үз чиратында хөкемдарларга бирер. Күп тә үтмәс, Котбыйны да судка чакырырлар, Барыйны да, Чаллыдагы адәмнәрне дә хөкем итәрләр.

Тикшерү барышында Котбый соңгы көнгәчә: «Мин анда булмадым, алар булгандыр, мин булмадым»,— дип барды. Әмма Зөлфия дә раслагач, теге өч егет тә кыйнадык дип чишелгәч, Котбыйга дөресен сөйләүдән башка әмәл калмады. Теге ике егет Чаллыда эшлиләр. Берсе шәһәр телефон челтәре станциясендә инженер, икенчесе КамАЗда АСУ корып ята икән. Анысы өйләнгән дә икән инде. Малайлары туган һәм нәкъ шул көннәрдә аңа Казаннан повестка килеп төшә... Әйе, яшьлек хатасы бик кыйммәткә төшәчәк яшь атага, дип уйлады Кәримә. Барый исә күп сөйләшмәде, әйе, булды андый хәлләр дип кенә утырды. Егетнең җинаятьче буласы килми иде. «Ә теге вакытта, Котбый котырткәнда, нигә каршы төшмәдең ярсу тилегә?! Син бит аңардан көчлерәк, гәүдәлерәк, сөйкемлерәк, кешелеклерәк булгансың, Барыйҗан. Шулай да соңгы чиктә ихтыяр көчең җуйгансың. Хәзер менә сөйгән кызың алдында җавап биреп утыр инде. Әйе, оят, бик-бик оятлыр сиңа хәзер, Барый».

Егетләрнең дүртесен бергә җыйгач, Кәримә үзенә күрә бер сынау ясады. Өстәл эчендә магнитофон калдырды һәм чыгып китте. Соңыннан ул язманы тыңлады. Сүзне Котбый башлады.

Котбый: «Җебегәннәр. Ахмаклар, диваналар! Тансагыз ни була иде. Биш елдан артык гомер үткән!.. Зөлфәне ул егет кичерәчәк. Ни өчен ул әлегәчә дәшми килде?.. Без тиләләрне коткару өчен! Ә син, син, Барый, нишләдең тагын! Тикшерүчебез — йөргән кызың. Гозерләп сораган булсаң, иртәгә үк өйләнәм дигән булсаң, ни булыр иде! Ләббәккәйләр сез, пешмәгәннәр! Туктата да ала иде бит ул эшне! Ә бер ябылган эш, вакыт узу белән бөтенләйгә кала!»

Димка: «Болгатып утырма әле, Котбый. Мин аңа үз кулым белән суктым. Моның өчен мин җәзаны биш ел элек алырга тиеш идем».

Котбый: «Тиле дигән саен тиганәк буе сикереп утырма әле, Димка, җебеп!»

Барый: «Син имгәтүче аны, Котбый. Тимер башлы туфлиң белән син аркасына тибүче. Безнең беребез дә аңа имгәтерлек итеп сукмадык, түгәрәктән чыкмасын өчен төрткәләдек кенә.

Котбый: «Мин дә аңа имгәтәм дип типмәдем»,— дип акланырга маташты.

Хәйри: «Туктагыз, соң инде. Нигә ачыклап торырга. Сез әүвәл минем хәлемә керегез. Эш урныма ни әйтерләр, рәсемемнең мактау тактасыннан төшкәне булмады. Бу хурлыкка ничек түзмәк кирәк!»

Котбый: «Кыланып утырган булма».

Хәйри: «Замолчи, Котбый! Мин өйләнгән кеше, балам бар. Повестка килеп төшкәч, хатынның коты алынды. Ни эшләдең син анда, ди. Покыдан калдым. Дөрес әйтә Барый, безне котыртучы син, Котбый! Син аңа тибүче һәм син аның арка сөяген имгәткәнсең әнә. Без бит алай ук булыр дип уйламаган да идек...»

Котбый: «Шәп сиптерә бу. Мин котырткан һәм ул котырган. Бәлкем синең психикаң нормаль түгелдер... Мин котырткан һәм ул котырган, имеш. Нәрсә, мин әллә синең кулыңнан тотып суктырдыммы аңа, мать якаңны! Юктыр бит?!»

Хәйри: «Каберең якын булмасын бу кешегә».

Котбый: «Кайгырма, мин Чаллыга барып үләсе кеше түгел».

Хәйри: «Күрегезче, коточкыч кеше бит бу. Ничек без аны элек белмәгәнбез».

Барый: «Җитте! Туктагыз! Безгә анда ничә яшь иде? Исегезгә төшеримме әллә! Шулай булгач... Зур җавапсызлык эшләдек без биш ел элек, мәңге онытмаслык явызлык кылдык. Мин тагын кабатлыйм, бу эшне башлап җибәрүче, Котбый — син!»

Котбый: «Мин! Ә син кая?!»

Барый: «Икейөзле кешеләр була. Бу — шул. Без аны яшьлегебез белән күрмәгәнбез, менә хәзер барысы да ачылды».

Котбый: «Тинтәк син, Барый. Тинтәк булдың һәм тинтәк булып дөнья да куарсың. Беләсең килсә, син утыртучы безне, син башлап сөйләгәнсең аңа! Азатова артыннан биш ел килеп сардың. Булдымы соң хет?.. Юктыр, булдыра алмаганга утырта ул сине, тинтәк!»

Барый: «Котбый, мин сине хәзер үтерәм. Менә шунда, тикшерүче кабинетында. Шаһитлар бар. Мин моның белән кыйналган егет алдында изге бурычымны үтәячәкмен, ышанасыңмы, Котбый?!»

Димка: «Барый, Барый дим, буялма!»

Котбый: «Сине моннан чыгарырлар дип уйлыйсыңмы, кабак бит. Тот капчыгыңны. Кемгә китте дип беләсең тикшерүчене?.. Машина заказать итәргә. Моннан сине конвой белән озатачаклар. Ә мин синнән курыкмыйм, Барый, курыкмыйм. Теге вакытта үзең кыйнаган егетне яклый алмаган кебек, миңа да кагыла алмаячаксың. Ихтыяр көчең сыек. Ярпач син, калай әтәч! Синдәйләрне абзаң күп күрде инде».

Барый: «Котбый, тагын бер дәшәсең икән, мин сине беләмсең нишләтәм».

Хәйри: «Яһудин, ул түгел, мин сине хәзер!»

Котбый: «Ну вот, тагын берәү табылды».

Дөбер-шатыр бар да кузгалды. Шул чак кабинетка Кәримә килеп керде.

— Менә нәрсә, әтәчләр,— диде ул Котбыйның изүеннән тоткан Барыйга карап.— Сезне конвой белән озатырга туры килер. Судка кадәр бераз ял итәрсез. Прокурор кул куйды, эш хәзер миннән китте. Бер киңәш сезгә...

Ишектә ике милиционер күренде, форма кигән таза ике егетне күргә, ир-егетләр шундук сүрелделәр. Кәримә милиционерларга ишарә ясады, тегеләр кереп, дүртесен дә алып чыгып киттеләр. Кәримә тиз генә өстәл янына үтте, магнитофонны ычкындырды. Тикшерү практикасында магнитофон куллану тыелмый иде, шулай да роликны әйләндереп, егетләр арасында сөйләшүне тыңлаганда ул үзендә ниндидер уңайсызлану тойды.

...Сорау алу, эшне ачыклау кыен булды димәс иде Кәримә, ә шулай да күңел түренә гүя ачуташ салганнар, аның йөрәге Барый өчен әрнешә иде.

## 20

Хәлил Гөлбикәнең изгелеген онытмады. Милициядән чыгаруга, артыннан гел күләгә булып йөрде. Әмма юллары вино магазинына житкәч, ирнең тәмам буыны бетте, йөзе-күзе алышынды.

— Ни булды сиңа, әллә хәлең беттеме? — дип әйләнеп сорап куйды Гөлбикә. Хәлил кибеткә таба ым какты, җиргә сеңәргә теләгәндәй, хәтта буйга кечерәеп, озын муенын кыршылып беткән пальто якасына җыера төште.

— Гөлбикә, бәгырь, кер хәлемә, тик торганда үтермә Хәлилеңне. Күрмисеңмени?..

Хәлил буыннары кантарланып, күгәреп калган кулларын Гөлбикәгә сузды.

— Нәрсә тагын?

Моны хатын юри сорады, ирнең ни соравын белә иде ул һәм ни өчен туктап калуына да күптән төшенгән иде, әмма нидер өмет итте, Хәлил монда калмас, иярепөйгә кайтыр, дип өмет итте.

— Гөлбикә дим, бәгырь. Үтермә, бир бер өч сум, һич югы ике сум, акчаң аз калган булса, бер сум да җитәр, бәлкем...

— Башта өйгә кайтасың. Ишеттеңме! Бер грамм да эчмисең.

— Эч-мим, бер грамм да эчмим,— диде Хәлил колагын угалап.— Ант итеп әйтәм, эчмим. Бакыр Фатихтан ике сум акча гына аласым бар иде. Ну, әҗәткә биреп тордым, ә ике сум җирдә аунамый... Ниемә эчим соң, менә кара,— Хәлил пальто һәм чалбар кесәләрен әйләндереп чыгарды. Ипи менә, эчмәячәкмен, бәгырь... Аннары кибете дә ачык түгел әле аның.

Гөлбикәгә кисәк оят, бик оят булып китте. Әйбәт-ыспай гына киенгән хатын йөзе-күзе таушалып беткән, өсте кыршылып, өтәләнеп калган кеше белән гастрономнарда янәшә йөрүенә кайта-кайта гарьләнде. Беренче тапкыр Хәлилгә ул ят бер кешегә караган кебек карады. Бу кеше аның күңелендә кызгану түгел, ә чиркану хисе уятты.

— Кал! — диде ул бер сүз белән. Ләкин шул «Кал!» сүзенә хатын шундый мәгънәле интонация салды ки, инде туктап калган ир кисәк кенә икеләнә калды.

— Гөлбикә, мин момент, хәзер, теге, шул Бакырдан ике сумымны гына алам да... Тик син бер сум булса да...

Гөлбикә тротуарга бер сум көмеш ташлады, акча чылтырап асфальтка төште һәм бераз тәгәрәп барды, гаҗәбе шул булды: кибет ягына ташланган акча, кире борылып, Гөлбикәгә таба тәгәри иде. Хәлил аны, балык каптыручы чикерткә тоткан кебек, мескен бүреге белән каплады. Гөлбикә китеп бара иде инде, ул янә ирнең шулай кылануын күреп, җир тишегенә кереп китәрдәй булып гарьләнде. Үзе китү ягына таба атлады, ә үзенең аяклары кире тартты. Кемдер аңа: «Гражданка, деньги уронили»,— диде. Аңа каршы Хәлил нидер сукранып калды.

Гөлбикә йөгерә-атлый кибет тирәсеннән тизрәк китеп барды, чатка җитте. Шмидт урамына борылды. Артына әйләнеп карарга оялды ул. Хәлил аның артыннан куа киләдер сыман иде.

* * *

Хәлилдә бүген бары тик бер кайгы — йөз грамм булса да эчеп алу кайгысы иде. Аның уч төбендә бер сум акча җылынып ята, ләкин бер сум ни ул — хәтта кызылга да җитмәячәк. Димәк, кем беләндер кушылырга кирәк булачак. Анда инде шешәгә син генә хуҗа түгел. Дөрес, Бакырчы Фатихтан ике сум аласы бар, тик булырмы ул бакырчы бүген биредә?

Хәлил, бер сум көмешне уч төбенә кыскан килеш, кибет ишеге янында басып тора. Ачылырга ун минут кала, ишек каршына аның кебек кичтән эчеп, иртән баш төзәтергә килүчеләр җыела башлады. Хәлил аларның күбесен белә.

Шулай да бүген Гөлбикәне ничек булса да куандырасы иде. Күрдә бит Хәлил, хатын яман ачуланды. Хәзер ничектер юмаларга кирәк үзен... Торт тапсан икән ул. Торт ярата Гөлбикә, торт алып кайтсаң, гел балалар кебек куана. Әмма бер сумга ни аласың инде...

Хәлил ишек каршында басып торганнарга күз йөртеп чыкты. Юк, рәтле кеше күренми. Әнә бер музыкант тора торуын, ләкин ул Хәлилгә аркасы белән баскан, кулында скрипка футляры, башында киң читле эшләпә. Юк, бу безнең кебек кушылып эчүчеләрдән түгелдер; я кунак килгән үзенә, я... кыскасы, нужа китергән моны кибет каршына. Әшулай да гәүдәсе таныш кебек. Кем булыр икән? Әлек бу кибет тирәсендә мондый гәүдәле кешене күргәне юк иде аның. Таныш та кебек үзе.

Кибет ишеге ачылуга, барысы да шунда таба ябырылды. Хәлил ашыкмады, ул көтте, барысының да кибеткә тулганын көтте. Ярата иде чиратта торырга, аның өчен бу үзенә күрә бер бәйрәм иде. Кулындагы бер сумны Хәлил тагын да кыса төште. Шул чак эшләпәле кеше ишеккә таба кузгалды. Хәлил аны якыннан күргәч шым булды, аңа таба, ягъни ачык ишеккә таба Сирай абзыйсы килә иде. Ә бит аны Гөлбикәнең ирен үтергән өчен утыртканнар иде. Исеме Хәлилнең авылдашларын гына түгел, Казан халкының да котын алган Сирай абзыйсы атлый иде аңа таба.

Сирай, әлбәттә, аны танымады, ничек танымак кирәк, кыяфәте кыяфәтмени хәзер Хәлилнең. Теге вакытта базарда очрашканда Хәлил чәчрәп торган сөлек кебек егет иде. Берәр дефицит әйбер китердеңме, Сирай абзасы уч тутырып акча бирер иде. Их, шул чорларны кире кайтарып булса икән!..

— Сирай абзый,— диде Хәлил.

Сирай башта аңа өстән генә карап алды, аннары таныды бугай, җиңеннән элэктереп, бер читкә алып китте.

— Хәлил! Хәлил бит син, билләһи! Күр әле моны, нишләттеләр сине, ни булды сиңа?.. Дәш, миңгерәүләндеңме әллә?..

Я хода, таныш тавыш, Сирай абзыйның тавышы, шулай ук көр, гайрәтле, кыю.

— Сирай абзый! Синме бу? Син исән?!

— Чертым булсынмы миңа! Әйдә сыраханәгә. Монда мине күзәтүләре бар. Хәлем турында сорашма. Соңыннан. Мәйле?

Сыраханәдә халык юк диярлек, түр як өстәл янында ике яшь егет кипкән килька белән сыра эчәләр. Сирай сыра ташучы егетне бармак изәп кенә чакырып алды.

— Бер ярты, дүрт кружка пиво. Мә!

Егет, бездә аракы сатылмый дип, авызын ачкан иде, Сирай аның уч төбенә егерме бишлекне салды.

— Сдача кирәкми. Тиз эшлә. Да, кабарга китер. Бармы берәр рәтле закуска...

— Табармын,— диде егет һәм китеп барды. Бераздан ул дүрт кружка сыра китерде, аннары газетага төреп ярты төртте. Сирай скрипка футлярын өстәлгә куйды, ачты, футляр буш иде, яртыны шунда сыдырып төшерде.

— Футляр шәп икән,— диде Хәлил Сирайга карамый гына.— Кем уйлаган анда аракы йөртеп булыр дип.

Залга тагын берничә кеше килеп керде, алар акрын гына түр яктагы өстәлләргә уздылар. Сирайны күрүгә, берсе кисәк тукталгандай итте, ләкин шундук иптәше белән кычкырып сөйләшергә тотынды.

— Эч тә, әйдә, китәбез,— диде Сирай.— Эш күп минем...

Алар урамга чыктылар, Сирай аны култыклап алды.

— Теге вакытта, Хәлил, мин сиңа өч йөз сум акча биргән идем, әҗәткә дип. Хәтерендәме, әллә оныттыңмы?

— Минем бер тиен дә акчам юк, Сирай абзый.

— Табарга туры килер, Хәлил. Син мине беләсен... Нужа кумаса, сорамаган да булыр идем. Мин бит беләм, син үзең эшләмәсәң дә, хатының, ике кызың эшли. Берсе хәтта тикшерүче дә икән. Хакмы шул?..

— Барысын да беләсең тагын, Сирай абзый.

— Һә, Сирай абзаңны кем дип белдең син. Менә тагын нәрсә, минем күптән күз төшеп йөргән бер карчык бар. Белүемчә, ул сезнең күршедә яши иде. Исәнме шул карчык?

— Ни булсын аңа, җен кебек йөри,— диде Хәлил, җанланып китеп, кружкада калган сыраны эчеп бетерде, аннары ишарә белән генә Сирайга дәште.— Беләсеңме, Сирай абзый, аңарда байлык...

— Һәй,— диде Сирай официантка, Хәлил әйткәнне ишетмәмешкә салышып.— Карале, егетем, китер әле җүнлерәк әйбер ашарга. Менә бу минем энекәш, корсагы ач, аңладың? Ә ач кешенең ачуы яман була.

— Минем карным ач түгел, Сирай абзый, сыра эчкәч гел ашыйсы килми башлады.

— Менә сиңа мә. Алкашмы әллә син. Алкашлар эчкәч ашый алмый. Сәламәт кеше, эчкәч, бүре башын ашардай ач булырга тиеш... Алып бар син мине теге карчыкка кунакка. Минем аңа йомышым бар. Музыкант мин, ә ул артистка булган кеше. Килештекме?!

— Ни бит, Сирай абзый...

— Ни түгел, кузгалдык.

Официант ике порция тавык китерде.

— Мә, аша. Тукта, без аны кәгазьгә төрәбез дә... кирәге чыгар әле...

Сирай тавык кисәкләрен төреп, футлярга салды.

— Ә хәзер киттек.

— Ну, ни бит, Сирай абзый...

Сирай өстәлгә ята төште, Хәлилнең колагына пышылдады.

— Син аны беләсең?... Белгәч, менә нәрсә: мин музыкант, ә син аның күршесе, алып керәсең мине аңа... Минем вакыт тар, уловил?

— Карале, Сирай абзый, әйбәт килеп чыкмас бит. Аннары мине яратып бетерми ул, әллә ни уйлавы бар...

— Уйлый бирсен. Әйдә. Юл өстендәге бер магазинга кереп бер кап торт, конфет, чәй, бер савыт кофе алабыз...

— Ну, Сирай абзый, ни бит инде...

— Менә сиңа акча,— диде Сирай сыраханәдән чыккач.— Мә-мә, ал, монда җитәрлек. Әнә теге гастрономга керәсең һәм мин әйткәннәрне аласың. Юк икән, директорга кер. Музыкант иптәшемнең туган көне диген, тап сәбәп, уловил?..

— Әллә ничек, Сирай абзый. Аяк тартмый минем анда.

— Хәлил! Син мине беләсең?!.

Хәлил теләр-теләмәс кенә гастрономга кереп китте, бераздан ул Сирай кушкан әйберләрне күтәреп килеп тә чыкты.

— Менә Казан торты бирделәр. Чәй дә, кофе дә, конфет та булды.

— Һо, син артист икәнсең бит, Хәлилҗан. Шул арада...

Подъезд янына җиткәч, Хәлил янә икеләнә калды. Кара сакал үстереп җибәргән, киң читле эшләпә кигән, кулына скрипка футляры тоткан Сирайны Хәлил әле генә күргәндәй, ни өчен Юлия Борисовналарга кереп баруларын аңларга теләп, туктап калды.

— Ишетәсеңме,— диде Сирай, тешен кысып, Хәлилнең беләгеннән әләктерде.— Ишетәсеңме, тинтәкләнмә, Сирай ике сөйләми. Тәвәккәллек — таш яра, ә син пешмәгән нәмәстә кебек атлыйсың.

— Пөрәк калтырый минем, күкрәк кыса. Элек эчкәч ачылып, күкрәкләр киңәеп китә торган иде. Салып бир әле футляреңдәген.

— Рюмка юк, авызыннан эчсәң генә инде...

Сирай тиз генә футлярдагы яртыны чыгарды, теше белән каерып калай бөкене ачты.

Хәлил шешәне Сирай кулыннан алды, күтәреп, берничә тапкыр уртлап кире бирде.

— Менә рәхмәт, Сирай абзый.

— Эч тагын.

— Житте, Сирай абзый. Беләмсең, сразу башка шаулап китте. Хәзер әйдә.

Сак кына өченче катка күтәрелделәр. Хәлил түр яктагы ишеккә күрсәтеп ым какты.

— Кыюрак,— диде аңа Сирай.— Бас звонок төймәсенә. Шулай...

Хәлилнең сул кулында торт тартмасы, чәй, кофе, бер кап конфет. Ишек ачылуга, эре роза чәчәкләре төшкән халат кигән ап-ак чәчле Юлия Борисовна, ишекнең чылбырын җибәрми генә ярыктан карады. Ул, әлбәттә, Хәлилне таныды, аптырабрак китте, ләкин аның кулында торт күргәч:

— Гөлбикә өйдә юкмы әллә? — диде, һични аңламый.

— Өйдә юк шул, Юлия Борисовна. Ни, бу күчтәнәчләр сезгә, минем музыкант иптәшем... Аның бүген туган көне...

Карчык саклык чылбырын ычкындырды, ишекне киереп ачты, Хәлилне, аннары үзе белән исәнләшеп өлгергән Сирайны коридорга уздырды. Коридорга килеп кергәч, Сирай скрипка футлярын тумбочка өстенә куйды да Юлия Борисовнаның кулын үпте, музыкантның бу кыланышына карчыкның хәтта бит очлары алсуланып китте.

— Рәхим итегез,— диде ул, алдан түр якка таба кузгала башлап.— Түрдән узыгыз.

Сирай торт һәм башка күчтәнәчләрен Хәлил кулыннан алды һәм аның артыннан кузгалды. Хәлил тиз генә футляр савытын ачты һәм шешәдә калган аракыны эчә башлады. Аннары тиз генә шешәнең бөкесен тыкты да, кире футлярга куйды. Шешәне футлярдан кире алып кесәсенә салды.

Ул арада торт тартмасын тотып коридорга Сирай әйләнеп тә чыкты.

— Хәлил,— диде ул, сулышына кабып.— Хәлил, чишенмә. Ки пальтоңны. Киттек. Карчык бүген кабул итми, иртәгә килербез.

— Ни бит инде, Сирай абзый, шулар белән генә чәй эчик...

— Тиз бул диләр сиңа, кибәк баш!— Сирай аңа җәһәт кенә пальтосын кидерешә.

Сирай тортны, скрипка футлярын кулына алды, шунда ул Хәлил кесәсеннән башы күренеп торган яртыны күрде, аны сиздерми генә үз кесәсенә алып салды. Бу хәлләрне ул шул хәтле тиз башкарды ки, баскычтан түбән төшә башлаган Хәлил берни дә сизмәде.

— Миннән калма,— диде Сирай алга чыгып.— Ишетәсеңме, Хәлил, бер адым калма.

Беренче булып, ишегалдына Сирай килеп чыкты һәм уңга-сулга карап алды, ул чыгып килгән подъездга таба бер хатын-кыз килә иде, аны күргәч, Сирай киң читле эшләпәсен батырыбрак киде, тиз генә икенче подъездга юнәлде. Подъездга килеп кергәч, әйләнеп карады. Хәлил яңа чыгып килә иде.

— Син нишләп йөрисең тагын, мөртәт!..

— Ә-ә, Гөлем бикәм сылуым иркәм, син икәнсең. Мин, ни, бераз йөреп кайтам. Ну, һава алып, бигайбәме?

— Күземә күренмә!

— Әйтәм бит, Гөлем бикәм сылуым иркәм, хәзер кайтам дип, барып газеталар гына алам да.

— Олак, кайтып керәсе булма!

— Ярый инде, ярый, Гөлем бикәм сылуым иркәм, ачуланма берәүне

Гөлбикә кереп китте, Хәлил йөгерә-атлый күрше подъездга юнәлде. Анда аны тешен кысып, Сирай көтеп тора иде.
— Син нәстә югалдың анда, тинтәк! Әйдә тизрәк!

*
* *

Такси туктатмадылар, дөресрәге — Сирай туктатмады. Аз гына чайкала төшеп, Хәлил битараф бер рәвештә басып торды. «Жигули»га кул күтәрделәр.
Машина йөртүче яшь кенә егет, тегеләрнең кая баруларын сорады.
— Чыңгыз поселогына,— диде алга утырган Сирай.
— Шул якка,— дип кабатлады Хәлил, Сирай аның авызын каплады.
— Поселокка житәр-житмәс туктатырсың, егетем,— диде Сирай һәм алгы утыргычка биш сум акча ташлады.— Бусы сиңа бензин хакы. Бензин сезгә хәзер сөттән дә кыйммәткәрәк төшә бугай...
— Әйе,— диде машина йөртүче, утыргычтагы бишлеккә күз төшереп,— бәяне куя беләләр...
— Менә шунда туктат, без урман аша кайтабыз. Рәхмәт сиңа.
— Рәх-хмәт, туганкай,— дигән булды Хәлил дә машинадан төшкәч, кесәсенә кулын тыкты һәм шунда гына шешәнең юклыгын абайлады.
— Сирай абзый, шешә кая?
— Кычкырма, тинтәк. Әйдә.
«Жигули» борылып китеп барды, алар әрәмәлеккә таба атладылар.
— Әйт әле, Сирай абзый, нигә инде Юлия Борисовналарда чәй эчмәдек? Тортны кире алып чыктың. Бер дә егетлек түгел бу. Беләм, мин начар кеше, әшәке адәм, әмма мин дә...
— Молчи! Өтек этәч! Ишетәсеңме, атлавыңны бел! Беләсеңме кем син?..
— Кем мин, Сирай абзый, кем?
— Әрәм тамак, соры корт, бер сүз белән әйткәндә.
— Әһә, мин соры корт, алкаш, ә син кем буласың инде?
— Мин син түгел.
— Әйе, син мин түгел, син — кеше үтерүче!
Сирай кисәк борылды да Хәлилнең авызына сукты.
— Сөйли белмәгән авыздан...
— Хак әйтәсең, Сирай абзый,— диде Хәлил, авызындагы канны пальто җиңенә сөртә-сөртә.— Дөрес әйтәсең, мин настоящий әрәм тамак, соры корт. Әнә йөрим бит сиңа сатылып, әнә шул кесәңдәге арака өчен.
— Бик эчәсең киләме?..
Куе таллар арасына керделәр. Сирай пальтосын салды, җиргә ташлады, шунда кырын ятты, Хәлил пальтосы-ние белән янәшәгә ауды. Сирай кесәсендәге шешәне чыгарды, футлярны ачты, кәгазьгә төрелгән тавык итен алып Хәлилгә бирде. Хәлил торт савытына үрелде, әмма Сирай тортны үзенәрәк тартты.
— Тортны зрә кире алып чыккансың, Сирай абзый.
— Карчыкның әченә тиюе бар, төче ризык бар кешегә дә ярамый, туган,— диде Сирай.
Хәлил тәмләп тавык ботын кимерә башлады.
— Бәхет ни ул, Сирай абзый? Хатын миңа: «Син генә, мөртәт, мине бәхетсез итүче», ди. Ә мин әйтәм, бәхет ул ир-ат алдында бөтен нигъмәт-ризык булу һәм син дим. Ышанмый. Ю-юк, ышана, ышанасы килми. Бәхетне ул минем эчмәвемдә күрә, ә мин бәхетне эчүдә күрәм. Димәк, без бәхетне икебез ике төрле аңлыйбыз булып чыга. Ә менә

син ничек уйлыйсың, Сирай абзый? Менә син тикторганда минем авызга суктың, кан китте хәтта...

— Ахмак син, Хәлил. Беләсең килсә, эчә белү ул үзе бер хикмәт, эчә белмәү — диваналык. Дивана син, гомереңне аракыга саткан мескен. Сине бит яшь чакта Бүсер Хәлил дип ирештерәләр иде. Шулаймы, әллә мин ялгышаммы?.. Шулай дисең, әнә баш кагасың. Эчүче кешедән дә мескен кеше юк бу дөньяда.

Хәлил шаккатты, егет чакта аны чынлап та Бүсер Хәлил дип ирештерәләр иде. Сирай шуны онытмаган, каян белгән, каян ишеткән диген.

Сирай йокыга киттеме — күзләрен йомган да тынып калган. Хәлил торт тартмасына күз төшереп алды. Тукта, Сирай йоклый, менә шушы тортны алып Гөлбикә янына кайтып керсә...

Башына шундый уй килүгә, Хәлил шешәдәге калган аракысын бер читкәрәк этәреп куйды. Әйе, тортны алырга да өйгә таярга. Хәлилнең зиһене ачылып киткәндәй булды, ул тын алмый Сирайны күзәтте, сабырсызланды, тортны күтәреп, Гөлбикә янына кайтып керүе күз алдына килде. Имеш, Гөлбикә елмая, бер аңа карый, бер тортка... Ләкин торт тартмасына үрелүгә, кызган табага тигәндәй, кулын янәдән кире тартып алды Хәлил. Кисәк Сирайның уянып китеп, кулыннан тотуы, усал, үткер карашы белән: «Торт кирәкме сиңа, кабәхәт!» — дип янә авызына сугуы, авызыннан гөжләп кан китүе күз алдына килде аның. Хәлилнең куллары гына түгел, йөрәге, бөтен тәне калтырана башлады. Алай да ул акрын гына кузгалды, аяк астында чытырдап чыбык сынды, әмма Сирай күзен ачмады. Хәлил тын алырга куркып, баскан җирендә шым булды. Йоклыймы, йоклаганга сабышып ятамы? Хәлил янә хәйләгә керешә, үлән кыягы алды, Сирайның бит тирәсендә йөртте, ул һичнигә игътибар итми йоклый сыман иде. Тагын бер адым ясады, Сирайның баш очындагы торт тартмасына үрелде. Кулына алды, йөрәге тибүдән туктаган сыман иде, шул кадәр дулкынланды, артка таба чигә алмый иза чикте: аяклары гүя аныкы түгел иде. Тартманы күкрәгенә кысты, эчтә нидер зыңлап киткәндәй булды, Хәлилнең йөрәге дерт итте. Ул шулай бер тын катып торды, Сирай йоклый иде, шик калмады. Хәлил борылды һәм сак кына китә башлады. Аңа калса, ул бик ерак киткән кебек тоелган иде, кинәт ул артында яман тавыш ишетте. Каты кычкырудан Сирайның тамагы чатнагандыр кебек тоелды Хәлилгә.

— Хәлил!

Тавыш аның колак төбендә кайтаваз булып яңгырады. Хәлил җан фәрманга олы юлга таба йөгерә башлады, ләкин шундук күкрәгенә ут капты, сулышы буылды. Шунда аны Сирай куып җитте.

— Тукта!

Гипнозга эләккән кешедәй Хәлил шым булды. Әйләнеп карады. Сирай әкрен генә аңа таба килә иде.

— Тукта диләр сиңа, эт җан!

Хәлил аның пычагын күреп алды һәм кычкырырга дип авызын ачты, әмма аваз чыкмады — өне юк иде. Хәлил хәтта авырту да тоймады, шул хәтле курыккан иде ул Сирайның акаеп киткән күзләреннән. Кулыннан торт тартмасы төшеп китте һәм ул, ачылып киткән торт тартмасыннан коелган ялтыравык әйберләрне соңгы мәлдә генә күреп калды...

Сирай Хәлилнең торт тартмасы өстенә капланган гәүдәсен бер читкә әйләндереп җибәрде. Тартма канга буялган иде. Сирай йөгереп барып пальтосын, скрипка футлярын алып килде, тиз генә әйберләрне футлярга тутырды. Аннары футлярны шыртлатып япты да торып басты, тирә-ягына күз ташлап алды. Тирә-юньдә тынлык иде. Ул янә Хәлилгә бакты һәм аның, авызын зур ачып, нидер әйтергә теләвен күрде дә

бернечә адым артка чикте. Хәлилнең күзләре акайган, өне-тавышы беткән, гүя Сирайга нидер әйтергә тели, әмма авазы чыкмый иде.
Хәлил үлем белән тартышып ятканда, Сирай Яһудин, култык астына скрипка футляры кыстырган килеш, инеш буйлап сузылган сукмактан урманга таба китеп бара иде инде.

## 21

Бу урамнан Кәримә көненә ике-өч тапкыр уза. Тауга түбән сузылган тыкрыктан үтүе бигрәк тә куркыныч. Юлы юл булса икән, машиналар ермачлап бетергән, бары тик койма буйларыннан гына тар сукмак сузылган, төнлә түгел, көндезен дә бередән сагаеп атлыйсың. Таң атып кына килә. Сукмак рәтләп күренми, шуңа карамастан, Кәримә тар сукмактан җан фәрманга йөгереп узды. Тыкрыкны үтүгә, олы урам яклап, почмакта зур урыс капкалы йорт. Шул йортны үтсә дә телефон будкасына нибарысы йөз метр чамасы калачак.
Йөз метр.
Шул йөз метр араны йөгереп узганда Кәримә әлләниләр уйлап бетерде. Сирай Яһудин таң алдыннан хатыны янына кайтып керә. Гата карт аны күреп кала һәм Кәримәне уята. Тиз арада милициягә хәбәр итәргә кирәк. Кәримә хәзер, менә хәзер телефон будкасына барып җитәр, үзәк диспетчерга шалтыратыр, шартлы сүзләр әйтер, һәм, күп тә үтмәс, махсус группа Серыйны тотарга Чыңгыз поселогына таба юнәлер. Ә хәзергә әле Кәримә милициягә шалтыратмаган һәм махсус группа да бирегә таба чыкмаган.
Менә ул будка. Кәримә сулышына кабынып будкага керде, номерны җыйды.
— Алло, дежурный. Это седьмой. Шефка әйтегез, Серый өендә. Азатова. Кем кабул итте? Лейтенант Хакимов...
Күп дигәндә ун-унбиш минуттан опергруппа килеп җитәр. Кәримә бераз тынычлана төште. Ләкин икенче мәлдә инде ул дулап киткән атсыман йөгерә башлады. Серый аны көтеп тормас, караңгыда өйдән чыгып китү җаен карар. Дөрес, бабасы кулыннан ансат кына ычкына алмас. Әмма кем белә, Серыйда җитмеш хәйлә бар, ди бит бабасы. Йөгергәндә Кәримә кесәсен капшады, пистолетын бабасына биреп калдырган иде ул.
Тар тыкрыкны шулай ук җан фәрманга йөгереп узды. Менә зур урамга җитте, шулчак, һаваны ярып, пистолеттан аткан тавыш ишетелде. Кәримә йөгереп килгән җиреннән шым булды, йөрәге ярсынаярсына типте. Ату кабатланмады. Кәримә тавыш килгән якка ташланды. Ату тавышы, һичшиксез, бакча ягыннан килде. Кәримә шул якка элдерде. Әйе, кемдер кычкыра, кемнедер чакыра иде. Бабасы бит, бабасы тавышы... Шулай ук Серый качты микәнни, корал-фәләне булып?.. Менә ул сукмак, бакча башы. Кәримә түбән таба йөгерде, шунда ул сукмакка аркылы яткан гәүдәне шәйләп алды.
— Бабай, бабакай!
— Кызым, булыш әле, торып булмый. Аяк каймыкты, күрәсең, басмалы түгел. Кызым, бар син аны куа кит... Тимер юлга таба титаклады мөртәт. Аттым мин аңа, аягына тиде бугай, аксый-туксый китеп барды. Мә коралыңны. Бар, йөгер.
Кәримә үз-үзен белештермичә алга ташланды. Опергруппа кайчан килеп җитәр, Серый инде качып бара. Куып җитәргә, җитәргә! Менә ул олы юл, тиздән тимер юлына килеп чыгармын...
Тимер юлга егерме-утыз метрлар кала, ул полоса буйлап кемнеңдер атлавын күрде. Аксап бара, димәк, бабасы чынлап та тидергән... Кәримәнең йөрәге тамагына җитеп тибә башлады. Шик юк, бабасы Серыйны яралаган, юкса болай гына элдерер идеме ул.

Тәмам таң беленеп җитте. Кәримә тимер юлга менде. Таң нурлары көнчыгыш тарафтагы офыкны алсу-саргылт төскә буяп һаман өскә, югарыга үрли — күзгә күренеп яктыра башлады.

Кәримә калтыранган кулына пистолетын алды. Кинәт аның күңеленә шик килде. Бәлкем бу кеше Серый түгелдер, иртә торып йөрергә яраткан берәр инвалидтыр? Аксый-туксый, йөгерә-атлый тимер юлдан китеп баручы адәм киң читле эшләпә кигән, култыгында скрипка футляры... Коты алынды Кәриманең, әгәр ул инвалид музыкант булып чыкса?.. Шулай ук ул Серыйны кулдан ычкындырды микәнни?..

Кәриманең аяк тавышын ишетепме, алдан барган кеше әйләнеп карады. Кәримә аны күрү белән танып алды. Әйе, Серыйны һичкем белән бутарлык түгел иде. Бу — ул, Кәримә аны фотоларыннан күреп белә. Киң читле эшләпә дә, фотоларында күренмәгән кәҗә сакал да Серыйның Кәримә хәтерендә сеңеп калган сурәтен җуя алмас иде.

Кәримә тиз генә полосадан читкә йөгерде, Серыйны узды да яңадан тимер юлына менеп басты. Серый туктады, кызның ни теләвен аңларга тырышты. Кем бу, нинди кыз бала, кая йөгерә? Электричка киләме әллә?.. Электричка килә бугай шул, тавышы бар.

— Әй син, сеңелкәй, туктале, кил әле бире. Курыкма миннән. Аягым яралы минем, егылдым да яраладым. Бәйлә әле аягымны... Ярдәм ит олы кешегә, савабы тияр...

Кәримә, кисәк пистолетын алга табарак сузып, Серыйга юнәлде: «Ә бит мин сине гәүдәңне күрү белән таныдым, ишетәсеңме, гәүдәңне күрү белән!» — дип ярсынды ул эчтән.

Ниһаять, Серый кыз кулындагы пистолетны күрде. Күрде һәм бер мизгелгә акылын җыя алмыйча торды. Адәм ышанмастай нәрсә иде, аңардан куркып, полосадан төшеп узып барган кыз кулында пистолет. Ни бу, нинди кош, күктән төштеме әллә? Әһә, төшенде: лягавай, милициядә хезмәт итә, картка булышырга җибәргәннәр.

Серыйның җаны актарылды, кан чәчрәп чыкканчы аскы иренен тешләде. Беренче тапкыр эләккәндә дә нәкъ шундый кызыл авыз каптырган иде аны. Каяндыр килеп чыкты, наив, гаепсез хатын-кыз сыман артисткаланып ышанычка керде һәм... соңыннан гына белде Серый: шымчы булган икән ул, самими хатын...

Серый кулын әкрен генә итек кунычына төшерә башлады.

— Серый, кымшанасы булма, күтәр кулларыңны!

Тавышы зәһәр чыкты кызның, кулларын күтәрмәсә дә, туктап калды Серый.

— Тагын бер хәрәкәт — ике дә уйламый атачакмын, Серый!

«Һәм чынлап та атачак»,— дип уйлады Серый, гәүдәсен турайта төшеп, кулларын күтәрде. Ул якынлашып килгән электричка тавышын ишетте. Электричка якынлашыр, кыз куркып, кайсы якка булса да ташланыр, ә Серый — икенче якка. Шулай итеп кыз бер якта, Серый икенче якта калыр. Электричка вагоннарын сөйрәп үткәләгәнче, ул инде күздән язар... Аның башка чарасы калмаган иде. Бу кыз аны элэктерә икән, аңа барыбер вышка. Бу юлы инде чынлап та вышка.

Машинист юлдагыларны күреп алды ахры, сызгыртып гудок бирде.

— Серый чык уң якка, ишетәсеңме, чык!..

«Чыкмый тор әле, чибәркәй. Хәзер карыйбыз менә, кайсыбызда нервы ныграк икән. Чыкмый тор...»

— Серый!..

Кыз түзмәде, уң якка ташланды, Серый сул якка омтылды, ләкин соңгы мәлдә яралы аягы аны тыңламады, абынып китте һәм гәүдәсе белән тимер юлына аркылы бөгелеп төште.

«Бер, ике, өч, дүрт, ах!» — Серый көч җыярга һәм үрмәләп булса да юлдан чыгарга иткән иде, бишкә кадәр саный алмый калды, аның гәүдәсенә үкерә-үкерә, әллә ниткән чуенга-чуен, тимергә-тимер ышкы-

ып чинаган, чажлаган тавышлар чыгарып, электричка килеп мендe.

Тимер юлдан читкә тайпылырга чак кына өлгергән Кәримә Серый гәүдәсе өстенә чажлап менгән тепловоз тәгәрмәчләрен күрде дә ике кулы белән битен каплады.

— Инәки, бабакай!

Тепловоз үтеп китте һәм шактый киткәч кенә туктады. Кәримә битеннән кулларын алды. Кулларын йөзеннән алуга, коты алынып, кисәк тез буыннары бушап китте һәм ул ушын җуеп җиргә сыгылып төште.

*
* *

Гөлбикәнең күңеле тулы ачу иде. Иртәнге якта Хәлилгә карата туган чиркану кичен аны баскычта күргәч, янә бер күпереп, кабарып, йөрәген әрнештереп алды. Җиттедер, күп түзде, бүгеннән ул аны өенә аяк та бастырмаячак.

Гөлбикә әкрен генә икенче катка күтәрелде. Аз гына кызуландымы, шундук тыны кысыла башлый. Ә бит элек, Якуб белән яшәгәндә, бу баскычлардан йөгереп кенә уза торган иде. Кайчак аны Якуб кулына күтәреп өченче катка кадәр меңгерә иде. Шулай уйланып менгәндә Гөлбикә өстән ыңгырашу тавышы ишетте. Ул ашыга төшеп, өченче катка күтәрелде. Юлия Борисовнаның ишеге ачык иде. Зәгыйфь тавыш белән ыңгырашып, бусагага аркылы яткан карчыкны күрүгә, Гөлбикә сумкаларын ташлап, аның янына иелде.

— Юлия Борисовна, Юлия Борисовна, җаным, ни булды сиңа?

— Суктылар... Хәлил,— диде карчык көч-хәл белән генә.— Синең Хәлилең дә бар иде.

Гөлбикә карчыкны торгызып утыртты, аннары йөгереп телефонга керде. Әүвәл ашыгыч ярдәм машинасын чакырды, аннары милициягә хәбәр итте.

— Хәлил нишләтте сине, Юлия Борисовна?

— Нииндидер музыкант ияртеп Хәлил килеп керде. Мин... кучтәнәчләр алып килгәннәр... Торт... Мин кухняга таба киттем. Кухняга килеп кенә кергән идем, кисәк башыма суктылар, шундук һуштан яздым... Шкатулкамдагы әйберләремне алып киткәннәр...

Гөлбикә Юлия Борисовнаны култыгыннан алып кертеп диванга салды.

— Хәлилне мин әле генә күрдем. Ул газеталар гына алып керәм диде.

Ул арада ашыгыч ярдәм машинасы килеп туктады, Гөлбикә аны сигнал тавышыннан ук таныды. Бүлмәгә врачлар керде.

— Ни булды?

— Квартира басарга иткәннәр. Хозяйканың башына сукканнар бугай.

— Үтте инде, башта бик авырткан иде,— диде Юлия Борисовна. Карчык нишләптер врачларга елмаерга тырышты, әмма елмаюы килеп чыкмады, авыз чите генә кыйшаеп куйды.

— Сез борчылмагыз, Юлия Борисовна...

— Без аны больницага алып китәбез,— диде врач, авыруны карагач.

— Мин бармыйм анда, мин сәламәт,— дип торып утырды карчык.— Бабамнан, әти-әниемнән калган затлы әйберләремне урлаганнар, әнә шкатулкасы түр бүлмәдә ята, буп-буш... Мин милиция килеп җиткәнне көтәм...

— Юлия Борисовна, шулай ук Хәлил...

— Әйе, Хәлилең дә бар иде, тегесен танымадым, карсаграк буйлы, кара пальто, киң читле эшләпә кигән. Хәлил түргә дә узмады...

— Юлия Борисовна, мин хәзер...

Гөлбикә урамга йөгереп чыкты, газет-журналлар киоскасына барып килде, тирә-юньгә күз ташлады — Хәлил беркая да юк иде. Хатынның миенә кайнар кан йөгерде. «Кеше талауга ук барып җиттеңмени инде, исерек баш»,— дип әрнешеп сыкранды ул. Гөлбикәнең тамагына каты төер килеп тыгылды. «Хәлил, Хәлил, нишләдең син, нишләдең! Барысы да шул эчү аркасында бит!..»

## 22

Үтерелгән кешенең исеме, фамилиясе билгеләнгәч, ачыклангач, оперативкада барысын да тыңлап утырган Кәримә, начальниктан рөхсәт сорап, опергруппа белән мәет яткан җиргә барып килергә булды. Куе таллар арасында яткан мәетне шалт-шолт төшерүче артыннан ул бер тотам калмады. Хәлил башта, күрәсең, алга капланган, әмма җан биргәндә тормакчы иткән һәм башын бераз гына артка ташлаган сурәттә катып калган иде.

Опергруппа егетләре мәет тирәсендә үтерүче калдырган дәлил әсбапларын эзләгәндә, Кәримә Хәлилнең кызганыч гомерен күз алдыннан кичерде. Ул аның кем тарафыннан үтерелүен чамалый — монда да житкән Серыйның кулы. Ай-һай озын куллы булды соң... Ничәмә кешенең башына житте. Ә бит үзенең җәмгыятькә мыскал да игелек иткәне юк... Менә соңгы корбаны — Хәлил, рәтсез яшәү рәвеше аны шушы һәлакәткә китергән. Ихтыяр көчен югалткан кешене үлем түгел, ул үзе үлемне эзли. Бу — хакыйкать. Һәм менә аянычлы нәтиҗә...

Опергруппа машинасыннан Кәримә алтынчы больница каршында төшеп калды. Ул иңенә ак халат салып палатага килеп керүгә, Юлия Борисовна каударланып урыныннан күтәрелде.

— И ходаем, Каракүз, күр әле, кая яптылар үземне. Бар әле врачны чакыр, чыгарсыннар мине моннан...

— Исәнме, Юлия Борисовна! Инәки, нишләп кайтып китми монда утырасың? — дип сорады Кәримә, күрше карчыгы белән исәнләшкәч, караватъ янында башын иеп утырган әнисенә.

— Утырсын,— диде аның өчен Юлия Борисовна.— Кайгымны уртаклаша ул. Хәлилнең миңа сугуда бернинди дә катнашы юк. Ул гел кухня ягына кермәде дә. Бөтен гаеп музыкантта. Аннары мин исәнсау, башым да авыртмый.

— Музыкант түгел ул, Юлия Борисовна, ата карак, рецидивист.

— Ә киеме, киеме, скрипка футляры?..

— Маскировка, Юлия Борисовна...

— Ай, бу дөньяны, ничек җир күтәрә икән шундаен кешеләрне, ничек җир йотмый икән. Хәлилнең монда гаебе юк.

— Инәки,— дип Кәримә әнисе янына килде.— Инәки, бар кайт, аңа хәзер Юлия Борисовна гына ярдәм итә алмый инде...

Кызының соңгы сүзен әллә ишетте, әллә ишетмәде Гөлбикә, әкрен генә күтәрелде дә палатадан чыгып китте. Әлеге хәбәргә исе-акылы китеп, тәмам телсез калган Юлия Борисовна Кәримәнең беләгенә килеп ябышты.

— Нәрсә, Каракүз, әллә үтергәннәрме, ходаем?!

— Шул карак үтергән,— диде Кәримә, Юлия Борисовна аша каядыр почмакка карап.

— Мине чыгарт, моннан, Каракүз. Бар, врачны китер. Минем әниең янында буласым килә. Җиңел дисеңме аңа бу минутларда.

Кәримә врач кабинетын эзләп китте. Кабинетның ишеге ярым ачык иде.

— Мөмкин булырмы? Исәнмесез! Мин милициядән, жиденче палатада ятучы Юлия Борисовна турында...

— Исәнмесез. Утырыгыз.

— Рәхмәт, утырып тормыйм. Сез аны, мөмкин булса, чыгарсагыз иде. Ул үзен яхшы хис итә.

— Әйе, карчыкның бәхете бар, җиңел котылган. Миңа калса, сугудан битәр, кисәк булган хәлдән куркып егылгандыр ул. Баш сөягендә яра эзе юк, һәрхәлдә снимок күрсәтмәде. Ләкин, иптәш лейтенант, мин аны пока чыгара алмыйм... Аңлыйм, шаһиттыр, кирәктер...

— Ул минем күрше әбием, бик якын кешем...

— Шулай укмы? Ләкин берни дә эшли алмыйбыз. Аны бездә эшләүче Азатова да җибәрегез, дип сорап кергән иде.

— Азатова — минем әнием.

— Сезнең әниегез? — дип гаҗәпләнә калды врач.

— Хәле куркыныч булмаса, зинһар чыгарыгыз сез аны. Мин аны үзем белән үк алып китәр идем.

— Алып ук... Хуш. Килештек тә ди... Гөлбикә апаның шундый житкән кызы бар, ә житмәсә милиция лейтенанты!

— Аның тагын бер кызы бар.

— Рифкать Ильясович мин, иптәш лейтенант.

— Минем әни сезгә бик олы күренгәндер, кешене мәшәкать картайтмый, хәсрәт картайта, Рифкать Ильясович.

Алар палатага килеп керү белән, Юлия Борисовна врачка ябырылды. Имеш, нигә ип-исән, тап-таза кешене тик торганда дәүләт ипие ашатып больницада яткыралар. Әгәр дә мәгәр аны хәзер үк чыгарып җибәрмәсәләр, ул бу палатада бер минут та калмаячак, тәрәзәдән булса да чыгып качачак. Врач, киңәш сорагандай, Кәримәгә карады.

— Мөмкин булса, чыгарыгыз,— диде аңа Кәримә, врачның күңелен укыгандай.

— Ярый, сез дигәнчә булсын. Кич якта мин аңа кереп хәлен белеп чыгармын,— диде врач һәм Юлия Борисовнага якынрак килеп: — Моны мин, әбекәй, сезнең күршегез хакына гына эшлим.

— Рәхмәтләр яусын үзеңә, мөгаен син игелекле баласыңдыр, изге айда тугансыңдыр. Әбекәй, дип дәшмәсәң дә була. Хатын-кызга йөз яшьтә дә әби димиләр. Төркиядә туксан биш яшьлек хатын, ишетәсеңме, егетем, туксан биш яшьлек хатын, йөз дә егерме җиде яшьлек иреннән игезәк бала таба,— диде Юлия Борисовна баш бармагын түшәмгә төртә-төртә.— Шулай бит, Каракүз.

— Каракүз,— дип көлемсерәде врач.— Сәер исем.

— Бер дә сәер түгел. Саф татар исеме,— диде Юлия Борисовна.

Шулай сөйләшә-сөйләшә Рифкать Ильясович аларны ишеккә кадәр озата барды.

## 23

Юлия Борисовна концерт залында. Барысы да илле ел элек булган кебек. Тамашачылар шулай ук ыгы-зыгы килә, утырышалар, танышларын күреп, ияк кагып кына исәнләшәләр.

Барысы да илле ел элек булган кебек, хәтта урындыкларны да алыштырмаганнар, бары тик кызыл төстәге тукыма белән генә тышлаганнар, элек яшел төстә иде бу урындыклар.

Әйе, илле ел... Шулай ук гомер дигәнең узып та барамыни соң? Узды дамы инде?.. Юк, узмады, ул яшь, аның укучысы, дәвамы бар. Үзе җырламаса да, аны тыңлый, шуннан юаныч, куаныч таба. Ә бу хәл, белгән-аңлаган кешегә, үзе бер гомер икән.

Бүген ул Зөлфиянең беренче концертында. Зөлфия аны үзе белән алып килде. Әнисе эштән соң килергә тиеш. Барый белән Кәримәгә дә

урыннар калдырылган. Юлия Борисовна концерт башланмас борын дулкынлана башлады. Зөлфиянең дә күңеле тыныч түгелдер. Җиңел ме шәхси концертың белән чыгулары. Зөлфиянең концертында булу Юлия Борисовнаның күптәнге хыялы иде. Һәм ул үзенең нинди укытучы-остаз булуына нәкъ менә шул концертта ышаначак. Кирәкми аңа газеталарда музыка белгечләренең мактавы, ул үзе хөкемдар, үзе бер жюри.

«Син оныта алмассың бу көнеңне, Зөлфиякәй. Җыр синең тормышыңа, яшәү мәгънәсенә әйләнер»,— дип уйлады Юлия Борисовна. «Җыр ул — халык күңеле, ышылек хатирәсе, җыр ул — ил тарихы, халык тарихы, үткәне, киләчәге»,— ди торган иде укытучысы. Моны ул сәхнәгә техника, микрофон менгәч бигрәк тә еш кабатлый торган булып китте. Имеш, чын артист буласыгыз килсә, тамашачы күңелен яулыйсыгыз килсә, микрофон белән мавыкмагыз. Әмма нишләмәк кирәк, тора-бара микрофон да сәхнәдә үз урынын алды. Дөрес анысы, микрофонга җырлап зур исем алган җырчылар да булгалады, ләкин вакыт аларга да үз бәясен бирә бара — күбесе инде халык күңеленнән күптән төшеп калдылар.

Зөлфия бүген үз концертын бирә. Борынгылар әйткәннәр, дөньяга килгән һәр адәм я бер бала багып үстерергә, я булмаса ике агач утыртырга тиеш, дигәннәр. Юлия Борисовна үкенми: үзе табып үстермәсә дә, үзе тәрбияләшеп үстергән кызның концертында утыра. Тик барысы да ул уйлаганча ук булырмы?.. Утырткан агачы җимеш бирерме?..

«Дулкынланадыр, балакай»,— дип уйлады Юлия Борисовна. Кызганды ул Зөлфияне. Кыз әчтән генә вөҗдан газабы кичерә иде. Күрә бит, сизә бит Юлия әбисе. Концертына хәзерлек барган көннәрдә Зөлфия еш кына күршедәге инвалид егет янына кергәләп йөрде. «Нигә, ни өчен керде? Кайчандыр кылган хатасы өчен газаплануымы шулай!..» — Юлия Борисовна сорамады.

Бәхтиярне кыйнаган егетләргә суд булды, ә Зөлфияне бөтенләй гаепләмәделәр, гафу итүләре булды, күрәсең. Ә менә кыз үз-үзен гафу итмәде булып чыга. Зөлфия егетне ташлап качып киткән дигәнгә Юлия Борисовна башта ышанмаган иде. Аның уенча, Зөлфия алай итмәскә тиеш иде, бу мөмкин хәл түгел кебек тоелган иде. Әмма, нишләмәк кирәк, шулай булып чыкты...

Гафу итте микән кызны Бәхтияр?

Юлия Борисовна бу турыда белми иде. Ул шушы уйларыннан арыну өченме, дикъкатен сәхнә ягына, авыр булып салынып торган калын пәрдәләргә юнәлтте. Хәер, бу мәлдә аны иң дулкынландырганы, иң борчыганы — тамашачының Зөлфияне ничек кабул итүе иде. Зөлфия бүген үз язмышын гына түгел, гүя аның язмышын да хәл итә иде. Үз заманында данга күмелгән атаклы җырчы ялгышмадымы Зөлфия йөзендә үткәндәге үзен күреп? Ышанычы, өмете коры куаныч кына булып калмасмы?.. Хикмәт шунда иде: беренче укытучысы буларак, Зөлфияне гади бер җырчы итеп кенә күрәсе килми иде аның, Казанда андый җырчылар буа буарлык. Булса — шундый булсын, Юлия Борисовнаның үзеннән дә бер башка өстен булсын!

Теләсә-теләмәсә дә Юлия Борисовна артына әйләнеп карады. Ул бирегә килеп утыргач та үзендә кемнеңдер күз карашын тойган кебек булган иде.

«Я ходаем, Бәхтияр бит! Янында әтисе белән әнисе».

Юлия Борисовна аларга карап елмайды, ияк кагып кына исәнләште. «Бер дә бүтән түгел, боларны да Зөлфия чакырган»,— дип уйлады ул.

Ул арада ишектә Гөлбикә, Кәримә, Барый күренделәр. Ашыгалар

Өченче звонок булды. Юлия Борисовна күтәрелә төште, керүчеләргә бирегә килегез, дип кул изәде.

Ниһаять, сәхнәгә Зөлфия чыкты. Ул әкрен генә сәхнә уртасына узды. Ярым караңгы зал сыек кына кул чапты.

Зөлфиянең беренче җырына тамашачы бик мөккибән китмәде. Әгәр дә мәгәр Юлия Борисовнадан: «Җырчының уңышы нидән гыйбарәт?» — дип сорасалар, ул һич тә икеләнергә урын калдырмыйча: «Осталыктан һәм таланттан»,— дияр иде. Юлия Борисовна сизеп торды: беренче җырдан соң тамашачы сагая калды, ләкин кинәт кенә гөр килеп кул чабарга да иртәрәк дип уйлады ахры. Иң мөһиме, Зөлфия сәхнәдә үз-үзен тота белә, беренче җырын матур, әйбәт башкарды. Менә икенче җыр. Зөлфия әкрен генә рольгә керә бара, тавышы моңлы, җырга тәңгәл, сагышлы. Инде гөрләтеп кул чаптылар. Юлия Борисовна үз күзләренә үзе ышанмыйча утырды. Бу инде уңыш иде. Ул янәшәсендә утыручы Гөлбикәнең кулын кысты, янәсе, күрче, күрче кызыбызны!

Гөлбикәнең күзләрендә яшь иде, ул елый, бите буйлап яшь бөртекләре тәгәрәшә, тирән сагыш күрде аның күзләрендә Юлия Борисовна. «Җыламаслык та түгел шул бичарага,— дип уйлады Юлия Борисовна.— Кичәле-бүгенле икенче ирен җирләде. Бәлкем ул Якубын исенә төшергәндер. Беренче ирең белән бәхетле идең син, Гөлбикә, ай бәхетле идең!.. Хәлил исә сиңа бәхетсезлек кенә китерде. Тикмәгә генә халык беренче ир алладан, икенчесе бәндәдән, өченчесе шайтаннан, димәгәндер шул...»

— Күрше егет Бәхтияр да биредә,— дип пышылдады Юлия Борисовна.— Бездән өч рәт артта утыралар.

Гөлбикә артына әйләнеп карамады, гүя ул Юлия Борисовнаны ишетмәде дә, сумкасыннан кулъяулыгын чыгарып күз яшен сөртте.

Зөлфия «Юксыну» җырын башкара иде. «Сүзләрен, сүзләрен генә әйт син аның... Кемнеке икән, нигә әйтми киттеләр? «...Яратам мин, әйтмим генә, син йөрәкне күреп белмисең...» Кемгә багышладың, балакай, бу җырыңны, үзәкләрне өзәсең бит»

Юлия Борисовна түзмәде, артына әйләнеп карады. Бәхтияр, дөньясын онытып, дикъкать белән Зөлфияне тыңлый иде, йөзендә шатлык катыш моңсулык.

Зөлфиянең йөрәгеннән кан булып тамадыр моң, бу сүзләр, бу көй, бу аһәңнәр. Җыр беткәч тә моң тәэсиренә әсир төшкән тамашачы, кул чабарга онытып, бер тын уяна алмый торгандай булды.

Зөлфиянең һәр җырыннан йөрәкләр куырылды, күзләр дымланды, күңелләр тулышты. Кыз, мөгаен, үзе дә бу хәтле уңышны көтмәгәндер. «Үттең болай булгач, балакай, үттең, зур сынау үттең. Хәерле юл сиңа!» — дип куанды Юлия Борисовна.

Юлия Борисовнаның уйларын ишеткән кебек кыз бу җырын искиткеч хиссият белән җырлады. «Әнкәй»не җырлаганда, Гөлбикә кисәк сыгылып төште һәм аның иреннәре калтырана башлады. «Хәтерләү» җыры Гөлбикәне тәмам ярсындырды, ул ни кылырга белми таянычы, яклаучысы итеп Юлия Борисовнага елышты.

*

* *

Ул вәгъдә иткән вакытында килде. Барый анда иде инде, әмма егет Кәримәне күрмәде, ул аны трамвай тукталышы ягыннан көтә иде.

— Барый, Барый дим, исәнме!

— Һо, Каракүз, мин сине трамвай ягыннан көтәм,— диде егет шатлыгын яшермичә.

— Чәчәкләр кемгә, Барый? — диде Кәримә бераз кылана төшеп. — Әллә инде башка бер-бер кешене көтә бу?..

— Хәтереңдәме, Кәримә, мин Алабугага синең янга килгәч, ни дигән идем?..

— Барый,— кызның йөзе кинәт үзгәрде.— Барый... Әйбәт кеше син. Мең-мең рәхмәт сиңа. Шуны истә тотуың өчен, игътибарлы булуың өчен...

Кыз аның күкрәгенә башын төртте.

— Син шундый әйбәтсең, Барый...

— Бик әйбәт булып булмады шул. Хөкем итә яздылар. Үзең үк гаепләп чыктың...

— Әйе, гаепләдем. Гаепләдем, ә күңелем: ул андый түгел, андый түгел дип тәкърарлап торды. Котбыйны тыярга тырышуың хак булып чыкты бит...

— Тотып ярырга булган да бит шунда ул сугыш чукмарын. Их, шул вакытта булса икән ул әлеге акыл. Акыл дигәнең кешегә яши-яши генә килә икән шул, Кәримәкәй...

— Бәхтияр судта сезгә тел дә тидермәде. Бер Котбыйны гаепләде.

— Без аңа чынлап та беребез дә сукмадык, тәрткәләдек кенә, бер Котбый... Ә шулай да күңелдә әллә нәрсә төенләнеп тик тора. Кичә концерттан соң баскычтан төшеп барганын күрсәң иде син аның. Көчкә атлый, ә үзе елмая.

— Бер уйлаганда, герой ул. Судта ничек тыныч утырды. Әнисе елый, әтисенең күзләрендә яшь, ә ул сезне яклап утыра.

— Барыбер без аның алдында гаепле, Кәримә. Аңлыйм мин аны. Шулай да... Миңа калса, киң күңелле булырга теләде ул анда. Миңа, әйтик, общественное порицание бирделәр. Ул порицание минем менә кайда таш булып ятты,— егет күкрәген төйде.— Менә кайда...

— Онытып торыйк аны, Барый. Әйдә, әнә, сигезенче трамвай килә түгелме...

— Онытып булса икән,— диде Барый үзалдына.

Якшәмбе булгангамы, зиратта кешеләр күп иде. Зур капкадан кергәч, үзәк аллеядан киттеләр, берара җир үтүгә, уңга — тар сукмакка борылдылар. Ике яклап та өянке, юкә, карама агачлары үскән, ком җәйгән сукмакка ябалдашлар арасыннан таңкә-таңкә булып кояш нурлары төшкән, сукмактан түгел, көмеш таңкәләр җәйгән келәмнән атлыйлар кебек иде.

— Кәримә, туктале. Ни, ашыкма әле. Минем сиңа бер сүз әйтәсем бар. Без инәй белән уйлаштык-уйлаштык та...

Кыз егетнең каршына чыкты, күзләренә карады.

— Әйтми тор, Барый! Әти кабере янында, ул да ишетсен...

— Бүген сәгать алтыларга сезгә инәй киләчәк. Яучы булып.

— Барый, җүләрем,— кыз егетнең күкрәгенә капланды.— Үзебез хәл иткәч җитмәгәнме?!

— Җиткән дип... Әйдәле, башта чәчкәләрне салыйк.

Кабергә җитәрәк чардуган эчендәге кечкенә эскәмиядә утыручы берәүне күреп, икесе дә шым булдылар. Хатын кара яулык бәйләгән, башын түбән игән иде.

— Барый, инәки бит бу!

— Чынлап та әниең икән шул. Инде нишлибез?

— Бармый торыйк, Барый.

Ләкин егет аны тыңламады, кызның кулыннан алды да туры кабер янына юнәлде.

— Чәчәкләрне салыйк, ул да күрсен. Аннары ризалыгыңны әти-әниең алдында алам.

— Җуләрләнмә, Барый...

Ялтырап торган кызгылт урал мәрмәре өстендә ике ал чәчкә бар иде, алар янына тагын дүртәү куелды.

Гөлбикә яшьләргә күтәрелеп тә карамады. Ул аларны дәү сукмактан борылгач та күргән иде инде. Кызын һәм булачак кияве күрүгә аның болай да тулышкан күңеле тәмам ташып китте, ул башын тагын да ия төште, ишетелер-ишетелмәс кенә, эчке бер сагышлану белән «Як-ку-п»,— диде. Әллә шулай ишетелде генәме яшьләргә, алар берберсенә ни әйтергә белми, тынып калдылар.

Сүзләр бирелә артык иде. Алар өчен кабер ташы өстендә яткан чәчәкләр телгә килде, мәрмәргә алтын хәрефләр белән язылган юллар телгә килде. «Азатов Якуп Гата улы. Батырларча һәлак булды...»

Шушы сүзләрне укыганда, егет, сөйгәне белән мәңге-мәңге бергә булырга ант иткәндәй, кызның кош мамыгы кебек йомшак кулын учына кысты.

## УКУЧЫНЫҢ КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕНӘ

### Монгол мәкальләре һәм әйтемнәре

*Тату тормаган ун кеше — черек стена, ике якын дус бергә — үзе таш кыя.*

*Хатны — пичәтенә карап, атны — тешенә күз салып, кешене — тыңлап беләсең.*

*Бак тамчылардан — диңгез, ишеткәннәрдән — гыйлем.*

*Саулыктан зуррак байлык юк, тәҗрибәдән яхшы фән булмый.*

*Кояштан үлән яшәрә, китап аңны яктырта.*

*Өйрәнгәнең — үзеңә кала, белмәгәнең югала.*

*Көчнең бетүе мөмкин, ә белем һич югалмый.*

*Лампа майдан яктыра, шәкертне — остаз яктырта.*

*Фәннең иң яхшысы — дуслык.*

*Малы күп — бай, баласы күп — аннан баерак, ә белеме күп — иң бае.*

*Фәннең иге-чиге юк.*

*Белгән кеше акыл сатмас, чын осталар масаймас.*

*Су белән әйбер юасың, белем белән аңыңны.*

*Ерактан күрмәүче юлда бәлаләргә юлыга.*

*Әйбер кадерен белмәүче әйбернең үзен боза.*

*Үз көчеңне үзең бел дә күтәрә алсаң күтәр.*

*Эштә осталык алдыра, кыенлыкны бердәмлек җиңә.*

*Балык су белән яшч, ә кеше — хезмәт белән.*

*Кечкенә таш атып та зур ташны ватып була.*

*Кәкре ukны — турайтып, кара кешене агартып була.*

*Печәнле булыйм дисәң, чалгы ал да үлән чап.*

*Ялкау кеше куркак та була.*

*Белемсез акыл — ярсыз елга ул.*

*Итәк кисеп, җиң ямый.*

*Үр менмәс борын итәк күтәрә, су күрмәс борын итеген сала.*

# Нури Арсланов

## Ана сөте белән

Илем миңа күкрәк сөте белән
Сагышларын бергә имезгән...
Хәтфә келәм түгел, җәйгән үлән,
Парча түгел, бүзен кигезгән.

Иркенләп бер яшел үләннәрдә
Аунап үссен әле дигәндер,
Асыл кием җайсыз була тәнгә, —
Шуңа юри бүзен биргәндер.

Ана сөте белән кергән сагыш
Гомерлеккә булды янымда,
Походларга алып чыккач язмыш —
Бергә акты солдат канында...

Ачысы да аның, татлысы да
Күзләремә яшьләр китерде:
Яшь аркылы бакты миңа дөнья,
Сөйдем аны Мәҗнүн шикелле!

Мәхәббәтне, яшьлек ярышларын
Авызлыксыз уздым атларда,
Көрәшләрдә даулы язмышларым
Үтте охшап күкбар тартканга.[1]

Ярый әле илем юк-бар белән
Бик иркәләп мине бозмаган:
Ил сагышын үзем татып беләм,
Бергә сыкрыйм, бергә сызланам...

Назда үссәм кадерен белмәс идем
Зарыктырып килгән бәхетнең.
Мин намуслы бер сакчысы, илем,
Син сайлаган алтын тәхетнең!

## Яңа елда

Һәр Яңа ел саен ил яңара,
Ә бер елга шәхес искерә...
Кешеләрнең исе китми аңа,
Тост тоталар бәйрәм исменә.

---

[1] Күкбар — төрки халыклар уены. Атлы егетләрдән ике төркем яңа суелып тутырылган кәҗә тиресен алып китәргә тартыша-ярыша.

Картлык — иске кием, кисәң — таман,
Ямаулары да бар, җөе дә:
Кимәс идем шуны, җитсә чамам,
Яшәр идем гел бер көемә.

Иске кием дисең?! — Яңара бел —
Кешеләргә бул син кирәкле.
Әйтәләр бит: «Эш киемдә түгел»,
Җик күрмәсләр әле сирәкне.

Яхшы атым калсын дисең икән
Искә алып, сагынып сөйләргә,—
Һәр яз саен яшәргәндәй имән,
Шаулап тор син җилгә, силләргә!

## Моңлы кеше

Моңлы кеше шатлана да белә,
Кайгыңны да бүлешә, кирәксә;
Яшә, саклап, кадерен белеп кенә,
Шундый иптәш сиңа эләксә.

Моңлы кеше аңлый бүтәннәрнең
Хәсрәтләрен, күңел көйләрен...
Үз сагышы кебек һәр бәндәнең
Якын итә янып-көйгәнен.

Күңеле нечкә аның — бик сак кылан,
Моңлы җанга тупас кагылма:
Моңдаш табып син үз иткән сыман
Үз итәсе килә аның да.

## Кызлар

Рус кызының буе-сыны килгән,
Үткен күзләр, алтын чәчләре,
Нечкә билле сарафанын кигән,
Керфегендә — бәхет яшьләре...
Бер карасаң Зоя төсле батыр,
Назлы, гади дә — бер карасаң...
Мин шулай да уйчан, салмак-сабыр,
Моңлы татар кызын яратам.

Рус кызлары мәхәббәттә кыю,
Авызын үпсәң бирә телләрен,
Бер кабынса мөмкин түгел тыю —
Әйләндерми башын кемнәрнең!
Япанчыдай [1] батыр егетләрне
Рус кызлары үзенә караткан.
Мин шулай да нәкъ безнеңчә ямьле —
Тыйнак татар кызын яратам.

---

[1] Япанчы — борынгы татар атлы гаскәр башлыгы. Мәскәү илчесе — рус кинәзенең кызы аңа гашыйк булган.

5*

Рус кызының аты — кызыл чәчәк,
Күкрәп үсә иркен бакчада.
Дөньяда юк төсле аннан да шәп,
Карама да аннан башкага,
Затлыракны эзләмә дә юкка,
Сайла да ал идең арадан!
Мин шулай да кар астында шыткан
Умырзая гөлен яратам.

## Борчуым кала

Тудым казакъ илендә,
Үстем йортым Иделдә,
Шушы ике өемдә
Әкиятем, чыным кала.

Дала җырга өйрәтте,
Идел җанны көйрәтте:
Бер уй телә йөрәкне —
Китсәм борчуым кала...

Мирасым юк алтыннан —
Гауга купмас артымнан,
Тик йөрәктән саркылган
Җырым-моңсуым кала.

Көмештәй кар суларым,
Язлардай ярсуларым,
Өмет-ымсынуларым,
Туган җир-суым кала.

Кырмыска иле сыман
Мыжылдап, кайнап торган,
Тырыш, тынгысыз, чыдам
Йортым — чыр-чуым кала.

Килгәннәр китә җирдә...
Зыян юк аннан бер дә.
Илем кайгысы миндә:
Китсәм борчуым кала...

*1982*

## Үзем турында

Олыларга мин күрсәттем хөрмәт,
Яшьләрне үз итеп яраттым:
Аксакалча хикмәт, егетчә дәрт
Сере булды шигъри канатның.

Акыл мине сабырлыкка илтте,
Җилкенчәклек гомерем озайтты:
Тормыш ваклыкларын тар-мар итте,
Ватты язмыш корган тозакны.

Хикмәт белән мин атладым уйлап,
Ә дәрт белән шашып йөгердем,
Шулай үттем гомер юлы буйлап,
Авырлыгын тоймый йөгемнең.

Гел үрләдем кояшыма карап,
Изге юлда азмы кичердем!
Мин хикмәттән алдым кыен сабак,
Дәртем белән рәхәт исердем.

Уйлыйсыздыр, үзеннән бик риза
Булган икән, диеп, бу бәндә:
Юк! Үземне әрләп чиктем иза...
Тик үкенмим бер дә бу хәлгә.

## Яшь аралаш

Өметләрем өзек-төтек...
Ә мин йөрим илһам көтеп:
Килсен диеп ләйсәнле яз
Яндыммы аз, көйдемме аз?!.

Күңел сынса сына икән:
Кайда җилләр? — сүлпән җилкән,
Көймәм бара агар-акмас,
Шәфәкъли таң атар-атмас...

Тынып калгый чиксез диңгез.
Көймәм белән без икебез
Шул диңгездә бер йомычка.
Омтылулар ахры бушка...

Юк, юк, диңгез әле шаулар:
Күтәрелер көмеш таулар! —
Йомычка, бөтерелеп суда,
Уйнар әле калка-чума,
Дулкын ялларына басар,
Шоңкар булып күккә ашар! —

Уянганда җанда өмет,
Яшь аралаш йөрим көлеп.

## Юасы иде

Елыйсы килә, яшь килми,
И җанның кыйналганы,—
Сагышның күздән түгелми,
Таш булып җыйналганы!..

Яшьсез елаулары авыр,
Түзсәң дә, түзмәсәң дә,
Теңкәң корып, катса бавыр,—
Юк дәва, эзләсәң дә...

Юасы иде, яшьләрем,
Шул газап ташларын бер,—
Юансын иде эчләрен
Бушатып калган гомер.

## Әзер бәхет

*Җыр*

Вак-вак атлап барулары,
Күз сирпеп алулары,
Без үкчәле эзләренә
Бер карап калулары!..

Авызы — уймак кына ла,
Гәүдәсе уйнап тора.
Ни кыланса да килешә —
Кылана уйлап кына.

Кашлары кыйгач каралган,
Чәчләр тузгып-таралган,
Битләре ал, иреннәр — бал,
Үбәр өчен яралган.

Беләге, беләзеге лә,
Билләренең нәзеге!
Кемгә генә насыйп икән
Бу бәхетнең әзере?!.

## Өннәр

*Исәнлектә булган үпкәләргә,*
*Рәнҗешләргә хәзер инде ни сан! —*
*Хаталардан хали түгел бәндә...*
*Нәрсә булган, әнием, исән булсаң?*

Бөек рухы калса искә кереп
Уйдан чыкмый икән шул әниләр,—
Кемнәр тагын мине сискәндереп:
«Әниең үлгән, әниең үлгән...» диләр.

Казан зиратына мин әнине
Җирләгәнгә инде ни гомерләр!
Бүгенгедәй, кемнәр борчып мине:
«Әниең үлгән, әниең үлгән...» диләр.

Әни үлгән... Хатирәләр исән,
Шулар өне һаман колагымда.
Бабай улы менә башын игән
Чардуганлы әние торагына.

Мәетләрнең тыныч илендә дә
Тынгы тапмас икән исән бәндә:
Акыл җитмәс икән Башлангычка,—
Әзәл [1] чиксез шул ул, гомер кыска...

Әйе, мин дә хәзер әни яшен
Узмасам да, җитеп киләм инде.
Әни кабере үләннәрдән яшел,

[1] Әзәл — мәңгелек.

Әни кабере хәтфә келәм инде:
Күрәзәче Хәйям әйткән сыман
Гөл-чәчәкләр үскән туфрагыннан...

Гөл-чәчәкләр... Тирә-ягы урман...
Элек дөнеп көлгә, аннан гөлгә,
Әверелгәнче үзәк өзгеч өнгә
Исән булса инде нәрсә булган...

## Яралар

Яраннары белән киңәш корган,
Чатырында беркен Искәндәр [1].
Җиде батыр шунда килеп кергән,—
Искәндәрнең җаны сискәнгән:

Ялангачлар... Тик балкыган каска —
Солдат тажы алар башында,
Тән җөйләнеп беткән — яра баскан...
Әйткән алар патша каршында:

«Кайтар илгә, түзеп булмый башка...»
Ә Искәндәр, шашкан хәлендә,
Киемен ертып ташлап, тәнен ачкан,—
Тоташ яра икән тәнендә...

Тик ул шундук үзен кулга алган,
Чыгып киткән ашыгып чатырдан,—
Оят аңа батыр солдатлардан:
Алар түгел, ул бит чакырган

Бөек дауга, бөек җиңүләргә!
Инде солдат белән тиңләшеп,
Алла башы белән [2] булып бәндә,
Бәхәсләшсенмени тиргәшеп?!.

Әмер биргән: «Кайтыр юлга!» дигән,
Белә торып максат калганны.
Солдатка ни аңа — каска чөйгән!
Рухан яра телгән сәрдарны... [3]

## Дөнья булыр тыныч

Җилкенсә дә узалмаган җилдән
Мәшһүр канатлы ат.
Таулар тишеп үзе ачкан силдән
Үлем тапкан Фәрһад.

Хатом-Тайлар, Оуэн, Сен-Симоннар
Изге булган белән
Туклык куралмаган ачлар-коллар...
Тик юмартлар бөлгән.

---

[1] Искәндәр — Александр Македониялы.
[2] Мисырда Искәндәрне Кояш алласы улы итеп таныл, Фиргавеннар дәрәҗәсенә күтәраләр.
[3] Сәрдар — полководец.

Елкы өерләре дулап чапса —
Җилләр юлын бора,
Таулар булып бөтен халык басса —
Силләр юлын буа.

Кумәклектә — дөнья иминлеге,
Һәлакәттән коргау.[1]
Тарих булып калыр сугыш гимны —
Быргыларда уйнау.

Кумәк көчтән бомба-ракеталар
Дүнәр балбал ташка,—
Үләксәдән мәхрүм козгын-комар
Һәлак булыр ачка.

Юк, чыңламас бер-берсенә орынып
Кылыч белән кылыч,
Илләр яшәр бәлаләрдән арынып,
Дөнья булыр тыныч!

*1981*

## Портрет

Ефәк чәчләр, кара дулкын булып,
Иңнәреңә төшеп таралган.
Иреннәрең көлемсери уелып,
Җылың балкып тора алардан.

Керфегеңнән тама төсле гөлләр,
Күзләреңдә тылсым кодрәте.
Назларыңа чыдар икән кемнәр,
Җитәр икән кемнең җөрьәте?!

Әнә күрәм, ничек син килешкә
Тирәңдә бар нәрсә үзгәргән,
Кергән бүтән бер иләһи төскә, —
Саклан, иркәм, яман күзләрдән!

Бер кем иҗат итәлмәслек сын син —
Венералар түгел ясалма:
Бөтен җирең килгән, гаҗәп чын син,
Пьедесталга сиңа басарга!

Синең сының өчен, сәнгать атлы
Хикмәтнең баш иеп әмренә,
Бирер идем, шиксез, лауреатны
Мин табигать дигән тәңрегә!

*1979—81*

---

[1] Коргау — яклау, саклау.

## Бер катлы күңел

Көн туа — шатлык уяна, рәхәт күңелгә:
Тагын насыйп булды дисең кояш күрергә!
Әмма сизгер әтәчләрен кычкыртып таңнан:
«Тагын бер төнгә кыскарды гомер...» ди Хәйям[1].
Гомерләр кыскара җирдә — таңнар туа да,
И беркатлы да соң күңел, шуңа куана...

## Япа-ялгыз

Яман — ямanыңны күрә,
Яхшы — сөенә яхшыңа.
Якынның кадерен кем белә?!—
Хөрмәтли тик ят кына.

Өйдәгеләр арасында
Ни һөнәр, ни хикмәтең?..
Яшәүнең мәгънәсе шунда —
Кискән булсын икмәгең!

Шатлыкларың, сагышларың
Фәкать үзеңә генә:
Япа-ялгыз кала җаның, —
Өмет... түземдә генә.

*1980—81*

## Поездда

Ни кадәрле шашып чапса да поезд,
Карыйм күккә,— һич арттан калмый йолдыз:
Ашыкканнан мотор я атта бәндә,
Күрәсең, үзгәреш булмый галәмдә.

Бөтен җисмең белән син бер тузан тик,
Хыялланма кояш, айдан узам, дип:
Нәби булып калыксаң да поракта
Китү үз йолдызыңнан юк еракка![2]

*1980*

---

[1] Бөек Гомәр Хәйямның бер робагыена ишарә.
[2] Нәби — пәйгамбәр, поракка (сихри атка) атланып күккә ашкан имеш.

## Зәет Мәҗитов

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Илдә була

Илдә була мең мәшәкать, мең шөгыль,
Һәр яңа көн алып килә яңасын.
Яшьме, картмы — иленә син баласың,
«Илем эшен үтәргә!» дип янасың.

...Илнең җыры, шатлыгы һәм хәвефе
Синең җыр ул, синеке ул һәрберсе.
Йөрәгенә берекмәсәң илнең, син —
Баласы да, шагыйре дә түгелсең.

### Хис ялкыны кирәк

Йомам күзне, куам хыялдан,
Үчектеме — китми бер сурәт:
Ник алдыма килдең син, Өрәк,
Бүген тагын сиңа ни кирәк?

Телгә килде циклоп-өрәгең:
— Кирәк миңа,— диде,— йөрәгең.
Нечкәргән ул артык, күрәмен,
Алыштырып аны бирәмен.

Бирәм сиңа шундый бер йөрәк,
Ул иң яхшы робот төслерәк,
Ул хисләнә белми, тимер ул,
Җырлап түгел, гүләп йөрер ул.

Автоматтай үтәр кушканны,
Аермас ул дусны, дошманны.
Көчсезләрне җәлләп аямас,
Чәчәкләргә сөеп карамас.

Заман шундый хәзер — НТР,
Тарихларың, эзең онтылыр.
Кайгы-шатлык сиңа ят булыр,
Җаның уйдан, гамьнән котылыр.

— Тукта!— дидем, суктым өстәлгә,
Читкә аттым каләм, кәгазьне.
Тынсыз калып тордым бер мәлгә,
Үзем уйлыйм синең вәгазьне.

Уалды да очты өрәгең
Зур дөньяны кабат күрәмен,
Әүвәлгечә нечкә көйләргә
Дулкынланып тибә йөрәгем.

Күз алдымда гөлләр тирбәлә,
Челтериләр көмеш чишмәләр.
Тургай җырлый зәңгәр түбәдә,
Әкрен генә җилләр исәләр.

Машиналар тыз-быз чабыша,
Чыр-чу килә бала-чагалар.
Көлеш, җырлау — тормыш.
Кешеләр
Йорт төзиләр, юллар салалар.

Тәмам җуйды җаным тынлыгын,
Тулды аңа тормыш шау-гөре.
Мең кылына минем йөрәкнең
Мең гамь булып чиртә һәрбере.

...Боз тауларын күрәм, чүлләрне,
Күрәм чит-ят ерак илләрне.
Җанлангандай була бабамнар,
Тарихларга кереп калганнар.

Күпме җаннар җирдә кыелган?
Мена тагын күпме полигон
Җан алырга корып куелган? —
Шуңа әрни бүген минем җан.

Күпме әле робот йөрәкләр
Кансызлыкка өндәп эш йөртә?
Шулар мине борчый кич-иртә,
Бәгыремне шулар өшетә!

Юк, тынгы юк һич тә йөрәккә,
Йөрәккә хис кирәк, гамь кирәк.
Бүгенгедән мең кат көчлерәк,
Хислерәк бул, йөрәк, ян йөрәк!

Сыңар күзле робот-әрәкне
Хис ялкыны белән өтик без.
Бар дөньяны нәфис, шәфкатьле,
Йөрәклеләр җире итик без!..

●

Ничек үскән? Нинди орлыктан? —
Юл буенда алма агачы.
Берәү шуның ап-ак чәчәкле
Бер ботагын кисеп алмакчы.

— Өзмә, юлчы, — агач үтенә,—
Юкса, ничек җимеш бирермен?
Китә юлчы. Алда — өмете:
«Җимешләре булгач килермен».

Алмагачы яшел. Чәчәксез.
Юлчы килгән, җимеш җыймакчы.
— Өзмә, юлчы,— агач үтенә,—
Җимешләрем әле бик ачы.

— Булсын әйдә, агач, синеңчә,
Бик түземсез кеше түгелмен...
Китә юлчы. Алда — өмете:
«Җимешләре пешкәч килермен».

Алмагачта алсу алмалар,
Күзнең явын хәтта алалар.
Карар кылган юлчы түзәргә,
Килүче юк алма өзәргә.

... Ничек үскән? Нинди
орлыктан? —
Юл буенда алма агачы.
Юлчы килгән. Җимеш җыймакчы.
Коелып беткән ләкин алмасы.

## Җил булып исәр идем

Кайтып булса иде икән
Безнең чәчәк чакларга,
Җил булып килер идем мин
Син яшәгән якларга...

Назлар идем дә, җил кебек,
Китәр идем таң белән,—
Гомерлек бәхетем белән,
Җыр белән, илһам белән.

## Син җырласаң...

Син җырласаң — тылсымлыйсың, ахры,
Сихерлиләр, ахры, көйләрең,—
Ага йөрәк моңнар дәрьясына
Синең җырларыңа ияреп.

Син җырласаң — туа шундый хисләр,
Сүзләр җитми аны әйтергә.
Син җырласаң — инде чирәм баскан
Ерак эзләр төшә хәтергә.

## Фәнис Яруллин

# ЙӨРЕП ТОРА ХАТЛАР ГЫНА...

*Фираяга*

●

...Җаныңны нәрсә әрнетә?
Ник бик сагышлы чагың?
Әллә күңел тәрәзәңә
Таш аттылармы тагын?

Әллә янар чәчәк диеп
Утларга үрелдеңме?
Утларга үрелүеңә
Үкенеп өлгердеңме?

Уйларың авырлыгыннан
Сыгылгансың, кыз бала.
Җилләр күпме исмәсеннәр,
Ә гөлләр бит төз кала!
Җил-давыллы бу дөньяда
Син дә бер Гөл, кыз бала.

●

Хатыңда мондый юллар бар:
«Син—миңа, мин—сиңа кирәк».
Әйе, дустым, бу дөньяда
Кирәкмәгән кеше сирәк.
Көчсезгә яклаучы кирәк,
Сансызга санлаучы кирәк.
Моңы барга, зары барга
Аны бер аңлаучы кирәк.
Атасызга ата кирәк,
Анасызга ана кирәк.
Баласызга нәселенең
Дәвамчысы — бала кирәк.
Иптәш кирәк ялгызларга,
Доктор кирәк чирлеләргә.
Сүзен җөпләп көлүчеләр
Кирәк шаян теллеләргә.
Шагыйрьгә укучы кирәк,
Укучыга шагыйрь кирәк.
Таһирларга Зөһрә кирәк
Зөһрәләргә Таһир кирәк.
Әнә шулай гомер буе
Кемдер кемгә була терәк.
Беркемгә дә кирәкмәсәң
Синең яшәү нигә кирәк?!

●

Безнең әле очрашкан юк бер тапкыр да,
Араларда йөреп тора хатлар гына.
Бер-беребезгә юл буласы сукмаклар да
Чишмә башы кебек кенә, тап-тар гына.
Әгәр аның чыганагы тирән булса,
Бара-бара бер киңәер бу чишмәбез.
Саф чишмәләр күп очрамый хәзер җирдә —
Без дә аның суларына ком ишмәбез.
Агар чишмә чуер ташлар арасыннан,
Туктамас ул, гел ашкынып барыр алга.
Адашмыйча, кара урман юлларыннан
Килеп чыгар кояш төшкән аланнарга.
Бәлки акмас бер юнәлеш белән генә,
Борылыр бәлки уңга да һәм сулга да ул.
Тик ышанам, алга таба бара-бара
Килеп кушылыр дуслык дигән елгага ул.
Ә хәзергә безнең әле очрашкан юк,
Араларда йөреп тора хатлар гына.
Бер-беребезгә илтә торган сукмаклар да
Чишмә башы кебек кенә, тап-тар гына.

## Ак диңгез

Кайвакыт кешегә
Кирәк бер бушану.
Иң яшерен уеңны
Кемгәдер ышану.
Тоясың шул чакта:
Ак кәгазь — ак диңгез,
Утырып корабка
Китәсең хыялың
Чакырган тарафка.
Син үзең — капитан.
Кулыңда штурвал,
Куркытмый давыллар
Булса да тугыз балл.
Сөйлисең сереңне
Ярсулы дулкынга.
Самими хисләрдән
Көлүче юк монда.
Ак диңгез тыңлый гел.
Бүлдерми сүзеңне.
Һәм шулай тын гына
Юата үзеңне.
Ак кәгазь — ак диңгез!
Ярлары юк аның.
Йөзәсең — басканчы
Йөрәгең янганын.

●

Синең белән икәү генә калсак
Диңгез уртасында, еракта,
Давыл кубып көймәбезне ватса,
Булмаса һич ярдәм сорап та;
Бар йолдызлар кинәт күзен йомса,
Болытларга кереп ай качса,
Без тотынган такта кисәкләрен
Кулыбыздан йолкып җил шашса,
Күкрәк тутырып һава сулар өчен
Калкып чыгам гына дигәндә,

Өереп алып яңа өермәләр
Ыргытсалар тагын түбәнгә;
Менә-менә кабып йотам диеп
Янап торса дулкын һәр даим,
Шул чакта да үзең бата-бата
Мине коткарырсың, мөгаен.

●

Ипи тәме, тоз тәме,
Йөз нәрсәнең — йөз тәме.
Бутамыйбыз бер-берсен,
Һәрнәрсәнең үз тәме.

Аерсак та ялгышмый
Йөз нәрсәнең йөз тәмен,
Аермыйбыз кайвакыт
Бер тәмне без — сүз тәмен.

●

Көннәр-баскыч, шул баскычтан
Төшәм яки менәм.
Төшүнең дә, менүнең дә
Авырлыгын беләм.
Ләкин әле иң авыры
Менү-төшү түгел:
Вак эшләргә көч куп китә,
Шуңа рәнҗи күңел.

Ә бит гомер үтеп бара,
Гомер — атылган ук.
Мәңгелек бәхет кошына
Һаман тидергән юк.
Эшләгән эшләр вак-төяк,
Максат кына олы.
Әллә вак-төяк ашамы
Зур максатның юлы?!

●

Мин бер агач — җиргә егылып ускән агач,
Минем өскә теләсә кем менә ала.
Теләсә кем ботакның иң биегенә
Тузанланган чабатасын элә ала.

Мин бер агач — җиргә егылып ускән агач,
Балта чабу авырмыни минем сыртка?
Моны киссәм, авып билне сытар диеп,
Маташулар кирәк түгел курка-курка.

Мин бер агач — җиргә егылып ускән агач,
Юк, тормыйм мин башым белән күкне сөзеп.
Буе җиткәч, үткән-сүткән һәрбер кеше
Берәм-берәм яфракларым китә өзеп.

Мин бер агач — җиргә егылып ускән агач,
Буем озын, тик күрмиләр җирдә булгач.
Озынлыгым күренер әле минем дә бер...
Янәшәмә башка агачлар егылгач.

Һәр шигырьне синең өчен язам,
Син яратсаң — миңа шул җиткән.
Кулларыма каләм алдым исә
Күзәтәсең кебек син читтән.
Тоям сине бөтен җаным белән,
Арыналмыйм синең караштан.
Үзем куам, үзем чакырам сине,
Үзем тиргим, үзем яратам.
Син таләпчән, акыллы һәм гадел,
Ташламалар көтмим үземә.
Мин бәхетле — күз тутырып туры
Карый алсам синең күзеңә.
Мин бәхетле сине аңлый алсам
Һәм аңласаң син дә җанымны,
Шатлыгыма чынлап сөенә алсаң,
Кичерә алсаң йомшак ягымны.
Минем хисләр — синең хисләр булса,
Янсак әгәр уртак уй өчен.
Шул чагында бәхетле дип сана
Шагыйрьне син, зирәк укучым.

# УКУЧЫНЫҢ КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕНӘ

**Монгол мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Кара төннәр узгачтын ак карачкы куймыйлар.*

*Сүздә акыллы, ә эштә юләр.*

*Каргага аткан угы керпегә барып тиде.*

*Дәшми торган юләрне акыллы дип беләләр.*

*Акыллы учак кабыза, юләр казанга карый.*

*Аттан төшеп, ишәккә атланды.*

*Яхшыны күрсә, ишәктәй атлый, күбәләк булып, яманга куна.*

*Син аңа ит каптырасың, ә ул кулыңны тешли.*

*Якын дус — бетмәс байлык.*

*Байның алтыны якты, ә эшләре караңгы.*

*Көтүне бүре баса, ярлыны байлар талый.*

*Бүре авызы һәрвакыт канлы.*

*Син аңа кул бирәсең, ә ул терсәктән тота.*

*Ышанычсыз кешенең ни сөйләвен тыңлама.*

*Кайнар су белән юган кер чистарак була, бергәләп хәл иткән эш — гадел дә һәм дөрес тә.*

*Сабый балага сөт кирәк, яшәү өчен — хакыйкать.*

*Дөреслекнең көче зур.*

*Эшең хак икән, дошманнан курыкма.*

*Куяннан көчсез, хаклык та тауларны иш(ә) ала.*

*Ат күрке — чабышта узу, кеше күрке — хак сөйләү.*

Гөлчәчәк Әдһәмова

# ҮКЕНЕЧКӘ КАЛМАСЫН...

КЕЧКЕНӘ ПОВЕСТЬ

*Табигатьтә шундый мизгел бар:*
*Жил тынгач та, яфрак тирбәлә.*

Мостай Кәрим

## I



Кәмил Сабитов йокысыннан куркынып уянды. Бер мәл исен җыя алмый торды хәтта. Кайда соң әле ул? Ни булды аңа? Аннары гына төшенде: һәммәсе саташулы төш икән ләбаса! Фу, каһәр!

Ул уң кулының сырты белән маңгаена бәреп чыккан тирне сөртте, көрсенүле итеп, тирән сулап куйды. Аркасына авыр йөк асып, әллә ничә чакрымны йөгереп узгандай, йөрәге ярсып тибә иде. Күзләрен зур ачып, түшәмгә текәгән килеш, әле генә күргән төшен хәтерләргә тырышып ятты. Йокысы тәмам ачылган иде. Янәшәсендә изрәп йоклаучы хатыны Йолдызга кызыгып та куйды бугай.

Төшендә ул үзенең тау итәгеннән югарыга таба күтәрелеп барганын күрде. Зөя буендагы Кыз тавы да төсле. Идел янындагы Тәтеш тавына да охшаган. Кинәт Кәмил ачыргаланып кычкырып җибәрде: каршысына тоташ таш өере шаулап төшә иде: эреле-ваклы ташлар тоташ агым булып шуыша. Тайпылып өлгермәсә, сытып-изеп узачак... Язмышны мизгелләр хәл кылды. Сабитов, җан ачысы белән талпынып, бер читкә сикерде. Таш агымы аңа сыланып узып китте, әмма зыян-заурәт салмады. Кәмил исән калды...

Төш шунда бетсә-өзелсә, артык тинтерәтмәс тә иде. Юк шул, яңа дәһшәт өстәлде. Тау астында аның күптәнге хезмәттәше, район мәгариф бүлеге мөдире Самат Асылгәрәев басып тора икән бит. Ташларның аны сытуы мөмкин! Шушы фаҗиганы абайлап алуга, Кәмил бар көченә кычкырмакчы булды:

— Самат Харисович! Китегез, бер читкә тайпылыгыз! Самат Харисович! Китегез, бетәсез...

Юк, кычкыра алмады, тавышы чыкмады. Күпме өзгәләнеп тә ярдәм итә алмагач, Кәмил күзләрен чытырдатып йомды, үз-үзенә хисап бирмәстән, чәчләрен учлады...

Уянып киткәндә, тырнак очлары, әйтерсең, ике учына батып кергән сыман иде.

Самат Асылгәрәевнең йөрәк авыруыннан кинәт үлеп китүе, гаиләсендәге матәм тетрәнүе Кәмил Сабитовны — район үзәге Акташтагы

Кыскартып басыла.

беренче урта мәктәп директорын — сугып мингерәткән кебек итте. Дус иделәр, киңәшләшеп эшләделәр. Кордашларча бер-берсен ярты сүздән аңлашалар иде. Менә шул кеше-кордаш һәм житәкче иптәш хәзер юк инде... Сагынып сөйләргә генә калды. Аны җирләгәннән соң өч-дүрт көн үтүгә, Камилне партия райкомына чакырттылар. Беренче секретарь янына. Район советы башкарма комитеты рәисе дә шунда иде.

Хәл-әхвәл сорашуга, үгезне мөгезеннән алдылар.

— Камил Әхмәтович,— диде райком секретаре гадәтенчә тыныч тавыш белән, басынкы гына итеп.— Ник чакырганыбызны төшенәсез дер дип беләм.— Секретарь саран гына елмаеп куйды. Ни гаҗәптер, бу елмаю аның йөзен яктыртып җибәрү белән бергә житдилеген дә күрсәтә төште.— Рононы кабул итәргә туры килер сезгә. Районда Анатолий Васильевич Луначарскийның варисы булырга...

Район мәгариф бүлеген җитәкләү дигән фикер, партия райкомы бусагасын атлап кергәндә, уена килеп тә карамаган иде Камилнең, әмма ул житәкчеләрнең бу тәкъдименә хәйран калмады. Мәгәр ризалашырга да ашыкмады.

— Сөләйман Шәйхиевич,— диде ул секретарьга, сүзләрнең иң кирәклесен сайларга тырышып.— Мондый ышаныч белдерүегезгә, дөресен әйтим, сөендем. Сезгә дә рәхмәт, Вильдан ага.— Сабитов райбашкарма рәисенә карап баш иеп куйды.— Шулай да бик үтенеп сорыйм, мине мәктәптән аермасагыз икән. Тырыша-тырыша эшне көйләп бара идек кебек.

— Анысын беләбез,— дип гөлдерләде Вильдан Сабирович.— Күз алдында бит. Белем-тәрбия бирүегез менә дигән. Укучыларга механизатор белгечлеге биреп чыгаруыгыз да әйбәт! Быел гына да райүзәк колхозы хәзерлекле тугыз егет алды...

Сөләйман Гафуров район советы башкарма комитеты председателенең һәркемгә мәгълүм нәрсәләрне кабатлап торуын өнәп житкермәде булса кирәк, чырай сытып куйды шикелле, ләкин аның сүзен бүлдермәде. Андый чакта бик ипле ул, җай белә, рәт белә. Вильдан Сабирович. сүзенә нокта куйгач, ялгап киткән кебек кенә әйтте:

— Бүгенгә хәтле, Камил Әхмәтович, бер урта мәктәптә эшне көйләдегез. Хәзер райком сезнең иңнәргә районның бөтен мәктәпләрендә дә эшне тиешле югарылыкка күтәрү бурычын сала,— диде.— Һәммәсен уйладык, үлчәп карадык шикелле, ризалыгыгызны көтәбез.

Гафуров урыныннан торды, бүлмә буйлап йөренеп алды. Шул чак телефон чылтырады. Секретарь трубканы күтәрде:

— Исәнмесез, исәнмесез! Сезнең белән бик сөйләшәсем бар, иптәш Иштуганов. Тик, зинһар, гафу итегез, ун-унбиш минуттан, үзем шалтыратырмын!..

— «Гигант»танмыни? — Вильдан сорамый калмады.— Терелгән алайса?

Сөләйман урынына килеп утырды һәм, үзалдына сөйләнгәнгә охшатып, әйтә куйды:

— Авырырга түгел, арырга да рөхсәт юк. Сиксәненче ел җәе бу... Иртәгә август керә. Шул сүз һәммәсен аңлатадыр. Урып-җыю, ашлык сату һәм...

Гафуров, бер тын сүзен бүлеп торды да, тавышын күтәрә төшеп, Камилгә төбәп сөйләп китте:

— ...Һәм мәктәпләрдә яңа уку елына соңгы хәстәрлекләрне күрү, әйеме, Камил Әхмәтович?

Камил җилкәсен генә жыерып куйды, сүз әйтмәде. Секретарь исә баягы фикерен түгәрәкләп:

— Мәктәпләрдә эш муеннан әле,— диде.— Төпкә җигелеп тарту бик таманга гына булыр. Бюро фикеренә җавабыгыз нинди инде, иптәш Сабитов?

— Уйларга, уйлашырга кирәк әле, Сөләйман Шәйхиевич. Бүтән кандидатура хакында исәп йөртмәдегезме?

Сөләйман көмеш җепләр белән аралаша башлаган чем-кара куе чәчләрен сул кулы белән артка сыпырып куйды да торып басты. Аның кояшта янган тулы түгәрәк йөзендә интеллигентлык нуры яктыра. Ул нур аның мөлаемлыгыннан, килешле елмаюыннан, хәтта тавыш тембрының үзенчәлегеннән сизелеп тора шикелле иде. Үз фикерләрен ул һичничек көчләп такмыйча бәян итә, ышандыру көченә ия булган логикага таянып аңлата. Ләкин бу юлы Камил сүзләренә каршы берни дә сөйләп китмәде, сорауга сорау белән җавап кайтарды:

— Сез, мәсәлән, кем кандидатурасын тәкъдим итәр идегез?

— Минме? — Камил да урындыгыннан күтәрелде.— Минем ихтыярымда булса, Нурислам Габделбәровны куяр идем мөдир итеп...

Райком секретаре моңа да бик җайлап җавап бирде.

— Бу хакта да сүз булды,— диде һич сер итмичә.— Әйбәт педагог, сезнең уң кулыгыз. Дүртенче ел директор урынбасары, әйеме?

Камил өчен Вильдан Сабиров җавап кайтарасы булды:

— Әйе, өч ел эшләде.

— Шулай да...— Сөләйман Гафуров сүзен өзеп торды.— Шулай да район мәгариф бүлегенә җитәкчелек итү эшенә иртәрәк әле. Ә менә сезнең урынга директор була алачак. Аңладыгызмы? Уйлашыр өчен нигә сәгать вакыт кирәгер сезгә?

Секретарь мәсьәләне шулай кырт кисеп куйгач, Камил ни диярга дә кыенсынды.

— Сәгать дип... Алай ансат кына түгел бит миңа, Сөләйман Шәйхиевич...

Гафуров тимерне кызуында сугарга ярата иде.

— Озын-озак сатулашыр чак түгел, иптәш Сабитов. Командир сафтан чыкканда, күп сүзгә урын була алмый.

— Ул кадәресе фронт шартларында бит аның, Сөләйман Шәйхиевич.— Камил һаман әңгәмәнең бүтән юнәлеш алуына өмет баглый иде бугай.

— Монда да фронт, иптәш Сабитов.— Гафуров тавышында әлегәчә сизелми торган кырыслык чагылып китте.— Монда да фронт: белем фронты, коммунистик тәрбия, идеология фронты. Сез моны миннән һич тә ким белмисез..

— Әтиең булса — Әхмәт абыйны әйтәм — бик тиз тәвәккәлләр иде.

Райбашкарма рәисе ерактан суктырып үгетләргә керешмәкче иде ахры, Сөләйман Шәйхиевич сүзне кыска тотты:

— Иртәгә мин колхозлардан йөреп кайтуга райкомга килсәгез икән, Камил Әхмәтович. Сәгать унга. Килештекме?

Вильдан Сабиров та секретарь бүлмәсеннән Камил белән бергә чыкты. Кабинетта әйтеп өлгермәгәнен коридорда сөйли барды. Камилнең әтисен Ватан сугышы елларыннан белә. Япь-яшь солдат көенчә Сталинград янында политругы Әхмәт Сабитов булган ротага эләккән ул. Политрукның һәлак булганын үз күзләре белән күргән...

Камил төшенә Самат Асылгәрәевнең керүе кичәге әнә шул сөйләшүләр тәэсиреннән булгандыр, мөгаен...

Иртәнге чәй янында сүз гадәттәгедән узмады. Йолдыз һәрвакыттагыча ирен дә, быел унынчы класска барачак улы Ниязны да кыстыйкыстый ашатты-эчерде. Өстәл яныннан торуга, Нияз мәктәпкә ашыкты. Ул кабинет җиһазлары, парталар ремонтлау өчен укучылардан төзелгән группада эшли иде.

Камил дә эшкә чыгып китәргә җыена башлады, ләкин аны күзгә күренмәс ниндидер бер җеп җибәрми тартып торды. Ул җеп — хатының өзеп әйтеп бетермәгән сүзе, биреп җиткермәгән киңәше.

Кичә эштән соң райкомда әйтелгән тәкъдим турында сүз чыккач, Йолдызның кәефе китте: кара тутлы ябык йөзенә ризасызлык галәмәте калыкты, юеш карлыгандай елтыр кара күзләре кысыла төште, кыйгач кашлар борын өстендә бергә кушылгандай булды, юка иреннәре үпкәләгән сабыйларныкы кебек бүлтәйде. Әмма, ничек кенә булмасын, бу иртәдә сөйләшәсен сөйләшеп бетерергә кирәк иде.

— Мин дә китәм, Йолдыз,— диде Камил кичтән бүленеп калган сүзне ялгарга теләп.— Сәгать унга райкомга! Син үз фикереңне тәки әле әйтмәдең...

— Тыңламаган кешегә сөйләү мәгънәсезлек икәнен аңладым инде мин.— Йолдыз шулай дип өзде дә куйды. Аның муен тамырлары бүртүеннән тагын үртәлә башлаганын күрү кыен түгел иде. Күкрәгенә төшкән озын чәч толымын артка алып ташлады да бер кирәксезгә чигә чәчләрен сыпырып куйды. Йөзенә кызыллык йөгерде. Төз борынының яфраклары сизелер-сизелмәс кенә дерелдәште.

— Соң син, Йолдыз, әйттем — бетте дип, үз фикереңне генә туп-туры хакыйкатькә санама әле. Кил, утыр, тыныч кына уйлашыйк.

Камил зал ягындагы өстәл буена барып утырды. Теләр-теләмәс кенә килеп, Йолдыз да иренең каршысына урнашты.

— Миннән дә якын кемең бар синең? — Камилгә сорау угы атылды.— Әйт, зинһар, кемең бар?

— Бер кемем дә югын беләсең...— Ире моны түгәрәк йөзен әз генә читкә борыбрак әйтте.

Йолдыз терсәкләре белән өстәлгә таянды, учларын яңакларына куйды. Читтән берәрсе килеп караса: «Тешләре сызлый микән әллә бу бичараның?» — дияр иде. Тешләре түгел, күңеле сызлый иде аның. Гомер юлдашына үз үгетен кертә алмаганга ачыргалана иде.

— Аңла, Камил,— диде ул, эчке ярсынуын тыярга тырышып.— Синдә әлегә мәктәптән китәргә кирәкми. Күпме көч салдың, ә тиешле бәясен ишеткәнең юк.

— Тырышканга күз йоммыйлар анысы...— Камил райком секретаре Сөләйман Гафуров сүзләрен хәтерләде:— «Бер урта мәктәптә эшне көйләдегез». Райком да, райбашкарма да белә. Министрлыкта да хәбәрдәрлар...

— Шуның белән вәссәлам! Кемнәрдер орден ала, атказанган дигән исемгә лаек була...

— Мондый нәрсәнең беркайчан да минем принцибым була алмаганын белә торып сөйлисең бит, Йолдыз. Партия райкомы кирәк дип тапкан икән...

Хатыны уң кулын өстәл аша сузып, кискен хәрәкәт ясап, аның сүзен бүлдерде.

— Тыңла, мин әле иң мөһимен әйтмәдем.

— Тыңларга дип утырдым.

— Шәрә принципларыңнан ваз кичмәсәң, эшеңә югары бәя көтмә дә син. Икенче мәктәпнең директоры нигә почетта? Өлгереш сыйфатын бирә белә, «дүрт»кә, «биш»кә генә укучылары ничә процент аларның? Дәшмисеңме? Менә шул. Ә синең үз сүзең генә аткан ук та каккан казык. «Миңа чын белемләр кирәк! Үземне дә, илне дә алдыйсым килми»,— имеш. Чын белем дия-дия, коллективны икеләтә җигәсең, ронога күчсәң, бөтен мәктәпләрдән шуны даулый башлаячаксың бит. Район буенча төпсез көймәгә утырасың әле син... Дипломатия дигәннең «д» хәрефе дә юк бит синдә...

— Беттемме?

Камил дә Йолдыз сүзләренә намусына тукыну тоеп, никтер йөрәксенә башлады шикелле.

— Юк әле, бетмәде. Сабырсызланма. Алдан ук искәртәм, анда күчсәң, диссертация турындагы хыялларың белән саубуллаш. Менә

сиңа укучыларның хезмәт берләшмәләренең профориентациядәге роле... Башың район мәктәпләреннән кайтып кермәячәк...

Камил артыгын тыңламаска риза иде инде.

— Мин җиңел булыр димим, әмма өркеп калырга да уйламыйм. Рононы да кемдер җитәкләргә тиеш.

— Алайса — ихтыярың...

Кичләтеп Камил Сабитов белән Нурислам Габделбәров Казанга, Мәгариф министрлыгына юл алдылар. Камил — район мәгариф бүлегенә мөдир булып раслану, Нурислам аның урынына директор булып билгеләнү өчен киттеләр.

Тимер юл вокзалына килеп төшкәндә, алар китәсе поезд белән Казаннан Волгоградка баручы состав икесе дә станциядә иделәр. Нурислам кассага йөгерде. Вагонга шабыр тиргә төшеп килеп керделәр.

Азрак сулу алгач, Нурислам, кабарып торган соргылт бөдрә чәчләрен сыйпаштыргалап, кысыграк соры күзләрендә хәйлә очкыннары ялтырата-ялтырата, һич көтелмәгәнчә сүз башлады:

— Станциядә поездлар еш очраша... Ә менә шушы минутларда гына элекке гашыйклар чак-чак очрашмый калды,— диде. Болай да зур авызы колакка җитәрдәй булып ерылды.

— Нәрсә дидең? — Ул үз янәшәсендә кинәнеп елмаеп торган Габделбәровка сәерсенеп карады.— Нинди гашыйклар?

Нурислам, үчекләшү комарлыгы кузгалган азгын малай төсле, беравык елмаеп торды. Күренер-күренмәс вак шакмаклы кара пинжәге кесәсеннән кулъяулыгы алып күзлек пыялаларын һәм кызарган, тирләп чыккан битен сөртте. Аннары гына сорады:

— Вокзал буенда әүвәлге танышларыңнан берәү дә күзеңә чалынмадымы? — диде.

— Юк. Ә кем бар иде соң анда?

Габделбәров, сөенчегә ни бирәсең дигән кебек, башын кыңгыр салып тагын бераз карап торды да, галәмәт зур сер чишкәнгә охшатып:

— Зөһрә кайтып төште! — дип пышылдады.

Камил Сабитов бу исемне ишеткәндә беркайчан да битараф кала алмый, бу юлы да шулай булды.

— Чынлапмы? — диюен тоймый да калды.

— Әйе!

Камил сүз озайтмады. Торып басып кесәсендәге «Беломор» кабын, шырпысын капшап барлады, вагон ишегендәге көзгегә карап, асфальт төсендәге затлы пинжәгенең чабуларын тартып куйгандай итте, буй-буй бизәкләре беленеп торган ап-ак күлмәк өстенә зәвык белән сайлап тагылган галстугын рәтләп куйды да тамбурга юнәлде. Буе-сыны төз, йөреше килешле, куе кара чәчле, сыланып торган кара кашлы, керфекләре озын зур, кара күзле, ихтыяр көчен белдереп бераз алгарак чыгып торган нык иякле бу кешегә, аны әле беренче күрүчеләрнең күбесе нигәдер аеруча зур игътибар белән карады.

Тамбурда — сирәк була торган хәл — аулак иде.

Көтелмәгән хәбәрдән кинәт тирән уйга чумган Камил ярсынырга торган хисләрен баса алды алуын, ләкин йөрәк авыртып, җан сыкрап тора. Шул ук вакытта үзәккә төшәрдәй әрнү катыш татлы сагыш күңелдән дөнья мәшәкатьләрен кысрыклап чыгарды, бер мизгелгә рәхәт булып калды. Поезд радиоузелы концерт тапшыра иде. Магнитофон тасмасына язылган җыр күңелгә уелганнар белән ярәште-берләште сыман.

...Сүнсә сүнсен утлар, йолдызлар да,
Миндә әле сүнмәс өмет бар.

Шул ләззәт эчендә Камил яшьлегенең татлы, газаплы ядкаре итеп саклаган Зөһрә җырын исенә төшерде.

Якты көнем, серле төнем,
Кояшым син, аем син...

Еракмы, якындамы, җир йөзендә йөрәгеңә якын кадерле кешең булу — фәкать үзеңә генә билгеле ярым татлы, ярым моңсу хис чыганагы ул. Аны искә төшерсәң, сиңа яшәү өмете өстәлә, җан-тән җиңеләя, акыл зирәкләнә сыман, канатлар үскәндәй тоела... Яшьлектә кабынган күңел учагы язмыш шаяруы аркасында эчкә яшерелеп тә, сүнмичә, еллар аша үзенең җылысын да, яктысын да сиздерергә кодрәтле икән — бу табигатьнең бөек бүләге. Җитди эшләргә колачы житкән, тирән кичерешләргә ия бай рухлы шәхес кенә бу хәзинәне сакларга сәләтледер. Камил Зөһрә турындагы кадерле хисләрен кем беләндер уртаклашудан ерак. Кемдер аңа кагылырга батырчылык итә алса, ул хис — вакланыр, арзанаер иде кебек...

## II

Зөһрә, Зөһрә, Зөһрә... Ул минем үткәнем, ул минем яшьлегем, ул минем гомер маягым!

Камил газаплы да, ләззәтле дә уйлардан арынырга талпынгандай, хәзерге тормышын күздән кичерде. «Йолдызның кай җире Зөһрәдән ким соң, ә ник болай өзгәләнәм соң?» — дип күңелен юатты. Ни өчен? Кем аңардан хисап сорый? Кем каршында аклана ул? Нигә кирәк бу чагыштыру?

Камил үз-үзе белән, җаны белән аңгәмә корды. Әйе, без гадәтләнгәнбез. Күңелебезгә хыянәт итәбез, яраклашабыз, җайлашабыз, шулай булырга тиеш дип үзебезне билгеле бер кыса эченә биклибез. Башкаларга шулай дип сөйлибез. Кешеләргә әйтеп була, ә менә үз-үзеңә, эчке бер җаваплылык белән җаныңны чистартып, вөҗданыңа турылыклы булып әйтеп кара!

Әйе, үткәнгә кире кайтып булмый, шул ук вакытта аны сызып ташлау да мөмкин түгел. Яшьлек үзенең эчкерсезлеге белән изге ул! Никадәр җыр, никадәр шигърият, никадәр күңел җәүһәрләрен үзенә тупларлык көч-куәт бар аңарда! Яшьлек Зөһрә образына тоташып күз алдына килә. Зөһрә үзенең сылулыгы, тик Камилнең үзенә генә таныш елмаюы белән аңа тынгылык бирми. Хәзер, менә шушы минутта, Зөһрәне үлеп күрәсе килә аның, әйтеп аңлатып бетереп булмый торган дәрәҗәдә күрәсе килә...

Камил хәтерендә педагогия институтында укыган чаклары яңарды. Зөһрә дә, Камил белән Нурислам да борынгы атамасы әле дә онытылып җитмәгән тулай торакта — «монастырь»да, яшиләр иде.

Алар — райондашлар. Зөһрә Нигъмәтова — район үзәге Акташтан дүрт-биш километрдагы Гөлле Борас авылы кызы. Камил Сабитов, Нурислам Габделбәров кебек үк, Зурләки дигән авылдан.

Кыскасы, алар өчесе дә бер елны педагогия институтына керделәр. Габделбәров физика-математикадан башка фәннәрне әллә ни санга сукмый иде, яраткан шул факультетын сайлады. Камил исә өлгергәнлек аттестатын район үзәгендәге мәктәптә алды. Аннары өч ел армиядә. Демобилизацияләнгән егет педагогия институтының тарих бүлегенә конкурссыз узды.

Әмма авылдаш егетләр чак кына мәхәббәт көндәшләре булмый калдылар. Икенче курс азагында Нурислам Зөһрә тирәсендә бөтерчектәй бөтерелеп бакты, мәгәр «йөзем җимешләре пешмәгән» булып чыкты. Имтиханнар башлангач, июнь таңнарының берсе сызылып атар алдын

нан, тулай торак бүлмәсенә кайтып яткач, ул Камилгә зарын сөйләде.

— Шәп кыз, чукынчык! Чибәрлек дисәң, өзелеп чыккан. Акыл дисәң — хәзинә. Ну... ну тәртәсе кыска. Бәясен бик белә, — диде.

— Бәясен «бик белгәннәрнең» сазаган кыз булып утырып калганнары күп була, диләр.— Камилнең авылдашы сөйләгән аһ-зарга җавабы шул булды. Аннары бу хакта бүтән сөйләшмәделәр.

Ә өченче курста укый башлагач, Камил үзе Зөһрәне чын-чынлап якын итте. Башы болай булды.

Октябрь урталары иде. Төп бинадагы вестибюль стенасына бик зур итеп «Яшен» чыгарып элгәннәр. Үткән-сүткән студентлар барысы да шунда туктала. Тукмактай хәрефләр белән «Котлыйбыз!» — дип язганнар. Аннары Ленин стипендиясенә лаеклы булган отличник-активистларның фамилияләре тезелеп киткән. Бишәү, шуларның берсе — Камил Сабитов. Җәяләр эченә: «Тарих бүлеге. Институтның ВЛКСМ комитеты члены. Студентларның фәнни җәмгыяте председателе урынбасары»,— дип тә куелган.

Камил, комсомол комитетында тикшереләсе ниндидер мәсьәләләр турында киңәшергә дип, парткомга менеп бара иде, ай-кояштай балкып үзенә таба килүче Зөһрә Нигъмәтованы күрде.

— Котлыйм, якташ! Чын күңелдән!— диде Зөһрә, үзе өчен сөенгәннән дә тегеләйрәк канатланып.— Ой, бәхет! Ой, бәхет!— Кыз Камилнең кулын кысты.

Егет сәер генә елмайды. «Ой, бәхет!» дигәне ни нәрсә аңлатканны ул тәгаен генә төшенми иде кебек. Аннары Зөһрәнең күзләренә текәлде һәм зәңгәр чәчкәләрне, юк ла, зәңгәр күкне, юк алай да түгел, тирән, серле, саф сулы зәңгәр күлне хәтерләткән сихри карашлы күзләрдә үзен күрде. Кызга ул соклануын яшерә алмыйча томырылып карады. Зөһрә хәтта башын ияргә мәҗбүр булды.

Егет табигатьнең сирәк бүләге булган шушы нәзакәтле җан иясенең әсиренә әйләнә баруын акылы-зиһене белән генә түгел, тәненең һәммә күзәнәге белән тоеп торды. Шул мизгелдә Камил Нурисламның «Чибәрлек дисәң, өзелеп чыккан» дигәнен хәтерләде.

Зөһрәне күргәч, шул рәвешле соклану, билгеле инде, берничә секунд эчендә булып алды. Кызның тәбригенә каршы җавап эзләп, Камил дә кесәгә кермәде.

— Бик рәхмәт, якташ, рәхмәт! Зөя буеның асыл кызларыннан котлау сүзе ишетү зур бәхет,— диде. Аннары шунда ук, әйтергә кичекмәгәем дигән төсле ашыгып өстәде:— Без бүген, Зөһрә, Мәскәүдән сөенечле хәбәр килүне билгеләп үтәргә ниятләдек. Авырсынмасаң, вакыт табалсаң һәм, әлбәттә, теләгең булса...

Менә шунда инде егетнең көймәсе комга утырды. Тотлыкты да калды ул.

— Нәрсә?— Зөһрәнең шул соравы җитте тагын, Камил тәкъдимен түгәрәкләп куйды.

— Сине шул кичкенә мәҗлескә кунак итеп чакырам.

Экспромт иде бу, үзен котлаган минутта туган яңа фикер иде. Исемле стипендиатлар мәҗлесенә ялгызы гына барырга чамалаган иде егет. Зөһрә тикле Зөһрә дә, алыштырып куйгандай, ялындырмады, назланмады, ризалашты да куйды.

Ул кичне алар «Таң» ресторанының кечкенә генә банкет бүлмәсендә утырдылар һәм студентлар мәҗлесеннән икесе дә бик канәгать булды. Дуслашып китүнең чишмә башы әнә шул иде. Өченче курсны бетергәнче су сипсәң дә аерылмас булып йөрделәр. Дуслары-иптәшләре, курсташлары аларның мөнәсәбәтләренә сокланып бетә алмады. Шунысы кызык, кыз да, егет тә телләреннән «яратам!» дигән сүз ычкындырмадылар. Әлеге сүз һәр икесе өчен дә чиксез кадерле, чамасыз изге иде бугай. Ә үзара килешүләре нык иде: бер-берсенә карата мө-

нәсәбәттә энә очы кадәр дә ялганга, икейөзлелеккә юл куймаска, фәкать дөресен генә сөйләргә!

Килешкәнчә килеп тә чыкты. Дүртенче курста укулар башланган көнне Зөһрә зәп-зәңгәр күзләрен һич йоммыйча әйтте дә салды Камилгә: «Мин офицер егеткә гашыйк булдым. Ул да мине ярата»,— диде. Башына бастырык белән органдай телсез-өнсез торган Камил уңнысулны абайлый башлаганчы, әйтәсен әйтеп тә бетерде. Офицер егет Казанныкы икән. Отпускага кайткан. Киткәндә Зөһрәне алып китәсе — ул читтән торып укуга күчәчәк.

— Шаярҭасың! Мине сынап каравыңмы бу? Юкка маташма, мин солдат кеше!— дип тә карады егет. Кыз хәтта ачулыга әйләнде.

— Честное комсомольское!— дип, елар дәрәҗәгә җитеп тулышты.

Бу сөйләшү паркта булды. Тын аллея буендагы эскәмиягә утырып сөйләштеләр. Зөһрәнең «честное комсомольское»сыннан соң Камил безгә кадалган шикелле сикереп торды.

— Үтерәм мин синең ул офицерыңны!— Тавышы үз колагына да кыргый, ят аваз булып ишетелде.

Зөһрә, Камилгә карап, шулкадәр мыскыллы елмайды, егет чыдамады, карашын читкә борды. Ә кыз теш арасыннан сыгып чыгара-чыгара өзеп әйтте:

— Булмас нәрсәләр белән хыялланып маташма. Кисәтеп куям: ул беренче разрядлы боксер,— диде. Монысы инде егылганны йодрыклау, кан саркыган җәрәхәткә учлап тоз сибү иде... Тулай торактан култыклашып чыгып киткәннәр иде, аерым-аерым кайтып керделәр.

Ләкин... монда тагын бер «ләкин» бар әле... Бер ай да үтмәде, Зөһрә Камил каршына килде: «Булдыра алсаң, гафу ит, Камил. Мин аны яратмаганмын. Сине күңелемнән сызып ташлый алмыйм»,— диде. Кичерәям, түбәнсенәм, сер бирәм, сынатам дип тә тормады, егетнең күкрәгенә капланып елады.

...Юллар аерылды. Эшкә билгеләүләр алдыннан Камил Зөһрә Нигъмәтова белән бер группада укучы Кукмара кызы Йолдызга өйләнде. Өйләнештеләр һәм Акташтагы беренче мәктәпкә эшкә киттеләр. Уллары туды. Шул Нияз быел унынчы класста укыячак... Күп еллар узды, тик яшьлек язында шыткан хисләр сүнмәде, сүрелмәде. Менә бүген дә Зөһрә исемен ишетү Камил йөрәгендә нинди зур өермә кузгатты...

## III

Беренче августтан отпускысы беткән укытучы, үзе моны телиме-теләмиме, асылда август киңәшмәсенә кадәр килән сарып йөрергә мәҗбүр: мәктәпкә килә — китә, коллегалары белән гәпләшә, артык ватылып эшләмәсә дә, яңа уку елына хәстәрлек чаралары күрә.

Хәлимә Хәбировнаның да шундый көннәре иде. Кәефе искитмәле — аяз көн төсле. Алай дию генә дә аз. Аллы-гөлле, чәчәкле-бизәкле аның кәеф-шәрифләре. Куанычы кырга сыймый. Ире галәмгә очкач, космонавт хатыны да бу тикле шатланмыйдыр — һәрхәлдә, аның сөенече хәвеф белән аралаш була бит инде. Ә Хәлимәнең ире — Нурислам Галиевич космос төпсезлегенә китмәде, Казан Кремленә генә юл тотты, хафаланасы юк. Герой булып кайтмый ул, билгеле. Ә менә урта мәктәп директоры булып кайтачак! Ди-рек-тор! Хәлимә Хәбировна — директор хатыны. Бу инде, беләсегез килсә, уен-муен түгел. Бу инде, аның уенча, мәктәп коллективының тезгене Нурислам Габделбәров кулында булса, дилбегәсен Хәлимә Габделбәрова тота дигән сүз. Ягъни Нурислам Галиевич директорлык арбасына җигелә, Хәлимә Хәбировна дугадагы кыңгырау булып чыңлый башлый. Ә кыңгырау чыңы, гадәттә, ерактан ишетелә. Алдан ук хәбәр итәргә ашкынгандай, аваз салып

бара. Шулай булмый хәле дә юк. Нурисламның үзенә генә ышансаң... Кем ни әйтсә, шуңа ианыр. Ни дип үгетләсәләр, шуңа күнәр. Моңа юл куярга һич ярамый. Дилбегә Хәлимә кулында булыр. Шулай кирәк. Ирләр һәр даим хатыннары акылына мохтаҗ алар. Ир-атта хатын-кыз тоемының әчмухасы да юктыр әле бәлки... Инде моннан соң Йолдыз Ярулловна да Хәлимә белән бүтәнчәрәк сөйләшә башлар. Дөрес, аның ире янә дә бер басмага күтәрелә күтәрелгән. Әмма ләкин безнең мәктәп өчен ул хәзер килсә — кунак, китсә — ерак. Йолдыз Ярулловна, Камил Әхмәтовичның чабуына ябышып, ронога барып утыра алмый ич. Мәктәптә кала. Ә мәктәпкә Габделбәров житәкче. Мөһим эшләр буенча иң ышанычлы киңәшчесенең күрсәтмәләренә таянып...

Үз гөмбәзе биеклегеннән торып, Хәлимә әнә шулай сөенде — канатланды, хыял дәрьясында йөзде. Көтмәгәндә аның күңеленә очып кунган куаныч кошы күкрәк читлеген бик тә тарсынды, тышка бәреп чыгарга дип тәкатьсезләнде. Кем беләндер сөйләшәсе, серләшәсе килү кытыгы тәмам кычуга әйләнде. Бүгенгесе көннән, һич югы иртәгәдән ул бит инде беренче урта мәктәптә биология укытучысы гына түгел, директор хатыны да!

Куанычын исбатлау әмәлен дә тапты Хәлимә. Башлангыч класслар укытучысы Нәзирәне аулак чәе эчәргә үзләренә чакырды.

— Әйдә әле, Нәзирә, безгә кайтыйк,— диде ул, мәктәптә буй-сынын күрсәтеп, теплица тирәсендә беркадәр йөренгәч.— Аулак чәе чәйләрбез. Нурислам абыең бу сәгатьләрдә министрның үзе белән сөйләшеп утыра булыр, без үз түребездә хозурланыйк бер. Ашыгыч эшең юктыр бит?

— Юк алай,— дип бик тиз ризалашты яшь укытучы. Яңа директор хатыны олы башын кече итеп үзе чакырып торганда, ник бармаска да, ник чәйләмәскә?

Габделбәровлар Акташта үзләре житкереп кергән алты почмаклы өйдә торалар. Ак мунчалары бар. Каралты-кура нык. Алма бакчалары — бер дигән. Өй тулы заманча җиһаз. Чисталык идеаль дип әйтерлек. Хәлимә өйдә үзе дә ат урынына эшли, кызларына да тынгы бирми.

Электр самавыры гөжләп кайнап чыкты. Түр як өстәлгә җиләк-җимеш килде, таба ашлары куелды һәм суыткычта зарыгып утырганлыктан бик тиз парланып киткән акбаш-шешә килеп кунаклады. Билгеле инде, ансыз дөнья сансыз...

— Би-и-ик тә тансык кунакка дигән энзе инде бу, кем, Нәзирә. Неприкосновенный запас дигәнем. Әйдә авыз итеп карыйк әле. Нурислам абыеңның тәпиләренә шифалы су бөркү булыр...

Хрусталь рюмкалар чыңы күңеленә хуш килдеме — Хәлимә кеткелдәп көлеп куйды. Сул бит уртасындагы бердәнбер шадра ясмыгы көлгәндә хасил булган чокырчыкка кереп югалды. Аннары ул кинәт житдиләнеп калды. Эскәк-мазар тимәгән куе, ләкин килешле генә кашлары җыерылып килде, коңгырт күзләренә суык бәреп чыккан сыман булды. Кан тибәргә торган калын иреннәр чөмәкәйләнеп рюмкага үрелделәр.

Маникюрлы бармак очлары аракы тулы рюмканы да кызартып күрсәтә иде кебек. Хаклык өчен әйтик, Хәлимә Хәбировнага тырнак кызарту елына бер генә, отпуск бетеп эшкә чыккан көннәрдә генә эләгә. Кем белсен, бәлки, директор хатыны булгач, косметикага да дикъкате арта төшәр?!

Эчә белеп эчеп җибәрде Хәлимә. Бик шома юлдан шуып төште «шифалы су». Алай да сискәндерми калмады. Тамак кыра-кыра торып ук басты. Иңнәрен уйнатып боргаланып алды. Хуҗабикәнең тулы тыгыз гәүдәсе сокланып, ымсынып, томырылып карар күзләргә мохтаж иде.

Нәзирә дә сынатмаска маташып баккан иде, булмады, тончыга язды.

— Һи-и-и, болай булмый, ярамый, Нәзирә. Һаман эчәргә димәгән диюен, алай да кабып куйганда сының сынса да сынатмаска кирәк. Мин үзем дә бик сирәк тотам болай моны...— Хәлимә Хәбировнаның кәефе кыйбла тарафларына борыла башлады бугай. Хәлимә апасының «энзе»ләре бетеп тормаганын да, ни чамада «бик сирәк» икәнен дә Нәзирә бик белә. Шулай да ул каршы сүз әйтми, елмая, тел тибрәтеп сүз озайтыр чак түгел. Хәзер Хәлимә ханымның положениесе бүтән булачак. Үзләрендә сыйланып утырганда, күп белгән булып, телдәрләнү бөтенләй урынсыз.

Бәллүр рюмка кызыл тырнаклы бармаклар арасыннан кысылып чыккач, Хәлимә ханым йомшый язды. Тик бу йомшау мәлҗерәү түгел, комарлык арту гына иде.

— Әйдә, кадалсын, булмаса — булган икән, җиппәрик тагын берәрне!— диде ул.— Абзаң Казанда, кызлар әниләрдә. Аулак тек аулак, сал әйдә...

Нәзирәгә кушкан кебек әйтсә дә, шешәгә Хәлимә үзе үрелде, тамчысын да читкә тамызмый рюмкаларга хәмер койды һәм:

— Әйдә, ашап эч, акча җимеше түгел, бакча җимеше, менә бу свиҗи балны да авыз ит, совхоздан китергәннәр иде, умарталыктан,— дип кыставында булды. Чынында бу риялану иде.

Тагын берәрне өстәгәч, Хәлимә Хәбировнаның күңеле тәмам да җебеде. Җыр дәрте кузгалды. Тимергә тимер тигәндә чыга торган яшелле-зәңгәрле тавышы белән җырлап җибәргән булды.

Сигезенче март хатын-кызны
Азатлыкка чыгарды.
Колхозница күлмәк кигән
Зәңгәрле дә чыбарлы.

Җырны азагыннан башлап, беренче юллары белән тәмамлап кую үзе үк нидер сөйли иде инде. Нәзирә үзенә кирәкле сүзләрне сөйләшү ягын каерды. Сүздән сүз чыга торды.

— Хәлимә апа, җаным, сигезенче март дигәннән, безнең каладагы апай кызының кияве Нижнийкамскида бик тә зур урында бит. Юк нәрсәләре юк. Шулар әллә нинди яңа фурмы холодильник алганнар, кая соң әле эттәгенәсе, исемен шунда язып кыстырган идем.— Сумкасын актарып, язуны сузды.

— Минск-12, я шуннан...

— Шуннан шул, сез инде безнең арка таянычыбыз, минем ужым бозавыннан була торган эш түгел, Габделбәров абый тапмый калмас, син әйтсәң дим инде. Кияүләр берәр бәйрәмдә безгә киләбез дигәннәр, шулар алдында ким булмыйк дигән идем, әй!? Хәлимә апа, җаным дим, Габделбәров абый синең сүздән чыкмый инде ул. Ир — баш, хатын — муен.

Юу-у-ук! — дип гайрәтләнеп куйды Хәлимә Хәбировна.— Ул сүз модадан төште хәзер. Ниткән ир баш... Матриархатка кайтып җитеп барабыз, сеңелем. Хатыннар хакимлегенә...— Булырмын мин аңа муен. Кем аркасында шул дәрәҗәгә җитте дип беләсең син аны. Мин булмасам...— Хуҗа хатын симез куллары белән күкрәк какты.

Мактау сүзләрен кызганмыйча, Нәзирә Хәлимә апасына мәдхия арты мәдхия укыды. Тегесе дә, шактый төшергән булуына карамастан, иплән кенә чамасын белеп кенә Нәзирәгә бер авыз майлы сүз әйтте. Аның киберле-һавалы холкына мин-минлек берегеп үскән, йөреше, торышы, кыяфәте, сүз сөреше үзен бәйгенең алгы сафында итәргә тырышудан гыйбарәт. Аныкы икән — һәр нәрсә менә дигән. Читтән

торып сигез ел укып алган дипломын да теленнән төшерми. Габделбаров белән әрепләшкән чакта да:

— Покрайне мере, мин — дипломлы хатын, синнән ким җирем юк!— дип кенә җибәрә. Кешенең кыйммәтен исә үзенә тигән файда белән үлчәве гадәткә әверелгән. Мә сиңа да бир миңа! Алдым-бирдем, бетте-китте. Нәзирә белән дуслыгы да шул формулага нигезле.

Ашап-эчеп, күп сүзләр сөйләшеп күңелләрен хушландыргач, икенче бүлмәгә чыгып, соңгы вакытта алынган затлы әйберләрне карап рәхәтләнделәр. Соклануы белән, көнләшүдән, әйтерсең, Нәзирә дә уклау йотты.

— Бусы — Салисәмә, бусы — Халисәмә,— дия-дия, Хәлимә импортный келәмнәр күрсәтте.

— Абау, монысы, Хәлимә апа җаным, ике түгелме?

— Складта бардыр әле, бетмәгән булса, сиңа да алырбыз, шалтыратырмын...

— Әй генәм дим, Хәлимә апа, хәзер хрустальга да, алтынга да ул кадәр ябырылмый халык, китап модасы китте бит.

Сүзнең берсен башладылар, икенчесен ташладылар. Гәпләшә торгач, гайбәт күчәре Сабитовларга да орынмый калмады. Хәлимә ханым, ник икәнен үзе дә белмәстән, Йолдызны өнәми иде.

— Шул мамыксыз, алтын кешенең гомерен әрәм итеп тора бит. Складтагы Майбәдәр әйтә, югославский коверны да, японский сервизны да алмадылар, ди. Имеш, теге кыланчыгы мондагылар белән, янәсе безнең белән инде, бер төсле булмасын, сирәгрәк очрый торганын табып кайтарып бирегез дип әйтә, ди, чытлык.

— Әйбер алмый, кунак яратмый, үлеш шәп киенә үзе каһәрең...— Хәлимә апасының салпы ягына салам кыстыра торды Нәзирә.

— Бик ярата, үз дигәненә бара. Район библиотекасында эшләүче Елена Ивановна дигән ялгыз хатын бармы, шуңа атна саен барып төн уздыра, ди, кыланмаганнары бер дә калмый, ди. Стильный пластинка боралар, ди, ла-ла... Әй, дөнья гизә. Конференция дисәң — ул, съезд дисәң — ул. Отпускасында да йорт дими, бакча дими, чыга да чаба. Казан, Мәскәү, Рига, Киев — әллә кай җәһәннәмнәргә җитә.

— Үткән ел Волгоградка 30 бала алып чыгып китте. Исәр сыман бер нәрсә инде шунда. Әй, мин булсам... белер идем кадерен ул тормышның...— Монысын да Нәзирә өстәде.

Хәлимәнең тагын әллә ниләр тезәргә исәбе бар иде, авызын ачарга өлгермәде, ярым ачык ишектән аларны тыңлап торган кызы Халисәгә күзе төште:

— Нәрсә син анда, күзләреңне футбол тубы иттереп шаккатың?

— Шаккатырам әле, әни, мин сине. Җиттеме, юкмы сиңа? Кайчан карама, шул Йолдыз Ярулловна гайбәтен сатасың. Синең томаналыгыңа кем гаепле?

— Ә син, кызым, өлкәннәр сүзенә катнашмый тор, яме.

— Катнашып кына калмыйм, кызык итәм әле, әни, мин сине!— Халисә магнитофонга ымлады. Нәзирәнең коты очты. Хәлимә дә өнсез калды. Башына киткән хәмерне җил очыргандай итте.

— Авызыңнан җил алсын, ташбаш!

— Сүз бозау имезә... тәмам...

Нәзирәне озаткач, Хәлимә тузгыган әйберләрен урнаштырды, үзе нәфрәтләнде. Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый, диләр. Тот капчыгыңны, алырмын мин сиңа яңа фурмы холодильник. Әле кайчан гына, авызын ачса, үпкәсе күренә иде, тәмам тернәкләнде, йолкыш. Тычканның йоны чыккан саен чи-чи итә, ачкүз. Арттырып җибәрә тагын, басымчак итәм дигәч тә, оялмыйча теле барып соранып торуын кара син аның. Гарьлегеңнән...

Бераз тынычланганнан соң, уеның икенче тармагы баш калкытты. Кайгы кайгыны баса дигәндәй, бу фикер алдында Нәзирә белән сөй-

ләшүләр бер өем чүп булып кечерәеп калды... Кызы Халисәнең Йолдыз Ярулловнага карата мөнәсәбәте турында әле беренче мәртәбә җитди уйлана башлавы иде ахрысы. Нидәндер куркынып китте, күз аллары әйле-шәйле килде, арка-җилкә чемердәп китте. Шуларның барысын оныттырырга тырышкандай, аек бер фикер алга узды...

Укытучысы буларак, класс җитәкчесе буларак ихтирам итә. Тымызык кына йөрсә дә, корырак булса да, гаделлеге беләнме, принципиальлеге беләнме укчыларның күңелен яулый бит, явыз! Икенче бер сәбәп тә бар... һәм, Хәлимә Хәбировна бусына теше-тырнагы белән каршы. Шулай да, нишлисең, Сабитовларның малаена гашыйк бит бу тинтәгебез. Ул димәгән сулышы юк. Әгәр инде үз-үзең алдында алдашмый гына уйласаң, егете ярамаслык та түгел. Чибәр... Акыллы... Тыйнак. Яшь чагым булсамы, берәүне дә якын китермәс идем. Әмма, кызыкаем белән дуслыклары берүк үсмерчакның дуамал саташуы гына булып кала күрсен. Ай күрде, кояш алды... Йолдыз Ярулловна белән кодагыйлык куркыныч нәрсә бит ул. Аның сиңа эре генә, сүзсез генә карап алуын, аннары кырт борылып, башны дугага күтәреп китеп баруларын күргәч тә аяк табаннарыма хәтле чымырдап китә. Халисәгә моны аңлатырмын димә...

## IV

Сабитов киткән көнне Йолдыз мәш килеп өй җыештырды, кер уды. Күршеләре Рәхилә апа ишектән керә-керешкә:

— Әбәү, бик тәмле исләр дә чыккан, кунакларыгыз бармы әллә? Камил өйдә юк чакта иркенләп бер эчемне бушатыйм әле дип керә идем.

— Юк, нинди кунак ди. Әйдә, хуш киләсез, Рәхилә апа, менә сез кунак булырсыз.

— Кунак-кунакны сөймәс, нясе берсен дә сөймәс, ди. Кем соң анда? — дип, Рәхилә гөжләп торган ванна бүлмәсенә таба ым какты.

— Кер чайкарга дип су җибәргән идем. Берәү дә юк.

Йолдыз үзе сөйләште, үзе үтә бер җитезлек белән өстәл хәзерләде. Газ плитәсе өстенә кыздырырга май куйды, кабарсын дип өстен ябып куйган бәрәңге пәрәмәченә күз салды.

— Хәзер менә пәрәмәч пешерәбез, тәмләп чәй эчәрбез, бик мактап йөрисез икән әле.

— Эше барның ашы бар. Син, Йолдызкаем, һаман пешереп-төшереп кенә торасың, синең кулдан аш тәмле. Ничекләр өлгерәсеңдер инде. Эшкә хирыслыгың зур. Солын да беләсең, пешекче сыман...

— Әйдәгез, әйдә, Рәхилә апа, уңайлабрак, якынрак утырыгыз.

Яшәешнең ямен тәэмин иткән ризык исә борынны кытыклады, күңелне хушландырды. Йолдызның кухняда һәр әйберенең үз урынында булуы, һәр эшне белеп, үз җае белән автомат сыман башкаруы Рәхилә апаның күңелен кузгатты.

— Кая тукмагың, шунда сукмагың, әле мин дә менә Майсәрәмнең хәлен белим дип Казанга барып кайттым.— Анда күргән хәлләрен әрнеп сөйләде ул.— Үзем гаепләмендер инде, яхшы укый, укысын, кеше булсын, дидем. Өйдә эш кушмадым, үзе аркылыны буйга алып салмады, һаман китап-дәфтәр белән авәрәләнде. Укыды, кеше булды, кияү дә бик ипле, бик яхшы кеше баласы булырга охшый. Тик кызым Мәйсәрә өйдә бер дә генә хуҗа булалмый. Аш-су белән мәшәкатьләнми, өен җыймый, ул теге салкын суы, кайнар суы агып торса да, җыештырып тормагач, анда да әллә нинди исләр чыга. Савыт-сабаны кияү юа. Тормышларының бер генә дә рәтләре юк. Бөтен җирен чистартып кайттым. Үз өең, үз көең, мин әйтәм, хатын — тормышның үзәге, өеңне ямьлерәк итәргә тырыш, чистарак тот, ял көннәрендә таба ашлары пешереп кара, иреңнең күңелен күр, димен. Юк, колагына да элми,

атна башында да шимбә, азагында да лә-лә-лә, һаман шул музыка, һаман шул буфет пирожкие.

— Я, житешегез эле, Рәхилә апа.

Рәхиләнең күңеле күл булды.

— Менә бит ничек рәхәт үзең пешергән әйберләр белән хуш исле чәй эчеп утырулары! Ә минеке баласын да атналык яслегә биргән. Эштән кайтканда, кефир белән пирожки алып кайта да, тиз генә ашый да, телевизор кабызып, диванга кырын ята. Асрау булып хезмәт итәргә унбиш ел укымадым, дип кенә җибәрә. Болай булсаң, ирең тормас, ташлар, дим. «Ташласа, башкасы бетмәс» ди, исе дә китми, ни хәл итәрсең. Ут йотып кайттым менә, озатырга да төшмәде. Дөнья әйбере төяп бардым, күңел өчен, кайткач, күршеләр белән җыйналып чәй эчәрсез дип, ярты кило конфет та җибәрмәде. Ни хәл итәрсең, кешегә сөйли торган сүз түгел, эчемдә кату булып торганга, аптырап, сиңа гына сөйлим инде, Йолдызкаем... Әйтсәң сүз, төртсәң күз. Бала хәсрәте утсыз көйдерә шул.

Жил-давылдай килеп кергәне шикелле, чәй яныннан торгач, Рәхилә ашыгып китеп тә барды.

Ул киткәч, Йолдыз аның сүзләре хакында күп уйланды. Бу — ялгыз ананың хәсрәте генә түгел, укытучылар, тәрбиячеләр бакчасына да таш. Әлеге сүзләр аның җанын кимерде. Дөрестән дә, укучыларга мөмкин кадәр якынрак булырга кирәк. Аларның уен, хыялын, җанын аңлый белергә тиеш бит без...

Шушы сүзләр — аның педагогик нигезе. Бүген пешеренә башлавы да матур бер ният белән иде. Аның классында укучы кыз — Гөлфирә исемле бик тырыш, бик намуслы бала язын мотоциклдан егылып аягын сындырган иде. Больницада озак ятты, сөяк дөрес ялганмау сәбәпле, бихисап газапларга дучар булды. Әле дә булса савыгып аягына басканы юк. Бүген Гөлфирәнең туган көне. Уналтысын тутыра. Йолдыз аларның өйләренә барачак. Тәбрикләп кайтасы килә. Боекмасын иде, төшенкелеккә бирелмәсен. Жылы сүз — җан азыгы бит. Алда тау чаклы мәшәкатьләр тора — унынчы классны тәмамлыйсы бар...

Чыгып барганда, улының бүлмәсе ишегенә кнопка белән ябыштырып куйган язуга күзе төшкәч, Йолдыз көлеп җибәрде.

— Әй, бу малай! Нинди генә мөгезләр чыгармый, билләһи... Шырпы буе хәрефләр белән ак кәгазь битенә мондый сүзләр тезелгән иде: «Әнием! Мин соң кайтырмын, борчылма, яме. Халисә белән эстрада концертына барабыз».

Йолдыз үзалдына елмаеп торды. Инде яшерми, Халисә белән дип туп-туры яза. Халисә белән горурлана, мактанасы килә. Бик әйбәт, улым, кадерен бел кыз баланың. Бәлки бәхет йолдызыңдыр шул кыз. Тел тидерерлек бала түгел, бик итагатьле. Әнисеннән аермалы булырак, башта уйлый, аннары сөйли...

## V

Камил министр яныннан чыкканда, сәгать унике тулып килә иде. Канатлар куйгандай җилкенеп, күтәренке күңел белән чыкты ул. Мәгариф өлкәсендәге төп хуҗаның фикерләре белән Камил үз уйларында уртаклык тапты. Сөйләшү-киңәшләшүдән канәгать калды ул. Эшкә, киң колач белән эшкә дәрт кузгалды. Кәеф шәп иде...

Сквер каршында аңа, һич көтмәгәндә-уйламаганда районташы Һидаят Бикмуллин очрады. Әлеге күрешүне Камил уена да китермәгән булса, юрист иптәш алдан планлаштырып куйган иде.

— Исәнмесез, Һидаят Әгъзамович!— Камил прокурорның кулын яхшы белешләрчә, үз холкына хас булган самимилек белән, нык итеп кысты.

— Сәлам бирдек, Камил Әхмәтович! — Бикмуллин да ай-кояш нурларын җыйган сыман балкый иде. Балтик буе кешеләрен хәтерләткән һәм кырыкка якынлашкан бу кешенең аксыл йөзе, арыш саламы төсендәге сыек чәчләре, тоныграк зәңгәр күзләре, каны качкан юка иреннәре — һәммәсе бергә елмаялар иде төсле. Күрешергә дип кул сузып, баш игәндә, озын какча гәүдәсе икегә сынган сыман булды.

— Котлыйм үзегезне, Камил Әхмәтович, чын күңелдән котлыйм!— Ул уң кулын күкрәгенә куеп, башын иеп бөгелеп алды.— Иерархия басмаларыннан югарыга атлавыгыз белән тәбрик итәм. Уңышлар телим, иксез-чиксез уңышлар, Камил Әхмәтович!— Бикмуллин аны култыклап алды. Камил көрән төстәге күн папкасын уң кулыннан сулына күчерергә мәҗбүр булды. Кая барасыларын анык кына белмәсәләр дә, Спасс манарасына таба атладылар. Һидаят Бикмуллин, Камил сүземне бүлдерә күрмәсен берүк дигәндәй, сөйләвендә булды.— Кечә мәктәбегезгә барып чыктым, Камил Әхмәтович. Акташта биш ел эшлим, мин әйтәм, беренче урта мәктәптә булырга туры килгәне юк...— Гәрчә кызым шунда биш ел укыса да дигән уй, сүзләргә терелмичә, эчтә бөтерелде. Кыз турында сабыр итәргә кирәклеген акыл дигәнен кисәтеп куйды.

Камил кинәт прокурорга күтәрелеп карады.

— Берәр гаеп-кыек килеп чыкмагандыр бит, Һидаят Әгъзамович?— Сабитов җитдиләнеп калды.

— Юк ла, юк, үземнең кызыксынып керүем иде...

Бикмуллин, күптән алган якын кеше белән очрашканга сөенгән сыман, күңелле итеп сөйли бирде:— Шу-у-ул, анда әйтәләр, «Сез Камил Әхмәтовичны хәзер ронода күрерсез. Әмма конкрет шушы моментта ул Казан каласында. Таҗ кияргә китте», диләр.— Бу сүзләрдәге ясалмалык катыш төчеләнү Сабитовка кире тәэсир итте. Түбәндә нидер булырга тиешлеген сизенгән хәлдә түзде, ахырын көтәргә ниятләде.

— Инде менә күреп торам, мономах бүреген киеп чыгуыгыз, әйеме?

— Әйе, мәгариф бүлеге мөдире булып билгеләнү турында приказ алдым...— Камилнең тавышы рәсми яңгырады.

Спасс манарасы янына җиткәч, зур сәгать аларның баш өстендә унике тапкыр доңгылдатып сугып куйды.

— О, әбәт җиткән бит, Камил Әхмәтович. Тамак ялгап алсак, дип әйтәм?— Прокурор, бик мөһим мәсьәләгә җавап көткән шикелле, Сабитовка текәлде.

— Начар булмас ул эш, Һидаят Әгъзамович.— Камил юлдашы белән шунда ук килеште.— Иртән, назлы кыстамак кебек, рәтле-юньле ашап-эчеп булмаган иде, хәзер аппетит юк димәс идем.

— Кайсы ресторанга барабыз? Елга портына сыпыртабызмы соң әллә?— Шулай дисә дә, Һидаят мизгел эчендә бүтән фикергә килде.— Юк, «Шәрык» ресторанына барабыз, «Восток»ка... Ремонттан соң мактап туя алмыйлар аны. Чатырлары гел ефәктән, дип язалар. Идәннәр мәрмәргә әйләнгән икән. Стена-түшәмнәр Сүрия ефәге белән тышланган, ди. Шәмдәл-лампочкалар, кыйммәтле келәмнәр... Кереп утырыйк әле бер шунда. Безгә, район кешеләренә, алай ләззәтләнү еш тәтеми. Де факто шулай...

Ресторанның җиһазлануы, анда салмак кына яңгыраган таныш моңнар кунаклар күңеленә чынлап та хуш килде.

— Сезнең яңа постка аз гына гайрәт суы бөркеми ярамастыр бит инде,— диде Бикмуллин. Ашкынып тормаса да, Камил бу тәкъдимне бөтенләй кире чөеп ташламады.

— Бераз гына,— дип килеште.

Сүзнең чыны беравыктан башланды.

— Минем өлкән кызның мәктәп белән саубуллашканын беләсез инде, Камил Әхмәтович.— Һидаят, тылсымлы сүз әйтергә җыенгандай,

урындыгын Сабитов янынарак күчереп утырды.— Аттестатны үз кулыгыз белән биреп чыгардыгыз. Инде менә вузга килә, бәхет сынап карарга...

— Медицина институтынамы?

— Юк, Камил Әхмәтович, юк. Русчалатып әйткәндә, без переиграли аны: пединститут. Инфак. Инглиз теле бүлегенә. Шулай уйлаштык.

— Һе!..— Камил ихтыярсыз шундый ымлык әйтте. Сәерсенү, хәтта канәгатьсезлек авазы. Кызының бу юлны сайлавын элекке директоры һәм укытучысының өнәмәвен Һидаять Бикмуллин ап-ачык төшенде. Прокурор иптәшнең:

— Хупламыйсызмыни? — диюдән бүтән чарасы калмады. Аның аксыл кашлары киерелеп калды, йөзе алмаштырып куйгандай төксәләнде.

Камил дә кәефсезләнә төште, ләкин бик тактлы итеп җавап кайтарды.

— Зинһар, күңелегезгә авыр алмагыз, Һидаять Әгъзәмович, мин турысын әйтүне хәерле күрәм: Зөмәрәдән әйбәт укытучы чыкмаячак. Балаларны яратмый ул. Бөтенләй сөйми. Тугызынчы класста укыганда, мәктәп комсомол комитеты аны дүртенчедә укучыларның отряд вожатые итеп билгеләгән иде. Булдыра алмады, теләмәде дә. Сабыйлар да өнәмәде — тиз бизделәр үзеннән. Икенче бер классташын билгеләгән идек, гөрләтеп эшләде.

— Булыр, булыр, бәхәсләшмим...— Һидаять, аптыраганга юл кая дигәндәй, өйдә, сәке түрендә утырган карт шикелле учлары белән тез башларына таянды.— Китертик әле тагын бераз...

— Юк, рәхмәт, минем бераз эшләр дә бар әле, ә сәгать дүрттә поезд кузгала...

— Ярый, соңгы очрашу булмас әле анысы,— дип ризалашты прокурор. Әйтеп калыйм дигән җитезлек белән сүзен дәвам итте:

— Вак мәсьәлә, ә менә Зөмәрә проблемасы мине бик тынгысызлый. Карагыз әле, Камил Әхмәтович, керсен иде кызый шунда, укысын, дипломын кесәсенә салсын иде, аннары обязательно мәктәптә эшләргә димәгән бит. Тәрҗемәче булыр...

Һидаятнең бу фәлсәфәсе Камилнең гайрәтен тәмам чигерде.

— Обязательно...— Сабитов прокурорның үз сүзен аңлы рәвештә басым ясап кабатлады.— Обязательно мәктәптә эшләргә дип хәзерлиләр аларны! Ә сез беләсезме, авыл районнарында ничә мәктәптә чит тел укытылмый? Педагоглар җитми, тәти кызлар, кесәләренә инфак дипломы салып, шәһәрдә посып калганга шулай ул... Халык хуҗалыгы ихтыяҗларын онытабыз, «үзем» дигәч, авыз йомыла...

— Ярый, Камил Әхмәтович, эшләр, мәктәптә укытыр! Эшләтербез. Ә хәзер конкурс дигән сират күперен кичәргә булышыгыз, зинһар. Бурычлы булып калмам.— Бу тавышта ялвару да, минем кем икәнемне беләсезме дигән аһәң катыш өркетү дә бергә укмашкан иде. Тик Камил ул кадәресенә әһәмият итеп тормады. Һич теләмәсә дә, мыскыллы елмаерга мәҗбүр булды.

— Ришвәтчелек юлына басарга җыенмыйсыздыр бит?

Бикмуллин чәнечкеле сүзне кабул итмәде.

— Алай ук усал шаяртмагыз, Камил Әхмәтович, кирәкми! Мин сезнең кафедра мөдире белән курсташ икәнлегегезне беләм, институтның комсомол комитетында бергә эшләгәнсез. Иң кыены — инглиз теле имтиханын «бишле»гә тапшыруда ярдәм итегез. Гозерем шул минем.

Камил йөзендәге елмаю галәмәте бөтенләй юкка чыкты. Ул гаҗәеп бер җаваплылык тоеп аңлатырга керешә. Тавыш нотасы үтә җитди иде.

— Мин сезгә яңалык әйтергә җыенмыйм, иптәш Бикмуллин...

Бу тикле рәсмилеккә күчү Һидаятькә таш белән органдай тәэсир итте. Ул инде ник авыз ачып сүз катканына үкенә башлаган иде бугай.

әллә үкенмиме? Сабитовның күңел бушатканын сабыр гына күтәп, өр-яңадан гәп куертырга исәп итәме?.. Белмәссең, кеше күңеле — карурман.

Камил, әңгәмәдәшенең чыраенда кара шәүлә уйнап алганны күрә торып, сүзен дәвам итте.

— Мин әйтәселәрне сез бик яхшы беләсез. Алай да тел тешләп калырга теләмим. Ярый, мин институт дустым, яшьлектәге якын иптәшем, хәзерге кафедра мөдиренә ялындым-ялвардым да ди. Нишләгән булып чыгабыз инде без? Чыннан да сәләтле бер абитуриент урынына, сезнең Зөмәрәне студент ясыйбыз. Алдашабыз, хакыйкатькә хыянәт итәбез булып чыга, әйеме? Кафедра мөдире миңа бармаячак. Андый урау юллар эзләп әрсезләнгәнем өчен ул мине кабинетыннан куып чыгарачак, дуслары исемлегеннән гомерлеккә сызып ташлаячак һәм... хаклы булачак ул.

Район прокуроры ни чарадан бичара көлеп куйды.

— Минем кечкенә генә бер гозеремне дөньякүләм проблемага әйләндермәгез инде, Камил Әхмәтович. Зинһар дип әйтәм! Ир-егетләрчә сөйләшик, уртак тел табарбыз дип ышанган идем мин...

Сабитов үз фикеренә нокта куймый кала алмый иде инде.

— Ир-егетләрчә бара безнең сөйләшү, иптәш Бикмуллин. Мин унике ел буена укучыларыма гаделлек, принципиальлек, хаклык өчен көрәш зарурлыгы турында сөйлим. Шуларны тарихка бәйләп аңлатам. Намус сафлыгы, вөҗдан пакълеге укучыларыма гомерлек юлдаш булсын дип җан атам. Ә үзем... үзем имтиханда ялган билге теләнеп, рухи хәерчелеккә тәгәримме? Булмый. Мине җинаятькә этәрмәгез...

Рестораннан чыкканда, Һидаят күзенә һәммә нәрсә бүтәнчә булып күренә иде: алар ашап-эчеп утырган зал яшел түгел, гүя кара көйгән каһәрле зал, чатырга охшатып түшәмгә эленгән алтынсу шарлар да кан төсенә кергәннәр сыман. Сүрия ефәге дә кара пәрдәгә әверелеп, күңелгә шом коя төсле, шәмдәлләрдә дә тирә-якка нур бөркүче лампочкалар түгелдер, күмерләнеп сынарга торган чыра башлары пыскыйдыр кебек... Ә күңел дигәнең әйләндереп каплаган кисә төсле буш иде...

Урамда беренче август кояшы елмая, Камил Сабитов зәңгәр күккә, җиргә якты да, җылы да сибүче шул кояшка сокланды. «Ярый әле кояш бар...»

## VI

Камил партия райкомында һәм район советы башкарма комитетында булгач, мәгариф бүлегенә кайтты. Аны көтәләр иде: мәктәп директорлары, укытучылар, ата-аналар... Монысы район мәгариф бүлеген кабул иткәннән бирле шулай. Күнегеп бара моңа Сабитов. Ә менә мөдир кабинетына чират көтүчеләр арасында Зөһрәне күрермен дип уена да кертмәгән иде ул. Тормышта көтелмәгән хәлләр тулып ята, хәер, ул үзенең шундый яклары белән кызыклы да. Бу очрашудан Камил бер мизгел каушап калды, тәне кызышты. Ләкин, эчке киеренкелеген сиздермәскә тырышып, коридордагыларның һәммәсенә ишетелерлек тавыш белән сәлам биргәч, Зөһрә белән аерым күрешеп һәм мәктәп директорларына — элекке коллегаларына кул сузды.

— Һәммәгез белән дә сөйләшермен, иптәшләр,— диде ул, үз янына дип килүчеләрне тагын бер кат күздән кичереп.— Ә сез, иптәш Нигъмәтова хәзер үк рәхим итегез.

— Рәхмәт!— Җанга сихәт булырлык тавыш белән шулай диде дә Зөһрә кабинетка таба атлады. Камил, ишекне ачып, бүлмә эченә Зөһрәне уздырды, аннары үзе керде. Кунакка йомшак креслода урын тәкъдим иткәч, мөдир үз урынына — эш өстәле янына барып утырды.

Коридорда әйткән «иптәш Нигъмәтова», «сез» урынына үз кешеләрчә якын итеп әйтелә торган «син» яңгырады.

— Ронога килеп чыгачагыңны Казаннан ук белеп кайттым, министр урынбасары әйтте. Әмма инде алдан звонок-мазарсыз чират алырсың дип уйламаган идем, Зөһрә,— диде Камил һәм, гаепкә санар дип һич шикләнмәстән, күз карашы белән кала кунагын назлап чыкты. Яшерер хәле юк иде, сөеп, сокланып текәлде ул аңа.

— Карамачы шулай үтәли күрергә тырышып...— Зөһрә тәки телләнеп әйтергә мәҗбүр булды.— Миңа читендер дип уйламыйсың да бугай... эш турында сөйләшергә дип килдем бит мин, Камил!

Зөһрәнең эчке ялкынын, киеренкелеген алсу алмадай кызарып киткән йөзеннән чамалау кыен түгел иде.

— Беләм. Сөйләшик.— Сабитов шунда ук җитдиләнеп калды. Күңелсезләнә дә төште шикелле.— Шулай итеп, районга кайтырга булдың, Зөһрә?

— Мәҗбүрмен, Камил.

— Педагогия фәннәре кандидатының, укытучылар белемен камилләштерү институты методистының районга укытырга кайтуы — безнең өчен мактаныч ул. Теорияне практика белән ныгытып, конкрет мәктәп мисалында күрсәтү менә дигән эш булачак.

Камил пафослы һәм ышанычлы тавыш белән бик үз итеп, якын итеп сорау бирде:

— Үзең укенмисеңме соң, Зөһрә-йолдыз?..

Зөһрә, заңгәрсу күлмәгенә иш төсле кул сумкасыннан бик нәфис, өрсәң очып китәрдәй кульяулыгы алып, авыз-ирен тирәләрен сөрткән төсле итте дә җавап бирде:

— Юк, Камил. Хәзер фән кандидатлары мәктәпләрдә дә юк түгел, дип юанудан гына түгел. Әнкәй алдындагы бурычымны да үти алу хәтта куандыра. Ишеткәнсеңдер бәлки, ул бит урын өстендә ята хәзер. Хәле бик авыр, ярдәмчесез тора алмый. Өченче айга китте. Башта, чираттагы ялымны алып, мин карадым. Аннары Сочидагы сеңелем отпускыга кайтты. Энекәш бераз торып китте. Ул хәрби кеше, вакыты чикле иде. Әлләни булыша да алмый — әнкәй бик тартына, ояла... Бердәнбер юл — миңа авылга кайтып укыту калды. Күпмегә булыр — әйтүе читен. Ничек хәл итәрбез икән? Эш мәсьәләсендә диюем...

Камил яшьлегендә җан дусты итеп йөргән кешесе тормышындагы күңелсезлекләр өчен чын күңелдән борчыла иде. Үзе дә сизмәстән, авторучкасының каләмсез башы белән өстәлгә шакып-шакып алды.

— Ничек хәл итү турында, Зөһрә, мин юлда ук уйлап кайттым. Син үз авылыгызда укыта башлыйсың. Нагрузка турында конкрет сөйләшербез. Унбишенче августтан — эшкә. Килештекме?

— Рәхмәт, Камил. Дөресен әйтим, бик борчылып та, син ронога күчерелгәч исә, бик ышанып та килгән идем. Рәхмәт!

— Дуслыкны искертергә ярамый, Зөһрә. Күрешербез әле. Шушы арада авылыгызга барып чыгасым бар...

Зөһрә кабинеттан чыккач, үтә борчулы директор керде. Урта Чишмәдән. Анда мәктәпнең ике катлы таш бинасы төзелеп бетеп килә. Проекттагы суммага төгәлли алмыйлар. Бу кадәресе министрлыкта да билгеле, әллә ни өермә күтәреп булмый. Колхоз булышмады түгел, артыгын булдыра алмый. Культура сараен өчлап чыгасылары бар. Киләсе бюджет елын көтәр мәл дә юк. Сентябрьдә булмаса, октябрь бәйрәменә яңа бинага керәсе иде. Ничек итеп?

Уйлаша торгач, Сабитов мондый фикергә килде: Көмешче авылында да яңа мәктәп салыначак. Фундаменты әзер. Ләкин фәкать фундаменты гына. Нулевой цикл. Акча шактый бирелгән, әлегә эшче көчләр юк. Шул акчаны монда күчерергә була.

Камил шунда ук башкарма комитет рәисенә шалтыратты. Вильдан агай мәсьәләне ике көн эчендә хәл кылырга вәгъдә итте.

Ишектә сүлпән хәрәкәтле, йончыганрак кыяфәтле, йөзе-бите салам көле сибелгәнгә охшаган бер хатын күренде. Сәламен дә авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс кенә мыгырдап бирде, урын күрсәткәч тә, урындыкның бер кырыена кыяр-кыймас кына ипсез итеп утырды.

— Тыңлыйм сезне, ни йомыш белән килдек, апай?

— Йомыш микән инде, кем Камил туган, җалу микән, хода үзе белсен. Малай турысында килүем. Синең шкулда быел язын сигезенчене бетерде. Сәяр. Мөхәмәтшин фамилияле. «Муха» дип йөртәләр аны, кушаматы белән. Беләсендер, азгынрак нәрсә... Төпчек малай...

— Беләм, бик беләм. Башлы малай, укып кына киңәндерми тик. Сезне менә танымыйм икән, гафу итә күрегез!

— Каян танып бетерәсең, ди, безне. Акташ зур кала хәтле җәелгән. Йортлары гына тәбәнәк...

— Ата-аналар җыелышына да әтисе йөри бит Сәярның. Дөрес, сирәк килә ул...

Шул сүзләрне ишетүе булды, ханым сыгылып төшеп, елый башлады. Көтелмәгән хәлдән каушабрак калган Камил аптырый язды.

— Туктагыз әле, тынычланыгыз, апай, ни булды сезгә? — дип хафаланды. Стаканга тиз генә су салып, инде яшь түгеп үк утыручы хатынга сузды. Андый нәзберекләрләргә күнекмәгән апа стаканны уң кулы белән читкә этәрде дә, кулъяулыгын алып, күз яшьләрен сөртте, гәүдәсен турайта төште, сүлпән-салмак булса да, аңлаешлы итеп сөйләп китте.

— Әтисе үлде бит, Камил, үлде. Ике атна була инде. Йөрәк, йөрәк хараплар итте үзен,— диде һәм бөтен барлыгы белән аһ итеп көрсенеп куйды.— Илле сигезенче белән генә бара иде әле.

Камил да авыр сулады.

— Кайгыгызның зур вакыты икән шул. Тик сабыр була күрегез инде. Үлем бер хак дигәннәр... Сабырлыгыгызны туплагыз.

— Рәхмәт яхшы сүзенә, кем, Камил, кешелеклегең өчен рәхмәт. Синең урынга калган кем, Нурислам гына бер дә хәлгә керә белми икән, бик рәнҗетеп чыгарды ул мине. Шуңа килдем әле синең янына.

Камил, урыныннан торып, янә Сәярның әнисе янына якынрак килде.

— Ничек рәнҗетсен ул сезне? Булмас, апа, хаталанасыздыр. Ни булды соң?

Чынында исә бу хатынның тел төбендә ни ятканын Камил чамалап өлгергән иде инде. Сәярны урта мәктәп тәмамлатасы килә аның. Анннары институтка барыр дип өметләнә икән. Нурислам Габделбәров Сәяр Мөхәммәтшинны авыл хуҗалыгы урта профессиональ-техник училищесына кертү кулайрак булыр дигән фикер әйткән һәм үз сүзендә нык торган.

Әйе, ана сүзләре нәкъ шуны раслады. Аны сабыр гына тыңлап бетергәч, Сабитов, бик тыныч һәм мөлаем булырга тырышып, үз киңәшен бирде.

— Сез, апа, Нурислам Галиевич сүзләрен күңелегез яралы, хәсрәтле булганлыктан авыр кабул иткәнсез,— диде ул, хатынның янәшәсендә баскан килеш.— Фактта директор дөрес киңәш биргән. Мин дә шуны ук әйтәм. Техучилищеда да урта белем бирелә. Иң кирәге — малай төпле һөнәр ала. Киң профильле механизатор булачак ул. Дөньяны туендыручы. Монысы тормышта, ай-һай, бик мөһим нәрсә бит. Семья башлыгы буласы егет кеше ныклы һөнәргә ия булырга тиеш. Шунсыз ярамый. Өч ел дигәндә кул арагызга кереп, тормышта терәк булып китәчәк ул. Хәзерге шартларда анысы да бик хаҗәт сезгә, шулай түгелме?..

Ана ләм-мим каршы эндәшмәде, ак димәде, кара димәде, эчтән тынып торды беравык. Нурисламның да, Камилнең дә бер үк сүзне туку-

ларына аптыравы идеме, әллә роно мөдире, үтемле сөйләп, чын-чынлап уйланырга мәҗбүр иттеме, тәгаенләве читен иде.

— Турысын әйтеп сөйләшкән яхшы, апа,— диде Камил.— Тугызынчыда, унынчыда укып, аттестат алу белән үк, Сәяр институтка керә алмаячак. Урта мәктәпне көчле яшьләр белән ярышырлык дәрәҗәдә тәмамлый алмас ул. СПТУны бетергәч, кирәк дип санаса, югары белемгә ихтыяҗ сизсә, җин сызганып хәзерләнер дә керер институтка.

Сәярнең әнисе килешепме, болай гынамы, баш кагып куйды.

— Аннары, апай, тагын бер нәрсә бар: һәркайсыбызның ил-көн алдындагы бурычы. Илгә, авыл хуҗалыгына бик күп механизаторлар кирәк. Әйбәт тракторчылар, комбайнчылар, шоферлар, шул машиналарны төзәтүчеләр, көйләүчеләр... Барыбыз да институтка китеп бетсә дә, дөрес булмас бит, әйеме?

Камил «әйе!» дигән җавап көткәндер, ихтимал. Хатын исә, кабинетка кергәннән бирле беренче тапкыр Сабитовка күтәрелеп карады да, әлегә кадәр ишетелмәгән ят тавыш белән:

— Бер дә әйе түгел. Үзең институт кирәкми димәгәнсең бит, мөнәтерә! — дип кистереп куйды һәм шунда ук урындыктан күтәрелеп, күләгә юкка чыккан төсле, тавышсыз-тынсыз гына ишеккә юнәлде. Саубуллашмады да шикелле.

Ишек ябылуга, Сабитов башында ике сүз — ике бөртек ядрә булып биешеп алды: «Холостой выстрел!» Солдат чактан телгә йогып калган сүзләр. «Күпме тел тегермәне тарттым, теләгемә ирешә алмадым. Укучыбызның анасын ышандырырга көчем дә, осталыгым да җитмәде» дигәнне аңлатырга тиеш сүзләр иде бу. Димәк, уйланасы, үз-үзеңә, эш стилеңә тәнкыйть белән карыйсы, эзләнәсе, укыйсы, табасы чаралар тау кадәр...

Озын-озак фәлсәфәгә бирелеп утырыр чак түгел, тагын бер хатын керде. Фәйрушина. Район үзәгендәге ресторан директоры. Актив җыелышларында әледән-әле очраша тора Камил аның белән. Районга кем килми дә, кем китми. Очрашу, сөйләшү, кунак итү шунда бит хәзер. Һәрхәлдә күргән күз. Аның кызы да быел унынчы класска бара. Гөлзада Фәйрушина. Үтә чыккан чибәр кыз. Сәләтле укучы. Җәмәгать эшләренең үзәгендә кайнаучы. Университетның механика-математика факультетына күз төбәп укый. Анда да сынатмаячагына шикләнмәскә мөмкин. Эти-әнисе дә зур өметләр баглап тора кызларына.

Гөлзада турында шундый фикердә булганга, Камил Саимә ханымнан ишеткән сүзләрне акылына кабул итә алмый торды: «Чынмы бу?»

Чын икән шул, кызганычка каршы. Бар кызыл да кыз булмый икән... Сөрлеккән Гөлзада. Бик иртә абынган.Кирәкмәскә ашкынган. Мәктәп өчен дә күңелсез, үзе өчен гомерлек фаҗигага әйләнүе мөмкин хәлгә сәбәп булган. Атның сере иясенә мәгълүм, кызның сере үз өенә мәгълүм: хәзергә Гөлзаданың балага узуын Саимә ханым гына белә икән. Зәйнәгол Фәйрушинга да чишми торалар хәзергә. Ә егет дигәнебез ветеринария техникумын тәмамлап кайткан бер чибәр спортчы булган, быел язгы призывта армиягә алынган.

— Сез мине гафу итегез, зинһар, Камил Әхмәтович, һәм аңларга тырышыгыз әле, зинһар өчен,— ди миңгерәп калган Саимә.— Сүз башлап ир-ат белән сөйләшә торган мәсьәлә түгел бу түгелен. Аптыраганнан килүем. Кызыбыз мәктәпкә кергәннән бирле, тугыз ел буе кинәшче булдыгыз бит...

— Борчылмагыз, тынычланыгыз, мин сер тотмас үрдәк түгел.

— Хатыныгызга тел тидерү булса да, турысын әйтми хәлем юк. Йолдыз янына туп-туры бара алмадым. Ул Гөлзаданың класс җитәкчесе дә бит югыйсә. Йолдыз — бик туры, дөрес хатын. Укучылары өчен үлеп тора. Ну җан җылысы юк, миһербансыз. Берәүгә дә мәрхәмәт күрсәтәсе түгел. Үз баласына да...

Саимә кинәт, оялгандай, сүземне ничек кабул итәр бу, дип уңайсызланып калды, көрсенеп куйды да сүзен дәвам итте.

— Зәйнәголга әйтергә дә котым очып тора. Кыйнап имгәтмәгәе дип куркам, холкы яман... Башым катты, Камил Әхмәтович... Нишлим? Ни хәлләр итим, аптырап сезгә килдем, бер киңәш бирегез, ярдәмегездән ташламагыз...

Байтак уйлаштылар. Егеткә хат язарга, баласыннан баш тартмастай булса, баланы саклап калырга, тудырырга, үстерергә кирәк дигән фикер дә булды. Беренче баланы юк итүнең Гөлзаданы ана булу бәхетеннән гомерлеккә мәхрүм итүе ихтимал дип тә уй йөрттеләр. Укуын кичке мәктәпкә күчеп тәмамлау хәерлерәк булмасмы дип тә карадылар.

Саимә ханым кызын Уфада яшәүче сеңелесе янына җибәрү кулай булмасмы, дип тә киңәште. Анда бер-ике ел яшәп кайтса дип әйтүе иде.

Без капчыкта ятмый, бүген үк хәлне әтисенә дә аңлатырга кирәк дигән карарга килделәр. Аннары тагын ирле-хатынлы Фәйрушиннар һәм Камил Сабитов бергәләп сөйләшергә булдылар.

Саимә киткәч, мөдир ялгызы гына калып, яңа килгән газета-журналларны күздән кичерә-кичерә, шактый тирән уйланып утырды. Яшьләрнең тиз җитлегүләре педагоглар армиясе алдына яңа бер — мең дә беренче — катлаулы проблеманы бастыруы турында иде аның баш ватуы. Бу мәсьәләне уңай хәл кылу өчен, педагогларның көчен медикларның тырышлыгы белән берләштерергә кирәк. Ата-аналары улларыкызлары белән җенси тәрбия хакында җәйлап, тирәнтен серләшә алырлык итеп агартуның кирәклеге дә көн кебек ачык.

Шулай да бу хактагы яңа әдәбиятны актарып, үземнең күп еллар мәктәптә тупланган тәҗрибәгә, күзәтүләргә нигезләнеп август киңәшмәсендә сөйлисе докладта рәсми рәвештә күрсәтмә бирергәдер, бәлки, дип фикер йөртте Камил.

## VII

Август киңәшмәсенә кадәр район мәктәпләренең барысында да булып чыгуны максат итеп куйды Сабитов. Яңа уку елына хәзерлекнең торышы, ремонтның барышы, класс-кабинетларның җиһазлануын, дәреслекләр белән ни рәвешле тәэмин ителүе кебек мөһим мәсьәләләрне үз күзләре белән күрергә кирәк иде. Укучыларның колхоз-совхозларга ни чамада ярдәм итүләре, производство берләшмәләре һәм бригадаларының эшчәнлеге һәм аның кайсы мәктәптә ничек исәпкә алынуы шулай ук конкрет һәм тирән кызыксындыра Сабитовны.

Гөлле Борас авылына баргач, аңа үтә зәвык белән заманча җиһазланган рус теле һәм әдәбияты кабинетын күрсәтеп, мәктәп директоры үзенчә бер горурлык белән Зөһрә фамилиясен атады. Аның хәл-әхвәлләрен исә Камил директордан үзе сорашып, шулай ук бик нечкәләп белде. Зөһрә белән алар мәктәп ишегалдында очраштылар. Ронода сөйләшкәннәренә бик аз вакыт үтсә дә, озак еллар күрешмәгән кебек, сөенешеп исәнләштеләр. Мөдир кабинетында гәпләшкәндәге тартыну, киеренкелек галәмәтләренең эзе дә калмаган иде. Зөһрә шул кадәр әсәрләнде ки, хәтта ул Камилне кочаклап алырга да күп сорамас иде. Шатлыгына нигез дә бар: үткәндә ябырылган барча көнелсезлекләрне, рәнҗү-үпкәләрне онытып, Камил Зөһрәнең биредә икәнлеген белгәнгә, Гөлле Бораска киләсе иткән. Ә хәзер ул Зөһрә әнисенең хәлен белеп чыгарга теләге барлыгын әйтеп куйды. Ничек кенә булмасын, йөрешкән-белешкән, килгән-киткән, сый-хөрмәтләрен бүлешкән гаилә бит заманында. Ләкин Зөһрә аның бу фикеренә катгый каршы төште.

— Аяусыз була күрмә, Камил, гафу ит, энкәй янына сине — нечкәтер бу сүз үзенә бер төсмерле басым белән әйтелде — алып керә алмыйм. Ул ир-ат халкыннан гына түгел, хатын-кызлардан да уңайсызлана. Миннән, үз баласыннан да читенсенә, күз алдыңа китерә аласыңмы? Хәле хәл бит... Торып та утыра алмый... айлар буенча...

Әйттем исә кайттым дигәндәй, Камил шунда ук килешергә тиеш иде. Бәхәскә керә торган хәл түгел!

Зөһрә исә мәсьәләнең икенче ягына да игътибар иткән икән.

— Сине бик яхшы белә бит ул,— диде, алда әйткәннәренә өстәп. «Килеп-китеп йөргән чакларыңны» сүзләрен йотып калды Зөһрә. Гап-гади бер нәрсә турында сөйләгән сыман, тыныч, тигез, ягымлы тавыш белән дәвам итте.— Яшьлектәге дуслыгыбызны да белә. Кавыша алмаганыбызга әрнегән чагы да исендә... Хәзер мине синең янәшәңдә күрү аның төзәлеп җитмәгән ярасына тоз салу булыр иде бит, Камил. Үзен әллә нинди күңелсез уйларга дучар итеп, хафага төшәр. Аннары сырхавы тагын да көчәер, рәнҗер миңа. Пакь гомер кичергән карчык бит ул...

Зөһрә белән очрашу, берничә минут булса да сөйләшү дәвамында, Камил әйтерсең яшьлегенә әйләнеп кайтты, ниндидер татлы газап кичерде.

Алдарак Сабитов августның уналтысында министрлыкка киңәшмәгә барасын әйткән иде, Зөһрә исә, онытылып китеп, кулларын балаларча чәбәкләп куйды.

— Менә шәп! Мин дә унбишендә Казанга барам бит. Әнкәй янында бер-ике көн торып торырга күрше карчыгын күндердем. Квартирыма танышларымны кертеп калдырам. Бер елга, договор белән. Буш торганчы — яшәсеннәр. Частныйда интегәләр, кеше хозурында.— Шуларны тиз дә, Зөһрә Камилнең күзләренә карап торды.— Киңәшмәдән соң килерсеңме?

Камил кинаяле елмайды.

— Адресыңны белмим бит.

Зөһрә квартир номерын әйтте, алай гына да түгел, уң кулының исән бармак очы белән Камил пинжәгенең түшенә язган сыман да итте:

— Килерсеңме?

— Вәгъдә! — диде Камил, яшүсмерләрчә самимилек белән. Әйткәне үзенә дә сәер тоелды ахрысы, шунда ук көлеп тә алды. Аннары тагын кабатлады.— Вәгъдә — иман!..

...Менә көткән көн килеп җитте. Ул Казанда, ундүрт катлы йортның җиденче катында. Күптән кичермәгән бер дулкынлану белән ишектәге звонокның төймәсенә кагылды. Бу кечкенә төймә аның бармагын көйдереп алган сыман булды. Ул арада ишек ачылды, анда сүз белән әйтеп бетергесез, якын кешенең ягымлы тавышы ишетелде, Камил ниндидер бер томан эчендә йөзде.

— Әйдүк, рәхим итеп, Камил! Исән-сау килеп җиттекме? Төгәллек — корольләр мактанычы диләр. Педагогларга да бик килешә ул.

Сабитов ишек яны бүлмәсенә кереп басты. Бераз сулдарак зур бүлмәгә уза торган ишек. Уң якта — кием элгечләре, аның каршысында зур көзге. Камил көзгедә үзен күреп хәйран калды: талчыгулары юкка чыккан, йөзе алсуланган, хәтта яшәргән кебек иде...

— Туфлиләреңне сал, аягың ял итсен, менә йомшак башмаклар сиңа,— диде Зөһрә кайгыртучан-җылы тавыш белән.

Камил телен йоткан сыман югалып калды, күз карашы белән «кая узыйм» дигәнен әйтте. Сүзсез дә аңлашу шулдыр инде ул. Аның күңелендәге сорауга җавап итеп Зөһрә:

— Ачыккан булсаң, туп-туры кухняга үт. Хәзер чәй өлгертәм. Куян каныдай куе, каты чәй эчәрбез.

— Хәлем ярыйсы әле. Түргә рөхсәтме?

— Рәхим ит, газета-журналлар карый тор... Мин хәзер...

Биредә ниндидер күңелле рәхәтлек сизде Камил. Ул, бөтен киеренкелектән котылган сыман, иң элек муенындагы галстугын чишеп диванга ташлады. Бүлмәнең стеналары, җиһазлар, тәрәзәгә элгән челтәр пәрдәләр — һәммәсе: «Ял ит, иркен сулыш ал, уйларыңны тәртипкә китер»,— диләр төсле. Һәр нәрсә үз урынында, артык әйбер юк. Нинди генә бәйләнчек булсаң да, тел-теш тидерә алмаслык чисталык, пөхтәлек. Дөреслеккә күз йомып булмый. Зөһрә дә Йолдыз кебек үк тырыш, унган икән, дигән фикер Камил уеннан сызылып үтте. Аерма шунда — өйдә киеренкелек, биредә рәхәт иде.

Пыялалы китап шкафы шыплап тутырылган, Бөтендөнья әдәбияты китапханәсенең ике йөз томын алдырган икән Зөһрә. Гарәп, латин шрифты белән чыгарылган иске китаплар да күренә. Тел гыйлеменә, эстетика, педагогика, психология фәненә караган әдәбият та байтак.

Көмеш йөгертелгән поднос белән чәйнек, чынаяклар күтәреп бүлмәгә Зөһрә керде. Өстәлгә кадерле кунак килгәндә куела торган затлы ашамлыклар, нигъмәтләр тезелде.

— Әйдә, кайнар чәй эчеп алыйк! — Ул Камил каршындагы креслога утырды. Шул чак Сабитов плащ кесәсендәге күчтәнәчен искә төшерде, тик барып алырга уңайсызланып калды. Сизгер күңелле Зөһрә аның хәлен тиз, бик тиз абайлады.

— Нидер әйтмәкче идеңме, никтер тынып калдың?

Камил чишелеп китте, читенсенүнең эзе дә калмады.

— Нечкә психолог син, Зөһрә, күңелдәген укый беләсең.

Зөһрә серванттан уймак кадәр генә рюмкалар китереп куйды.

— Рәхмәт сиңа! — Камил, җилкәсеннән таш төшкән шикелле, иркен сулады.— Ару-талуны оныттырдың әле бераз.— Ул бөке ача-ача рәхәтләнеп сөйли иде.

— Я, Зөһрә, аз-маз авыз итеп куйыйк булмаса!

— Нәрсә хакына эчәбез? — Зөһрә ничә еллар күрешмәгән-очрашмаганнан соң иркенләп утыру җае чыкканга бик канәгать иде. Ул шул чакларны телгә алган тост өмет итте шикелле. Камил кистереп кенә һични әйтергә ашыкмагач, бераз әрнү катыш ярым сорау белән:

— Ут белән шаяруыбыз өченме? — диде.

— Юк, моның белән килешәсем килми.— Сабитов рюмканы өстәлгә куеп тормакчы иде дә, яхшысынмады, янә өскә күтәрде.— Синең бүген нинди икәнеңне белер өчен, Зөһрә. Моннан унҗиде-унсигез ел элек булган ашыгуларың өчен үкенмисеңме икән, шуны төшенер өчен. Бераүләрне гомерлек утка салдың бит шул чакны...

Зөһрә йөзендәге көләчлек, кояшның болыт артына керә башлавын хәтерләтеп, кимеде. Кашларын җыерып куйды ул, зур зәңгәр күзләр төссезләнеп, тоныкланып калды шикелле. Әйтер сүзен йоткан сыман, өске иренен тешләштергәләде. Ниһаять, уңайсыз хәлдән чыгуның башка чарасы калмаганлыгына гаҗиз булгандай итеп:

— Допрос алмыйча гына, Камил, ярыймы? — Әле генә чыңлап торган ягымлы, матур тавыш та сүлпәнләнә төшкән иде.— Җиде катлы үзәккә үк булып кадалган соравыңа бер генә сүз белән җавап бирәм: үткәнгә суд юк. Гомернең калган өлешен яңа үкенүләрсез яшәсәк икән. Синең яшәвең, эшеңнең уңышлы баруы, кыскасы, бәхетле булуың — миңа шатлык ул. Уйларым, хисләрем белән беркайчан да синнән аерылганым булмады — һәм беркадәр көрсенеп куйды да, кунагына шатланган хуҗа сыман итеп, эчке бер тетрәнү белән: — Әйдә, синең еллар ашаелмаюың өчен булсын бу тост! — диде.

— Кушылам, ләкин өстәмәсе шул: гомер бер генә, үкенмәслек итеп яшәү өчен!..

Байтак сүз сөйләшенде, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, уртак танышлар искә төшерелде, әллә ничаклы тормыш бормалары хәтердә яңарды, тик бер генә кешенең исемен читләтеп уздылар. Ул — Зөһрәнең ел ярым гына яшәп аерылган ире иде. Шулай да утыра торгач, Камил, үзе дә тоймастан, бу темага кагылды:

— Оныттым инде мин аны,— диде Зөһрә.— Сызлаган тешне суырткандай котылдым. Җан жылысы булмагач, бер түбә астында яшәүдән ни файда... Бөтенләй газапсыз оныттым.— Шулай дипе булды, телен тешләгән кебек, кинәт сүзсез калды. Еллар томаны эченнән дүртенче курс студенты Камил Сабитовның әрнү катыш ярсып әйткән сүзләре кайтавaз булып яңгырады: «Син мине дә, аны да яратмагансың. Син чын мәхәббәткә сәләтсез, Зөһрә!..» «Бөтенләй газапсыз оныттым» дипенә каршы Камил тагын шул аяусыз-шәфкатьсез сүзләрен генә әйтмәсен иде!

Чыннан да, Камилне оныта алмады бит ул, оныта алмаячак та...

Камилне исә Зөһрәнең бер сүзе — «җан жылысы булмагач» дипе сискәндерде. Кем әйткән иде соң әле бу сирәк очрый торган сүзне дип хәтер сандыгын актарды, ә искә төшерү бу рухи халәтне тагын да авырлаштырды. Саимә Фәйрушина әйтте бу сүзне, Йолдызга карата кулланды. Ул чакта Сабитов бер колагыннан кертеп, икенчесеннән шундук чыгарган иде. Ә хәзер... Язмыш ирониясеме бу, очраклылыкмы, ләгънәт төшкән тәңгәллек. Акыллы уйчан күзләрен ерак бер ноктага төбәп өнсез калган Камилгә эндәшеп, Зөһрә:

— Инфарктны эштә чамасыз киеренкелектән, кирәгеннән артык көчәнүләрдән түгел, тормышка ашмаган теләкләр аркасында була дип әйтәләр, Камил. Әйдә, бездән инфаркт читләтеп узсын өчен!..— диде.

Тагын истәлекләр дөньясына чумдылар... Хатирәләр кайнарлыгы яшьлекне кире кайтармый, билгеле, тик барыбер хисләрне яңартып җибәргәндәй итә, җанга ял бирә. Студентлык елларыннан башлап сүтелә торган сүз йомгакларыннан һәркайсының очы бүгенге көнгә килеп ялгана иде.

Камил Зөһрәнең җылы кулына кагылды. Зөһрә куе озын керфекләрен какмый торды.

— Монысы ни дигән сүз? Яшьлектәге мәхәббәтне яңартырга дипме кагуы?

Фәлсәфәгә урын юк иде, Сабитов кып-кыска итеп:

— Үзем дә белмим! — диде.

— Гаҗәп, нишләп әле кулың кинәт тик тормый башлады. Сез — ирләргә хас читтән нәрсәдер эзләнү галәмәте түгелме бу? Синең менә семьяңда ни җитми?

— Кислород...

Камил әлеге сорауны шаярган булып уздырды, әгәр житди җавап бирергә кирәксә? Азаккача самими булып, ачык кына җавап таба алыр идеме ул? Йолдызның кырыслыгыннан, дан кууыннан, акчага табынуыннан арынып торырга, гомер буе яраткан кешесе янында җанына кыска вакытлы булса да ял табарга теләүме әллә?

— Минем турында ялгыш фикер йөртмә, Зөһрә, мин син әйткән ирләр категориясенә кермим, чит ятак минем өчен юк ул...

Аларны кара-каршы утыртып шулай чын күңелдән сөйләштергән, бәхәсләштергән, инде шактый күп өлешен үткән гомер юллары буйлап сәяхәт иттергән, ниһаять, бер бүлмә һавасын иркенләп сулаткан истәлекле бу төн гаять тиз үтте.

Бүлмә тынлыгы алар өстенә әйтерсең мамык юрган булып таң алдыннан гына җәелде.

Якшәмбе көн булганлыктан, мөдир роно машинасы шоферын авылларга чыгарга кыстамады: семьясы, балалары бар, ниһаять ял итәргә хакы бар, ә Камил Әхмәтович үзе дә бик әйбәт йөртә машинаны.

«Гигант» колхозы басуларын узып, олы юлга чыкканда, аның күңелендә җыр тибрәнде. Салмак та, канатлы да, моңы да, хисе дә мул җыр. Күңел җыры...

Папирос көйрәткәч, ян тәрәзәне ачып, җилләнеп барганда, куллары — рульдә, күзләре юлда килеш, Камил уена беркетеп куйды: августагы зур педсоветта «Гигант» колхозы башлыкларының тәҗрибәсе турында сөйләүләрен планлаштырырга.

Машина, олы юлдан төшеп, кыр юлына борылды да, «Чулпан» колхозының бодай басуына барып чыкты. Басуның аргы башыннан, кыр казлары сыман тезелешеп, комбайннар килә иде.

Ә тагын беркадәр ара үткәч, Камил кыр ышыклау урман полосасы буенда туктап калган «Колос» комбайнына игътибар итте. «Ватылгандыр, ахрысы...» дип уйлаганда гына, машина җиленә уралып, аңа колак яргыч кыргый аваз ишетелде. Тиз-тиз шунда барып туктаса, үз күзләренә үзе ышанмас хәлдә катып калды: әзмәвердәй агай бер яшүсмерне кыйный икән бит... Малайның авыз-борыныннан кан киткән, бите күгәреп чыккан... Шулай да, бар көчен җыйнап, тегенең кулларын үзеннән читкә этәргә тартыша.

— Тукта, сволочь, нишләвең бу?!

Мондый тавыш белән, бу тикле ачыргаланып аның гомерендә бер дә кычкырганы юк иде әле. Әмма күзләре тонган, чәчләре тузгыган ир уртасы бәндә Камилнең җан ачысы белән салган бу авазына әйләнеп тә карамады хәтта. Ул гына да түгел, аяк чалып, малайны камыл өстенә екты да типкәли башлады. Шул мизгелдә Камил аның изүеннән умырып алды һәм, тешләрен кысып, бар куәтенә читкә этәрде. Таза агай әпен-төпен чигенә-чигенә ике-өч адым ара үтте һәм комбайнга барып бәрелде... Баш түбәсеннән кан саркыганы күзгә чалынды... Шуңа ул зоопарктагы аю урынына үкерә башлады.

— Кем син, басуга килеп, эштәге кешене кыйнап йөрергә? Мин...

Хәмер гайрәте, аракы шашындыруы булган икән, кинәт айный башлады агаең. Куаклык буена механизаторлар йөгерешеп килгәч, ык-мык итә калды.

Беренче эш итеп егетне — ул быел унынчы класска барасы икән, биредә комбайнчы ярдәмчесе булып эшли — кагындырып, юындырып, «бишекле» мотоцикл белән Аланлык больницасына озаттылар. Аннары абзыйның башын бәйләделәр. Һәр минутның алтындай кадерле чагы. Озын-озак тоткарланмадылар, сугыш чукмарын бары тик ирләрчә кисәтеләр генә: «Күрсәтербез әле без сиңа күсәклек иманнең кайда үскәнен...— Сәрхүш комбайнчы Камилгә ябырылырга маташкан иде, баш түбәсенә тагын бер йодрык менеп төште.— Кылганнарың өчен дә колмак әчесе татыйсың бар әле. Бар, кайтып кит тизрәк, айныгач, аңлашырбыз...»

Сабитов «Чулпан» колхозы кырыннан иңнәренә, әйтерсең, тегермән ташы салып китте. Әлеге кыргый күренештән соң вөҗдан газабы кичерү иде бу. Акташка кайтып җитәрәк, Камил машинадагы көзгегә күз салгач, кәефе чырае белән бер икәнен аңлады.

Басудагы фаҗиганың сәбәбе исә аңа бик кыска итеп, менә ничек аңлатылды:

Әһли-оста — комбайнчыны шулай дип йөртәләр икән — уракка төшкәннән бирле кучмә вымпелны үзендә тоткан. Соңгы бишкөнлектәге күрсәткечләргә йомгак ясаганда, Мисбах дигән комбайнчының да урып суктырганы нәкъ Әһли-останыкы кадәр килеп чыга. Колхоз идарәсе,

партком, профсоюз оешмасы коллективы белән киңәшеп, вымпелны Мисбахка бирергә дигән карарга киләләр. Баксаң-күрсәң, Әһли-оста, ут уйнатып эшләсә дә, «котырган сыер сөтен» үлеп ярата икән. Уракка төшкәч кенә дә, бер-ике тапкыр шул яман чире тоткан инде аны. «Күрсәткечләр ягыннан колакка-колак килсәгез дә, тәртибең белән тәртәгә тибүең сиңа күләгә төшерә,— дигәннәр.— Аннары сине ярдәмчең Илгизәр сөйрәшеп барганны онытма. Ул алтын куллы егет булмаса, арсланың айга сикерә алмас иде». Өермә шуннан башланып, бугазга да нык Әһли-оста һәммәсе алдында сөрән салган:

— Беләм мин сезнең махинацаларыгызны! — дигән.— Мисбах бит — председатель кайнише! Кода-кодагыйлык чәчәк ата «Чулпан»да...

Бугаз киереп кенә калмаган Әһли. Иртәгесен сәрхүш килеп, бодай басуын бүтәннәр белән бер-ике әйләнгән дә комбайнын читкә алган: «Барабан барахлить итә, бөртекне вата,— ди икән.— Әйдәле, Илгизәр, карап карыйк әле без аны...» Төркемнән аерылгач, битлеген да салып ыргыткан Әһли-оста. «Анагызның арт сөяге сынсын! Ударник Мисбахның эшләп җаны чыксын әнә! Мать якасына! — дип мыгырданган. Үзен ике сәгатьтән уятырга кушып, күләгәгә кереп яткан. Чыдаган Илгизәр, көткән ике сәгать узганны, майлыйсын майлаган, ныгытасын ныгыткан. Кыскасы, төп-төзек «Колос»ны янә бер кат күздән кичергән, аннары Әһлине уяткан: «Әһли абый, әйдә, кушылыйк төркемгә, алтын вакыт заяга уза, эшкә зыян салабыз лабаса!» — дип ялынган-ялварган, еламаган гына. Әһли-оста исә, егетнең әнисен-әбисен хәтерләп, кабер такталарына җитеп сүгенгән дә, кире якка гына әйләнеп яткан. Шуннан соң Илгизәр комбайнны кабызып, ялгызы гына кузгалмакчы булгач, әнә шул хәлгә тарган...

Камил Әһли-оста холкындагы тигәнәкләр турында уйламый булдыра алмады. Тәрбия мәсьәләсе, әхлакка кагылышлы һәр нәрсәне җиз иләктән уздыру педагогның җелегенә сеңгән инде ул. Әйе, Әһли-останы паразит дип тә, әрәмтамак дип тә атар җай юк. Ләкин чын фидакарь хезмәт аның өчен тормыш ихтыяҗы булудан да бигрәк һәм материаль һәм әхлакый комфорт чыганагы гына. Аңа күп акча кирәк, дан кирәк, әйләнә-тирәдәгеләрне шаккатыру кирәк.

Шул фикердән аның уйлары һич көтмәгәндә бөтенләй бүтәнгә күчте. Камил июльнең утыз бере таңында күргән саер һәм шомлы төшен хәтерләде. Хәтерләве булды, үзен-үзе мыскыллагандай ачы елмаеп куйды. «Диндар булсам икән, ырымнарга ышансам икән, төш юрауларны бар дип белсәм икән...» Кинәт искә төште, күз алдына килде бит менә таудан ыргыган таш ташкыны... Минем өскә ябырылачак гайбәт... Һәй, шайтан алсын сана!

Сабитов Акташка кайтып кергәч тә, машинасын район милиция бүлегенә борырга, начальникны күреп, «Чулпан» басуындагы хәлләрне сөйләргә ниятләгән иде. Тик уйның икенче буе бу исәпне кире какты.

— Тукта әле, артык кечерәю булмасмы? — үзалдына үзе сорау куйды.— Ул — бүлек начальнигы, мин — бүлек мөдире, ул да — райсовет депутаты, мин дә. Бүлек башлыкларының житәкчесе бар ич. Барыйм туп-туры райбашкарма рәисе янына.

Сабитов һәммәсен ачык итеп сөйләп бирде.

— Тәк-тәк...— Рәиснең тәкелдәве ни аңлатканын Камил төшенмәде.— Алай, алай...

Вилдан Сабирович кара дерматин белән тышланган креслосыннан чак кына күтәрелде дә, хәле беткән сыман, кире ласылдап утырды. Симез гәүдә авырлыгыннан кресло көрсенеп куйды шикелле. Аннары йонлач беләкләрен алмаш-тилмәш ышкып алды, кыска җиңле күлмәгенең изүеннән чеметеп җилләнгәндәй итте һәм орчык башы белән төртеп тишкән төсле кечкенә түгәрәк күзләрен Камилгә төбәп әйтте:

— Баш Себер китәрлек гөнаһ кылмагансың анысы, энем. Хәер, не

то слово. Себергә хәзер комсомол путевкасы белән китү өчен чират.— Тагын урыныннан кузгалмакчы булды, селкенеп куйды да аптыраган-дай тагын утырды. Битараф тавыш белән сүзен сүлпән генә дәвам итте.— Ул баланы Әһли-аю кулыннан йолып алмасаң, хөкемгә тартырлар иде сине. Но...— Түгәрәк күзләр янә ялтырашып алды.— Әхмәт абый политрук булса, әтиең мәрхүмне әйтәм, баш тишмичә генә дә башкарып чыгар иде бу эшне... Менә бер заман шулай...— Нәкъ шул чакта Камилгә, ашыгыч ярдәмгә килгәндәй, телефон шалтырады.

Сабировка ник кергәненә үкенде Камил.

Ә иртәгесен көндез аны прокурор Һидият Бикмуллин үз кабинетына чакырып алды һәм мөдирне ишек буена ук килеп каршылады. Кул биреп, баш иеп исәнләште, кабинет түрендә урын тәкъдим итте. Бүген дә аның аксыл йөзе көләч, салам төсендәге сыек чәчләре майлап таралган шикелле ыспай, төсе уңа төшкән зәңгәр күзләре гөнаһсыз карыйлар сыман иде. Ә кыланышы Казанда очрашкан чактагыдан бөтенләй башка, илтифатлы булып күренергә маташуы да ак җеп белән теккән кара ямау сыман күренә:

— Исән-сау гына йөрисезме, Камил Әхмәтович? — дип төчеләнеп сүз башлады ул. Гүя аның җаны тантана итә, тыштан шуны сиздермәскә тырышканлыгы киеренке рәвештә калтыраныбрак чыккан тавышында ишетелеп күңелне изә, түбәнсетә.— Бу кабинетта очрашырбыз дип башыма да китермәгән идем. Ләкин... тормышта метаморфозалар бихисап бит. Бәла аяк астында йөри... Күрәчәк күз йомдыра, диләр. Күңелсезлеккә таргансыз икән бит?!

— Башка чара калмаган иде, иптәш Бикмуллин.

— Шулай димсез?

— Шулай дим. Фәкать шулай гына. Мәктәп баласын күрәләтә гарип итәргә ничек юл куя алыйм ди мин...

— Изге эш кылам дип, чаманы җуйгансыз түгелме соң? — Бу сорау кинаяле иде.

Сабитов ирексездән җилкәләрен җыерып куйды һәм тыныч итеп, җитди тонда җавап кайтарды:

— Минем максатым исерек хулиганны тагын да яманрак эш чыгаруыннан читләштерү иде.

Прокурор, өстәл буенда утырган хәлдә, башын уңга кыйшайтты, кашларын өскә күтәрде, күзләрен зур ачты да мәгънәсен чамалап булмый торган итеп көлемсерәде.

— Каш ясыйм дип, күз чыгаргансыз түгелме, Камил Әхмәтович? Кылны кырыкка ярырдай чакта алдынгы механизатор больничныйда утырырга мәҗбүр. Бу кадәресен бәялисезме соң?

Сабитовның җаны кыйнала башлады, ләкин ул кинәт кенә дуамалланучылардан түгел иде. Прокурорның кинаяле сүзләренә чәнечкеле җавап кайтару белән чикләнде.

— Больничныйда түгел, төрмәдә утырырга тиеш ул кеше, иптәш Бикмуллин. Төрмәдә!

— Бариев Әһлиулла кулы белән кылганын иңе белән күтәрергә тиеш, сүз дә юк.— Прокурор уң кулының имән бармагы белән ялкылдап торган өстәл читенә сугып куйды.— Сез дә үз чиратыгызда...

Шулчак Камил прокурорның сүзеннән битәр йөзендәге канәгатьләнеп, ләззәтләнеп сөйләү галәмәтләренә гаҗәпләнеп, нәфрәтләнеп, карады. Чыдамады, әйтеп салды:

— Сез исәп-хисап ясарга җай чыгуына бик шатсыз, иптәш Бикмуллин. Күрәм, хисләрегезне йөгәнли дә алмыйсыз,— диде.

Һидият Әгъзәмович әлеге сүзләргә бер дә исе китмәгән кыяфәттә калырга теләсә дә, булдыра алмады. Урыныннан торды, ачык тәрәзә буеннан әйләнеп килде. Өстәл кырыена басып шактый коры тонга күчте.

— Ниткән исәп-хисап, Камил Әхмәтович? Мин сезне җитди иптәш дип беләм, ә сез нииндидер малайлык күрсәтәсез. Мин — закон сагында. Бары шул гына. Шуны да әйтим: бу йортта, кагыйдә буларак, бәхәсләшмиләр. Мин сездән Бариев Әһлиулланы ничек җәрәхәтләвегез турында аңлатма язуыгызны үтенәм. Әйе, әйе, әлегә үтенәм. Менә кагазь, каләм...

— Рәхмәт, үземнеке бар...

Сабитов язарга керешкәч, Һидият бүлмәдән чыкты, ләкин ерак китмәгән иде булса кирәк, телефон чыңлый башлагач, бик тиз әйләнеп керде.

— Прокуратура, Бикмуллин,— диде ул һавалы гына итеп.— Тыңлыйм. Кинәт аның тавышы да, йөзе дә үзгәреп китте.— Исәнмесез, Сөләйман Шәйхиевич, исәнмесез! Хәерле көн! Рәхмәт, тырышабыз...— Татлы елмаю да бик тиз юкка чыкты, аны сагаю алмаштырды.— Әйе, монда. Сүз бар иде аның белән...

Телефон трубкасында райком секретаре Сөләйман Гафуровның салмак, басынкы, көр тавышы ишетелеп торды.

— Иптәш Бикмуллин, сезнең эшчәнлеккә тыкшыну дип аңламагыз, зинһар, яме. Мин үземә бирелгән вәкаләтнең чиген яхшы беләм. СССР Конституциясенең 168 нче статьясы белән әйбәт танышмын. Алай да иптәш Сабитовны бик тиз бушатуыгызны сорыйм. Аның иртәгә район укытучылар конференциясен уздырасы бар. Аңлашыламы? Бүген исә партия райкомында хәл итәсе мәсьәләләр байтак. Шуны да искәртеп үтим, гафу итегез: конкрет бу очракта Сабитов гаепле табыла калганда да, башта аның коммунист буларак язмышы хәл кылынып иде, аннары район Советына сайланган депутат буларак... Озак тотмагыз әле аны, туры райкомга килсен...

Бикмуллин бер сүз дә әйтә алмый тотлыгып калды. Аңлатмасын очлап килүче Камилгә кырыс кына эндәште:

— Сезне иптәш Гафуров бик тиз килергә чакыра.

## IX

Зур педсовет. Район укытучыларының һәр елны була торган август киңәшмәсе. Пленар утырышлар, секцияләргә бүленеп эшләүләр.

Бу киңәшмәне мәгариф фронты халкы төрлечә уй-кичереш белән көтеп ала. Берәүләр үзләренең еллык хезмәтләренә әйбәт бәя ишетүне өметләнеп, икенчеләре сагаеп, яман яктан телгә кермәгәем дип кан калтырап, җил-давыл кагылмый, тыныч кына үтеп китсә, алдагы елда тырышыбрак эшләрмен дип, күңеленә беркетеп куя. Шулай тынгысыз инде ул укытучы халкы... Әмма арада шактый ваемсыз гына килүчеләр дә табыла бу киңәшмәгә. Кайберсе яшь-җилкенчәк, эшкә әле мүеннан чумып җитмәгән, читтән торып укырга җыена гына, ә бер төркем исә егерме биш елын тутырган, выслуга кәгазе инде учында, пенсия яшенә җиткәнче берәү дә аны мәктәптән кузгатмаячагын — профсоюз законнарын — яхшы белә. Ә иң зур күпчелек исә белем һәм тәрбия бирүдә төпкә җигелеп тартучылар — август киңәшмәләрен мөһим мәсьәләләрне хәл кылу, ишетү, тәҗрибә уртаклашу трибунасы дип саный.

...Матур итеп җиһазланган, чәчәкләр белән бизәлгән район культура йорты шыгрым тулы. Бәйрәмчә киенгән зал. Яңа җитәкченең беренче чыгышы. Залда зур тынлык.

Камил Сабитовның докладка бик җентекләп, һәр деталь, һәр факт, һәр мисалны кат-кат уйлап-үлчәп хәзерләнгәне беренче җөмләләреннән үк сизелде.

Сөләйман Гафуров та президиумда. Һәр елны киңәшмәнең башын-

нан ахырына кадәр катнаша. Кирәк икән, чыгыш та ясый. Сорауларга җавап бирә. Боргаланып-сыргаланып торучылардан түгел. Булмасны вәгъдә итми, сүз бирсә — үтәми калмый. Шуңа күрә аның белән хисаплашмаган кеше юк. Менә ул Сабитов докладын бирелеп тыңлый. «Камил Әхмәтович кандидатурасына тукталып ялгышмадык шикелле,— дип фикер йөртә ул бу минутларда.— Тирәннән каера егет. Кыюлыгы да, теоретик белеме дә, хәзерлеге дә җитәрлек күренә. Чын-чынлап орбитага чыкканчы, терәк кирәк үзенә. Игътибар, игътибар яшь җитәкчегә! Иң әһәмиятле участок бу, кадрлар шунда формалаша, мәктәптә...»

Нурислам Габделбәров быел шулай ук президиумда. Беренче урта мәктәп директоры буларак түрдә. Камилне мавыгып та, яратып та, бераз көенеп тә тыңлый ул. Кеше күңеле дәрья бит — төрлесен уйлый... «Мәктәп коллективы, телиме-теләмиме, аны — Нурисламны — элекке директор, хәзерге мөдир белән янәшә куеп карагач, ничек күрә икән?.. Бик объектив зат, әмма турылыкта арттырып та җибәрә, минемчә... Күчәр башлары орынудан сак булуың хәерле... Нәкъ Камил кебекләр җилкәсендә бара бит хәзер тормыш.

Ә Йолдыз Сабитова залда, алгы рәтләрнең берсендә. Затлы киенгән, артык ялтырамый, кырыс карашлы, чамасын белеп кенә, беленер-беленмәс итеп кенә бизәнгән. Мәгълүм булганча, иренең яңа положениесе аны артык сөендерми. Мөдирлектә Камил вакытыннан алда биртеләчәк дип исәпли Йолдыз. Кинәт аның бу фикер җебе өзелә дә икенчесе сузыла башлый. «Зөһрәнең районга кайтуы очраклы хәлме? Әнисенең сәламәтлеге генә сәбәпме моңа? Фән кандидаты Нигъмәтова Сабитовларның гаилә иминлегенә янамый диган тулы гарантия бармы?» Байтак хатыннарга хас булганча, ирен шәхси әйбере сыман итеп караганлыгын Зөһрә районга кайткан хәбәрне ишеткәч тә сизенде Йолдыз. Уңайсызланды, дерелдәп китте, тик эчтән тынды. Камил белән ике арадагы салкынлык, киеренкелек элек күнеккән гадәт булса, хәзер — Зөһрә кайткач — яман чир сыман бертуктаусыз сыкрауга әйләнде...

Хәлимә Хәбировна шулай ук иң алгы рәттә. Чекерәеп торган чуар чәчәкле трикотин күлмәк кигән, кулда алтын сәгать ялтырый, бармакларында дүртме йөзек балкый, алтын муенса аскан. Сөрмә тарткан күзләр, иннек бер дә кызганмыйча мул буялган иреннәр — һәммәсе шәрран ярып кычкыралар... Бик бирелеп тыңлый. Беренче чыганактан алынган информация — уен картасы кебек аңа. Куян шулпасының шулпасын чөмереп, сүз сөйләп йөрүчеләрнең авызын томалар өчен иң көчле корал шул. Камил Әхмәтович бүген аңа сөйкемле, элегант, чын рыцарь булып күренә. Молодец, егетлек эшләде — мәктәптән китә бел-де. Аның китүе Хәлимәгә иркен суларга мөмкинлек бирде. Үзе дә күтәрелде, Нурисламга да вакансия калды. Тик менә кире борып кайтара күрмәсеннәр иде шушы посттан. Яраксыз эш майтарып ташлаган, ди бит. «Чулпан» колхозына баргач, «Уттай кызу эш вакытында ник исереп йөрисең» дип, комбайнерны тотып яңаклаган ди. Ә тегесе хөкемгә тарттыра икән...

Зөһрә. Зал уртасындагы рәтләрнең берсенә, стена буена барып утырган да, беркемгә дә һич нинди эшем-йомышым юк дигәндәй, дөньясын онытып, доклад тыңлый. Юк, докладның төп тезисларын гына отып кала ул. Рәхәтләнеп Камилгә карый, аның турында уйлый. Аралар ерак, күңелләр якын. Үзгәргән, олыгайган, карашлары ныгыган. Укучыларның хезмәт берләшмәләре турында гыйльми эш язарга ниятләве дә тикмәгә генә түгел. Студент чагыннан ук кырыс сүзле, принципиаль булуы бәлки байтак камчы да ашатыр әле аңа, аның каравы, вөҗданына каршы барып, нидер кылдым дип бер вакытта да үкенмәячәк. «Үкенеч!» — миңа гомерлеккә нәргән күләгә сүз бу. Аннан гомер-

гә дә арынасы юк инде күрәсең. Һич югы язмыш дигәнең уртәмәсен иде дә, гомер йомгагын Акташ якларына тәгәрәтмәгән булсын иде! Хәер, хис дигәнең бу уйга каршы баш күтәрә. Кайда, кайчан, ничек итеп очрашыр-аңлашыр идем мин гомерлек мәхәббәтем белән. Бер күрүең үзе бер гомер!.. Табигый җирлектә үскән гөл сыман күңелдә тирән тамыр җәйгән ул кадерле хис унтугыз ел буе мине яшәтә... Унтугыз ел — уем, сагышым, сөенечем, көенечем, өметем, шигем — бер син! Ул хис шундый кодрәткә ия — әгәр нинди дер очраклылык яки шәфкатьсезлек аркасында ике йөрәкне тоташтырган нәфис җеп өзелсә (тфү, тфү, уйлап каравы да куркыныч!), яшәүнең бер мәгънәсе дә калмас кебек. Сөю бетсә, кеше сүнә.

Кыскасы, Зөһрәнең уйлары диңгез сыман тирән, кара төндәй шомлы, күктәге йолдыздай ерак һәм якты иде. Ул шундый каршылыклы һәм иксез-чиксез уйлар дәрьясында бөтерелгәндә, кинәт сискәнеп китте... Тып-тын утырган зал көчле кул чабу тавышына күмелеп яңгырады.

Тәнәфес игълан ителде. Мөдир райком секретаре белән сөйләшә-сөйләшә чыгып барганда, төсләре киткән Зөһрә аның каршына килеп эндәште:

— Камил Әхмәтович! Гафу итегез, сүзегезне бүлдерәм. Хәзер килеп әйттеләр, әнкәйнең хәле бик авырайган икән, конференциядән китәргә рөхсәт сорыйм, зинһар...

Артык сүз әйтә алмады, күзләрен яшь сарган, тамагына утлы төер утырган иде. Сөләйман Шәйхиевичка нидер әйтте дә, Зөһрәне ияртеп Культура йорты ишегалдына чыкты Сабитов.

— Зөһрә апаңны бик тиз Гөлле Бораска илт! — диде ул шоферга. — Әйләнеп килердәй булса, көтәрсең...

Бик тиз булган шушы вакыйганың да шаһитлары табылыр һәм аны авыз тутырып сөйләү, күпертү теләге туар дип кем уйлый алыр? Тик факт: Хәлимә Хәбировна үзенә аглыйга-таглый булып йөргән Назирәгә бик тәмләп «иҗади» үстереп аңлата иде.

— Зөһрә Нигъмәтованың әнисе хәл эчендә, ди, әнә. Камил абыең Зөһрәне, роно машинасына утыртып, авылына озатып җибәрде, үзем күреп тордым. Машинага утыргач та нидер сөйләштеләр тагын...

Каршына Йолдыз килгәнен чамалагач, гәрчә «соңгы хәбәр» инде Назирәгә тиешенчә ирешкән булса да, Хәлимә Хәбировна аны көррәк тавыш белән тәкрарлауны кирәк санады:

— Кем дисеңме? Зөһрә апаң ул. Гөлле Бораска укытырга кайтты. Әнисе үлем түшәгендә, ди, әнә. Камил Әхмәтович аны роно машинасына утыртып озатты. Дөнья хәлен белеп булмый бит..

Соңгы җөмләсе аның күп мәгънәле, үтә тылсымлы булып ишетелде. Як-ягына карангалап, башкаларның йөзендәге мимикаларны «исәпкә алгач», канәгатьләнү хисе тоеп, тымызык кына елмаеп куйды яңа директор хатыны.

## X

Сентябрьнең беренче көннәрендә күк йөзе елап күңелен бушаткан бала җаны төсле иде. Тыелгысыз явымнардан арынган зәңгәр гөмбәз түрендә кояш кинәнеп елмайды. Гүя ул яңа уку елы башлануга канатланып йөрүче укучыларны тәбрикли, йөзләрен һәм юлларын балкыта алуыннан ләззәт таба иде.

Унынчы «А» да беренче көнне Гөлзада Фәйрушинаны юксындылар. Дус кызлары хәтта үпкәләде дә. «Менә сиңа серсез Гөлзада! Эчкерлелеген кара әле син аның. Ник беребезгә бер сүз әйтсен! Уфа тикле Уфага китеп барсын да кеше, саубуллашып та тормасын, имеш. Кыла-

нышы кырга сыймый»,— диештеләр. Ярый әле, башкасын уйлаулар булмады...

Рус теленнән беренче дәрескә керүгә, Йолдыз Ярулловна үз классында кемнең җәйне ничек уздыруы белән җентекләп кызыксынды: кайда эшләгәннәр яки сәяхәттә булганнар, ял тәэсирләре нинди, алда нишләргә җыенуларын ачыклаганнармы? Тәкъдим ителгән исемлектән кем нинди китаплар укыган?.. Укучылар актив иде, шулай да кайберләренең тыштан гына ялтыравын чамаларга да мөмкинлек җитәрлек. Программа материалын нигезле үзләштергән, тиреннән сөрган тырыш укучылар белән беррәттән «барыбер өч куймый хәлләре юк» дигән сыман кыяфәттә, ваемсызланып утыручы укучыларның күзләреннән күңелләрен уку мөгаллименең күңелен, әлбәттә, өшетә иде. Нишлисең, барысын да бер калыпка салып булмый. Азакта класс җитәкчесе укучыларга өйдә ирекле темага сочинение язып килергә кушты. «Һәркайсыгыз үзегез өчен кызыклы, әһәмиятле тоелган темага язасыз»,— диде ул. Язма эшләрне нәкъ бер атнадан җыеп аласын әйтте.

...Нияз Сабитов белән Халисә Габделбәрованың сентябрь уртасында Җиңү паркы дип йөртелгән яшь куаклык буенда чираттагы очрашуларына төп сәбәп шул сочинениеләрнең берсе — Халисәнең язганнары булды шикелле.

Йолдыз Ярулловнага ошады Халисәнең язмасы: эчтәлекле, пөхтә, ихлас күңелдән башкарылган иде. Әмма аны ул Ниязга да укырга тәкъдим иткәндә, ул, барыннан да алда, кызның мәхәббәткә мөнәсәбәтен дә күздә тотмый булмагандыр.

Әнисенең фикерен Нияз дөрес тоемлады. Халисәне ихтирам иткәне өчен аңа бик рәхмәтле иде ул. Классташының борчак-борчак хәрефләр белән язып тутырган дәфтәр битләре әле дә Ниязның күз алдында...

«Нәрсә соң ул мәхәббәт?»

«Сөю — бөек сер» дигәннәр борынгылар. Әйе, һәр кешенең мәхәббәте — үзенчә, башкаларда кабатланмый торган серле бер хис, тойгы ул. Аның нәрсә икәнен аңлатырга тырышып караганнар. Кайсылары «Мәхәббәт — ул зур фидакарьлек һәм ниндидер яхшылык хакына үз-үзеңне корбан итү» дигәннәр. Икенчеләре моның нәкъ киресен әйткән: «Мәхәббәт ул — үз-үзеңне генә ярату, эгоистлык ул, чөнки сөюче кеше бөтен эшләрен үзенең шәхси теләкләренә буйсындырып кора» дип расламакчы булган. Арада «Мәхәббәт — сукыр көч ул, акылны томалый» яки «ул — икенче бер шәхесне хөрмәтләү, аны җаның-тәнең белән ихтирам итү, шуңа күрә ул — әдәплелекнең анасы санала» кебек раслаулар да бар...

Мин исә бу хисне үземчә төсмерлим...

Тышта язгы серле төн. Әкрен генә тәрәзәне ачуга, чәчәккә бөреләнергә җыенган шомырт куаклары мине сәламли кебек. Кар суларында коенып шыткан беренче үләннең дымлы исе җанны рәхәтләндерә. Мәхәббәтнең чиксез кодрәте, тормышның кырыслыгын, ярсу дулкыннарын татымаган яшь күңел алдында, әйтерсең, табигать үзе баш ия! Мин бүгенгә барысыннан канәгать, бәхетле, тик йокы килми. Чулпан таңны уяткан мизгелдә тынып калам да өстәл лампасын сүндерәм. Ә хыял сүнми... Мин эчемнән укыган шикелле итеп: «Син минем күңел нурым, синең бер сүзең мине дәвалый, синең бер карашың мине җылыта һәм... Кинәт күңелемә сагыш тула... Яшьлекнең, гүзәллекнең, мәхәббәтнең рәхимсез күренешләр белән уртаклыгы бармыни?.. Син миңа шул кадәр кадерле, син аның нинди микъдарда икәнлеген белмисең, тоймыйсың, сизмисең. Хәер, кадерле, затлы, әйбер сыман бөек хис артык күзгә бәрелеп тормый, ялтырамый, әрсезләнми, арзанланмый», дип пышылдыйм... Синең нур чәчеп торган якты йөзең, аек акылың ми-

ңа көч өсти. Күзгә-күз карашып сүзсез аңлаша алырдай сөйгән кешең булу — бәхет! Чиксез, әйтеп бетергесез, бәяләп җиткесез бәхет!

Инде яктыра, еракта язгы таң беленә. Мин тагын урынымнан торам, тәрәзә янына килеп, әкрен генә, сизелер-сизелмәс кенә тавыш биреп йөгергән урам гөрләвеген тыңлыйм. Торган саен, тавыш ачыграк ишетелә, шашкын мәхәббәт белән җилкенгән сихри күңелдә җыр бөреләнә, авыз эченнән генә шуны көйлим, берүк өйдәгеләр уяна күрмәсеннәр...

Чишмә җырлый челтер-челтер,
Хис-сагыш бар җырында.
Күпме гашыйкларның серен
Кушкан ул үз моңына...»

Яшьләр хуш ис бөркелгән парк эчендәге эскәмиягә кереп утырдылар. Нияз Халисәнең сул кулын сак кына үз учларына алды, йомшак кына сыйпый-сыйпый кызның күзләренә карады. Халисә дә сүзсез генә Ниязга текәлде. Шуннан да бәхетлерәк мизгел бармы икән дип сынашкан төсле, өнсез калган сыман байтак тордылар. Ахырда Халисә чыдамады, көлеп җибәрде.

— Ник көләсең?

Нияз җитди иде.

— Күзләреңдә үземне күрү бәхетеннән,— диде кыз.— Канәгатьмесин?

— Синең бәхетеңә үрелгән сагыш та бар бит, Халисә, әйеме,— Нияз һич сәбәпсезгә урыныннан торды һәм, Халисә каршысына басып, аның яңакларына учларын куйды, бу юлы сорау ярылып яткан күзләре белән томырылып карады.— Дөрес, ул сагышың синең борынгы гашыйкларныкына охшамаган...

Халисә егетнең кулларын битеннән алды да эскәмиядән күтәрелде. Алар, бер-берсенең сулышын тоеп, кара-каршы бастылар.

— Минем сочинениене укыдыңмы?

— Ярамый идемени?

Халисә эндәшмәде. Болай булырын бөтенләй көтмәгән Нияз аптырап, уңайсызланып китте. Үзен генә түгел, димәк, әнисен дә ипсез халгә калдырды түгелме соң ул, күңелендәгесен сүзләргә төреп әйтте:

— Укырга ярамый идеме әллә? Син бит аны укытучыбыз кулына үзең тапшыргансың. Әнинең аны класс алдында теге яки бу яктан телгә алырга хакы бар... Синең сочинениең, синең иҗатың ич ул...

Халисә сәбәбен үзе дә аңлата алмаслык булып тулышты. Яшь бөртекләре тыңлаусызга әйләнеп сытылды һәм бите буйлап сузылды. Күз яше күргәч уңайсызланучан Нияз, юатыр сүз таба алмый интегеп, ыкмык итеп калганда, кызның ишетелер-ишетелмәс кенә әйткән сүзләре аның өстеннән авыр йөкне сыпырып төшергәндәй итте.

— Сиңа да барып җитсен дип яздым мин аларны,— диде кыз һәм, башын түбән иеп, аягындагы тәбәнәк үкчәле туфли очына карап тора башлады. Нияз, тирән сулап, аны култыклады. Алар, берән-сәрән коела башлап, аллеяга инде сары келәм түшәргә керешкән яфраклар өстеннән атлап ары киттеләр.

— Әни рөхсәте белән укыдым мин сочинениеңне,— дияргә ашыкты Нияз.— Язмаңны ул ошаткан.— Аннары егет берничә адым тын барды да, «Нәрсә булса, шул булыр!» дигән төсле, капыл гына әйтеп салды.— Әни дә ярата сине, Халисә.

— Аның ихтирамыннан миңа кыен да хәтта, Нияз...

— Моңа кыенсынмасаң да ярый.

Тагын сүзсез генә атладылар. Башланып та өзелеп калган әңгәмәгә дәвам кирәк иде. Авызга су кабып торыр чак түгел.

— Минем эти дә безнең дуслыкка һич каршы түгел.— Халисә үтә җитди сөйләп китте.— Әни генә... Үз әниеңнең гайбәтен сату әшәкелектер инде ул, Нияз. Синең миннән күңелең бизүе бар, алай да ачыклык өчен әйтми хәлем юк. Әни безнең дуслыкны өнәми. Тагын да төгәлрәге — Йолдыз Яруллованы яратмый ул. Аның сәләтеннән, уңганлыгыннан көнләшә дип әйтимме?..

Нияз бу кадәресен үзе дә байтактан чамалап йөри иде инде. Шунлыктан Халисә әйткәннәр аны чыгырыннан чыгармады, киресенчә, аңлырак булырга кирәк дигән уйны беркетте. Беркадәр паузадан соң шактый сабыр кыяфәттә, олысымак итеп:

— Алар дөньяга икесе ике күзлектән карыйлар, Халисә,— диде...

## XI

Камил өенә телефон куйдырырга өлгермәгән иде әле. Дөресен әйткәндә, телефон кертергә ашыкмый да иде. Менә ул тәнәфес булырга тиеш вакытны чамалап, Гөлле Борастан беренче мәктәпкә шалтыратты, Йолдызны чакыруларын үтенде.

— Минем беркадәр соңаруым бар, Йолдыз,— диде ире.— Педколлектив белән сөйләшеп алырга булдык. Син хафаланма, яме.

Йолдызның кәефе кырылды. Ул бу хәлне яшереп торуны да кирәк санамады, ачуы тавышына ук чыкты:

— Анда баргач шулай булуы билгеле инде...— Таптың көнен дә...

Камил, һичнәрсә аңламаган сыман, сорау бирде:

— «Анда баргач»ы нәрсә тагын?

— Ярар, белмәмешкә салма башыңны! — Йолдыз тагы да кырыслана төште.— Наивный булып кылану сиңа абсолютно килешми. Бүген ничәнче число икәне хәтереңдәдер ләбаса! Мин ничә көннән бирле хәстәрләнеп йөрим. Синең уеңда тузга язмаган башка мәшәкать...

Сабитовның шул мизгелдә кылт итеп исенә төште. «Ах, хода бәндәсе! — дип үзен эчтән сүгеп алды.— Октябрьның унысы бит бүген. Туган көнем икән минем»... Кырык өчне тутырды булып чыга Камил. Хатаны төзәтергә, туган көнен онытып җибәргәнлеген сиздермәскә кирәк иде:

— Мөмкин булган кадәр оператив булырга тырышырбыз. Педсовет бетүгә, җилдәй җитез кайтып житәрмен, әнисе! — дип телдәрләнде.

Ә кәефе көзге пычрак төн кебек иде. Гөлле Бораска килү белән, Зөһрә әнисенең вафат булуын ишеткән, дөньядан үткән кебек йөргән Зөһрәне күреп, күңелсезләнгән иде ул.

Мәктәптә сөйләшү, чыннан да, озакка сузылмады. Сабитов, педсовет тәмамлануга, минуты-секунды белән дигәндәй, Акташка юл алды.

Камил өйгә кайтып кергәндә, Йолдыз түр як өстәлгә сый-нигъмәт тезә иде инде. Нияз әнисенә булышып йөри. Өйгә һәркем күңеленә хуш килердәй тәмле аш-су, ризык исе чыккан. Аналы-уллы бәйрәмчә киенеп алганнар. Тик Йолдызның алъяпкычы гына тантана киемнәренә иш түгеллеген ерактан кычкырып тора.

— Әти кайтты, әни! — Нияз, ишек төбеннән торып, зал якта өстәл хәзерләп йөрүче Йолдызга хәбәр салды.— Син бер колагыннан тартасың, мин икенчесеннән. Кырык өчәрне икәүләп тарткач, күпмегә үсәр, күрербез.

Камил өске киемнәрен салып узарга өлгермәде, Йолдыз да килеп житте. Телефоннан сөйләшкәннән бирле йөзе аязмаган иде булса кирәк.

— Гөлле Борас юлына тоз сипкәннәрме соң әллә?! — дип үзалдына сөйләгәндәй әйтеп куйды.

— Менә кайтып та життем ич,— диде Камил яктырып. Нияз барында тел шомартуга юл куярга исәбе юк иде аның.
— Хәзергә кунып ук калганың юк әле. Анысы хак.
— Булды, әнисе.— Сабитов тагын да сабыррак әйтте бу сүзләрне.— Ишекне теге яктан ябып чыгып китәсе иде дә, көне ул түгел, шарты ул түгел... Туры — иң актыккы чара.
— Көне ул түгел, имеш. Күпме тел тешләп яшәргә мөмкин синең чә. Үз күңелемдә туган сорауларга җавап таба алмагач, сиңа мөрәҗәгать итәргә тиешмендер дип уйлыйм мин...
— Һәрхәлдә, сорау-җавап кичәсе бүген түгел, Йолдыз.— Бик сабыр булырга тырышып әйтелгән басынкы-салмак бу сүзләрдән Камилнең түземе төкәнеп килүе аңлашылып калды. Әмма Йолдызны иренең кызып китү ихтималы түгел, сабырлык саклавы үрти һәм үчләндерә иде.
— Кайчан соң ул аңлашу кичәсе алайса? Синең белән миңа махсус аңлашу өчен дип аерым көн билгеләнмәстер бит?
Камил җавап кайтарырга өлгермәде, ишек кыңгыравы чыңлады. Сабитов ишек ачарга ашыкты.
Кунаклар — ирле-хатынлы Габделбәровлар килеп керделәр.
— Рөхсәт микән бу йортка? Нурислам, парланган күзлеген сул кулына тоткан килеш, күзләрен ачалак-йомалак китереп, Камилгә кул сузды.
— Туган көнең мөбарәк булсын, Камил Әхмәтович! Тагын кимендә ике тапкыр шул хәтле яшәргә насыйп булсын!
Хәлимә дә, ай-кояштай балкып, Сабитовны котларга да, Йолдыз белән чүкердәшеп алырга да өлгерде. Бер-берсен ихластан ихтирам итешмәгән бу ике хатын, ничарадан-бичара килештереп елмаерга, телләреннән гөл түккән булып кыланырга мәҗбүр иделәр бу кичәдә. Хәлимә Хәбировна, йорт башын туган көне белән тәбрикләргә килгән кунакларның берсе буларак, хуҗабикәне дә олыларга тиешлеген уйлый — чөнки Халисә белән Ниязның дуслыгы күзгә күренеп ныгып барачагын белә. Йолдыз исә, ирен зурлап килгән ханымның күңелен табарга бурычлы икәнлеген төптән төшенә. Мондый очракта авызы тулы кара кан булса да төкерми инде ул.
Сабитовлар туган көнгә кунак чакырмыйлар. Мондый көннәрне алар гаилә бәйрәме итеп санарга күнеккәннәр. Кемдер, искә алып, үз ихтыяры белән килә икән, рәхим итсен, ишек уйган, тәрәзә куйган. Чакырылмаган кунакның хакы олы. Күңел дә, өй дә иркен. Сыйның сые-гы да, куесы да куелган өстәл һәрвакыт әзер була.
Габделбәровлардан башка килүче булмады бу юлы. Дүртәүләшеп бик күңелле итеп утырдылар. Нияз өлкәннәр янында тыкшынып утырудан уттан качкандай кача, ул каядыр чыгып ук китте. Шунысы да әйбәт: эшкә, мәктәпкә кагылышлы сүзне авызга да алмадылар диярлек. Бу мәҗлестә гүя мәгариф бүлеге мөдире белән урта мәктәп директоры да, укытучылар да юк иде. Чын-чынлап гаилә мәҗлесе булып кына үтте бу кичә. Ачыктан-ачык күзгә бәрелеп тормаган киеренкелек төсмерләре хөкем сөрсә дә, һәркем эчтән тынды, күрмәмешкә-белмәмешкә салынды.
Төнге унбер тулганда, кунакларны озаттылар. Сәгать, нәкъ шул чакны сугып, өйдәге тынлыкны бозды. Йолдызның тынычсызлыгы дәвам итте, әйтми булдыра алмады, кунаклар килү сәбәпле өзелеп калган сүзен дәвам итәргә ашкынды.
— Әйт әле, Камил,— диде ул, иреннәрен бөрештерә-бөрештерә,— турысын гына әйт, Зөһрә белән мөнәсәбәтегез нинди стадиядә?
— Мондый сорау бирергә нинди нигезең бар синең? — Камил сорауга сорау белән җавап бирде, аның тавышы да битараф һәм рәсми төстәрәк ишетелде. Ләкин Йолдызның туктар исәбе юк иде.
— Хатын-кыз сиземләвенә таянам мин, Камил. Кул белән тотып,

күз белән күреп булмый торган билгеләр була. Мин дә менә җаным белән генә түгел, тәнем белән дә сизәм шуны.— Йолдызның йөзе кырыслана төште, күзләре очкынлана төште, яңак калкыннары зураеп киткән кебек булды.

— Минем аның белән мөнәсәбәтем районлагы һәр педагог белән булган мөгамәлә шикелле үк...— диде Камил сагаебрак. Бер яктан Йолдызның көтелмәгән һөҗүме, икенче яктан вөҗдан газабы телгәли аны: Зөһрә турында сүз барганда, мондый сөйләшүләргә юл куярга ярыймы соң? Шунлыктан ул хәзергә бу сорауларга җавап бирүдән баш тартырга ниятли.

— Ә ирләрчә батырлык җыеп, дөресен әйтә алсаң, ни дияр идең?

Юк, юк, Зөһрәгә карата күңелендә булганнарның һәммәсен туп-туры әйтергә тел җитми. Ул хисләр шундый изге, нәфис, шундый нечкә, шундый газиз иде! Мондый хис тупас сүзләрне күтәрә алмый, ә ул хис юкка чыкса — Камилнең канатлары сынар, кулыннан эше төшәр, гомумән яшәүдән туктар сыман.

— Дөресен әйтеп булмыймы, Камил Әхмәтович! — Йолдызның рәсми тонда әйтелгән сүзләре өскә бозлы су койгандай рәхимсез иде. Йолдыз сүзен дәвам итте, ләкин Камил, тыңлаган булып кыланса да, ишетми иде. Ул Зөһрә нурында, аның күңел яктысында коена, шундый авыр чакларда, яшьлек хыялына уралып, Зөһрә образы күз алдына килә дә тормышның салкын җилләренә каршы барырга ярдәм итә. Әле һаман хәтта фән тикшереп бетерә алмаган могҗизадай мәхәббәт мәгаен шул үзедер?! Йолдызның сүзләре, ерактан ишетелгән кайтаваз шикелле, Камилнең аңына килеп бәрелеп юкка чыга баралар сыман...

— Семьяда мине аңламыйлар дип шыңшыгансыңдыр инде син аңа, әйеме? Минем хатын ир кадерен белүче түгел дигәнсеңдер. Җан җылысына туймыйм дип зар түккәнсеңдер. Бер үзең дә, ике күзең генә уйлап яши, миңа игътибары җитми дип мескенләнгәнсеңдер?..

Камилгә үзенең мәлҗерәп баруы күңел болгаткыч булып тоелды. Шул халәттән котылыр өчен кинәт һәм кискен итеп әйтеп салды:

— Ташла әле сафсатаңны! Берәү алдында да шыңшырга җыенганым юк,— диде.— Ачуың купкан, шуңа тел чарлыйсың.

— Күңелем хушланганнан түгел, билгеле.— Йолдыз түр тәрәзә буендагы креслодан җәһәт кенә торды да, диванга ире янәшәсенә килеп утырды.— Менә нәрсә, Камил, ныгытып уйла, уйла да сайла: я мин, я ул... «Ярым ятлар белән уртак, янамын да көямен» дип, моң-зар түгеп йөрергә исәбем юк минем. Тот та хәл ит, бетте-китте.— Йолдыз, үз авызыннан чыккан артык дуамал сүзләр дулкынында күмелеп калгандай, моңсуланып куйды. Моңа ышансаң... Юк, ул күбрәк законга, җәмәгатьчелеккә, ниһаять, үзе башта кабул күрмәсә дә, эшкә башлау белән районга танылып өлгергән иренең абруена ышана. Шул уйлар шаукымында бераз йомшарып, тагы сүзен дәвам итә Йолдыз.

— Күрәм, син хәзер өзеп нидер әйтергә әзер түгел. Борғалануың кирәкми. Мин сине ихтирам иттем, мине шуңардан мәхрүм итмә. Тамам уйлап бетер дә...— Сүзе өзелеп калды Йолдызның, тавышы карлыкты, күз яшьләрен тыя алмады ул...

Бүтән бер сүз дә сөйләшмәделәр. Икесе ике бүлмәгә кереп ятты. Йокы гына алмады үзләрен... Йокысыз төннәрнең беренчесе дә, соңгысы да түгел бу төн...

## XII

Кыш хәбәрчесе — кырпак кар октябрьның егерме өчендә үк күренгән иде, әмма бәйрәмне кышкы киемнәргә төренмичә генә уздырдылар.

Кабинетта җылы, якты. Камилнең кәефе дә зарланырлык түгел иде. Аның артыннанияреп үк диярлек хат ташучы килде. Бер кочак газет-журналлар, министрлыктан хат калдырып китте.

Тагын бер хат бар иде. Анысы районнан гына, «Чулпан» колхозыннан. Әһлиулла Бариев кызыннан. Әйе, Әһли-останың төпчек баласыннан. Кыз алтынчы класста укый икән.

«Сезгә, Сабитов абый, күптин-күп сәламнәр язам, яхшы теләкләрем белән бергә, сезгә булган үпкәмне, рәнҗүемне дә әйтәсем килә.

Әгәр сез судта каты тормаган булсагыз, әтине төрмәгә утыртмаслар иде, принудработ белән калдырырлар иде, бәлкем. Сез шул аның помушнигы булган егетне генә бик җәлләп сөйләгәнсез, аның саулыгын гына кайгырткансыз. Сез бит, Сабитов абый, укытучыларга да, директорга да акыл бирә торган кеше, Әһлиулла Бариевның да балалары бар, укыйсылары бар, аларны ятим итү ярамас дип уйлап карамадыгызмы? Уйларга кирәк иде бит бу турыда.

Әтинең хөкем карарын Казандагы Верховный судта да шул көе калдырдылар. Ул хәзер төрмәдә утырачак. Абый белән апа зурлар, ә мин бит әле алтынчыда гына укыйм. Шушы яшемнән әтисез сыңар канатлы булып калуның авырлыгын күз алдына китерә аласызмы? Үзегезнең дә балаларыгыз бардыр. Алар минем хәлдә калса, әйбәт булыр идеме?..»

Баланың хәсрәте зурлыгын, үтемлелеген аңлый Сабитов. Ләкин ул хәсрәтне балаларына да, хатынына да, ниһаять, үзенә дә Әһлиулла үзе китерде бит. Үз куллары белән. Шуны иңе белән күтәрә хәзер. Ә хатны әнисе әйтеп торып яздырган, әлбәттә. Ана кеше дә хаталана. Баланың башын бутый. Әтиең ярамаган эше аркасында шул хәлгә төште дип дөресен аңлатасы урында, кемнедер гаепләп, кызыннан хат яздыра. Гаепсез кешеләргә үчлелек, азаккы чиктә дөреслеккә, законга үчләнүгә кайтып кала бит! «Чулпан» якларына юл төшкәндә, Бариевлар гаиләсенә кереп, хатка җавап рәвешендә аңлатма бирергә кирәк. Һич югы Әһли-останың хатынына хакыйкатьне төшендерү зарур...

Борчуга салырлык, кайта-кайта уйланырлык хәл; кешеләрдә дөреслекнең күзенә туп-туры карый алырлык батырлык бик тансыкка әйләнеп бара түгелме соң? Бариев хатынына карата гына түгел, гомумән алганда да «үзем дигәч авыз йомылу» шулмыни соң әллә?!

Кәефе кырыла язды Сабитовның. Шулай да үзе янына эш башланган сәгатьтә үк килеп кергән Нурисламны ул ачык чырай белән каршылады. Габделбәров көзге пальтосын, шуңа иш итеп сайланган кашнесын һәм эшләпәсен ишек буендагы элгечкә элде.

— Ник бик иртәләдең? — Гадәткә кергән, исәнме-саумы сүзләреннән соң ук Камилнең беренче соравы шул булды. Зур кара күзләрен авылдашына төбәгән иде ул, ирен читләренә хәйләкәр елмаю галәмәте кунаклаган иде.

— Бәйрәмнән исән-сау калуымны хәбәр итеп, начальствога буй-сын күрсәтеп чыгыйм дип керүем,— диде Нурислам җиңелчә шаяру тонында.

— Бер уңайдан сезнең хәлләрдән дә хәбәрдар булырмын, мин әйтәм...

— Рәхмәт илтифатыңа.— Мөдир түзмәде, елмайды. Габделбәровның хәл-әхвәл белешергә генә кермәгәнен белеп тора иде.— Мин бәйрәм көннәрен гаҗәп шәп уздырдым, иптәшкәем. Алтысында кич бөек бәйрәм хөрмәтенә бокал күтәрдем дә калган ике көнне баш күтәрми эшләдем. Укыдым, яздым, сыздым, боздым...

Нурислам да, тавышын мөдирнекенә охшатырга тырышып, тезә башлады:

— Кандидатлык диссертациясе мәшәкатьләре... тормыш материалы, анализ, резюме, җыйналган фикерләрне кәгазьгә төшерү...

Камил исә житди итеп әйтте:

— Шунсыз мөмкин түгел. Шулай җигелмәсәм, һич нәрсә барып чыкмаячак... Шуннан сүзне кырт кына бүтәнгә борды.

— Синең ник килгәнеңне беләм мин...

— Никтер дип уйлыйсың?

— Беренче чирек нәтиҗәләре буенча отчетың тыңгы бирми сиңа. Башта син җиңел кулдан укытучыларны «сыйфат, сыйфат!»— дип кудырдың, менә биреп күрсәттеләр алар сиңа сыйфатны. Син шуларны роноға китердең, ә мин аларга ышанып җитмәдем.

— Ышанмаска нинди нигез бар?

— Минем ул мәктәпне бик яхшы беләм һәм синең анда ике ай эчендә генә революция ясый алу мөмкинлегең юклыгы...

— Берәү дә бер урында гына тормый, Камил Әхмәтович!..

— Килешәм. Ләкин синең өлгереш процентлы белән мавыгу чирең күз алдында икәнлеген дә туп-туры әйтәм.

— Соң бит...

— Бәхәсләшмибез. Болай сөйләшәбез. Икенче чирек барышында беренче урта мәктәптә фронталь тикшерү уздырабыз. Булдымы? Шул чагында да отчетыңдагы сыйфат күрсәткечләре, ягъни дүртләр, бишләр аякларында басып калса, мин бүгенге сүзләрем өчен гафу үтенермен.

Нурислам үпкә белдерде:

— Яңа директор башына килә-килешкә имән күсәк! Дусларча түгел бу, Камил Әхмәтович...

Сабитов, урыныннан калкып, ике учы белән дә өстәл кырыена таянды һәм дәрес аңлаткандагы төсле итеп әйтте:

— Дуслык хакына дип миннән бернинди ташлама, ягъни скидка өмет итмә!..

Сәгать ун тула дигәндә, кабинет ишеген шакып, Зөһрә килеп керде. Бу гел көтелмәгәндә булды, Камил аптырабрак та калды хәтта. Әмма, ни генә әйтмә, Зөһрә иде бит ул, Зөһрә! Сизелер-сизелмәс кенә бизәнеп алгангамы, саф һавадан кергәнгәме, чибәр актрисалар сыман матур иде ул бүген. Әнисе хәсрәтеннән дә арына төшкән иде ахрысы. Тавышы һәрвакыттагыча көмеш чыңлавы шикелле, җанны рәхәтләндерә.

— Гафу ит, Камил,— диде ул, кабинетка пальтодан узып аңлатып. Берничә генә минутка мин... Сине соңгы тапкыр борчыйм бу юлы.

— Соңгы тапкыр?

— Әйе, соңгы тапкыр.— Зөһрә шундый итеп елмайды, Камилнең йөрәге сызылып куйды.— Әйләндерден башларымны дип орышма, яме. Мине логикасызлыкта гаепләргә дә ашыкма... Тормышта көтелмәгән хәлләр, өмет итмәгән бәхетләр тулып ята икән...

Камил, өстәл артыннан чыкты, стена буена тезгән урындыкларның берсен алып, Зөһрә каршысына ук килеп утырды.

— Тукта әле, Зөһрә-йолдыз, нигә гафу сораулар, кереш сүз, увертюра? Чит кешемени мин сиңа?! Туп-туры гына әйт әле, ни булды, нәрсә бар?

Зөһрә, мәңге сагынмаслык итеп карап каласы иде дигән сыман, Камилнең күзенә тутырып карады да:

— Китәм мин, Камил. Китәргә булдым, китми ярамый,— диде һәм аннары, һич көтмәгәндә-уйламаганда күңелсезләнеп, сүрелеп, сүлпәнләнеп калды.

— Кая китәсең? Ник?

— Еракка, Камил. Директор белән аңлаштык, килештек дияргә мөмкин. Минем сәгатьләрне бүлеп бирергә булдылар, инде эш синең рөхсәттә калды.

— Сәбәп нәрсәдә? — диде ул, тулы аңлату өметләнеп.— Ачыграк сөйлә әле, зинһар, Зөһрә...

— Ап-ачыгы шул, Камил. Бу шартларда сөйләшү кыенрак инде.—

Зөһрә, ихтыяр көчен эшкә җигеп, күңелендәге моңсулыкны читкә тибәргәндәй булды.— Әнкәй хакына дип кенә кайткан идем, анысын беләсең. Ул юк инде хәзер. Димәк, авылда торыр максатым юк. Миссиям төгәлләнде. Аспирантурада бергә укыган дус кызым белән элемтәдә торабыз, ул РСФСР мәгариф министрлыгында эшли. Миңа бик тиз урын тапты һәм квартира алыштыруда да булышлык күрсәтергә алынды. Башка шәһәргә китәргә булдым, нәкъ минем профильгә туры килгән эшкә — рус теле укыту методикасы буенча фәнни-тикшеренү институтына урнашам... Менә шул. Син тоткарламассың дип ышанам...

Камил урам як тәрәзәгә карап уйга уралды: «Бик-бик күңелсез булып калачак бит...»

— Я, ни дисең? — Зөһрә җавап көтә иде.

— Син миңа шундый кроссворд бирәсең, андагы шакмакларны тутыру өчен энциклопедия томнары актару да ярдәм итмәс...

Зөһрә көлеп куйды.

— Юк, Камил, алай баш ватмыйк, гадирәк карыйк мәсьәләгә. Димәк, каршы түгелсең?

— Фәлән укытучының районнан китү фактына мин гадәти күренеш дип карар идем. Ләкин бит ул фәлән укытучы син, Зөһрә?!

— Шулай кирәк миңа, Камил!.. Китми кала алмыйм мин, хәтта Казанда да кала алмыйм. Сәбәбе шул: мин киләчәктә ялгыз булмаячакмын инде...

— Ягъни?

— Һай, бу ир-ат халкы!

Зөһрәнең менә шушы җөмләсе Камил өчен һәммәсен аңлаешлы итте.

— Чынмы? — Камилнең башы әйләнеп киткәндәй булды. Уйчан карашлы карасу коңгырт күзләре очкынланды.

— Уйнап сөйләшә торган эш түгел.

Һәр икесе бер мизгелгә тынып калдылар. Сүзсезлекне тагы Зөһрә өзде.

— Ул булса — Ядькәр, кыз була калса, Хатирә дип кушармын,— аның тавышы тантаналы да, аянычлы да иде.— Һәрхәлдә хәбәр итү җаен табармын дип беләм... Тик син исән-сау бул, тыныч бул, һәрчак янымда син!— Сагышын буена сеңдергән сыман, яшьләрен дә йота алды Зөһрә. Тамарга җыенган күз яшьләрен кысрыклап, йөзенә елмаю балкытты, гүя ул Камил хәтерендә шул кыяфәттә яшәп калырга тели иде...

— Инде хуш, Камил! — Зөһрә аңа кул сузды.— Бер генә гозерем калды: озата чыкма...

Камил ике кулы белән башын учлап, терсәкләрен өстәлгә терәп утыра бирде. «Кеше иң кыйммәтлесен ник бик тиз югалта икән? — дигән сорау аның аңында терекөмеш тамчысы булып бии иде.— Үкенмәсәк икән дип яшибез, үкенечтән арынып та булмый...»

*1970—1980*

## Давыт Кугелтдинов,

калмык шагыйре

*Быел Татарстан китап нәшрияты калмык халык шагыйре, СССР һәм РСФСР дәүләт премияләре лауреаты Давыт Кугелтдиновның «Иркенлек» дигән шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарырга әзерләнә. Д. Кугелтдинов үз иҗатында татар халкын, Татарстан җирен, республикабызның атаклы кешеләрен дә чагылдырды. Аның «Моабит тоткыны» дигән поэмасы да бар. Ул халкыбызның батыр улы, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты патриот шагыйрь Муса Җәлил батырлыгына (биредә Тимер исемле) багышланган. Поэманың кыскача бер өлеше 1959 елда шагыйрь Зәки Нури тәрҗемәсендә «Совет әдәбияты» журналында (9 нчы сан) басылып чыккан иде. Хәзер аны шагыйрь Гәрәй Рәхим тулысынча тәрҗемә итте. Шуннан бер яңа өзек тәкъдим ителә.*

## МОАБИТ ТОТКЫНЫ

ӨЗЕКЛӘР

●

... — Профессор, өч көн һушсыз яттым...
Шул көннәрнең бәгъзе берендә
Бер-бер хәбәр ишетелмәдеме,
Диварлардан, морзе телендә?
— Булды, булды, җаным, шатландырам.
Һәр иртәдә «шык... шык...» кактылар.
Әнә тагын йөзең ап-ак синең,
Торма, торма, әле ят кына.

Тимер шунда шинель артындагы
Нәни дәфтәренә үрелде.
Күз алдында аның яңа образ,
Яңа шигъри сурәт күренде.
Сүтеп алды күлмәк якасыннан
Нәни генә каләм үзәге.
Мондый чакта инде шагыйрь күңеле
Иҗат итми, язмый түзәме?!.
«Әй син ятып, ятып кына эшлә...»
«Әй изге карт, аңла шөгыльне —
Аягүрә языла чын шигырьләр,
Ятып язып булмый шигырьне!..»

Бүген Тимер шундый төш күрде:
Гүя ерак һәм чит иллардән
Кайтып килешлидер — Моабитка
Толстой һәм Чехов кергәннәр.
Чехов — озын, бераз бөкрәйгән.

Ул Тимергә карый иркәләп.
Ә Толстой кашын җыерган,
Ул кемгәдер бик нык үртәлгән:
«Сез, дускаем, дөрес юлдасыз,
Язучылык бурычын аклыйсыз,
Җаныгызны алып чыгасыз
Кырык үлем, кар, боз аркылы...»
Пенснесе аша карый да
Чехов саный йөрәк тибешен.
Башын чайкый гаҗәпләнүдән —
(Ниләр генә төштә күрмисең?!) —
Кесәсеннән алып бер кәгазь,
Майга талон язып бирә ул:
«Менә дару... Ярдәм итәчәк...»
Ләкин Тимер күрә, күрә ул —
Нинди ябык Чехов үзе дә.
Май талоны Антон Палычның
Бик кирәктер бәлки үзенә?!

Бер читлектә икәү... Хәлсез, тыныч...
Яшьрәге яза шигырьләр.
Олырагы уйлый... Икесе дә —
Потенциаль озын гомерләр.

Икәү булгач әле көч тә бар,
Уртак дошманнарга үч тә бар.

Бер читлектә икәү... Яклаучысыз,
Коралсызлар... Нәрсә диясе?..
Ләкин берсе аның япь-яшь шагыйрь,
Икенчесе — акыл иясе.
Язмыш тупаслыгын бит алар
Акыл белән кире кагалар.

Бер читлектә икәү... Куркынычлар
Фикер көче булмаганнарга.
Фанатиклык белән баштан ашып
Акылга бик тулмаганнарга.
Һәм аларны үтерү дә шундый
Җиңел кебек... Ләкин һаман да
Акыл көче кинәт, феникстай,
Очып чыга җиргә, заманга!..

Һәм коткарып кала бу икәүне,
Алар белән тагын бик күбәүне,

Фикер!.. Ул бер бөек көчкә әверелә
Зур омтылыш белән кушылганда.
Танкларың тына, самолетлар —
Данко йөрәгенең көче анда!..

## Эпилог

Сугыш беткән. Кырык алтынчы ел.
Җимерелгән Берлин каласы.
Шәһәр ята әле җәрәхәттә,
Төзәлмәгән аның ярасы.
Франц Шмидт — Берлин каласында
Туып-үскән немец... Күп күргән...

Өстәленә тәмам яткан килеш
Чын мәгълүмат яза хәтердән.
Картка кыен. Хәтеренә төшә
Мыскыллаулар, ачлык... Әнә бит
Күз алдында өрәк булып тора
Җан өшеткеч төрмә — Моабит.

Ә урамда — Берлин... Туган шәһәр...
Аһ, никадәр үзгә ул бүген.
Төннәрендә тәмам сукырая,
Сыңар ут яктыртмый күген.
Биналарда әнә кызыл кирпеч
Кутырлаган кызыл кан кебек.
Җимерелгән, тәмам тетелгән ул,
Туган кала үлгән җан кебек.
Берән-сәрән йөргән кешеләрдән
Зур калага барыбер кот кунмый.
Түбәләрдән купкан калай җилдә
Каһәрләнгән кебек шыкылдый.
Яза-яза күпме кәгазь тулды.
Ачы хатирәләр азмы соң?!
Карт коммунист күз яшьләрен йота —
Бигрәк ачы ватан язмышы.
Әшәкелек канунына табынып,
Тик бер өер банда, күр инде,
Германия дигән бөек илне
Шушы түбәнлеккә җиткерде.
Бу кайгыны гади үлчәү белән
Үлчәп булмый... Кая соң дуслар?..
Алар янды төрмә мичләрендә,
Шул ук мичтә янды ич руслар.
Шмидт торып, әре-әре атлап,
Бүлмә буйлап йөри, түзми ул,
Гүя өйнең һәрбер почмагыннан
Үтерелгән дустын эзли ул...
...Әнә... Күз төпләре күм-күк булган,
Эндәшә ул теге дөньядан:
«Син исәнсең... Минем шәхесемне
Арала син анда яладан...»
Зур юлларга чыга ул шәүләләр
Җир шарының барлык ягыннан.
Дардагылар гына атлый алмый,
Чайкалалар бары давылда.
Сәләмәсен сөйрәп килә алар,
Шалтыр-шолтыр килә скелет:
«Безне дә яз, без дә бар идек бит...
Үзең күрдең безне син килеп,
Ишек ярыгыннан карап тордың —
Майор мине ничек таптады...
Мин бит галим, карт бер профессор,
Мине майор кыйнап ташлады.
Врач-палач аннан минем кулга
Кадап китте үлем уколын.
Менә кара, һаман саклый әле
Үлем-укол эзен уң кулым.
Син — ишеттең елау, өзгәләнү,
Һәм... Тимернең көлү авазын!

Шул көнне бит биш мең әсир үлде,
Син онытма моны, яз барын.
Биш мең әсир янды күмерләнеп,
Алар тере көе яндылар.
Кальтенбруннер шулай кушкан иде,
Шулай биш мең җанны алдылар...»
Иң соңыннан бары шуны әйтәм:
Уяу булыгыз сез һәр мәлдә!
Алар үлде... Ләкин яңадан да
Кабатлану мөмкин бу хәлләр.
Дошман һәрчак үзгәртә чын йөзен,
Исемен дә хәтта яшерә.
Үлем һәрчак карт чалгычы булмый,
Күренә ул кайчак яшь кенә.
Һәлак булган ата уллары, сез,
Оныклары... Уяу булыгыз!..
Ялганнарга, тәмле алдауларга,
Хәйләләргә каршы торыгыз.
Күрегез, күр!.. Сезнең алдыгыздан
Узып бара әнә әрвахлар.
Алар дәшә: — Онытмагыз безне,
Сез бит бездән киткән тармаклар!..
Әй тереләр! Онытмагыз безне!..
Без бар идек!.. Без нык көрәштек!..
Хәзер сезгә зур бер мирас итеп
Калдырабыз хәтер-йөрәкне!..

**ГӘРӘЙ РӘХИМ** тәрҗемәсе

## Укучының күңел дәфтәренә

### КОРЕЯ ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРЕ

*Туккан дөгене җыеп булмый, ә әйткән сүзне кире кайтарып булмый.*
*Якын кешеләрең белән һәрвакыт туры сөйләш.*
*Телендә — бал, күңелендә хәнҗәр.*
*Күрмәгән кешеңне сөйләмә.*
*Хәбәрдән хәбәр туа.*
*Стенаның да колагы бар.*
*Буш сүз начар көй кебек.*
*Юләр язып куйган сүз акыллы хәтереннән артыграк.*
*Җәзалаган баланны көчлерәк яратасың.*
*Яхшы мичнең җылысы начар анадан шәбрәк.*
*Бәхет хезмәттән килә.*
*Суда балык тотам дип куанма, аны токач куанырсың.*
*Бәхетсез кешенең эте карак күргәч тә өрми.*
*Бәла — елга шикелле: төрле яктан агып килә.*
*Сулы тәлинкәдәге балык ирекә түгел.*
*Шаулы табында ризык та аз була.*
*Сүз белән сыйламыйлар.*
*Начар кавын аппетит боза.*
*Хуҗалары күп йорттан барча кунак ач китә.*
*Вакчыл кеше вак корт кебек.*
*Яңа юл салгач, иң алдан комсыз кешеләр үзә.*
*Бушлай бирсәң, комсыз кеше ачы агу да эчә.*
*Яшеннән сакланыр өчен башына чүмеч кигән.*

# Александр Капустин

*Александр Петрович Капустин — сугыш ветераны. Бөек Ватан сугышы барганда ул үзенең туган авылы Гомель өлкәсе, Жлобин районы Старая Руднода яшерен комсомол-яшьләр группасы төзи, соңрак партизан отряды составында фашистларга каршы көрәшә, фронтта була. Берничә тапкыр яралана, контузия ала. Сугышчан орденнар белән бүләкләнә. Сугыштан соң комсомол, юстиция һәм матбугат органнарында эшли. СССР Язучылар союзы члены, ун проза китабы авторы. Күптән түгел язучы «Тозлы чык» исемле документаль повесть тәгәлләде. Әсәрнең төп геройларыннан берсе — Казанда туып үскән, шунда хәрби училище тәмамлаган, түбәндә китерелгән өзектә күрсәтелгән батырлыгы өчен 1941 елның августында ук Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган капитан Ф. А. Баталов. Әсәрдә реаль персонажлар буларак сурәтләнгән бүтән якташларыбыз да бар.*

# ТОЗЛЫ ЧЫК

Баталов, киңәшмә бетүгә, үз батальонына ашыкты. Корневич ул арада атларны штаб янына алып килгән иде. Тыгыз гәүдәле комбат атына житез генә сикереп атланды да, юлдагы суларны чәчрәтеп, юыртып китте. Яңгыр туктаган. Күк яңадан аяз, болытлар таралып беткән, әүвәлгечә кояш балкый. Биек-биектә, төпсез зәңгәрлектә, фронт сызыгына каяндыр килеп эләккән бер тилгән әйләнеп йөри. Канатын бер-ике тапкыр талгын гына җилпеп ала да киң итеп язып җибәрә, аннары тагын әйләнә дә әйләнә.

Озынчарак бер аланлыкта, почмак-почмак боргаланып, траншея сузылган, юл шунда таба борылды. Баталов, тезгенен тартып, атын тыя төште. Була бит шулай кайчак, кешенең күңелендә үзенә дә ачык кына аңлашылып бетмәгән сәер теләкләр кузгала. Аның белән дә шундыйрак хәл булды: атын шушы урында туктатып, урманның сихри авазларын, гаҗәеп тынлыгын тыңлыйсы, авыр сугыш мәшәкатьләреннән аз гына булса да бушап аласы килеп китте. Тыныч вакытта күңелне моңсулата, ә сугышта җанга тынычлык бирә торган шундый халәткә сусавын тойды ул. Кайчан гына булмасын, урман аңарда бер төрле ләззәтле уй-тойгылар уята торган иде. Хәзер дә менә шулай...

Еллар үтә-үтә бу траншеяны үлән басып китәр, чәчәкләр, җиләкләр каплар. Тормыш дәрте ташып торган бер яшь кеше шушында хуш исле җир җиләге, тук тәнле ак гөмбәләр җыярга килер, кошларның куанычлы чыр-чуын тыңлар, күкеләр белән бергә еллар санар. Һәм, мөгаен, ул монда кайчандыр элек — кырык беренче елда фашистларга каршы канлы сугышлар барганын, шушы җирдә генерал Петровский, лейтенант Шәрәфетдинов, сержант Головченя-Вишневский, халык ополчениесе сугышчысы Ткачев сугышып йөргәнен белмәстер дә, уйламас та...

Искә төшермиләр икән, төшермәсеннәр. Баталовны анысы бик куркытмый. Онытсалар соң, хикмәт андамыни? Бигрәк тә шунысын, тыныч көннең ни бәягә яулап алынганын онытмасыннар, белсеннәр. Ә алар... Алар бит дан өчен дип түгел, җирдәге тормыш хакына яуга керделәр.

Менә син дә бер генә минутка сугышны, кан коешны онытып торырга, урман тынлыгына ләззәтләнергә дип уйлаган иде... Әмма, урман һавасын тирән итеп, күкрәк тутырып бер сулады да, ияренә җайлабрак утырды, атын тагын кузгатты.

Штабта капитан Садовников белән ниндидер ярым хәрби киемле ят кеше бар иде. Өстәл артында сөйләшеп утыралар. Комбат шунда ук төшенде: Ткачев. Янына килде. Үз исемен әйтеп кул сузды. Ткачев ялт сикереп торды, хәрбиләрчә честь бирде, үзен таныштырды һәм Баталовның кытыршы кулын каты итеп кысты.

— Мин сезне нигәдер нәкъ менә шушындый итеп күз алдына китергән идем,— диде капитан, тәвәккәл разведчикны кызыксынып карый-карый.— Шундый калку, төз гәүдәле итеп. Ә бәлки очрашканыбыз да бардыр? Хәтерләмисезме?

— Очрашкан идек. Ләкин ул чакта сез миңа игътибар итмәгәнсездер, мин үзем генә түгел идем. Моннан өч көн элек без истребительный батальон командиры Миронов, комиссар Злынов, штаб начальнигы Ярошев белән сезнең полк штабыннан чыкканда, сез кереп килә идегез.

— Хәтерлим... Утырышыйк, Антон Петрович, әзрәк сөйләшик тә, эшкә тотыныйк.

— Әйдә, эш көтеп тормас.

— Димәк, немецлар шушы арада Җлобин урамында яңа пулемет ноктасы куйдылар дисез? Бер генә микән. Бәлки, тагын да бардыр, ә без белмибез генә?..

Ткачев комбатка игътибар белән карады:

— Аңлыйм ни әйтүегезне.

— Юк, сез тыңлагыз әле. Разведчикларыгыз шәһәргә тагын бер кат барсын дип әйтүем түгел. Безнекеләргә елга аша чыгарга ярдәм итмәсләрме диюем генә. Монда яшәүчеләр кичү өчен уңайлы урыннарны яхшы белә. Ә вакыт бик аз. Таңга кадәр генә.

— Минем разведчиклар хәзер теге як ярда. Беркадәресе төн уртасында кайтырга тиеш. Берәр яңалык булса, шунда ук хәбәр итәрмен.

— Килештек, Антон Петрович. Хәзер теге пулемет турында. Тынгы бирми ул миңа. Аңа ничегрәк якынлашырга икәнен әйтә алмассызмы?

— Җлобинда калган разведчикларга пулеметны юк итәргә куштык. Уңайлы момент җиткәч.

Баталовның күзләре яктырып куйды, әмма берничә секундтан ул инде яңадан уйда иде:

— Ә алар безнең ут астына эләкмәсләрме соң? Ул «уңайлы моментта» без артиллерия хәзерлеге алып барырбыз бит?

Ткачев елмаеп куйды. Озынча чырае киңәеп киткәндәй булды, яңаклары йомрыланды.

— Юк, иптәш капитан, эләкмәсләр. Алар моны партизаннарча итеп, сез ут ачканчы ук эшләрләр. Сез елганы кичә башлагач, немецлар, билгеле, карап тормас, ата башлар. Менә шул чакта разведчиклар пулеметның эшен бетерер.

Баталовның да Ткачев кебек үк елмаясы килеп куйды. Нәкъ менә елмаясы килде. Әмма кырыс чынбарлык шәүләсе әйбәт теләктән өстенрәк иде: алда торган мәшәкатьләр йөзгә җәеләсе елмаюны сыпырып алды сыман...

— Яхшы, Антон Петрович, рәхмәт.

Алар аякка бастылар. Аерылышып киткәнче Баталов Ткачевның төсе уңган гимнастеркасы түшендәге «Батырлык өчен» медаленә кулын тидереп алды.

— Кайчан, кайда?
— Былтыр. Фин сугышында.
— Шулаймыни?!

Сүз башлауга ук икесенең дә бер үк частьта хезмәт иткәнлеге ачыкланды. Ул гына да түгел, Ткачев Баталовның батырлыклары турында да белә икән әле: политработниклардан ишетеп тә, «дивизионка»да да укыган.

— Димәк, агай-энеләр икән без.— Капитан бу юлы елмайды.— Туган-тумачалардан бәхет бар минем бүген. Көндез коданы күргән идем, хәзер менә сезне,— диде ул кәефе күтәрелеп.— Ярый, әлегә сау булыгыз, агай-эне.

Ткачев ашыкмады.

— Иптәш капитан, немецларның Җлобинга ничек кергәннәрен күреп торган идем мин. Хәзер бөтен теләгем — аларның моннан ничек сыпыртуларын күрү. Белоруссия җиреннән яңадан азат булуын күрү. Тиз генә күреп булыр микән шуны?

Баталов берни дип тә җавап кайтармады, үзе сорады:

— Ә ничек кергәннәр иде соң?

— Оһо — ничек кенә әле! Мотоциклистлары — урмәкүчләр диярсең. Кулларын җәеп салганнар, озын кара перчаткалары терсәккә житеп тора. Битләренең яртысы диярлек күзлек астында. Тимгел-тимгел плащлары арттан җилкән кебек кабарган. Коляскадагылары бертуктаусыз автоматтан сиптерәләр. Төзәп түгел, болай куркыту өчен генә. Аннары таш урамнан пехота төялгән бронетранспортерлары, автомашиналары дөбердәп үтте, танкалары күренде. Беренче Май урамыннан киләләр бит, хәшәрәтләр, элек бәйрәмнәрдә безнең демонстрация үтә торган урамнан...— Ткачев усал итеп башын чайкап куйды һәм үз соравына үзе үк җавап бирде:— Беләм, табаннарын тиз ялтыратырлар.

Кырт борылды да китеп барды.

Баталов өлкән адъютантка таба борылды.

— Һөҗүм итәбез, иптәш капитан. Командирларны чакыр, штабны җый.

* * *

Кырык яшенә җитеп, аның беренче тапкыр гына сугышта булуы түгел иде инде. Гражданнар сугышында Кызыл Армиягә үзе теләп язылган Баталов Самара һәм Сембер тирәсендә чех фетнәчеләренә каршы сугышты, Царицын янында, кылыч болгап, деникинчыларга каршы атакага чапты. Соңрак, кече командир булгач, Көнчыгыш Бохарада Кызыл Армия отряды белән басмачыларга каршы көрәште. Кырык-кырык беренче елларның төкерек җиргә төшмәслек салкын кышында капитан Баталов, үз батальоны белән кар ярып, ак финнарның һичкем ала алмаслык дип исәпләнгән ныгытмаларын атакалады. Әмма беркайчан да сугышка хәзерге кебек ашкынып торганы юк иде әле. Бу омтылыш аңарда күцел төбендә куптәннән йөрткән «һөҗүм итәбез» дигән сүзне Садовниковка әйтеп салуга уянды.

Командирлар белән сүз кыска тотылды. Баталов һәркайсына кичә алдан ук әйтеп куелган заданиене кабатлады, һөҗүмгә сигнал нинди буласын күрсәтте. Сәгатьләрен чагыштырып дөресләделәр.

— Менә шул, иптәшләр. Хәзер алга да алга гына. Шунысын истән чыгармагыз, һәр геройның, һәр сугышчының батырлыклары турында Мәскәүдә белеп торачаклар.— Баталов болай ук дип әйтергә җыенмаган иде җиенуын. Инде авызыннан чыккач, бу сүзләрне әйтмичә кала алмаганлыгын төшенде, чөнки тегенди-мондый кешедән түгел, Петровскийдан ишеткән иде бит ул моны.

*
* *

Көнчыгышта күк йөзенә алсулык сызылды. Анда яңа көн туып килә. Форсирование группалары артыннан ук елганы кичә башлаган Баталов батальоны инде бөтенләе белән диярлек Днепрның уң як ярында иде. Агач башларында җил шаулый, ярга җай гына дулкыннар кага. Аннары кисәк кенә төрле яктан автоматлар һәм пулеметлар тырылдый башлады, туплар һәм минометлар гөрселдәде, снарядлар һәм миналар шартлавы тынлыкны челпәрәмә китерде.

Немецлар, яңа һөҗүмгә көч җыйганда оборона сызыкларын ныгыткан булсалар да, алтмыш өченче укчы корпусның шулкадәр дәррәү, ярсулы буласын көтмәгән иде. Шуңадырмы, алар башта югалып калдылар, каршылык күрсәтүләре зәгыйфь, таркау иде.

Баталов сугышчылары ташкындай куәтле атака белән дошманны беренче траншеядан бәреп чыгардылар. Немецларга капты — алар җан кайгысы, коралларын, сугыш кирәк-яракларын, шинельләрен, плащ-палаткаларын һәм башка амуницияләрен дә ташлап качты. Әмма шулай да исләрен тиз җыйдылар, икенче траншеяда утырып калдылар. Аннары безнекеләрне шундый күз ачкысыз ут өермәсе белән каршыладылар, бишенче рота җиргә елышырга ук мәҗбүр булды.

Тузан һәм сөрем җир өстендә күе томан булып ята. Дымлы һава гөрселдәү, күкрәү авазларыннан дерелдәп тора. Берничә агач өйгә ут капты. Саргылт-кызыл ялкын ярты күккәчә күтәрелде, әйләнә-тирәдә чыдый алмаслык кызу булып китте.

Рота туктап калган җирдә миналар һәм снарядлар шактый вакыт ярылып торды. Анда тере җан иясе калдымы икән, дип тә уйларлык иде. Баталов биноклен күзеннән алмады. Таштай каткан йөзе, эчтән йөрәге чеметтереп алгандагы кебек, чытылып куйды. Чигәләре чәнчеде. Тешләрен шытырдатып кысты.

Ниһаять, артиллерия уты туктады. Немецлар бишенче ротага каршы контратакага күтәрелделәр. Автоматлардан өзмәстән ата-ата киләләр. Ротаның исә тыны да юк. Ник бер кеше атсын, яисә дошман каршына сикереп чыксын, я булмаса артка таба йөгерсен. Гүя әле генә шартлаулардан тетрәп торган җирдә бер җан иясе калмаган. Фашистлар, ә дигәнче килеп житеп, үтеп тә китәрләр, әле исән булганнарын да дагалы итекләр изәр.

Бәрелешнең беренче сәгатендә һөҗүмне җәелдерү өчен мөмкин булганның барысын да эшләргә кирәген Баталов аңлый иде. Һөҗүм туктап кала икән, гитлерчылар ары узар, ул чакта инде эшләр кая борыласын белер хәл юк...

Бишенче ротаның тавыш-тыны юк, Баталовның күңеленнән бер шом узды. Ни галәмәт?! Фашистларның флангларына пулеметлардан бәрергә кирәк! Әнә теге яшел йорт артыннан. Станоклы пулеметчылар взводын шунда!

Баталов, соң дәрәҗәдә киеренкелек туйган хәлдә, пулемет ротасы командирына приказ бирергә дип, телефонга борылмакчы гына иде, шул чакны бишенчегә җан керде. Өере-өере белән гранаталар очты. Баталовка аларның шартлавыннан җир селкенгән кебек тоелды. Урам читендә асты өскә килеп яткан немец арбасы артыннан Шәрәфетдинов сикереп чыкты. Әллә комбатка шулай тоелды гына, әллә колаклары чынлап та Шәрәфетдиновның кысылып чыккан кебек тыгыз, яңгыравык тавышын ишетте:

— Атакага!

Рота командирының җыйнак таза фигурасы немецлар ягына атылды.

Атыш көчәйде. Лейтенант нелә төште, тукталды. Тавышы да һавада эленеп калгандай тоелды. Лейтенант аны гүя яңадан күтәреп алды.

көч бирде. Аннары янә тураеп басты, алга таба ыргылды. Икеләнергә урын калдырмаслык көч белән дәртләнеп әй... ән шул сүз сугышчыларны тагын да күтәрде.

Кул сугышы аяусыз каты булды. Беркадәр вакыт кемне кем җиңгәнен әйтерлек түгел иде. Баталов та, канлы бәрелештә бер-берсенең сөякләрен чәрдәкләгән, мускулларын умырган кешеләр үзләре дә моның физик көч яки корал бәрелешеннән бигрәк нервлар алышы икәнлеген баштарак әле төшенеп җитмәгәннәр иде. Бусы соңыннан ачыкланды.

Көтмәгәндә-уйламаганда шушы мәхшәргә охшап калган кыр өстеннән тәннәрне чымырдатырлык бер кыргый аваз яңгырап узды, бергә кушылган гөрелте, шартлау, сүгенүләр аша ул җан ачысы булып ярып чыкты. Немецлар, исләрен югалтып, тынып калдылар. Әрнү дә, хайвани бер кот алыну да, көчсез усаллык та бергә кушылып ишетелгән бу аваз, ачыргалану, әҗәл газабы булып әверелгән бу тавыш гүя аларны өнсез итте. Кычкыручы — немец иде, акылдан шашкан ахрысы. Кызылармеецлар да аптырашкан кыяфәт белән туктап калдылар: каршылык күрсәтмәгән дошманны бетерергә куллары бармады. Ләкин нигә кул күтәрми, бирелми соң алар?

Гитлерчыларның бу сәер халәте минут эчендә үтте, һәм алар көтү кебек артка ташландылар.

Баталов түзмәде, кычкырып җибәрде:

— Молодец, Шәрәфетдинов! — Аннары ординарецына борылды: — Күрдеңме, Короневич? Аңладыңмы? Чыдый алмады, ерткычлар, куркудан котлары очты.— Аның киеренкелектән каткан йөзен шатлыклы елмаю йомшартты.

«Чыдый алмадылар» дигән гади генә сүзгә сыйган бу нәрсә Баталовны шушы беренче бәләкәй җиңүгә караганда да ныграк куандырды. Илбасарлар алар шул ук талаучылар, залимнар, бандитлар бит. Һәрбер җинаятьченеке кебек аларның да кара җаннарында үзләреннән көчлерәк курку ята: кылган эшләре өчен тиешле җәза киләчәген сизенә алар, әнә шуннан курка.

«Чыдый алмадылар!..» — комбат күңеленнән тагын шуны кабатлады. Хәзер бу сүзләрдә беренче тапкыр уена килгәндәгегә караганда олырак бер мәгънә ишетелә кебек иде.

— Иптәш комбат!— диделәр арттан. Ул борылып карамыйча гына кулын сузды. Элемтәче тир белән дымланган телефон трубкасын аның учына салды. Дүртенче рота командиры Вишняк шалтырата иде.

Танып та булмаслык карлыккан тавыш белән ул бишенче ротаның беренче траншеяга таба чигенә башлавын хәбәр итте. Бу хәбәрнең үзеннән, хәтта ротаның чигенүеннән дә бигрәк, капитанны иң тетрәткәне шушы уңай белән башында туган фикер иде: «Чыдый алмадылар...»

— Садовников, минем урынга каласың,— Баталов муеныннан бинокльне йолкып алды да, өлкән адъютантка таба ыргытты.

— Сез кая? Ярамый анда сезгә!..

Комбат ишетмәде, ул бөтен җаны белән шунда иде инде. Ишетсә дә, барыбер берни үзгәрмәячәк. Үзенекен эшләми кала торган кеше түгел ул.

Аннан да, моннан да пулеметлар ут сибә. Әчкелтем дару исе аңкыган, металл уйнаклаудан кайнарланган эссе һавада пулялар берөзлексез сызгырыша. Немецлар коймага ышыкланып йөгергән Баталов белән Короневичны искәреп алдылар, аларга төзәп ата башладылар. Çай гына снаряд чокырына качудан башка чара калмады.

Бераз тын алганнан соң комбат башын күтәреп, як-якка күз салды. Рота сибелеп яткан җир каршында почмакланып-почмакланып сузылган траншеялардан немец автоматчылары котырынып ут яудыралар

иде. «Боларны минометлар белән тыгылдырып булыр. Ә дзотларны нишләтергә? Ничек кенә бастырырга шуларны? Гранаталар беләнме?..» Баталовның башыннан яшен булып шундый уйлар узды. Шуның өстенә тагын бер нәрсә җанын борчый иде: «Вишняк кайда? Ник күренми ул?»

Әйләнә-тирәне игътибар белән күздән кичереп, рота командирын ул ярым җимерек сарай яныннан эзләп тапты. Өлкән лейтенант каралып беткән иске стенага арка терәп утыра. Кырыенда санинструктор тезләнгән, кулын бәйли.

Баталовның йөзе каралды, әмма берничә секундка гына. Үҗәтләнеп тәне тартылды, үзендә яңа көч тулышуын тойды. Комбат аякка тагын басты, бер мизгелгә тын калды.

— Внимание! — дип кычкырды ул гайрәтле тавыш белән. Күкрәгенә һава алып, тавышын тагын да күтәрә төште.— Тыңлагыз минем команданы. Автоматчыларга һәм пулеметчыларга төбәп — ут!

Чокыр читенә шартлый торган пулялар агымы сибелде. Комбат иелде. Безнең автоматчылар бердәм булып җавап бирде. Ротаның ачуsыз уты немецларның җен ачуын чыгарды. Шартлауларның кыргый биешүе әйләнә-тирәдә бөтен нәрсәне вата, көл итә кебек иде. «Шул кирәк сезгә»,— комбат яктырып китте. Ул Короневичның җиңеннән тартты.

— Хәзер — Садовников янына. Минометлардан дошман автоматчылары өстенә тондырсын утны.

Ординарец җәһәт кенә чокырдан чыкты да, миналар, снарядлардан иләк кебек тишкәләнгән бакча коймасы ягына юнәлде. Кулләвеккә туры килде, кояшның сөзәк нурларында ялтырап, аяк астыннан төрле якка тамчылар чәчрәде. Баталов Короневичны күзләре белән озатып калды — әһә, үтте! Бераз гына уңайлы момент җиткәнне көтеп торды да, аннары, җаен туры китереп, стенага таба, командир янына ташланды.

Вишняк хәле китеп утыра, йөзе көлсуланган, очлаеп калган. Гүя дөнья гаме беткән, уйлыйсы да, кыймылдыйсы да килмәгән кебек күренә. «Кан күп югалткан булса кирәк».— дип уйлады комбат һәм санинструкторга приказ бирде:

— Өлкән лейтенантны — санчасть ка!

Моны ишетеп Вишняк турайды, кашларын калкындырды:

— Ничек санчасть ка? Сугыш бара!— Карлыккан тавышында кирелек сизелде.— Ерунда гына бу, яралану түгел. Ышкылып кына китте.

Алар бер-берсенә караштылар. «Бармас». Комбат икеләнә иде.

— Ярый, алайса, утыр шушында.— Ул ротаның сул флангысына күз төшереп алды.— Теге ике өй арасындагы дзотның артына төшеп, гранаталар ташлап булыр бит, шулаймы?— Аннары ул алгы ягы тырналган дәү каскалы башын тагын Вишнякка таба борды: — Кемне җибәрик?

Рота командиры чак кына уйланып калды. Шунда кинәт Баталовның артында тоныграк тавыш ишетелде:

— Мин барам, иптәш капитан, рөхсәт итегез!

Баталов әйләнеп карады. Арырак чүгәләп утырган базык гәүдәле, кара тутлы, киң маңгайлы бу сугышчы аңа таныш кебек тоелса да, кем икәнен тиз генә абайлый алмады. Дөресрәге, танымады түгел, шушы сугышчы белән бәйле ниндидер мөһим нәрсәне хәтеренә төшерә алмады. Ә нәрсәдер булганлыгы тәгаен иде. Шул чак келт итеп исенә төште: рота командирының ординарецы Градулевич бит. Узган атнада аны партиягә кабул иткәннәр иде. Шул вакытта ук Баталовка бу сугышчыда тәвәккәллек чалымнары сизелгән иде.

— Нигә сез? Ә булдыра алырсызмы?— Үзе сорады комбат, җыелыштагы кебек үк кызылармеец ятлаган сүзләрне ярып салыр дип көтте: «Коммунистлар сугышта иң кыен һәм хәвефле заданиеләргә

баралар, чөнки алар — коммунистлар». Баталовның нигәдер шундый җавап ишетәсе дә килде. Хәзер, шушындый шартларда, башкача җавап та булмас кебек иде, батырлык күрсәтүгә кешене югары аңлылык, кайнар патриотизм һәм фидакарьлек илтә бит.

Сугышчы бераз гына эндәшми торды. Зәңгәр күзләрендә сагыш та, өмет тә чагылды.

— Тренировка вакытында гранатаны иң еракка атучы мин идем. Шулай булгач, булдыра алырмын.— Күзләренең зәңгәрлеге тагын да йөзенә сирпелеп чыкты.

Кызылармеецның бу гади, гадәти сүзләре шундый ихлас, табигый булып ишетелде, Баталовның хәтта күз карашы җылынып китте кебек.

— Рәхмәт, иптәш Градулевич, рәхмәт!

Бөтенесе дә приказдагыча килеп чыкты: шуышып бардылар, үзләренә караттылар. Градулевич, иелә төшеп, каралтыларга таба томырылды. Барып җитте, почмак артына сыенды. Баталов өмет белән аны күзәтә, ә йөрәгенә һаман нидер баса, гүя аны кемдер рәхимсез кулы белән кыса иде.

Немец автоматчылары урнашкан траншеяга миналар ява башлады. Балчык кантарлары белән бергә һаваганиндидер сынык-санаклар, әйбер кисәкләре очты. «Атаманчук снайпер икән, өсләренә генә сала!» — дип уйлап куйды капитан миномет батареясының командиры турында. Күңелендә шул аз сүзле, йомык өлкән лейтенантка карата җылылык уянуын тойды. Туры атканы өчен генә түгел, ниһаять, үзен мактарга җай тудырганы өчен дә булса кирәк. Өйрәнүләр вакытында Атаманчукны гел битәрләп кенә торырга туры килә иде бит: я бер нәрсәсе барып чыкмый, я икенчесе...

Сугышта шундый бер момент була: дошманның каушавы соң чиккә җитә һәм дәһшәтле паникага әверелә. Менә шунда инде син аңа тын алырга, исен җыярга ирек бирмә. Шушы моментны ычкындырмаска кирәк.

Батальон командиры үзен куркынычка куярга тиеш түгеллеген Баталов аңлый иде аңлавын. Ул — сугышны оештыручы, җитәкчелек итүче. Атакага ул инде бүтән чара калмаган очракта гына бара ала. Ә син, әнә, әйтеп кара, шул очракмы бу, түгелме. Нык утырсын өчен ул каскасын, учлары белән кысып, батырыбрак киде.

Атышу, өзелеп калган кебек, кырт тукталды. Искиткеч тын булып калды. Баталов теге якка, Градулевич посып торган өйгә күз салды. Аңардан җилләр искән иде инде. Капитан сугышчыны немец траншеясына табарак, бер юан агач артыннан эзләп тапты: «Безнең минометлар атканда житешкән икән, җен. Шүрләмәгән». Шул ук минутта Градулевич агач артыннан атылып чыкты һәм дзотка таба ыргылды. «Атыгарлар!— дип коты алынды Баталовның.— Нигә шуышып бармый инде?» Шул мизгелдә үк команда бирде:

— Атакага, минем арттан!

Тавышы да тынарга өлгермәгәндер, пулемет тырылдатып ата башлады. Аның өзек-өзек атуы комбатның аңындагы бөтен нәрсәне каплап китте, тик бер уй талпынды: алга, алга... Үлем кургашы яудырган соры амбразура авызына таба. Баталов, бүрәнә сыныклары, кирпеч ватыклары, мина чокырлары аша сикерә-сикерә, алга йөгерде. Шул йөгерүе белән Градулевичның граната ыргытуын да, аңнары абынган шикелле сөрлегеп калуын да күрмәде.

Шартлау дзотны тузанга күмде. Пулемет тынды. Әмма тузан басылу белән аңа яңадан җан керде. Ә рота пулемет алдында уч төбендәге кебек ята. Градулевич тезләренә күтәрелде, бил каешыннан икенче гранатасын суырып алды. Чайкалып китсә китте, барыбер ыргытты.

Шартлау белән кушылып ук диярлек кодрәтле «ура» тавышы яңгырады.

Кулы бәйләнгән озын гәүдәле берәү Баталовны узып бара. Атака белән мавыккан капитан Вишнякны бер күрүгә танымады да ул. Ә таныгач кычкырды:

— Син кая? Яралы бит...

Өлкән лейтенант туктамады, алдан чабуында булды. Баталовның башыннан «мине каплый» дигән уй чагылып үтте.

Гитлерчылар траншеяны каршылыксыз бирделәр. Рота аларны траншея сызыгыннан йөз метрлар читтәрәк торган бер катлы кирпеч бинага таба кысрыклады. Немецлар шунда туктарга ниятләделәр.

Баталов Вишнякны узып китте. «Ура-а-а!»

Теге өйнең урта тәрәзәсеннән бер автомат көпшәсе күренде. Баталов ялт читкә сикерде, агач артына ышыкланып, пистолеттан атып җибәрде. Тәрәзәгә гранаталар очты.

Пулялар һәм тимер ярчыклары тишкәләп бетергән ишек янында туктап, Баталов каскасын салды, кайнар маңгаендагы тирен учы белән сөртте. Короневичның тузан сарган, юл-юл кара тир агып төшкән йөзенә күз салды. Үз яңагыннан да шундый керле юллар сузылгандыр кебек тоелды. Ул да битен кулы белән сыпырды.

Итегенә нидер ышкылгандай булып, ул аягын кучереп басты. Әмма янә дә балтырына нәрсәдер сырпалануын тойды. Шыңшыган тавыш та ишетелде. Башын борып караса, менә сиңа могҗиза: итек кунычына зур колаклы бер ала көчек борынын төртә икән. Капитанның иң элек башына килгәне бу иясез мәхлукны тибеп җибәрү иде. Шул гына җитмәгән ди монда. Каян килеп эләккән диген син аны? Анасын эзлиме? Ә үзе үлемгә таба бара бит, юләркәй.

— Короневич, ал әле... Илтеп куй,— комбат башы белән ишеккә таба изәде.

Ординарец көчекне сыртыннан алды. Тегесе шунда ук тынычланды, шыңшуыннан да туктады. Кара күзләре генә дымланып зурайгандай булды. Короневич аны, икенче кулы белән астан учлап, түшенә кысты.

Сугыш гөрелтесе ерагая бара. Баталов янына штабтан элемтәче чабып килде. Кулын фуражка читенә тидерде:

— Иптәш капитан, өлкән адъютант...— Кинәт аның борыны җыерылып килде, йөзе чалшайды да каты итеп төчкереп куйды.

Короневич таза ак тешләрен ялтыратып елмая гына башлаган иде, комбатка күзе төшүгә елмаюдан тыелды.

— Исән бул! Әйдә, сөйлә тизрәк, өлкән адъютант, ничек анда?— дип сорады комбат.

— Алтынчы рота каршында танклар күренде. Әлегә разведчиклар бугай.

— Рота кайсы рубежга чыкты?

— Мунчаны алдылар да зур урамга килеп чыктылар.

— Капитан Садовниковның команда-күзәтү пункты кайда урнашкан?

— Урам башында. Зур тупыл янындагы бакчада.

Комбат Вишнякка борылды.

— Санчастька барасы килми дисең инде?

Тегесе юк дип баш чайкады.

— Үзеңә кара... Бүген тын алмаслык итеп куыгыз үзләрен...

Юлда Баталов элемтәчедән сораша барды.

— Артиллерия батареясы елганы кичтеме әле?

— Так точно. Ут позициясе урнаша, элемтәчеләр кабель сузалар.

Көчекне йортка илтеп куйгач, аларны Короневич куып җитте.

Команда-күзәтү пунктында Баталов биноклен алды, өйрәнелгән хәрәкәт белән күзләренә якын китерде. Дәшмичә генә танкларны күзәтте.

Алар ерак иде әле. Акрын киләләр, ә артта автоматчылар. «Пехотаны ничек кенә булса да аерып калдырырга кирәк. Танклар күп түгел, үзләре генә алга китәргә шүрләрләр...» Бинокльне төшерде дә өлкән адъютантка сүз кушты:

— Алтынчы ротага пулеметчылар взводын җибәр. Пехотага флангылардан бәрсеннәр.

Танклар бер-бер артлы туплардан атып җибәрделәр. Снарядлар югарыдан сызгырып үтте дә, батальонның ерак тылында, кайдадыр Днепр буенда шартладылар. Икенче, өченче тапкыр да шулай булды. Дүртенчесеннән соң шартлаулар якынрак ишетелде. Аннары бөтенләй якынга төште. Бер снаряд мунча почмагына туры килде, аны каерып ташлады. Аннары икесе рәттән диярлек урам ташларын кубарды. Су колонкасы һавага очты, телеграф баганалары авып төште...

— Алтынчы рота командирын бирегез!— диде Баталов, элемтәчегә борылып карамыйча гына. Һәм трубкага кычкырды:— Горнаго, нишләп синең бронебойщикларың тынып калды? Төзиләр дисеңме?.. Хәзер үк минем приказны җиткер: танкларга ут ачсыннар!

Баталов трубканы элемтәчегә кире бирергә өлгергәнче, танкка каршы мылтыктан бер-бер артлы ике тапкыр аткан тавыш ишетелде. Алдагы танк бөтерчек кебек бөтерелә башлады. Аннары янтаеп туктап калды. «Шәп төзәгәннәр, молодцы! Шул кирәк юньсезләргә!» Күңеле булудан хәтта тамагын да кырып куйды комбат.

Ротаның уң флангысыннан, аннары сулыннан да пулеметлар ата башлады. Дошман автоматчылары буталышты, төрле якка сибелде. Агачлар, су колонкалары, көл-күмер ителгән өйләрнең утырып калган мичләре артына йөгерделәр. Кайберләре, ни эшләгәннәрен белмичә, урам буйлап кирегә таба ташландылар.

Ватылып туктаган танк башнясын борды, туп көпшәсен аскарак төшерде һәм ут төкерде. Калганнары ата-ата автоматчыларсыз гына алга үрмәләделәр. Баталов аларның ниятен аңлады: үз автоматчыларын саклап калыр өчен пулеметларны бетермәкчеләр.

— Иптәш капитан!— телефонист комбатка трубка сузды.

Телефоннан лейтенант Фоменконың гаепле сыман тавышы ишетелде. Батарея командиры үзенең «кырык бишле»ләрен кайда урнаштыруын әйтте, нинди приказ буласын сорады.

— Танкларга ат! Әмма туктамаганнарына гына. Туктаганнарын пехотачылар башкарыр.

Броняга төренгән албастылар авыр чылбырлары белән урам ташын лөбердәтеп киләләр. Чыкырдау, чыңлау, пулеметларның кабатланып тыкылдавы һәм тупларның күк күкрәтеп атуы һаваны умырып-умырып ала кебек иде. Комбат бер нәрсәне белә, бер нәрсәне күңелендә тота: әгәр алгы сызыкта кем дә булса түзмичә кача башлый икән, ул чакта төзәтә алмастай хәл булуы бар — бүтәннәр дә паникага бирелер һәм курку баскан кешеләрне инде туктатырмын димә. Бронебойщиклар яңына чабарга, мылтыктан атарга да атарга — бөтен зиһенен биләгән шундый омтылыштан көчкә генә тыелып тора иде ул. Шулай да үз-үзен тыя алды, күңеленә беркетеп куйды: «Нервларны нык тотарга кирәк, тыныч булырга, югыйсә үзеңнең паникага төшүең бар».

Икенче «тәре йөртүче» алдагы ватылган танкны әйләнеп узды. Артында да, алдында да шартлаулар һавага күтәрелә иде. Илле метр чамасы баруга, аның тәбәнәк башнясы астыннан аксыл төтен сузылды. Төтен артыннан төссез-саргылт ялкын теле дә күренде. Башта ул кайнар рәшә чайкалган кебек кенә иде, аннары шартлады, бернича урыннан өскә таба якты ялкын бәреп чыкты. Минут та үтмәде, гаҗәеп бер көч башняны тубы-ние белән куптарып алды да аны койма аша ерактагы бер ишегалдына атты.

Өченче ерткыч, оста борылышлар ясап, алга чыкты һәм ярсып алга ташланды. Аның бронясындагы ак читле кара тәресе инде аермачык

күренә. Баталов күңеленнән, әгәр танк артиллеристларның прицелына эләкмәсә, менә-менә кирегә борылыр, дип өметләнә иде. Шашынган немецлар исләренә килерлер, күрәләтә үлемгә баруларын белеп котлары очар һәм үкчәләрен күтәрерләр.

Ерактагырак урамга ике яклап танклар керә башламаса, ихтимал, шулай да булыр иде. Коронevич санарга керешгте. Унга кадәр санады да ташлады. Ә алар, таракан кебек, һаман каяндыр чыгып кына торалар. Ул арада һавада самолетлар гөрелтесе ишетелде. Якынайганнан-якыная барып, башка авазларны басып китте. «Юнкерс»лар иде бу. Түбәннән генә очалар.

Комбат бөтен подразделениеләргә атуны туктатырга приказ бирде. Әйдә, бу сыңар танк Днепрга таба үтсә үтсен. Анда яндыргыч сыекчалы шешәләр белән тиз эшен бетерерләр. Тик менә бу урамга тулганнарын нишләтергә? Китереп кысачаклар бит...

Аның уйларын телефон бүлде. Полк штабыннан шалтыраталар икән.

— Ни хәлләр, Баталов?— дип сорады майор Вайнтрауб.

— Постым. Тынымны да чыгармыйм.

Берничә секунд тынып торганнан соң майор болай диде:

— Дөрес, пока дәшмә. Тик кара аны, озаккарак китмәсен. Танкларны ничек каршыламакчы буласың?

«Ничек каршыларга соң аларны? Ничек?» Баталовның аңын шул уй ярып үтте.

— Элек ничек каршылаган булсак, бу юлы да шулай. «Кырык бишле»ләрдән дә, бронебойный мылтыклардан да атып.

— Ә бит алар әнә никадәр!

Баталов җавап бирмәде — үзен дә, полк командованиесен дә канәгатьләндерә алырлык сүзе юк иде. Ул бит сүзен җилгә очыра торганнардан түгел. Баталов уйлый. Уйлардан башы ярылырдай дәрәҗәдә иде ул.

— Менә дәшмәгәнеңне мин дә ишетәм,— Вайнтраубның калын тавышы бөтенләй янәшә генә ишетелгәндәй булды, әйтерсең ул моннан бер километрда түгел, янында ук басып тора.

— Баталов, ник дәшмисең?— Трубкадагы тавыш борчулы яңгырады.— Ало, ало, Баталов? Нәрсә, телеңне йоттыңмы әллә?

— Икенче уңайлы урын бар. Шундыйрак бер тар җир...

Бомбалар улавы ишетелде. Әллә кайда өстә үк башланган бу улау, якыная бару белән көчәеп, дәһшәтле әче сызгыруга әйләнә иде. Комбат трубкадан «шулай ит» дигәнне генә аңлап калды, шунда җир селкенә, ыңгыраша башлады.

Бомбалар ява, баш өстендә сызгырып тимер ярчыклары оча. Баталовның аркасына бер авыр нәрсә китереп бәрде дә, калак сөяген авырттырды. Ул җилкәсен селкетеп куйды. Ә колаклары чамасыз гөжли иде.

Самолетларның гүләгәне әле ишетелсә дә, бомбалар инде шартламый. Баталов тәрәзәдән башын сузып карады.

Батарея командиры белән сөйләшү Баталовның ышанычын ныгытты. Фашистлар белән алышып карыйк. Теге «тар урыннан» үткәннәрен «кул снарядлары» белән бетерербез. Яндыргыч сыекчалы шешәләр житәрлек әле, анысы әйбәт.

Танклар тупыллар яныннан үтә башлады. Берәү, икәү, өчәү... Тик нәрсә бу? Инде бишенчесе дә ул турыдан үтеп китте, ә батарея һаман ләм-мим. Баталовның каны кызды: «Нәрсә, әллә көпшәләре тутыкканмы анда? Нәрсә карый бу Фоменко?»... Эчендә лейтенантка карата ачу кайнады.

Тупыллар арасында алтынчы танк күренде. Һәм шул чагында урамның иңеннән иңенә кара фонтаннар булып балчык атылды. Бөтен дөньясын төтен басты, агачларның очы гына күренеп калды.

Төтен эченнән гөлт итеп якты күренде. Аннары Баталов ялкынын да күрде — танк яна иде. Артыннан килгән башкалары туктап калды. Әйләнеп үтәрлек түгел. Тупыллар да колач житмәслек, аударам димә. Йортлар да ишәрлек түгел, кирпечтән, тазалар. Агачлар белән өйләр арасына сыеп булмый. Янган танкка да якынлашырга ярамый — шартлавы бар... Бераз аптырашып торгач, танклар борылыша башладылар. Тар урамда борылгалаган арада алар артиллеристлар өчен бер дигән мишень булды. Тагын икесе зәңгәр ялкынга төренде.

«Тар урын»ны үтеп киткән теге бишесе башта ташбака кебек кенә үрмәләгән иде, аннары кызулый башладылар. Аларга каршы снарядлар очмый һәм фашистлар, шуннан файдаланып, алгы сызыкка мөмкин кадәр якынрак үтү кирәклеген аңладылар. Ул чакта инде безнең артиллериядән куркасы юк, снарядларның үзебезнекеләр өстенә төшүе бар.

Танклар Горнаго ротасы урнашкан җирдән өч йөз метрда гына иде инде. Бер-ике минуттан килеп җитәрләр дә, ашык-пошык казылган тар һәм сай окопларны тигезли башларлар.

Тавышын тигез, тыныч тотарга тырышып, Баталов алтынчының командирына болай диде:

— Нык торыгыз, Горнаго. Гранаталар, шешәләр белән! Сынатмаска!

Танкка каршы ата торган мылтыкларның өзеп-өзеп тавыш биргәне ишетелде. Арттан уң яклап туплар гөрселдәде.

Ә танклар килә дә килә. Сугышның киеренкелеге соңгы чиккә җитте — барлык рухи һәм физик көчләреңне бер төенгә туплау таләп итлә иде.

Кинәт окоптан бер кызылармеец сикереп чыкты да, Днепр ягына таба чабып китте. Шул ук окоптан икенчесе күренде, кул пулеметын күтәреп тегенә таба бер чират бирде. Качып баручы туктады. Аннары җиргә ауды, бераз шуышып барды да җан-фәрманга кире йөгерде.

Баталов боларны куркыныч төштәге кебек итеп күрде. Качкын үз окобына сикереп төшкәч, бу күренешләрнең берсе дә аңында калмады. Уен тагын танклар биләде. Бар фикере, бөтен акыл көче бер нәрсәгә тупланды: танкларны туктатырга, юк итәргә!

Алдагысы үз койрыгын тешләргә маташкан эт кебек бер урында әйләнә башлады. Өзек чылбыры җиргә сузылып төште. Арттан килгәне, аның кырыеннан узып, агач тротуарга менде. Меңләгән аяклар астында шомарып беткән такталар өстеннән туп-туры команда-күзәтү пунктына килә.

Капитан Корневич кулыннан тартып диярлек яндыргыч сыекчалы шешә алды. Юк, иртәрәк әле, җиткереп булмастыр... Секундлар ялыктыргыч озак үтә. Ә хәзер?.. Чүгә төште, аннары атылган пружина кебек сикереп торды да шешәне бөтен көченә атып җибәрде. Тимәде? Эх, тагын берәү булса икән!.. Ә-ә, менә икән... Юк, хәзер соңрактыр... Ул окоп стенасына сыенды. Алагаем зур танк сасы төтен бөркеп, май чәчрәтеп, окоп өстеннән дөбердәп узды. Баталовка ул танк түгел, озын товар поезды булып тоелды.

Икенче шешәне комбат арттан тондырды. Аның ут балкышы күзне сукырайтырлык булып күренде.

Бик түбәннән генә снарядлар сызгырып узды. Бу Баталовны айнытып җибәргәндәй булды. Ул калган танкларга таба борылды.

Тагын икесе яна иде. Алары Горнаго сугышчылары утыннан. Берсеннән немецлар сикерешеп төште. Ачык капкадан ишегалдына ташландылар. Баталов «штаб автоматын» яңагына терәп курокка басты. Соңгы танкист чыгып җитешә алмады. Люктан сузылуга, танк эчендә

снарядлар шартлады. Шартлау аны югарыга чөйде һәм ауган телеграф баганасы өстенә аркылы ташлады.

Горнаго ротасын күтәрде. Сугышчылар винтовкалардан һәм кул пулеметларыннан ата-ата алга омтылдылар. Бер мизгел эчендә урамны тутырып, алар алга, теге «тар урынга» таба йөгерделәр. Баталов ату тавышлары, сугыш шау-шуы аша аларның кайнар сулышын, таза солдат итекләренең каты тупылдавын ишетә кебек иде.

**И. БӘДРЕТДИНОВ** тәрҗемәсе.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Корея халык мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Әгәр бергәләп күтәрсәң авыр йөк җиңеләя.*
*Зур кавынны ялгыз ашамыйлар.*
*Елга янында булса да су белән сыйлау яхшы.*
*Ихтыяры юк кеше — басуда йөргән сукыр.*
*Тәмле ашны ашар өчен тел ярдәме кирәкми.*
*Юлбарыс үлсә — тиресе, кеше үлсә эше кала.*
*Өчләтә түземле булу үлемнән дә коткара ала.*
*Кеше өчен эссе дә, суык та газап.*
*Юлбарыстан качар өчен тау арасына кермә.*
*Акыл көчтән кирәгрәк.*
*Үзе яхшы язган кеше каләмен гаепләмәс.*
*Кеп-кечкенә карлыгач та меңәр чакрымга оча.*
*Үзе мәчегә охшаган, ә тычкан тота белми.*
*Бөгелмәгән агач тиз сына.*
*Чиксез матур чәчәкнең дә начар исе булса.*
*Бер башлык эшләгән хата бөтен әртилгә зыян.*
*Этен үтергән кешегә бөтен авыл үпкәли.*
*Үзең барган һәр төбәкнең йолаларын үти бел.*
*Бер балакка ике аяк сыймый.*
*Сөзгәк сыер мөгрәми.*

# МАЙ ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

*Унберенче бишьеллыкта елга... йомыркаңы 72 миллиард һәм 78—79 миллиард данәгә җиткерү бурычы куела.*

«1990 елга кадәрге чорга СССРның азык-төлек программа»сыннан.

## Мәрди Рафиков

# ЧАПТАР ТУКТАМЫЙ

ОЧЕРК



Авылны чыкканда инеш күпереннән узасың. Аннан үр башлана. Сәзәк чокыр буйлап бормалы юлдан менәсе. Бераз киткәч, машина тагын уйсулыкка төшә башлый. Аста, чыклы чирәмгә коелган талир таңкаләрне хәтерләтеп, күлләр ялтырый. Үзән уртасында ак тасмадай Зөя сузылган. Тасманың бер очы гүя тау астыннан килеп чыга, икенче башы гаҗәеп матур урманга тоташа. Елга шул яшеллек дәрьясында югала сыман.

Әнвәр, көн саен инеш буендагы тын авылдан чыгып, әлеге үргә күтәрелә, һәркөнне шушы матурлык белән очраша. Иртәнге сәгатьләр. Урман артындагы таулар өстендә таң сызыла. Анда ниндидер сихри зат әйтерсең лә биниһая зур учак яккан да, аның ялкыны очынып-очынып төн пәрдәсен куа, аннары тау астыннан үрләгән кояш нурлары белән кушылып югарыга сузыла, бөтен дөньяны яктырта.

Таңны каршылаучы кеше бәхетле була. Безнең ата-бабайлардан калган сүз бу. Көн саен, айлар, еллар буе һәр иртәдә кояшны аяк өсте көтеп алу кыендыр, әлбәттә. Кешегә ял да кирәк ич. Күз кабакларың күтәрелмәгәндә, җиһан гүзәллеге дә күренмәс булыр. Әмма хезмәтнең үз кагыйдәсе бар, ул төгәллек ярата. Әнвәр күңеле белән шуны сизә һәм ару-талуларын онытып, һәр иртәдә юлга җыена.

Ул тагын, күпер чыгып, тауга күтәрелде. Барыр юлы ерак та түгел. Фабриканың торбалары Каш урманы өстеннән күренеп үк тора. Алар Зөя аръягы калкулыкларында утыралар. Япан кырда шул корылмаларны торгызганда Әнвәргә байтак борчылырга туры килде.

Аңа кадәр Апас инкубаторында эшли иде ул. Колхозлар өчен һәм халыкка чебиләр чыгаралар. Эш җайлы. Инкубатордан бары да канәгать. Шулчакны Әнвәрне партия райкомына чакырдылар. Әнвәр ниндидер җитди сөйләшү сизендә, үзен алдан ук шуңа әзерләде. Инкубаторга кагылышлы җитди әңгәмә, хәтта кырыс сүзләр дә көтте.

Әмма секретарьның кәефе бөтенләй башкача иде, бик мөлаем каршылады, түрдән урын күрсәтте, үзе дә Әнвәр янына ук утырды.

— Эшегез белән таныш. Коллективны туплый беләсез,— дип башлады ул.— Оештыру сәләтегез бар.

Әнвәр сагаеп калды. Ул әле бернәрсә дә аңламый, ни җавап бирергә, нәрсә турында сорарга да белми иде. Ә секретарь дәвам иттерде:

— Безгә нәкъ шундый кеше кирәк. Бу эшегезне калдырып торырга туры килер. Ясалма орлыкландыру станциясе корырга керешәбез. Сез — директор!

Әнвәр бу кадәресен үк көтмәгән иде. Аның әле инкубатор-кошчылык станциясендә дә зур эшләре бар, станцияне киңәйтергә хыялланалар иде. Секретарь да аның икеләнүен сизде.

— Риза түгелме әллә? Безнең бөтән ышаныч сездә иде бит...

Кеше ачыктан-ачык сөйләшә икән, димәк, синнән дә шуны көтә: җавабыңны кистереп әйт!

Әнвәрнең ветеринария буенча белемә бар. Шуны исәпкә алганнардыр. Хуҗалык эшендәге уңышларын күзәтеп торганнардыр. Әлегә тикле бер урында да сертенгәне булмады ич аның.

Секретарь һаман үз фикерен куәтли бара.

— Сүз хуҗалыкта өр-яңа тармак оештыру турында бара,— диде ул «яңа» сүзенә басым ясап.— Районда бары тик яхшы нәселле терлекләр генә булдырырга уйлыйбыз. — Ул Әнвәргә тагын сынап карады.— Хәзерге эшегезне бик яратуыгызны да беләбез. Аңа әйләнеп тә кайтырга була. Башта яңа станцияне генә корып бирегез. Каралтыларын күтәреп, коллективын туплап... Әзер хуҗалыкка җитәкче табылыр.

Кыр уртасында станция эшчеләре өчен йортлар, нәсел үгезләренә абзарлар, лаборатория һәм машина гаражлары күтәрелә башлады. Төзелеш һәм станция өчен кадрлар туплауда, колхозлар белән элемтә урнаштыруда күпме хафалануын Әнвәр үзе генә белә. Тора-бара исә ул станциядәге хезмәтне ярата да башлады. Төзелеш мәшәкатьләреннән арынгач, ул бөтен сәләтен төп максатка — колхозларда нәселле терлекләр үрчетүне юлга салуга, һәр сыерны бозаулатуны тәэмин итүгә бирде.

Кеше күңеле шундый инде: эше уң булса, җаны рәхәтләнә. Бу хис аны уйландыра, хыялга баета, яңалыкка омтылдыра. Җитәкчедәге күтәренке кәеф коллективка да күчә, аны да яңа уңышка илтә. Ирешелгәннәрне ныгыта алмаучы, гел бүгенге көн белән генә яшәүче кешеләр иртәме-соңмы үзен дә, коллективын да кыен хәлдә калдыра. Хуҗалык җитәкчеләре белән уздырылган бер киңәшмәдә Әнвәр моңа тагын бер кат инанды. Сүз терлекчелек продуктлары җитештерү турында бара иде. Колхозларда тавык фермаларының бетерелгән чагы. Йомырка әзерләү бөтенләе белән кошчылык фабрикасына тапшырылган. Дәүләт планының үтәлеше дә шул коллективка йөкләнгән. Ләкин план өзелә дә өзелә. Күрсәткечләр көннән-көн кими бара.

Берәүләр колхоз фермаларын бетерүне хата санады: алар, аз булса да, йомырка бирәләр иде бит әле, янәсе. Икенчеләре хәзерләүчеләрне гаепләде: ялкауландылар, янәсе, шәхси хуҗалыклардан йомырка җыюны кирәгенчә оештырмыйлар...

Әнвәр өчен бу сөйләүчеләр гаҗәп түгел. Кемнедер гаепләвә җиңел. Кошчылыктагы тагы мең төрле чишелмәгән кыенлыкны аңласалар икән!.. Башкаларны гаепләргә генә күнеккән кешеләр, тәртәнең бер ягына үзләре җигелеп карасалар, бәлки, файдалы бер киңәш тә бирерләр иде. Фабрика директорын тиргиләр дә тиргиләр, тегесе акланмый да: «Булдыра алмыйм, сәламәтлегем начар»,— дип тик тора. Аңа ни әйтәсең, намуслы кеше үзе дә борчыла, ләкин хәлне үзгәртә алмый. Чамасы юк. Ачыктан-ачык әйтеп тора: миңа ышанмагыз, башка директор табыгыз, ди.

Әнвәр аның хәлен яхшы аңлый иде аңлавын. Шулай да кабат райкомга чакырылгач, сүз нәкъ шул фабрика хакында барыр дигән уй аның башына да килмәде. Бу юлы аңа өздереп әйттеләр: «Иптәш Ибраһимов, сезне Апас кошчылык фабрикасына директорлыкка тәкъдим итәбез. Кирәкле ярдәмне сорарсыз, хәлне бергәләп төзәтербез...»

Машина уйсу җиргә төште. Фабрика торбалары күздән югалдылар. Ачык тәрәзәдән кабинага үзән җиле тулды. Зөягә якынлашканда, йөзгә гел саф җил килеп бәрелә. Тирә-як тын торганда, җил талгын була, тынычсыз көннәрдә, монда кистереп үк ала. Ничек кенә иссә дә, Әнвәр аны сихәт итеп тоя. Фабрикага якынлашканда, җилгә ияреп, кыздырылган үлән исе дә таралган була. Димәк, витаминлы он агрегаты эшли. Бу хуш ис, кетәклекләрне җилләткәндә, тавыкларны җилкендерә сыман, аларга да саф һава кирәк бит. Ансыз бер җан иясе дә яши алмый.

Әнвәр бу хакта кошчылык фабрикасын кабул иткәннең икенче иртәсендә үк уйлана башлады. Килгән көнне фабрика белән танышкан иде. Белгечләр белән төп кетәклеккә керделәр. Ындыр табагыдай зур бина, ә һавасы тынчу. Тавыклар җир идәндә тибенгәләп йөриләр, шунда ук йомырка да салалар. Күңелсезләр, пычраклар. Күрше кетәклекне ачтылар. Анда да шул ук хәл. Йомырканы күбрәк алу турында түгел,

бу тавыкларның җаннарын ничек саклау хакында уйларга кирәк. Ишегалдында әр-яңа җиһазлар әөләп ята, күгәрә-тутыга башлаганнар инде.

Танышканда яңа директор бу хакта бернинди сүз дә кузгатмады. Белә ул: эшең-не кемнедер гаепләүдән башлау кешеләрне бездәрә генә иде. Әле аннан башка да Әнвәр жанына урын таба алмый йөрде. Җыелышта аны коллективка яңа директор дип тәкъдим иттеләр. Эшчеләрнең йөзендә һичнинди кызыксыну сизелмәде. Алар каршысында дулкын-дулкын коңгырт чәчле, ак йөзле, чандыр гына япь-яшь кеше утыра. Яңа директор, эшчеләр исә аңа монда андыйлар күп булды, әйдә, бераз эш-ләп йөрсен, бик озакка түзмәс әле, дип кенә карыйлар.

Әнвәрне, эшнең таркаулыгыннан бигрәк, кешеләрдәге битарафлык борчый иде. Ул, беренче эше итеп, белгечләрне җыеп киңәште. Әңгәмәсен тынчу кетәклекләрдән һәм файдаланылмый яткан җиһазлардан башлады. Кетәклекләргә кичекмәстән җылы читлекләр куярга булдылар. Үзгәртеп кору — файдалану мәйданын арттырырга һәм йомырка алуны арттырырга ярдәм итәчәк иде. Әнвәргә ветеринар белеме дә, инкуба-тор-кошчылык станциясендә алган тәҗрибәсе дә үз фикерен дәлилләргә, раслап күрсәтергә ярдәм итте. Киңәшмәдәгеләр аңа, беренче кат күргәндәй, игътибар бе-лән карадылар. Бригадир-агроном Фәһим Сөнгатуллин директор фикерен яклап чык-ты. Аны Әлфия Мифтахова куәтләде. Кошчылык бригадиры коммунист Энҗе Шәй-хетдинова үз фикерләрен әйтте. Экономист Сафа Насыйбуллин да аларга кушылды, чөнки сүз фабриканы табышлы итү турында бара иде.

Директор беренче киңәшмәдә үк кыен юлга кемнәр белән чыгасын, кемнәргә таянасын белде. Өметләр сүнмәгән икән әле, тиешле чарасын күрсәң, кешеләрнең йөрәге кабынып, очкынланып китәчәк, аннары теләсә нинди хыялны тормышка ашы-рып була.

Актив эшчеләр директор фикерен яклап чыккач, кетәкләргә батареялы читлекләр куя башладылар. Әмма тынычланырга иртәрәк иде әле. Әнвәр борчылырлык хәл-ләргә очрап кына торды. Берсендә аны җилкәсенә капчык салган кеше туктатты. Агай кызып-кызып сөйли. «Кетәклекләрне тавыклар белән тутырасыз икән. Хуш, бик әйбәт, йомырка күбәер, планны да үтәрсез. Ә безнең турыда, эшчеләр хакында әзрәк уйлыйсызмы соң, әллә башыгызда тавык кайгысы гынамы? Азыкны кайчанга кадәр сыртыбызга салып ташырбыз? Ишәкме әллә без?»

Агай күңелендәгесен сипте-сипте дә, җилкәсендәге капчыгын сикертеп куеп, тагы да сыгылып төшеп, китеп барды. Әнвәр кадаклангандай басып калды. Агаең яңа директорга әнә никадәр мәсьәлә бирде, чишеп кенә бетер. Ул дөресен әйтә, уйлана белә, фикере бар. Шундый таләпчән эшчеләр белән яшәсәң, шактый нәрсәләрнә хәл итәргә өлгерер идең.

Дөресен әйткәндә, кошчыларның хезмәте турында капчык күтәргән кеше дәрә-җәсендә үк уйламаган иде Әнвәр. Эшчеләр белән дә сөйләшмәде түгел. Фабрикада бик озак эшләүче ирле-хатынлы Сания һәм Гыйльмулла Галиуллиннар белән дә ки-ңәште. Тыйнакланулары булдымы, зарланмадылар. Миңнуллиннардан да аһ-зар ишет-телмәде. Барысы да, теге агай кебек үк, көн саен амбардан, азык кухнясыннан та-выкларга ун-унбиш тонна азык ташыйлар. Гел капчыклар белән, гел күтәреп. Кухня-ны кара тагын: һәр чак юеш — тоташ күзгә көн кебек. Машиналар гаражы да кысан, салкын. Анда да кешеләр эшли, план үтәлешен, фабриканың рентабельлеген тәэмин итүчеләр. Дөрес битәрли «тelle агай», тавык турында гына уйлап, кешеләрне оны-тырга ярамый, оттырасың.

Әнвәр, Казанга шалтыратып, трест белгечләре белән киңәште. Аның ачык бер фикере бар иде инде. Амбарларда транспортерлар көйләнә. Ашлык амбардан-ам-барга да, вагоннарга да «агып» кына тора. Фабрикада да шул ысулны кулланырга мөмкин ич! Табасы иде җиһазларын, сузасы иде җир астыннан тасма юлны, ишег-алды буйлап капчык күтәреп йөрүләр бетәр иде. Директор трест белгечләре белән шул хакта киңәште. Фикерен якладылар. Аннары ашлык хәзерләүчеләр белән элем-тәгә керде. Җиһазлар табуда ярдәм иттеләр. Партия райкомы белән киңәшкәч, тө-зүчеләр дә табылды. Фабриканың иң җәфалы хезмәте шулай җайга салынды, азык турыдан-туры һәр кетәклеккә җир асты транспортеры белән китерелә башлады.

Яңалыкка беркайчан да битараф булмыйлар: кемдер хуплый, кемдер хурлый. Әмма фабрикада хезмәтне механизмнарга йөкләү барысына да ошады. Бигрәк тә эшчеләр шатланды. Бу җиңү яңадан-яңа хыяллар уятты, эшне җиңеләйтү турында

гади кошчылар үзләре дә кайгырта башладылар. Бер җыелышта ишегалдындагы «чүп оясы» турында борчулы сүз кузгалды. Аңа директорның үзенең дә эче пошып йөри иде. Фабрика проектында тамыразыклар саклагыч та каралган булган. Проект буенча зур чокыр казыганнар, стеналар да беркетелгән, төбәсенә кадәр менеп җитә алмаганнар. Ишегалдында калган чокырга чүп-чар ташлый башлаганнар.

Директор шул «чүп оясы» турында белгечләр белән махсус киңәште, уенын дәреслеген беләсе килде. Үзе ул саклагычны чистартып, түбәләрен ябып, тагын бер кетәклек итеп үзгәртергә теләгән иде. Бу фикергә каршы килүчеләр дә булды. Аларның дәлилләре дә җитәрлек: тавык яктылык һәм саф һава ярата, аны тынчу урынга, чокырга урнаштыру гамәлгә сыймый. Бу яктан алар хаклы иде. Ләкин өстәмә яктылык бирергә, һава алмаштыру өчен җилләткечләр куярга була ич. Иң әһәмиятлесе — кош асрарга мәйдан киңәя, тавыкларның баш санын арттыру мөмкинлеге туа. Төп кетәкләргә берничә катлы читлекләр куйгач, тавыклар саны да, йомырка алу да артыр иде. Ә бусы — тагын бер, кетелмәгән өстәмә.

Киңәшеп, «чокырны» үзгәртеп корырга булдылар. Төзелешкә фабрика эшчеләре чыкты. Стенаны биегәйттеләр, түбә яптылар. Элекке чүп чокырына батареялы читлекләр, җилләткечләр куйдылар. Яңа урынга егерме меңләп тавык сыйды.

Хезмәтенә тугрылыклы кеше ирешелгәннәр белән беркайчан да тынычлана алмый. Эшнең киләчәге турында уйламый башлау, ни булган белән ризалашып яшәү кеше тормышын мәгънәсез итә. Алда тагын да матурракны күрергә тырышу исә үзеннән-үзе яңа мәсьәләләр тудырып кына тора. Бервакыт Әнвәр инкубацион йомырка турында уйлап гаҗизләнде. Фабрика үзендә ун миллионлаган йомырка җитештерә. Әмма барысы да табын өчен генә ярый торган диетик йомыркалар. Алардан, кем әйтмешли, өшкерсәң дә чеби чыгара алмыйсың. Ә чебилек йомырканы Бөгелмә, Буа якларыннан ташыйлар. Анысын күп мәшәкатьләр белән юллап табасы, юл азапларын җиңеп кайтарасы бар. Юлда йомырканың бер өлеше чатный, хуҗалыкка зыян килә.

Фабрика зурайгач, инкубацион йомырка мәсьәләсе җитдиләнгәннән җитдиләнә барды. Икенчедән, кетелмәгән яңа хәл килеп чыкты. Таң атканчы ук, фабрика капкасы янына кәрзинле хатыннар килеп утыра. Директорны көтәләр. Үтенечләре гел бер үк төрле: «Зинһар, бер-ике дистә чеби бир». Колхозларның тавык фермалары бетерелде, аларның үзләрен йомырка белән тәэмин итәргә кирәк иде. Инде китереп авыл тормышы, крестьян холкы белән санашып тормыйча, инкубацион-кошчылык станцияләрен дә ябарга фәрман булган. Иң җиңел нәрсә — вату, ябу, туздыру. Станцияләрне туктаттылар — шәхси хуҗалыклар чебешсез калды, апалар, зинһарлап, фабрика капкасына киләләр. Хәлләрен аңлап була, ләкин булышуы кыен. Фабриканың чеби чыгару цехын да киңәйттеләр, әмма инкубацион йомырка табуы авыр.

Нишләргә? Әнвәр инкубацион йомырканы да фабрикада ук җитештерү турында уйлана башлады. Шул фикерен бер киңәшмәдә белгечләргә дә әйтте. Бәхәс чыгасын да сизә иде ул.

— Беренче чиратта ике мең баш тавык тотарбыз.

— Әтәчле ферма оештырабыз алайса,— диде кемдер, үзалдына сөйләнгәндәй.

— Ферма ук булмасын, цех дип атыйк.

— Трест нәрсә әйтер бит әле?

Чынында Әнвәр үзе дә шуннан шикләнә иде. Ул юлда килгәндә үк яңа эш кузгатуының кирәклелеген дәлилләү турында кат-кат уйлаган иде. Әмма үзе махсус цех ачарга рөхсәт бирмәячәкләрен, «Кайдан аласыз — шуннан кайтара бирегез, мөгез чыгармагыз! — дип әйтәчәкләрен сизенә иде. Өстәмә акча сорау турында башыңа да китермә — бирмиләр. Чөнки һәр нәрсәнең чамасы бар. Әнвәрнең бөтен өмете фабриканың үзендә өстәмә мәйдан табып, янга калдырылган акчадан файдалану иде. Аннары күз күрер әле!

Бу эштә авырлыкның иң зур өлеше үз җилкәсенә төшәчәген директор чамалый иде. Гауга чыкса да, җавабын ул үзе бирергә тиеш булачак.

Озак та үтмәде, трестта кискен сөйләшү башланды, җавап таләп иттеләр. Бу вакытта «яшерен цехта» әтәчләр кычкыра, тавыклар дәртләнеп-дәртләнеп кыткылдый иде инде. Аннан алынган беренче йомыркалар инкубаторга да салынды. Кошчылар «әтәчле ферманың» отышлы булуын үз күзләре белән күрделәр. Директор җавап тотканда, алар аның янына басарга әзер торалар иде.

Аннары ерактагы фабрикаларга инкубацион йомырка элэп бармас булдылар. Үзлэренэ житэ, хэтта артып кала. Фабрика чеби чыгару буенча колхозлар соравын да үтэргэ алынды, шэхси хужалыклар ихтыяжы да канэгатьлэндерелде. Арткан йомырканы күрше фабрикаларга сатарга тотындылар. Өстэмэ табыш килэ башлады.

Трестта да яхшыны яхшы, дими булдыра алмадылар.

Тик андый башлангычлар, тэвэккэллеклэр эзсез калмады. Һэркайсы Энвэр маңгаена бер сыр булып төште, дулкынлы чэчендэ, сентябрьдэ үк ярган кырпак кебек, аклык кунды.

Жиңүдэн соң яралар батырлык билгесе булып кына кала. Коммунист Энвэр Ибраһимов та тынгысыз батыр хезмэттэ үткэн көннэрен бэхеттэн саный. Эшчелэр аның ачык күңелен тиз аңладылар һэм гел киңэш тотучан булдылар. Уртак көч уртак максатка юнэлтелде. Фабрика бишьеллык дэвамында йомырка житештерүне ике тапкырга арттырды. Фабрикада телэсэ нинди бурычка алынырлык булдырлык бердэм коллектив тупланды. Апас кошчылары Бөтенроссия социалистик ярышында да жиңеп чыктылар. Россия Федерациясенең күчмэ Кызыл байрагын яуладылар.

...Чаптар ат туктау белмэгэн кебек үк, уңган житэкче дэ уйсыз яши алмый. Энвэр Ибраһимов һэр көн авыл чыгып, таңга карап үр менгэндэ, аның күңелендэ уйларның иң яктылары кила, килэчэккэ тагын да киң колачлырак планнар туа.

## Укучының күңел дэфтэренэ

**Корея халык мэкальлэре һэм әйтемнәре**

*Эре балык вакны ашый.*
*Су өстэн кайный башлый.*
*Кап-караңгы төндэ дэ су яктырып күренэ.*
*Бэп-бэлэкэй тэлинкэдэн зур кашык белэн ашый.*
*Бик матур күренгэн жимеш еш кына тэмсез була.*
*Энэ жепсез тегэ алмый.*
*Энэ урлаган кеше, сыер да урлый ала.*
*Тамырсыз агач яфраксыз булмас.*
*Иң зур агач та нэни орлыктан үсэ.*
*Тулы итеп тутырып салсаң шешэдэ су чайпалмый.*
*Туры таяк тизрэк сына.*
*Күзе кырмагэн кеше үз этэчен дэ урлый.*

Рәис Сабиров

# БӨЕК ЮЛНЫҢ БАШЛАНГЫЧЫ

Декабрьның җан өшеткеч салкын бер төнендә Яңа Комиссариат урамындагы (хәзерге Комлев урамы, 15) нык итеп эшләнгән, тыштан такта белән тышланган агач өйдә яшәүчеләр кинәт тәкәллефсез генә ишек шакыган тавышка уянды. Куркуга төшкән хуҗабикә ишекне ачарга да өлгермәде, аны бер читкә тибәреп, өй эченә, үзләре белән өшеткеч салкын иятреп, жандармнар килеп керде. Чалара башлаган чәчле, яше илледән ашкан сөйкемле хуҗабикә, өйгә бәла килүне сизенүдән йөрәге сыкрап, идән уртасында тораташ булып калды. Күнегелмәгән шау-шудан, тупас кычкырынулардан уянган балалар — унөч яшьлек үсмер малай һәм тугыз яшьлек кыз — әниләренә барып сарылдылар. Алардан бераз гына читтәрәк, як-ягына карангалап басып торучы уналты яшьлек кыз сораулы караш белән жандармнарга текәлде. Өй эчендәгеләрдән берәү генә, бердәнбер ир кеше, инде тужуркасын кияргә дә өлгергән студент тыныч һәм җитди күренә иде. Аның төнге кунаклар киләчәген белеп, үзен бу очрашуга әзерләп куйганлыгы сизелеп тора.

— Владимир Ульянов? Сез кулга алынасыз! Җыеныгыз!

Димәк, төрмә! Ашыкмый гына киенгән арада Казан император университетының кичәге студенты бу кулга алынуга кадәр булган вакыйгаларны күңеленнән тагын бер тапкыр кичерде.

«Сходкага, иптәшләр! Сходкага!» Дүртенче декабрьда, иртән университетның озын коридорларында шундый чакырулар яңгырады. Тиздән актлар залына ярсыган, дулкынланган студент егетләр килеп тулды. Иң алдагылары арасында юридик факультетның беренче курсында укучы Владимир Ульянов та бар иде.

Бу яшь-яшь егетләрне бергә нәрсә алып килгән иде соң?

Кыскача гына булса да шул заманнарны хәтергә төшереп үтик. Россия капиталистик үсеше юлына, кем әйтмешли, ике аяклап баскан вакыт бу. Пролетариат әле туып кына килә, ул әле үзенең сыйнфый таләпләрен оешкан төстә куярга өйрәнмәгән, коточкыч изелүгә, эш һәм тормышның адәм түзмәслек шартларына стихияле рәвештә генә каршылык күрсәтә. Әмма ул үзенең барлыгын һәм ныгый баручы көч икәнлеген торган саен ешрак сиздерә. Соңрак ул вакытларга характеристика биреп, В. И. Ленинның апасы Анна Ильинична Ульянова-Елизарова үзенең истәлекләрендә болай яза: «Гомумән алганда, бу тынлык, торгынлык чоры иде, «Народная воля» инде тар-мар ителгән, ә социал-демократия Россиядә әле тумаган, көрәш мәйданына массалар чыкмаган... әледән-әле кабынып китеп, үзен сиздереп торучы бердәнбер катлам булып студентлар саналган бер чор иде. Алар арасында ачыктан-ачык ризасызлык белдерүче, көрәшергә маташучы кызу канлы кешеләр һәрвакыт табылып тора... Хөкүмәтнең кулы барыннан да ныграк нәкъ менә аларны кыса иде. Тентүләр, кулга алулар, сөргенгә җибәрүләр күбрәк студентлар өстенә төшә иде».

Халыкның ачуы кабарудан, дәһшәтле демократик хәрәкәт дулкынының көчәюеннән, гомумхалык протестының якынлашуыннан куркып калган патша самодержавиесе, боларның барысына да җавап итеп, террорны тагын да рәхимсезрәк итүдән гайре бернәрсә дә уйлап таба алмый. Ә куркуга төшәрлек сәбәп чыннан да бар. Нибары

унбер ел эчендә тәхет ияләре — патшаларга ике тапкыр һөҗүм ясалган. Аларга кем ата диген әле? Тәхетнең ышанычлы терәге, аның сакчылары итеп тәрбияләнергә тиешле, император университетларында укучы студентлар ата.

Тагын шунысы игътибарга лаек. Бу мәсьәләдә Казан университеты аерата борчу тудыра. 1861 елда Казан уку-укыту округының инспекторы Вяземскийга каршы студентлар бунты оештыруда гаепләнеп, Дмитрий Каракозовны университеттан чыгаралар. Ике елдан ул яңадан шунда ук укый башлый. һәм менә шул егет 1866 елда патша хәзрәтләренә һөҗүм итә. Казан университетының башта — медицина факультетында, аннары юридик факультетында укучы студенты Василий Осипанов 1887 елның мартында Александр III кә һөҗүм оештыруда актив катнаша. Инде дә килеп тәхеткә каршы шул ук җинаятьтә катнашкан Александр Ульяновның әтисе дә Казан университетын тәмамлаганны искә алсак,— патша властьларына зур борчу белән уйланырлык нәрсәләрнең күп булуы яхшы аңлашыла. Өстәвенә шул ук Ульяновның икенче улы Владимир да бирегә килеп укый башлый...

Әйе, Казан университетында азатлык сөю рухы, А. П. Щапов, Д. И. Мейер, П. Ф. Лесгафт кебек алдынгы карашлы профессорлар ярдәмендә яңадан-яңа импульслар алып килгән демократик рух яши бирә. Нәкъ шушы елларда Казанда булып киткән халык мәгарифе министры И. Деляновның университет профессорларына: «Казан студентларында Пугачев каны уйный»,— дип әйтүе тикмәгә булмаган.

Шунлыктан, патша ялчылары бер нәрсәдән дә тартынып тормыйча, әлеге рухны сүндерергә, «Пугачев канын» соңгы тамчысына кадәр сыгып чыгарырга, университетта һәм башка уку йортларында бер генә кеше дә царизмның изге нигезләренә кул тидерү, хөкүмәткә каршы сүз әйтү, көрәш оештыру турында уйлый да алмаслык тәртип урнаштырырга тырышалар. Беренче чиратта уку йортларына ярлы-ябагай балаларының керүе тагын да чикләнә төшә. 1887 елда мәгариф министры тарафыннан урыннарга җибәрелгән һәм халык арасында «кухарка балалары турында циркуляр» дип яманаты чыккан документ нәкъ шул максатка юнәлдерелгән. Бу циркулярда министр галиҗәнаблары гимназия һәм прогимназия җитәкчеләрен «кучер, лакей, пешекче, кер юуучылар, вак кибетче һәм шуларга охшаш кешеләрнең балаларын» әлеге уку йортларына кертүдән тыя. һәркайда университет уставларының үзгәртелүе, алардагы демократия калдыкларының бетерелүе, полиция тәртипләре урнаштырылу, студентларны яшерен күзәтү астына алу, шымчылыкның киң таралуы шул максатны алга сөрә. Ректорлар, попечительләр һәм инспекторлар мантиясе кигән патша ялчылары, шундый уставлар белән коралланып, укучылар арасында һичнинди ризасызлык та булдырмау өчен бар көчләрен куеп тырышалар. Хәтта студентлар арасында күптәннән яшәп килгән традицион землячестволар да тыела. Властьлар кулында аларны кысу өчен дәлил җитәрлек була. Губерна жандарм идарәсе начальнигы полковник Гангардтның 1887 елгы отчетында мондый сүзләр бар: «...мохтаҗ иптәшләренә үзара ярдәм итешү өчен диган булып оештырылган бу землячестволар чынлыкта бер-берсе белән тыгыз элемтәдәге, укыту начальниклары үткәрә торган чараларга системалы рәвештә каршылык күрсәтүне генә түгел, башлыча шул ук землячестволардагы гектографларда бастырылган һәм хөкүмәткә каршы юнәлдерелгән китапларны бүтән студентлар арасында тарату юлы белән туп-туры революцион максатларга ирешүне дә үзләренә бурыч итеп куйган яшерен түгәрәкләргә әверелделәр...»

Бу чор вакыйгаларына кагылышлы әдәбиятта землячестволар эшенә күпмедер дәрәҗәдә социал-демократларның да йогынтысы булгандыр, диган фикер әйтелә. Аерым алганда, 1886 елның ноябрендә бөек рус демократ-тәнкыйтьчесе Н. А. Добролюбовның үлүенә егерме биш ел тулу уңае белән Петербургның Волков зиратында өч мең кешелек демонстрацияне оештыруда гаепләнеп, пайтәхеттән Казанга сөрелгән социал-демократлар — укытучы Анна Амбарова һәм хатын-кыз югары курсларында укыган Юлия Беловаларның Самара-Сембер землячествосының эшендә катнашулары билгеле. Әлбәттә, алар бирёдә бу землячествоның актив члены Владимир Ульянов белән очрашкан һәм бу оешманың эше, планнары, аерым алганда, студентлар сходкасын оештыру турында сүз алып барган булырга тиешләр. «Нәкъ менә землячество җыелышларында,— дип яза югарыда телгә алынган жандарм

полковнигы,— Мәскәүдә булып үткән чуалышлар үрнәгендә Казан шәһәрендә да студентлар чуалышын башлау мәсьәләсе кузгатыла һәм хәл ителә».

Биредә, мөгаен, тагын бер нәрсәне ачыклап үтәргә кирәктер. Казан университетына укырга кергәндә Владимир Ульянов ниндирәк шәхес булган соң? Әйдәгез, хәтерне бераз яңартыйк. Сембер шәһәрендәге прогрессив кешеләр һәм Кокушкино авылындагы ярлы крестьяннар белән бәйләнештә-аралашуда, самими дуслык, демократия принципларына корылган гаиләдә үткән балачак. Тарихны һәм бигрәк тә изелгән халыкның изүчеләргә каршы көрәше белән бәйле булган драматик вакыйгаларга гаять бай булган Россия тарихын бик тәпле өйрәнү, революцион-демократ язучыларның, тәнкыйтьчеләрнең әсәрләрен йотлыгып уку. Ниһаять, патшага һөҗүм оештыруда гаепләнеп, җәзалап үтерелгән абыйсы Александрны югалту. Еллар буе үзенә үрнәк итеп, яратып кына түгел, табынып килгән бу кешенең революцион көрәштә ялгыш юл сайлавын аңлаганлыктан икеләтә фаҗигале драма кичерү. Болар барысы да егетнең дөньяга карашы формалашуда, әлбәттә, хәлиткеч роль уйнаган. Социаль көрәштә ялгыз террор юлы белән җиңүгә ирешеп булмаганлыгын аңлаган һәм абыйсының һәлакәте турында ишеткәч: «Юк, без мондый юл белән китмәбез!»— дип, кыю һәм катгый фикер әйткән Владимир Ульянов әле Казанга килгәнче үк җәмгыятьне үзгәртеп коруның, кешенең кешене изүен бетерүнең бердәнбер дөрес юлын эзләп озак баш вата. Һәм барыннан да элек җәмгыятьнең үсеш законнарын белергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килә. «Хәзер вакыт шундый,— хокук фәннәрен һәм политик экономияне өйрәнү бик мөһим». Һәм юридик факультетка керергә карар кыла.

1887 елның җәендә Казанга энергия һәм яшьлек дәрте ташып торган, гаделсезлекнең теләсә нинди чагылышына нәфрәт белән караучы, алган тәрбиясе, эзләнү-уйланулары, теләк-омтылышлары белән халык бәхете хакына революцион көрәшкә ашкынып яшәүче егет килә. Андый кеше студентлар землячествосына керү мөмкинлегеннән файдаланмый калламы соң? Укулар башлануның беренче көннәреннән үк Владимир Ульянов Самара-Сембер землячествосына керә. Алай гына да түгел, Ульяновны барлык землячестволарның гомумшәһәр органы сымаграк бер союз советына делегат итеп тә җибәрәләр. Владимир Ильичның студент яшьләр арасындагы роле, авторитеты турында сүз барганда, без тагын бер нәрсәне онытмаска тиеш. Күп укыган булуы, иптәшләренә ярдәмчеллеге, алар белән җиңел аралашуы, гаделлеге, кыюлыгы һәм үз карашларын яклый белүе, принципиальлеге өстенә ул бит әле патшага һөҗүмдә катнашкан, шул юлда һәлак булган Александр Ульяновның энесе дә! Бу нәрсә демократик караштагы яшьләрдә Владимир Ильичка карата игътибарны тагын да көчәйткән.

Землячестволарга катнашу — яшь Ульяновның җәмәгать эшчәнлегенең бер ягы гына. Хәлбуки, безгә бит әле булачак юлбашчының нәкъ менә шушы чорда ветеринария институты студентлары А. Скворцов һәм Л. Богораз җитәкчелек иткән, жандарм чиннары фикеренчә, үтә дә «зарарлы юнәлештәге» революцион түгәрәкнең актив члены икәнлеге дә билгеле. Түгәрәк членнары Эт тыкрыгындагы (хәзерге Некрасов урамы, 22) мещан Агеевның ике катлы йортына җыелучан булганнар.

Бу түгәрәк членнары сходка оештыруда актив катнашканнар. Димәк, революцион сходканы үткәрүдә Владимир Ильич икеләтә зур роль уйнаган.

Кыскасы, Владимир Ульяновның Казанга килүеннән башлап сходка көненә кадәр дәвам иткән берничә ай вакыты гаҗәеп киеренке узган. Полиция шымчылары «дәүләт җинаятьчесе»нең энесен һәр адымда күзәтеп торганнар. Университеттагы чуалышлар алдыннан Владимир Ульяновның нәрсә белән шөгыльләнүе полиция документларына теркәлгән. Аларда Ульяновның «занятиеләргә сирәк йөргәнлеге» дә, 5 ноябрьда — Александр I университетны ачу турындагы грамотага кул куйган көнне ел саен үткәрелә торган «тантаналы актта булмавы» да, «революцион түгәрәкләр оештыруда актив катнашуы» да язып барылган. Ләкин Владимир Ильич, шымчылардан эз яшереп, землячество җыелышларына да йөри, Богораз-Скворцов түгәрәгендә дә катнаша һәм аларның һәркайсында университетта демонстрация оештыру турындагы фикерне ачыктан-ачык яклап чыга. Сходкага хәзерлек барышында листовка басыла.

Ул мондый сүзләр белән башлана: «Казан студентлары!.. Без бөтен киңлегенә җәелеп бара торган реакциягә үзебезнең протестны белдермәбезмени?..»

Казан университетында студентларның массовый демонстрациясенә Мәскәүдә булып үткән вакыйгалар соңгы этәргеч була. Анда полиция белән бәрелештә ике студент үтерелә. Бу вакыйгалар алдыннан гына университетларда уку өчен түләүнең биш тапкыр арттырылуы да үзенең ролен уйнамый калмагандыр. Реакцион инспектор Н. Потаповның явызлыклары да студентларның канын кыздыра төшкән булса кирәк.

Сходка 1887 елның дүртенче декабрендә була. Император университеты дүрт сәгать буена бөтенләе белән студентлар кулында тора. Владимир Ульянов — сходкадагыларның иң алдынгы сафында. «Бер-бер артлы речьләр сөйләнде һәм алар күбрәк политик характерда иделәр,— дип яза сходкада катнашкан, соңыннан фәннәр докторы булган Н. Н. Алексеев.— Сөйкемле ачык йөзле, күзләре янып торган, әле малай гына кебек күренгән Владимир Ульянов та чыгыш ясады — патшаның изүе турында, патша судының гаделсез булуы һәм студентларның протест белдерергә тиешлекләре турында сөйләде».

Сходка түбәндәге сүзләр белән башланган петиция кабул итә: «Безне бирегә гомумән Россия тормышы, аерым алганда, студентлар тормышы шартларының түзеп тормаслык булуын аңлау хисе китерде...»

...һәм менә — жандармнар. Хуш, университет, сау бул, ирек, сау булыгыз, туганнар. Шомлы төн, салкын төн. Аерылышу төне, күп нәрсә турында уйланулар төне. Сходкада катнашкан өчен университеттан чыгарылган һәм кулга алынган кырык кешенең иң яше — Владимир Ильич царизмның килачәген алдан күреп: «Стенасын стена, ләкин черек бит ул, төртсәң, аварга тора»,— дигән зирәк сүзләр әйткән төн. Аннары беренче сөргөн, Кокушкино...

Сходка бастырыла. Ләкин ул тарихта эзсез калмый. Казан студентларының кузгалеше Россиядәге революцион көрәш тарихында лаеклы урын ала. Сходка В. И. Ленинның чын революционер-марксист булып формалашуында да зур роль уйный. Сходкада катнашкан бүтән егетләр дә, еллар үтү белән, Федосеев җитәкләгән марксистик түгәрәк членнары булып китәләр. Плехановның «Хезмәтне азат итү» оешмасындагы фикердәшләре, Петербург, Харьков, Ростовтагы түгәрәкләре һәм оешмалары белән элемтә урнаштыралар.

...Патша ялчылары Владимир Ульяновка Казан университетын тәмамларга ирек бирмәделәр. Ләкин ул безнең көннәрдә университетка барыбер әйләнеп кайтты. Әнә ул, утыртма якалы күлмәген билбау белән бәйләп, тужуркасын иңенә салып, кулына китаплар тотып, университетның ак колонналы мәһабәт бинасы каршында мәрмәр постаментта басып тора. Язмышында шундый зур роль уйнаган университеттан ул бөтенләй китмәгән дә кебек. Һәйкәл тирәсендә елның теләсә нинди вакытында — чәчәкләр. Аның янынннан студентлар үтеп йөри. Алар лекцияләргә, зачетларга, семинарларга ашыгалар. Беренче курстагыларның студентлыкка аяк басулары да һәйкәл каршында бәйрәм ителә. Монда мәктәп балаларын комсомолга кабул итәләр. Һәр елны, иске стиль белән дүртенче декабрьдә, Казан студентлары самодержавиегә каршы политик демонстрация оештырган көнне, университет коридорларында традицион: «Сходкага, иптәшләр! Сходкага!» — дигән аваз яңгырый.

Университетның актлар залы, Владимир Ульянов хокук тарихыннан лекцияләр тыңлаган аудитория 1887 елдагы хәленә кайтарылган. Стенада — шул елны университеттан чыгарылган студентлар исемлеге. Утыз тугызынчысы — Ульянов. Мемориаль зона төзелгәннән бирле биредә дүрт миллионнан артык кеше булган. Алар җир шарының төрле почмакларыннан киләләр, сходкада катнашучылар актлар залына күтәрелгән баскычтан икенче катка менәләр, Ульянов утырган парта янында басып торалар, университеттан чыгарылучылар исемлеген — аларның күбесе өчен беренче партия характеристикасы булган бу документны укыйлар һәм, фактлар, вакыйгалар турында уйланып, даһи кешенең бөек тормышы һәм көрәше турындагы бөек хакыйкатьне аңларга тырышалар.

# БЕРЕНЧЕ МАРКСИСТ

Җәйге челләнең нәкъ кызган чагында 1889 елның июль уртасында Иделнең уң як ярына урнашкан Печище авылында яшәүче фельдшер хатын Н. Каменская өенә ябырылып жандармнар кереп тула. Патша шымчылары бу авылдан бик канәгать булып китәләр. Шатланырлык та шул: ничә айлар искәнеп эзләп йөргән куркынычлы группаның эзенә төштеләр бит. Аларга бик күп борчулар китергән фетнәчеләрнең башлыгы Николай Федосеев — менә инде үзе алар кулында. Әйтсәң, кеше ышанмас: әле кичә генә гимназист булган япь-яшь җилкенчәк, патшага каршы түгәрәкләр оештырып, зарарлы речьләр сөйләп, тыелган китаплар таратып, күпме мәшәкать ясады! Күрер күзгә җинаятьчегә дә охшамаган үзе. Өсте-башы килешле, җитез, чибәр, төз гәүдәле, коңгырт чәчләре киң маңгаена төшеп тора, күзләре дә мөлаем карый. Кешенең тышкы кыяфәтенә генә ышанырга ярамый шул. Шәһәр читендәге яшертен квартирында да бер үк нәрсә белән мәшгуль — «Карл Маркcның экономик тәгълиматы» дигән «фетнә китабы» басып маташа. Рәшәткә артында утырып карасын әле, акылына килер.

Бу — аның беренче тапкыр кулга алынуы. Унсигез яшь! Николай Евграфовичның соңрак төрмәдән язган хатларында «тирән рәхмәт хисе белән» телгә алыначак еллар — ата-ана янында, туганнар янында үткән балалык еллары артта калган. Алардан соң — ата-ана белән «ел саен көчәя барган бозылыш, аңлашылмаучанлыклар, ә тагын да соңрак — гаиләдән бөтенләй читләшү». Болар барысы да узган инде. Казанның император гимназиясендә җиде ел буе уку да артта. Бирелә ул Анна Ильинична Ульянова сүзләре белән әйткәндә, «иптәшләрен үзенә тартып торучы магнит» булган, «ә 1887 елның башында... практик эш башлану максаты белән түгәрәк оештырган». Китапларда Россия чынбарлыгының күп кенә мәсьәләләренә җавап эзләп, баш күтәрми уку еллары да узган инде. Җәмгыятьне үзгәртеп кору турында уйланулар, марксизм юлына аяк басу, баш ватулар, эзләнүләр. Бу бөек тәгълиматны эшчеләр хәрәкәте белән бәйләргә омтылулар, Алафузов фабрикаларындагы, Адмиралтейство бистәсендәге эшчеләр белән беренче элемтәләр...

Әйе, болар барысы да — артта. Ул үзе — жандармнар кулында. Анда — ун ел буе дәвам итәчәк бөтенләй башка тормыш. Николай Федосеев ул гомернең нибары җиде аен гына иректә үткәрәчәк. Сорау алулар, суд тикшерүчеләре, төрмәләр, озынозак сөрген юллары. Алда — туып үскән гаилә белән, үз сыйныфының шартлы гадәтләре, кагыйдәләре белән тәмам агуланган, власть сөюче алпавыт әнисе белән араның тулысынча өзелүе. Николай Евграфович кулга алынгач, ул улы белән күрешү өчен төрмәгә килмәячәк һәм хәтта кош теле кадәр генә хат та язып салмаячак кына түгел, бүтән туганнарын да мондый эшләрдән катгый рәвештә тыячак. Алда — яраткан кешесен югалту, чибәр кыз, киң күңелле кеше, үз эшенә чиксез бирелгән революционерка — аның белән бер үк көнне кулга алынган Анна Соловьева белән мәңгегә аерылышу фаҗигасе. Алда — Казан төрмәсенең, Петербургтагы «Кресты» һәм Мәскәүдәге Бутырский төрмәләренең бер кешелек камераларында, Сольвычегодск (хәзерге Архангельск өлкәсе) һәм Көнбатыш Себер сөргеннәрендәге коточкыч шартларда ару-талуны белми эшләүләр. Кыскасы, алда әле Николай Евграфович Федосеевны В. И. Ленинга аны «гадәттән тыш талантлы һәм үз эшенә гадәттән тыш бирелгән революционер» итеп сурәтләү өчен нигез булачак эшләр, түземлек-сабырлыклар, фидакарьлек-тырышлыклар көтә.

В. И. Ленин Федосеевның тормышын яхшы белә, аның хезмәтләре белән якыннан таныш була, аның эшләрен игътибар белән күзәтеп бара. Бу ике бөек кешенең революцион хәрәкәттәге юллары бер үк елларда гына түгел, бер үк урында, бер үк шәһәрдә — Казанда башлана. Үзләре бер генә тапкыр да очрашмасалар да (гәрчә алар икесе дә мондый очрашуга омтылалар), бер-берсенә күп тапкырлар бик нык якынлашалар. Алар — яшь аермалары белән бер генә ел булган кордашлар (Н. Е. Федосеев 1871 елның маенда Вятка губернасында туа), бер үк вакытта һәм нәкъ менә Казанда, марксизмның дөньяны үзгәртеп корырга сәләтле бердәнбер тәгълимат булуына инанып, аның белән чын-чынлап мавыгып китәләр һәм бөтен тормышларын хезмәт ияләрен азат итү өчен көрәшкә багышлыйлар.

1887 елның декабрь башында булган студентлар сходкасыннан соң аны оешты-

ручылар һәм анда актив катнашучылар,— шул исәптән юридик факультетның беренче курс студенты, унҗиде яшьлек Владимир Ульянов,— кулга алыналар һәм озак та үтми Казаннан сөреләләр. Беренче гимназиянең чыгарылыш классында укучы Николай Федосеев — кулга алынучыларның күбесе белән турыдан-туры элемтәдә торган уналты яшьлек үсмер — сөрелгән иптәшләрнең язмышын җиңеләйтергә тырышып йөри, аларга ярдәм итү өчен акча җыюны оештыра һәм шул ук максат белән үзенең шәхси китапханәсен сата.

Шуннан соң бер-ике атна узгач, декабрь азагында Николай Федосеев үзе дә шундый ук язмышка дучар була. Гимназияне тәмамларга нибары берничә ай кала «политик яктан ышанычсызлыгы, фикерләренең зарарлы юнәлештә булуы һәм тыелган китаплар укыганы өчен» аны гимназиядән куып чыгаралар.

Бу вакытта Владимир Ильич белән Николай Евграфович бер-берсе турында ишеткән булырга тиешләр. Искә төшереп үтик: шул ук гимназия, алай гына да түгел — Николай Евграфович белән бер үк сыйныфта, Владимир Ильичның туганнан туган энеләре (Мария Александровнаның апаларының уллары) Владимир Ардашев һәм Николай Веретенниковлар укый. Эш моның белән генә дә бетми әле. Шул ук беренче гимназиядә (дәрес, Николай Евграфовичтан ике сыйныф түбәнрәк) Владимир Ильичның бертуган энесе Дмитрий Ульянов та укып йөри бит әле. Аларның өчесеннән берәве генә булса да, гимназиядә бик зур авторитет казанган Николай Федосеев турында Владимир Ильичка сөйләми калмагандыр.

В. И. Ленинның һәм Н. Е. Федосеевның тормыш параллельләре моның белән генә өзелми. 1888 елның көзендә, Кокушкинода сөрген срогын тутырып, Казанга әйләнеп кайткач, Владимир Ильич биредә инде оештыру ягыннан шактый ук нык формалашкан һәм актив эшләүче марксистик түгәрәкләр барын белә. Идел буенда гына түгел, ил күләмендә дә беренчеләрдән булган бу түгәрәкләрне оештыручы һәм җитәкләүче кеше унҗиде яшьлек Федосеев була. Владимир Ильич шул түгәрәкләрдән берсенең эшендә актив катнаша башлый. Шактый еллар үткәч, В. И. Ленин: «Н. Е. Федосеев,— дип яза,— марксистик юнәлештә торуларын беренче булып игълан итә башлаган кешеләрнең берсе иде».

1888 елның көзендә Казандагы мондый түгәрәкләр саны унга җитә. Аларның членнары — университет һәм ветеринария институты студентлары, урта уку йортларындагы сабакташлар. Бу яшьләр политик экономия һәм тарих белән, Россиядәге төрле сыйныфларның хәле һәм җәмгыятьтә тоткан урыны белән танышалар, К. Маркс, Ф. Энгельс, «Хезмәтне азат итү» группасы җитәкчеләренең әсәрләрен өйрәнәләр. Федосеев түгәрәкләре марксизм идеяләрен таратуны, народниклык идеологиясенә каршы көрәш алып баруны максат итеп куялар. Николай Евграфович тарафыннан бу түгәрәкләр өчен эшләнгән теоретик хәзерлек программасы бөтен Россиядә киң таныла һәм «Казан программасы» исеме белән революцион хәрәкәт тарихына кереп кала. Владимир Ильич Самарага күчкәч, 1889—1891 елларда биредәге марксистик түгәрәк дәресләрен нәкъ менә шул «Казан программмасы» буенча алып бара.

Н. Е. Федосеев, бер ел да өч ай буена Казандагы пересыльный төрмәдә утырганнан соң, суд алдына баса һәм Петербургтагы «Кресты» (бинасы тәре формасында булганга аны халык телендә шулай дип атап йөрткәннәр — Р. С.) төрмәсенә 15 айга хөкем ителә. Аның көрәштәшләре А. Санин, К. Ягодкин, П. Лавровский, П. Масловлар да ирекләреннән мәхрүм ителәләр. Николай Евграфовичның яраткан кызы Анна Григорьевна Соловьева, кулга алынып, төрмәгә ябылуыннан соң ике атна үтәр-үтмәс, шул ук төрмәдә утыручы Николай Федосеев белән ярәшергә рөхсәт сорап, төрмә администрациясенә үтенеч яза. Шундый ук кәгазь Федосеевның үзеннән дә алына. Ләкин аңа, ярәшү суд карары игълан ителгәннән соң гына мөмкин, дип җавап бирәләр. Әмма аларның эшләрен карау ел ярым чамасына сузыла. Ул арада Анна Григорьевнаны азат итәләр, ә Николай Евграфович Петербург төрмәсенә күчерелә. Шулай итеп, ике гашыйкның аралары өзелә. Соловьеваның моннан соңгы язмышы билгеле түгел.

Казан һәм Петербург төрмәләрендә утырганда Николай Евграфович Россиянең экономик үсеш юлларын, крепостниклык хокукының бетерелүе сәбәпләрен ныклап өйрәнә.

1891 елның июнендә Н. Е. Федосеев, «Кресты» төрмәсендә утыру срогын туты-

рып, ирекко чыга. Лэкин аңа марксист дуслары калган Казанга да, аңа читтән торып булса да инде таныш Владимир Ульянов яши торган Самарага да юл ябык. Полиция Владимир шәһәренә барырга куша. Һәм ул, Петербургтагы иптәшләре, элемтә тотарга уңай булсын өчен, аңа «кәләше» итеп тәкъдим иткән һәм тора-бара аның якын кешесе булып киткән курсистка кыз Мария Гопфенгауз, шулай ук Казанда танышкан дусты К. Ягодкин белән бергәләп шушы шәһәргә китә. Биредә ул бераз гына булса да тыныч яшәргә, беркнинди революцион эшләргә катнашмаска, белемен тулыландыра төшәргә карар итә. Ләкин: «...әгәр ул, күпчелек эшләгәнчә, туктап калса, сагаеп кына атлый башласа,— дип яза А. И. Ульянова Н. Е. Федосеев турындагы истәлекләрендә,— әгәр сак астында яшәү шартларында да эшчеләр арасында пропаганда алып бару гаять кыен, бөтенләй диярлек мөмкин булмастай эш кебек күренсә дә, аны барыбер алып барырга тырышып карамаса, ул революция карлыгачы булудан туктар иде».

Николай Евграфович бу эшне чыннан да үзенә хас фидакарьлек һәм дәрт белән алып бара башлый. Ул үзенең фәнни тикшеренүләрен дә дәвам иттерә. Инде без телгә алган Мария Гопфенгауз аңа, ниһаять, Владимир Ульянов белән элемтә урнаштырырга ярдәм итә. Ул В. И. Ленинга тапшыру өчен Самарага Н. Е. Федосеевның крепостниклык хокукы турындагы әле тәмамланмаган хезмәтенең бүлекчәләрен алып бара, Николай Евграфовичның Самарага күчүе мәсьәләсе турында сөйләшә. Владимир Ильич Николай Федосеевның хезмәтенә югары бәя бирә, Гопфенгауз аша аңа үзенең мәкаләләрен җибәрә, күп тә үтми, аның белән хат алыша башлый. Ә 1893 елда Федосеев белән күрешү өчен махсус рәвештә Владимирга килә. Ул килешкә Николай Евграфович төрмәдән чыгар дип исәп тотылса да, аны чыгармыйлар, күптән көтелгән очрашу булмый кала. Әле бусы да язмышның бу ике бөек шәхескә соңгы тапкыр аяк чалуы түгел. 1897 елда да шундыйрак хәл туа. Бу юлы инде Владимир Ильич белән Николай Евграфовичны очраштыру турында патша властьлары үзләре үк кайгыртлалар кебек. Владимир һәм Орехово-Зуево эшчеләре арасында революцион эш алып барганы өчен чираттагы тапкыр кулга алынган һәм сөргенгә хөкем ителгән Н. Е. Федосеевны Себергә озатыр алдыннан Мәскәүнең Бутырский төрмәсендә тоталар. Ә 1897 елның башында шулай ук сөргенгә җибәрелергә тиешле Владимир Ульяновны Петербургтан шунда китерергә тиеш булалар. Ләкин алар тагын очраша алмыйлар. Владимир Ильич сөрген урынына үз ирегендә барырга рөхсәт алуга ирешә. Аның каравы Н. Е. Федосеев «Бутырка»да Владимир Ульяновның «Көрәш союзы» буенча иптәшләре Г. М. Кржижановский, А. А. Ванеев белән очраша.

Николай Евграфович Себергә инде танылган марксист-публицист булып китә. Ләкин рәхимсез язмыш революционерның күп еллык хезмәт җимешләрен дә аямый. Н. Е. Федосеевның язганнары бастырылганга караганда күп тапкыр артыграк була. Россия тарихы буенча, экономик мәсьәләләргә караган җитди тикшеренүләре,— ул сөргендә чакта эзсез югала, тентү-тикшеренүләр вакытында полиция тарафыннан юк ителә. Николай Евграфович сөргендә, Верхоленск шәһәрендә дә (хәзерге Иркутск өлкәсе) хезмәтләрен дәвам иттерергә исәп тота, үзе белән бик күп китап, архив материаллары күчермәләрен алып бара. Ләкин аның бу планнарына тормышка ашарга насыйп булмый. Озак еллар буена төрмәдә утырулар, авыр тормыш шартлары, шактый җитди төс алган үпкә авыруы батыр рухлы бу кешенең көчен тәмам какшата. Тормыш кыенлыкларына тагын Юхоцкий фамилияле бер кабахәт бәндә оештырган эзәрлекләү-яла ягулар килеп кушыла. Боларның барысы да Федосеев тормышының фаҗигале төстә өзелүенә китерәләр — 1898 елның 21 июнендә ул ялгызы гына тайгага китә һәм шунда үзен-үзе атып үтерә. А. И. Ульянова: «...Сәләтле, нурлы шәхес һәлак булды,— дип яза,— безнең иң кадерле, беренче карлыгачларыбызның берсе үзенең канатларын сындырды».

Язмыш дигәнең Николай Евграфович Федосеевка нибары егерме җиде еллык гомер биргән. Шуның да ун елы төрмәләрдә һәм сөргеннәрдә үткән. Ләкин язгы яшен төсле якты һәм кыска булган шул гомер дә Федосеевның исемен үлемсез итү, мәңгеләштерү өчен җитәрлек. Аның батырлыкка тиң тормышы, революция эшенә чиксез бирелгәнлеге — халык бәхете өчен көрәшүчеләрнең күп буыннарына үрнәк. Казанлылар шушы гомернең өчтән бер өлеше үз шәһәрләрендә үтүе белән урынлы горурланалар.

# ИКЕ ДАҺИНЫҢ УНИВЕРСИТЕТЛАРЫ

Башта менә мондый кечкенә генә өзек: «...Мин ярым татар шәһәрендә, бер катлы өйнең кысан квартирында. Бу өй ярлы гына бер урамның очында, калкулыкта тырпаеп утыра, аның бер стенасы янгын урыны — бушлыкка чыга, ул бушлыкта куе булып чүп үләннәр үсә; үсеп утырган әрем, әрекмән, аю баланы куаклары арасында — зур гына подвал, анда хуҗасыз этләр яши һәм үлә. Минем университетларымның берсе булган бу подвал хәтеремдә бик нык саклана».

Укучы, ихтимал, бу өзекнең бөек пролетар язучысы Алексей Максимович Горькийның «Минем университетларым» исемле автобиографик повестеннан алынган булуына төшенгәндер. Димәк, ул өзектә телгә алынган «ярым татар шәһәренең» безнең Казан икәнлеген, 1884 елның августында уналты яшьлек Алеша Пешковның бу шәһәргә Нижний Новгородтан пароходның иң аскы катында, тартма-мичкәләр арасында идәнгә чүмәшеп килгән булуын да белә. Ә «ярлы гына урам»ы белем алу турындагы хыял белән яшәүче үсмерне беренче көннәрдә сыендырган Беренче тау (хәзерге Ульяновлар исемендәге) урамы була. Алексей Пешков белән Нижний Новгородта танышып, аны укырга керү өчен Казанга килергә күндергән гимназист егет Николай Евреинов аны шушы йортка, әнисе квартирына алып килә.

Бу вакыйгадан соң нәкъ өч ел вакыт үткәч, Казанга шулай ук Идел буйлап, икенче бер үсмер килеп төшә. Шулай ук укуын дәвам иттерү хыялы белән килә. Ләкин охшашлык моның белән генә бетми әле: бу үсмер дә Казанга килеп төшкәннән соң бераз вакыт яңа гына тасвирланган Беренче тау урамында, Николай Евреинов торган йорттан берничә генә өй аша — Ростова йортында яши (Ульяновлар урамы, 24).

Укучы, әлбәттә, сүзнең Сембер гимназиясен тәмамлаганнан соң, 1887 елның җәендә Казан университетына керү нияте белән безнең шәһәргә килгән Владимир Ульянов турында баруын да чамалап өлгерде.

Үсмерләрнең икесенә дә император университетында урын табылмый. Аларның беренчесе — мещан малае, ярлы-ятим өчен аның ишекләре гомумән ябык булып чыга. Ә икенчесен, белгәнебезчә, алуын алсалар да, укый башлавына өч ай тулар-тулмас, студентларның революцион сходкасында катнашканы өчен куып чыгаралар. Һәм ике үсмергә Казанда бүтән бер төрле университет, авыр кичерешләр һәм борчылукыенлыклар белән тулы, тик шулай да, ахыр чиктә, аларның һәр икесе өчен бик тә файдалы булган тормыш университетын үтәргә туры килә.

Алексей Максимович Казанга килеп төшүенең беренче көннәрендә үк «малайлыкта» йөрәп алган белемә белән, үзенең чыгышы һәм ул чактагы матәриаль хәлә белән аңа югары белем алу турында хыялланырга да ярамаганлыгын аңлый. Бәхеткә каршы, ул икенчә бер хакыйкатькә дә тиз төшенә: биредә, шәһәр урамнарында мещанлык сазлыгына батып калуың да бик ихтимал икән. Соңрак бөек язучы үзе турында язганда: «әйләнәдәге мохиткә каршы тору» аркасында гына кешә була алуына аерым басым ясый.

Казан пристане, пекарнялар, йорт-җирсез кешеләр куныл йөри торган урыннар — Максим Горький университетларының төп «аудиторияләре». Нәкъ менә шул аудиторияләрдә, «йөк ташучылар, сукбайлар, угрылар арасында,— дип яза Алексәй Максимович автобиографик повестенда,— мин үземнә утлы күмәр эчәнә тыгылган тимер кисәге итеп хис итә идем, һәр яңа көн минә үткен, яндыргыч тәэсирләр белән тузындыра иде». Дөньяга карашы, тормыш принциплары әле ныгып җитмәгән егетнең күз алдына бер төркем ярлыларның коточкыч тормышы бөтән шәрәләгә бәлән килеп баса. Алар кинәт кенә баеп киткән үтә тупас, саран, оятсыз мещан Марусәвның Рыбнорядская урамындагы (хәзерге Куйбышев урамы, 30) йортында яшиләр. Алексәй Максимович бу «Марусовка»да чарлакка менә торган баскыч астындагы алачык сыман кысан бер бүлмәдә полициянең яшерен күзәтүе астында булган революцион фикердәге яшь егет, университет студенты Гурий Плетнев бәлән бергә 1884 елның октябреннан 1885 елның маена кадәр тора. Кешене алҗыта, миңгерәтә торган авыр эштән, «тормыш төбенең» чиркандыргыч бозыклыкларыннан тыш Казанда яшь Горький килеп эләккән бу коточкыч «университетлар»ның үзенә күрә уңай яклары да була.

Яңа дуслары Николай Евреинов, Гурий Плетнев Горькийны демократик караштагы яшьләр белән, народниклык идеяләре тәэсирендәге революционерлар белән таныштыралар. Ул Деренков атлы кешенең Иске Горшечная (хәзерге Щапов) урамындагы бакалея кибетендә яшертен җыела торган студентлар түгәрәгенә йөри башлый. Сүз уңаенда шуны да әйтеп утәргә кирәк: Андрей Степанович Деренков белән аны шул ук Гурий Плетнев һәм Петр Кудрявцев дигән икенче бер студент таныштыра. Деренков яшь Горькийның дөньяга карашы формалашуда шактый роль уйный. Ул әлеге кибеттән килә торган булыр-булмас бар керемен яшьләрнең революцион хәрәкәтенә ярдәм итүгә тота. «Мөлаем йөзле, аксыл сакаллы, бу чулак кешенең,— дип яза Деренков турында Горький,— сирәк очраучы, тыелган китаплардан торган һәм шәһәрдә иң яхшы саналган китапханәсе бар, алардан Казандагы күп санлы уку йортларының студентлары һәм революцион караштагы төрле кешеләр файдалана иде». Бу китаплардан, әлбәттә, укуга ифрат хирыс Алексей Максимович та файдаланган.

Революцион карашлы студентлар белән очрашу, дөньясын онытып уку яшь Горькийга күп нәрсә биргән. Ләкин ул, икенче яктан, Деренков дусларының сүзләренә, кызу бәхәсләренә игътибарлы була барган саен, алардан ишеткәннәрне чынбарлык белән чагыштырып карагач, күңелендәге канәгатьсезлекнең көчәя баруын сизә. Деренков кибетенә килеп йөрүче түгәрәк членнарының Россия өчен, халык өчән хафаланулары, аның язмышын җиңеләйтергә омтылулары аңа яхшы аңлашыла. Шуңа күрә ул бу яшерен җыелышларга теләп һәм кызыксынып йөри, Андрей Стәпановичка һәм аның яшь дусларына әдәбият таратуда ярдәм итәргә дә тырыша. Аларга һәм аларның эшләренә якынрак торыр өчен Деренковның Лядская (хәзер Горький урамы, 10) урамында яңа ачылган пекарнясына ярдәмче булып та күчә.

Ләкин булачак пролетар язучысы, икенче яктан, бу кешеләрнең халыктан, аның чын ихтыяҗларыннан һәм теләк-омтылышларыннан ни дәрәҗәдә ерак торуларын, реаль тормышны бик начар белүләрен, шуңа күрә дә алар табынган, алар үзләренә корал итеп алган народниклык теориясенең нигезсез икәнлеген аңлый башлый.

Деренков булочныена күчкәндә, Горькийның икмәк пешерү өлкәсендә азмы-күпме тәҗрибәсе була инде. Аңа ул Рыбнорядская урамында (хәзерге Куйбышев ур., 13) Семеновның клиндер пекарнясында өйрәнгән була. Биредә ул ирексез хезмәтнең, ялланып эшләүнең «түмен» үз җилкәсендә татый. Бәлки, «Егерме алты һәм бер» дигән хикәядәге менә бу юллар хәтерегездәдер: «Көннән-көнгә он тузаны эчендә, аякларыбызга ишегалдыннан нярэп керә торган пычрак эчендә, авыр исле куе тынчулыкта без, камыр изеп, аны үзебезнең тиребезгә манчып, клиндер ясый идек һәм үзебезнең бу эшебезне ачы нәфрәт белән дошман күрә идек...»

Семеновта Алексей Максимович кешенең кешене изүен күреп, үз җилкәсендә татып кына калмый. Ул хезмәт кешеләре белән аралашуның, алар белән эш итүнең — беренче сабакларын да үтә, клиндер пешерүчеләрнең пекарня хуҗасына каршы чыгуларын оештырып, беренче сугышчан чыныгу ала. Аның, менә марксизмга Казан булочнигы Семенов өйрәтте, дип язуы тикмәгә түгел.

Хәер, бу чакта яшь Горький марксизмнан бик ерак тора әле. Бу елларда ул — кабаланып эзләнүче, хакыйкатькә таба сукырларча капшанып, абына-сөртенә баручы кеше. Ныклы марксистик караштa торган пролетар язучы булып җитешкәнче аңа әле күңел кайтулар, өметсез уйланулар аша үтәргә, үз-үзенә кул салырга омтылу кебек шәхси драма кичерергә һәм, ниһаять, Казанның беренче марксисты Николай Евграфович Федосеев белән очрашырга кирәк.

Бу урында без хикәябезнең башына әйләнеп кайтырга тиешбез. Без инде 1888 елның көзендә Кокушкино сөргененнән Казанга кайткач, Владимир Ульяновның Федосеев тарафыннан оештырылган марксистик түгәрәкләрдән берсенең эшендә катнашуын беләбез. Ә Алексей Максимович бу хәлләрдән бер ел элек, 1887 елның 15 августында Федосеевның үзе белән очраша. Әйдәгез, «Минем университетларым»нан бу турыда бәян иткән урынны табып укыйк. Бу очрашу Арча кырында, духовный академия урнашкан бинаның (хәзерге 6 нчы шәһәр больницасы) артындагы бакча эчендә, кеше яшәми торган бер өйдә, түгәрәк членнарының яшерен җыелышы вакытында була.

Менә алар арасындагы сөйләшү:

«— Сез — Пешков, булочникмы? Мин — Федосеев. Безгә танышырга кирәк. Де-

ресен әйткәндә, эш юк монда, бу шау-шу озакка барачак, ә аның файдасы аз. Киттекме?

Яшьләрнең бик җитди түгәрәкләрен оештыручы Федосеев турында минем ишеткәнем бар иде инде. Миңа аның якты йөзе, тирән утырган күзләре ошады.

Минем белән янәшә атлаган хәлдә ул миннән, эшчеләр арасында танышларың бармы, нәрсәләр укыйсың, буш вакытың күпме, дип сорашты. Сүз арасында әйтә салды:

— Сезнең ул булочныегыз турында ишеткәнем бар,— сезнең шундый юк-бар нәрсә белән шөгыльләнүегез гаҗәп. Нигә кирәге бар моның сезгә?

...Мин үзем дә моның миңа кирәге юклыгын аңлый идем. Шул турыда аңа да әйттем. Минем сүзләрем аны шатландырды; ул каты итеп минем кулымны кысты, ачык итеп елмайды һәм бер көннән өч атна чамасы вакытка каядыр китәчәген, ә кайткач ничек һәм кайда очрашырга икәнлеген миңа хәбәр итәчәген әйтте».

Бер-берсен беренче очрашуда ук ошаткан бу ике кешенең кабат очрашу-очрашмаулары турында безнең берниндә дә хәбәребез юк. Ләкин бер яктан, аларның очрашкан булулары бик тә ихтимал, дигән нәтиҗә ясарга, икенче яктан, Владимир Ульянов белән яшь Горькийның юллары бер-берсенә ни тикле якын килүләре турында фикер йөртергә нигез булырлык детальләрне искә төшерик. Элекке Эт тыкрыгында (Хәзерге Некрасов урамы) бу төбәкнең тарихына Плетнев йорты буларак кереп калган ике катлы агач йорт сакланган. Ул йорт Горькийның иптәше һәм киңәшчесе булган Гурий Плетневның әтисенеке була. Тарихчылар шул нәрсәне ачыкладылар: Гурийның әтисе улының революцион эш белән мавыгуларын хупламаган, шул нигездә алар арасында низаг чыккан, һәм Гурий әтисеннән аерылып, «Марусовка»га күчеп яшәргә мәҗбүр булган. Әтисе өйдә юк чакларда ул, Алексей Максимович белән бергә, шул өйгә килеп, гектографта листовкалар һәм брошюралар баса торган булган. Алар моны Федосеев кушуы буенча эшләгәннәр. Алар гектографта баскан текстлар арасында Владимир Ульяновның актив катнашында узган тарихи сходкада Казан студентлары кабул иткән петиция дә бар. Шунысы да билгеле: бу вакыйгалардан соң, полиция сходкада катнашкан студентлар белән бергә Алексей Максимовичның дуслары Николай Евреинов белән Гурий Плетневны да кулга ала. Димәк... Кыскасы, монда ахырынача ачыкланмыйсы нәрсәләр күп әле.

Тик без белгән кадәресе дә менә шуларны әйтергә нигез бирә. Аңлы тормыш юлына басучы ике егет, соңрак бөтен кешелек дөньясының горурлыгы булып әверeләчәк, озак еллардан соң барыбер якын дуслар-фикердәшләр булып китәчәк ике кеше безнең шәһәрдә үзләренең тормыш университетларын узганнар. Шулай да язмыш аларны Казанда очраштырмаган. Кызганыч, бик кызганыч.

Максим Горькийның Казан университетларының соңгы «курсы» — Идел буенда, Красновидово авылында үтә. Ул бу авылга (хәзер анда А. М. Горький музееның филиалы оештырылды) 1888 елның җәендә революцион караштагы народник М. А. Ромась белән бергә китә. Красновидовода үткән берничә ай булачак язучыга рус крестьянын, Деренковның кибет алачыгында җыелучы студентлар сөйләгәнчә итеп түгел, нәкъ тормыштагыча күрергә һәм народниклык карашларыннан тәмам арынырга мөмкинлек бирә.

Горький Казанда дүрт елдан аз гына кимрәк яши. Ләкин бу еллар бөек язучының тормышында, аның дөньяга карашы формалашуда шул кадәр зур роль уйнаганнар ки, ул соңрак бик нигезле рәвештә: «Физик яктан мин — Нижний Новгородта, ә рухи яктан Казанда тудым»,— дигән.

Туфан Миңнуллин

# КЫЗЫЛ ТЫШЛЫ ДӘФТӘРДӘН

*Тормышта үрнәк булырлык һәм гыйбрәтле вакыйгалар еш очрый. Без аларның зурларын, әһәмиятле дип саналганнарын әсәрләребездә файдаланабыз. Кайберләре онытыла. Ә язучы вак кебек күренгәннәрен дә читләтеп үтәргә тиеш түгел. Аерым бер очракта игътибарга лаек булган икән, димәк, ул вакыйганың төбендә нидер бар. Уйланырга, эзләнергә генә кирәк.*

*Аннан соң, бүтәннәр кебек үк, язучы да гел уйланып йөри — үзе турында, эше турында, дөнья, кешеләр турында уйлана. Уйланып, ниндидер бер нәтиҗә дә ясап куйгалый.*

*Күргәннәрем-белгәннәрем турында уйлануларны мин кызыл тышлы дәфтәргә язып барырга күнектем. Шул дәфтәрдән берничә сәхифәне инде сезгә дә ачып күрсәтергә булдым. Кызыклы дип санарлык нәтиҗәләр ясаганмындырмы — белмим. Шунысы хак: бу уйланулар барысы да эчкерсез. Үзем нинди — уем шундый.*

## Ашыкма!

М. Горький исемендәге ял паркы янында троллейбуска утырдым. Алгы рәтләрне чегән хатын-кызлары сырып алган. Шулар янынарак барып бастым. Телләрен аңламасам да, аларның үзара сөйләшкәнен тыңларга яратам. Шау-гөр киләләр. Әйтерсең, алардан башка дөньяда бүтән адәми зат юк. Берникә дә, беркемгә дә исләре китми.

Троллейбус Татар академия театры янына җиткәндә, урамга карадым. Театрның афишалар тактасында «Премьера. Туфан Миңнуллин. Адәм баласына ял кирәк» дип зур хәрефләр белән язылган белдерү тора. Күңелдә рәхәтлек. Масаю да бар, әлбәттә. Чөнки мин инде премияләр алгалап, тәнкыйтьчеләр тарафыннан шактый үк иркәләнеп, бераз гына бозыла башлаган кеше. Җае туры килгән саен, менә күрәсез, «мин» алмашлыгын да ешрак кулланам. Бу юлы да, мине күрәләр микән дип, кукраеп як-ягыма карангалап алдым. Урамга текәлеп баручылар минем исем-фамилиямне укыр өчен генә тәрәзгә каранганнардыр кебек тоелды.

Рәхәт! Валлаһи дип әйтәм, рәхәт! Күпләрнең күзе афишада ябышып калды кебек. Хәтта чегән хатыннары да татарча язылган афишаны укып үттеләр. Әйе, әйе, үтүләренә әз генә дә шигем юк иде. Ник дигәндә, тәрәзәгә төбәлгәннәренең берсе, борылып, миңа карап куйган сыман итте дә: «Драматург!» — диде. Кирәк бит ә! Татары белә дә белә инде мине, анысына печтик тә шикләнгән юк. Керфек буйый, күз төбе каралта, каш сыза торган карандаш сатып табыш итүче чегәннәр дә мине таныйлар икән ләбаса. Әнә, үз телләрендә кызып-кызып сөйләшәләр, драматург, драматург дип туктаусыз кабатлыйлар. Билгеле инде, сүз минем турыда бара. Троллейбуста драматург мин генә, афишада минем исем.

Шунысы гаҗәп, исемемне, фамилиямне ни өчендер телгә алмыйлар. Югыйсә, афишадан укыдылар ич инде.

Колакларны тагын да сагайтыбрак тыңлыйм: бәлки әйтәләрдер минем исемне, мин генә ишетеп өлгерми каламдыр! Тыңлый торгач, чегәннәр сөйләшүендә Армавир,

Константиновка диган сүзләр ешрак чыга башлады. Тукталә, Армавир, Константиновканың драматургка, ягъни мәсәлән, миңа ни катнашы бар? Әллә минем пьесалар Армавир шәһәрендә, Константиновка авылында куелып, бу чегәннәр шунда спектакль караганнармы?

Троллейбус базарга якынлашканда, ниһаять, барысы да ачыкланды. Чегән хатыннары драматург димиләр, Краматоров диләр икән. Ялгышмасам, шундый шәһәрме, станцияме бар.

Кычкырып көлеп җибәргәнемне үзем дә сизми калдым. Чегән хатыннары базарда төшкәч тә, вокзал тукталышына үзем төшкәч тә көлдем. Үткән-сүткәннәрне гаҗәпләндереп, эчемне уа-уа көлдем. Шушы вакыйганы дусларга сөйләп көлдем.

Ә язганда көлмичә генә язам. Чөнки бик гыйбрәтле вакыйга бит. Масаюның куркыныч чир икәнен янә бер кат исбатлаучы мисал. Масаю чире колакны томалаган, «Краматоров»ны драматург дип ишеттергән.

Димәк, хәтта күзеңә карап, кабат-кабат исемеңне әйтеп мактаган очракта да күккә сикерергә ашыкма. Бәлки сине мактаучы «Краматоров» дип әйтәдер.

*Сентябрь, 1980*



# Ышандым бугай

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында «Моңлы бер җыр» исемле пьеса язып утырган чак. Шактый өлеше язылган. Тизрәк тәмамларга дип ашыгам. Шуңа күрә, өйдән беркая да чыкмыйм. Аннан-моннан гына юынам да, кырынып та тормыйча үземне өстәл янына «кадаклап» куям. Өс-баш та, әлбәттә, өйдәгечә: укчәсе таптапып, кыйшаеп беткән «дамашный тапычкы», төбе ашалып, тезләре чыккан, үтүк күрмәгән чалбар һәм башкалар, һәм башкалар. Мин — аларга, алар миңа ияләшкән. Чиста, йомшак, җылы, җайлы булсалар, матурлыгы ни чуртыма кирәк. Үз бүлмәмдә үзем генә утырам ләбаса.

Өч-дүрт көн шәп кенә эшләдем. Шуннан соң чыгымладым. Бер җөмлә дә яза алмыйм. Язганымны сызып ташлыйм. Килеп кенә чыкмый бит, әкәмәт. Таки мин үзем теләгәнчә килеп чыкмый. Җитмәсә, пьесаның үтә җаваплы урыны: Муса Җәлил көрәштәшләре белән үлем камерасында дөньяда яшәүнең мәгънәсе турында сөйләшергә тиешле сәхнә һәм җәза бүлмәсенә юнәлү күренеше. Монда аз гына да фальшь китмәскә тиеш. Менә шул кәгазьгә төшкән хәтлесе үземне ышандырмый. Муса Җәлил ниндидер вак шәхес булып чыга. Андыйның куплэрне шаккатырырлык батырлык эшләве мөмкин түгел. Язганымны сызып, тагын башлыйм.

Шактый озак азапландым. Арыдым. Шуннан, туктале, мин әйтәм, бераз һавада йөреп керим, башны ял иттерим. Ваннага кереп, әйбәтләп кырындым, юындым. Матурлап киендем. (Урамга өйдәге кыяфәт белән чыгып булмый ич инде.) Чыгып китәр алдыннан өстәл өстендә яткан кәгазьләрне (кулъязманы) тәртипкә китерергә тотындым. Шунда...

Үзем дә сизмәстән, язылa башлады. Гаҗәеп хәл. Ни язасымны, әйтерсең, кемдер миңа әйтеп тора. Әйтерсең, мин инде әзерне генә күчерәм. Үзеннән-үзе сырлана. Көн буе диярлек интегеп яза алмаган сәхнәне, ярты сәгать тә үтмәгәндер, төгәлләп куйдым. Ул күренеш турында бүтәннәр ни әйтер, белмим, әмма үзем теләгәнчә, үзем уйлаганча яздым. Шатлыктан кычкырып җырлап җибәрдем.

Соңыннан бу халәтемне салкын баш белән анализлап карадым. Һәм шундый нәтиҗәгә килдем: күрәсең, Муса Җәлил кебек шәхеснең Ил, Ватан, халык алдындагы намус чисталыгы турында язганда, минем өс-башымның, кыяфәтемнең җыйнаксызлыгы да комачаулаган. Чистарынып, киенеп утырырга кирәк булган өстәл янына.

Иҗат итү процессы турында китаплар укыганда кайберәүләрнең, героемның үлүе турында язганда җылап җибәрдем, яки үзем язган, үзем сурәтләгән кызга үзем гашыйк булып, төннәрен йоклый алмадым дигәннәрен арттыралар дип уйлый идем. Инде ышандым бугай. Серле нәрсә бу иҗат, валлаһи.

*Декабрь, 1980*

## Шул ачуны китерә...

«Серле нәрсә бу иҗат» дигәннән, озак вакытлар берәүгә дә әйтми йөргән серемне дә язып куйыйм әле.

Агай-энеләр телендә «ашыккан» дигән сүз йөри. Теге яки бу әсәрне ошатып җиткермәсәләр, автор ашыккан, шуңа күрә әсәр урыны-урыны белән аксый, әйтергә теләгән фикере аңлашылып бетми, диләр. Мин язган әйбер турында да шул сүзне әйтүләреннән куркып йөрәгем алына. Теләсә ни дисеннәр, тик ашыккан дип кенә әйтмәсеннәр. Чөнки...

Драматургия юлыннан җилле генә юыртып барган елларның берендә яңа пьеса яздым. Озак яздым. Яратып... Уйланып. Шуны театрда укыгач: «Туфан, бу юлы ашыккансың, пьесаң барып чыкмаган»,— диделәр. Әсәрне укучы башка иптәшләр дә «ашыккансың» диделәр. Җен ачуларым чыкты. «Ничек инде ашыгыйм, алты ай утырдым ич. Җитмеш битле пьесага алты ай азмыни»,— дип талаштым. Барыбер, ашыккансың, диделәр. Ашыкмаганлыгыма ышандыра алмадым...

Шушы хәлдән соң «теге яки бу пьесаңны күпме вакыт эчендә яздың?» дип сораучыларга алдашып җавап бирә башладым. Кимендә ике-өч ел вакыт үтте дип ялганлый идем. Хәер, әле дә шулай дим. «Әлдермештән Әлмәндәр»не күпме яздың дип сорасалар, дүрт ел эшләдем дип җавап бирәм. Ышаналар. «Шулайдыр шул, шулайдыр, шуңа күрә әйбәт килеп чыккан ул», диләр...

Дөресе ничек иде соң әле? Дөресеме? Дөресе — мин «Әлдермештән Әлмәндәр» белән «Ай булмаса йолдыз бар»ны икесен берьюлы бер утырганда егерме биш көндә яздым. М. Горький исемендәге әдәбият институты каршындагы югары курсларда укыган чак иде. Имтихан вакытында Переделкино дип аталган иҗат йортына путевка алып киттем дә имтиханнарга әзерләнгән арада ике пьеса язып кайттым. Әгәр ышанмасагыз, шагыйрь Зөлфәттән сорагыз, ул «унбиш көндә ике пьеса язучы халтурщик» дип миннән көлеп тә йөрде.

Менә шуннан аңла инде ашыгуның ни икәнен. Мәсьәлә, күрәсең, ашыгуда түгелдер. Иҗатның без үзебез дә аңлап бетермәгән серләре бардыр. Яратмыйм ашыккан дигән сүзне. Әдәби әсәр турында сүз барганда ул төшенчә кулланылмаска тиештер. Булмаса, ник тагын «млиун ел» утырма, булмый инде ул. Ихтимал, минем теге пьесаның «гаебе» ашыгудан булмагандыр. Бүтән сәбәптер.

Сүз уңаенда әйтим, ашыгып (ашкынып) эшләгәндә, әйбәт языла. Күп тә языла, әйбәт тә. Ашыкмасаң, каләм тупаслана, акыл үшәнләнә, күңел салкыная. Кайбер ялкаулар үзләрен аклар өчен, башкаларга да ашыгып яза дигән гаеп ташлыйлар. Кемнең ничек язуында беркемнең дә эше юк минемчә (һәркемнең үз эш алымы), язганнары гына әдәм рәтле булсын.

Ялкау язучылар дип ачу белән әйтүнең аерым бер сәбәбе дә бар. Алар нәшриятка килеп бер әйберләрен әллә ничә кат бастырып чыгаруны сорап ялыналар. Әнә бит аны ел саен чыгарып торасыз дип, «ашыгып» язучыларга төртеп күрсәтәләр. Күп эшләгән кешенең кадере бетә башлады, шул ачуны китерә.

*Декабрь, 1980*

## Тагын тел турында

Язучылар союзында прозаиклар һәм тел белгечләре җыйналып «Бүгенге көн татар прозасында тел мәсьәләләрен тикшерәләр. Үземне прозаик дип санамасам, утырышка чакырылмасам да кереп утырдым. Бик озак сөйләштеләр, акыллыакыллы фикерләр әйтелде.

Әрсезләнеп мин дә сүз сорадым һәм җай белән генә барган сөйләшүнең тәмен җибәрдем бугай. Тел белгечләренең кайберләре мине «надан» дип кызганып та куйдылар шикелле.

Эш менә нәрсәдә: язучы һәм аның теле дигән масьәлә һичнинди анализга бирелми, минемчә. Гомумән, ул проблема юк. Язучы дибез икән, аның теле булырга тиешлеге үзеннән-үзе аңлашыла. Әдәби әсәр язарлык теле юк икән кемнеңдер, димәк, ул язучы түгел. Күз алдына китереп карыйк әле — композиторлар җыелды да композиторның колагы ишетергә тиешме-юкмы?» дип җитди сөйләшә башладылар адәм көлкесе булыр иде. Яки рәссамнар җыелып, тумыштан сукыр кеше картина яза аламы дип сөйләштеләр ди. Җитди булмас иде. Ишетү, күрү сәләте табигать тарафыннан бирелгән кебек, сүзне тою сәләте дә, минемчә, тумыштан ук килә...

Язучы белән дә шулай. Авылда бер класс та сабак укымаган кайбер абзыйлар шундый тәмле итеп сөйлиләр, авызларына карап кына торасың! Әгәр шул кеше вакытында тиешле юнәлеш, белем алган булса, аңардан язучы чыгуы бик мөмкин. Әмма, иң кызыклы мәзәкне сөйләргә алынып та, аны рәтле-юньле сөйли белмәгәннән, сүзнең тәмен тоймаган кешедән язучы чыкмаслыгына иманым камил. Хет ун институт бетерсен, чыкмый аңардан язучы. Бөтен сүзлекләрне яттан белсен, барыбер чыкмый аннан язучы. Ул сүзне сүзгә акыл белән ялгап җөмлә төзи һәм җөмләсе чуртан балыгы сыман шома була: кулга эләкми — шуып төшә, ягъни мәсәлән, күңелгә ятмый.

Авылның көяз егетләре искә төшә. Алар маңгай чәчләрен бүрек астыннан чыгарып, бүрекне кыңгыр салып, илле градус салкын булса да, изүне ачып җибәреп клубка килеп керерләр иде. Сөйләшкәндә, җырлаганда да кыланып, сүзләрне юри бозып әйтерләр иде. «Сибелә чәчем» дип әйтәсе урынга «Сибелә сачем» диярләр иде. Чәчәк аларча «сачәк» булыр иде.

Мин аларның кыланганнарын аңлыйм, хәтта кыланчыклыкларын яратам да. Әмма язучы да үз эшен шулай «ясап» кылана башласа, ул көязлектән түгел, мескенлектән, телнең матурлыгын тоймаудан дип беләм.

Әйтик, безнең заманның яшь-яшь кенә язучысы тәэсир дип язасы урынга «Тәэссорат» дип язып куя. Янәсе, ул гади итеп язарга теләми, янәсе, ул күбрәк белә. Ә менә мин, укучы, ул язганны укыйм да күп белгәненә шаккатмыйм, киресенчә, кызганам. Чөнки «тәэссорат» дип аның «әсәре»ндә гап-гади авыл агае сөйләшә. Кыланып түгел, чынлап сөйләшә. Бактың исә, әлеге авыл агае, тәэссоратны түгел, тәэсир дигән сүзне дә әйтә микән әле. Мин үзем, мәсәлән, тәэсир дигән сүзне авылда ишеткәнем юк. Димәк, «тәэссорат»лы язучы иптәш телне тоймый, тоймый икән — аны өйрәтеп тә булмый.

Минемчә болай: теге яки бу яшь иптәшнең беренче кульязмасын укыганда аның теленә нык әһәмият бирергә кирәк. Телне тою сәләте юк икән иптәшнең, турысын әйтергә кирәк,— интекмәсен кеше, азапланмасын. Көчен бүтән нәрсәгә юнәлтсен, бәлки шунда аңардан шәп белгеч чыгар. Теле булмаган кеше образлы фикер йөртә алмый. Ә әдәбият — ул образлы фикерләү.

*Март, 1981*

## Баш кемнеке?

Парикмахерскаяга чәч алдырырга кердем. Яшь-яшь кенә чибәр бер кыз иңбашыма ак җәймә салды да:

— Ничек алырга? — дип сорады.

Чәчне заманча итеп алдырырга иде исәп. Яшь кыз бүгенге көн модасын миннән яхшырак беләдер дип уйлап:

— Үзегез теләгәнчә алыгыз,— дидем.

— Ничек инде ул мин теләгәнчә?

— Сезгә ничек ошый — шулай...

— Баш бит минеке түгел, сезнеке,— дип көлеп җибәрде кызыкай.

Чибәр кызыйның көлүе, әлбәттә, күңелгә хуш килде. Парикмахерская кебек

жирләрдә, дөресен әйтергә кирәк, һәрвакыт көлеп-елмаеп сөйләшәләр. Җае туры килгәндә яшь кызлар белән шаяртып сөйләшеп алу минем яшьтәге агайлар өчен үзенә күрә кечкенә генә бәхет.

— Юк инде, чибәркәй,— дидем,— бу очракта минем баш сезнеке. Йөрәкне әйтеп торасы да юк.

— Шаярмагыз. Әйтегез, ничек алыйм,— дип җитдиләнде кыз.

— Ә мин чынлап та шаяртмыйм. Баш сезнеке — теләсәгез нишләтегез. Миңа ничек тә ярый, чәчне мин кешеләргә ошар өчен алдырам.

— Кызык.

— Киенүем дә шулай. Үземә ялангач йөрсәм дә ярый, кешеләрдән оялып киенәм. Аларга ошар өчен матуррак киенеп йөрергә тырышам. Гомумән, бу дөньяда кеше кешеләргә ошар өчен яши.

— Дөрес түгел,— диде кызый.— Үз матурлыгыннан кеше үзе тәм табарга тиеш.

— Ялгышасыз. Кеше кешеләр арасында яши, шуңа күрә...

— Я, җитте, әйтегез... Клиентлар көтә.

— Мин сездән үтенеп сорыйм. Үзегезгә ошаганча алыгыз. Чәчне ничек йөртсәм миңа килешкәнен сез бит беләсез, мине күреп торасыз.

— Соңыннан миңа претензиягез булмасын,— дип кыз кайчы белән тарак алды да җилкә чокыры, колаклар тирәсендә берничә тапкыр чырт-чырт иттереп:— булды,— диде.

— Шул арадамы?

— Миңа шулай ошый,— диде кыз.

Нишлисең, кыз мин кушканны төгәл үтәде.

Чәч алдырганның тулы бәясен түләп чыгып киттем.

Мәзәк кебек кенә күренгән бу вакыйга соңыннан уйландырды.

Чыннан да, кем өчен кирәк безнең матурлыгыбыз? Кем өчен без иртән торып юынабыз, бизәнәбез, каш сызабыз, сөрмә тартабыз, сакал-мыек җибәрәбез? Әллә ни тамаша акча тотып, затлы, модалы киемнәр эзлибез? Алтын-көмешләр асабыз. Шуларны табу юлында талашабыз, хәтта җинаять эшләүгә чаклы барып җитәбез. Билгеле, һәрнәрсәнең чиге-чамасы бар. Ләкин...

Кеше кешеләр өчен яши. Бу — яшәүнең төп принцибы. Югыйсә, кешеләр җәмгыять булып яши алмаслар иде. Кешене кеше иткән нәрсә — аның бүтәннәр арасында яши алырлык акылы булуында. Кешеләр арасында кешеләр өчен кайгырып яшәү — кешенең рухи ихтыяҗы. Ә тышкы матурлык? Монысы, күрәсең, бәхәсле. Кешеләргә ошар өчен киенсәм, бизәнсәм, дөньядагы әллә ничә миллиард кешедә әллә ничә миллиард зәвык. Барысына да ничек ошап бетәсең? Үзең өчен генә тырышсаң, ни пычагыма ул бизәнү, киенүләр? Ни пычагыма һәр иртә саен кырынып мәшәкатьләнергә? Өч-дүрт көнгә бер кырынып яки бөтенләй кырынмыйча да рәхәтләнеп яшәп була ич. Ни әлекте шуны киеп тә йөреп була. Салкын үтмәслек булсын да, кызу сукмаслык булсын.

Гади генә булып тоелган сорауга төгәл җавап табуы шактый читен икән. Бәлки җавап эзләп мәшәкатьләнмәскәдер? Кешеләрне рухи яктан кеше иткән принцип булган кебек, аларның тышкы кыяфәтләре өчен дә аерым бер уртаклык, норма, калып, чик бардыр? Шул чикне үтсәң, кыяфәтең кешеләр өчен дә, үзең өчен дә ошамый башлыйдыр? Шулайдыр.

Шушы хакта мин язганда да уйланам. Минем язганнарым беренче очракта кемгә ошарга тиеш? Укучыларгамы, әллә үземәме? Күләргә ашыкмагыз. Аерым бер укучыларга ошарга тырышып харап булган язучылар бар. Укучылар, тамашачылар өчен язсак та, алар күп төрле. Барысына да ошап бетеп булмый. Язу иң элек үзеңә рухи канәгатьлек, ләззәт бирергә тиеш. Бүтәнчә язып булмый. Ә инде язганыңның бүтәннәргә ошавы-ошамавы синең кем булуыңнан тора. Әгәр син шәхес буларак бөтен икәнсең, кеше буларак бүтәннәр өчен кызыклы икәнсең, язганнарыңны да яратып укучы табылыр.

*18 июнь, 1981*

## Тәрәзә рамнары буяганда уйлану

Яңа төзелеп ята торган дачада тәрәзә рамнары буяп йөрим. Үзем уйланам. Ниемә кирәк инде бу дача, бу мәшәкатьләр, дим. Казан янында тактадан кадаклан-ган булса да дачам бар. Инде менә үз районымда, туып-үскән авылымнан ерак түгел (Идел ярында) бурап өй салып ятам. Нигә кирәк? Яшем дә инде шактый — дача өстенә дача салып йөри торган түгел. Өстәвенә өйдәгеләр бәйләнә. Нигә кирәк ул өй сиңа, диләр, акча туздырып, вакыт уздырып йөрисең, диләр. Без барыбер анда кайтмаячакбыз, дип тә җибәрәләр. Ә мин һичнигә карамый үзсүзләнәм. Кайберәүләр минем болай итеп, ягъни ныклы итеп өй, мунча, гараж төзетеп йөрүемнән этлек эзлиләр: төзеп бетергәч сатасыңдыр инде дип шаярткалаган булалар. Ә мин төзим: файдасы, зыяны турында уйламыйча дача салам. Нигә кирәк? Сәбәбен беркем дә белми, хәтта үзем дә белеп бетермим. Шуңа күрә, еш кына, «нигә кирәк?» дип уйланам.

Һәм, ниһаять, уйлана торгач, хикмәт әз-мәз ачыклана бугай.

Беренчедән, минем канымда ата-бабалардан калган төзү инстинкты яши ахрысы. Татарларда (башка халыкларда да шулайдыр) элек-электән йорт салып керү ирлек дәрәҗәсен билгеләгән. Йортка кергән ир-атка кимсетеп караганнар. Булдыксыз ирләрне «үзенә бер куыш та кора алмаган бәндә» дип мыскыллаганнар. Ир-ат үз гомерендә бер генә булса да өй салырга тиеш, дигән сүз әле дә ишетелгәли. Әлбәттә, хәзер заманалар үзгәрде. Урбанизация кешеләрнең психологиясенә тәэсир итми калмагандыр. Шәһәрдә туып үскән кеше өй салып йөрү турында башына да китерми. Чөнки ул инде әзергә бәзерне көтеп ятарга күнеккән: хөкүмәт квартира бирергә тиеш дип саный... Авыл җирендә дә (бигрәк тә эшчеләр поселогында) өй салырга ашкынып тормыйлар — анда да дәүләт төзеп бирә. Элекке крестьянлык традицияләре югала. Минеке, мин төзедем дигән нәрсәләр әкренләп юкка чыга. Ә миндә ул, күрәсең, яши. Мин төзедем дигән горурлык хисе канда нык сакланган.

Икенчедән, (монысы характерыма бәйледер) мин тик тора алмыйм, кайбер адәм балалары сыман онытылып ял итә белмим. Өйрәнмәгән. Язганда рәхәт: бөтен энергия чыгып бетә. Язылмаганда үземне кая куярга белмичә интегәм, эч поша, дөньяда яшәүнең кызыгы калмый, мәгънәсезгә яшимдер кебек тоела... Шуңа күрә, язылмаган чакта җанда тупланган тынгысызлыкны, канда җыелган адренолинны файдалы эшкә җигәргә тырышам — ни дә булса төзим. Ярый, мин инде олыгаям ди, бәлки бу дачаның рәхәтен дә әллә ни озак күрмәмен. Ләкин мин төзегән әйбер кала, аның рәхәтен кемнәрдер барыбер күрәчәк. Ул минем хезмәтемнең ниндидер нәтиҗәсе — мин дөньядан нәрсәнедер җимереп түгел, нидер төзеп китәм, шуның өчен мине сагынып иска алачаклар. Дурак дип көлүчеләр дә табылыр. Табылсын. Дурак диючеләр хәзер дә бардыр. Мине аңлаган кешеләр алай димәс. «Акыллы» булып трай тибеп йөргәнче төзим — нишлим, башкача булдыра алмыйм. Мин төзим һәм шуның белән рухымны ял иттерәм.

Өченчедән, язучы буларак, мин һәрвакыт төзүчеләр яклы. (Төзүче дигәндә русның «созидатель» дигән сүзен күз алдында тотам). Җимерүчеләрне хуплап беркайчан да бер юл да язмадым һәм язмам да. Гидайлар, мескеннәр, сукбайлар минем геройларым түгел. Алар турында язсам да, алардан көлеп, яки андыйларны кызганып кына язам. Язучының төп эше төзүчеләр турында язу дип саныйм. Һәр әсәрнең төбендә төзү, яңарту, яшәү идеясе ятарга тиешлеген белсәк тә, доганы кабатлаган кебек, көн саен шул турыда үзебезгә үзебез тукып торырга тиешбез. Юкса онытыла. Каһәр суккыры — төзүгә караганда тик тору җиңелрәк кебек тоела бит кайчакта. Төзегәндә «ниемә кирәк?» дигән сораулар туа. Тик торганда андый сорау тумый, акыл үшәнләнә, уйламый башлый. Үшәнләнгән акылга «һәй, дөньяда бер генә яшисе, типтереп калыйм» дигән «допинг»ны да өстәсәң, «прушшай Маручка!..»

Димәк ки, «нигә кирәк?» дигән куркыныч сорауны бирмичә, тәрәзә рамнарын буяп бетерергә кирәк. Менә эшләве рәхәт булып китте. Эх, шайтан алгырысы! Тәрәзә рамнарын буяп бетерәм дә иртәгә «Монда тудык, монда үстек»не язарга утырам. Язу сагындыра башлады. Кул эшләгәндә, баш ял итә ахрысы — җан да мәгънәсезгә бәргәләнүеннән туктап сафланып җитте. Нәкъ языла торган вакыт. Җырлыйсы

килә. Яхшы фал бу. Тавык та бит йомырка салып төшкәч җырлап-кытаклап җибәрә. Мин, әлбәттә, йомырка ук салмадым, бары тик тәрәзә рамнары гына буядым. Әмма барыбер.

*30 июль, 1981*

## Мунча ничә тәңкә?

Язучы өчен дөньяда вак нәрсә юк дигән идем. Бу хакта әле күп тапкырлар кабатланыр. Вак нәрсәләр артында кайвакыт шактый эре нәрсәләр ята. Менә бер мисал.

Өйнең техник паспортын укып утырам. Һәр нәрсә җирен җиргә китереп, тәртип белән тәфтишләп теркәлгән. Өйнең, мунчаның, «действительная стоимость»лары да куелган. Хәтта туалет белән койма да онытылмаган, аларның да бәяләре язылган. Шәп! Чү, тукта, ни бу? Буе 5, иңе 3 метр, бурап ясалган, бура белән икегә бүленгән, түбәсе шифер белән ябылган мунчаның «действительная стоимосте» 126 сум 70 тиен. Бер кеше кереп чүмәшерлек, тактадан ясалган туалетның бәясе 45 сум диелгән.

Минем өчен паспортта язылган бәяләрнең әһәмияте булмаганга башта кычкырып көлеп җибәрдем. Ничаклы надан булсаң да, бу ике санның аермасын күрми калып булмас иде. Бәлки җиргә бүген төшкән «ай кешесе» дә «монда что-то не так» дияр иде. Көлеп туктагач уйландырды, ачу килде. Юк, техник паспортны тутыручы Малафеева фамилияле ханымны ачуланмадым. Ул, күрәсең, ниндидер күрсәтмәләр, кагыйдәләр, прейскурант-фәләннәргә таянып тутырган паспортны. Хәер, дөресен әйткәндә, мунча белән туалетның ни икәнен ул да аерырга һәм очы очка ялганмаганны күрергә тиеш иде. Туалет турында сүз бармый — ярый, аның чын бәясе паспортта язылганга якын да булсын ди. Ә мунча? Бүгенге заманда 126 сум 70 тиенгә мунча эшләттем дисәң, я сине ахмакка, яки ата жуликка санарлар иде. Каян алынган ул бәя? Дәүләт исәбе беләнме? Чепуха! Агач материалларының бәясе күпме торганын дәүләт учреждениеләрендә утыручылар һәм ул бәяләрне куючылар белмиләрме? Күрәсең, белмиләр. Ниндидер искергән бәяләр буенча эш йөртәләр. Яки расценкалар идеаль шартлардан чыгып ясалган. Кайда ул идеаль шартлар? Авылдамы? Шәһәрдәме? Төзү материалларын исәпкә алмаганда да, эшләтү өчен генә 500 сум түләргә кирәк. Агачны ташыту, аның үз бәяләрен кушсаң, мунча дигәнең 800—900 сумга менә дә баса. Ярый, миннән артыгын алдылар ди, ләкин шул хәтлегә үк алдатырга шыр томана түгелмен ләбаса. Мин дөньяда яшим, сорашам, белешәм. Дәүләт оешмаларына мөрәҗәгать итәргә иде, төзү оешмалары 126 сум 70 тиенгә төзеп бирерләр иде, дисезме? Төзеде ди, төземи ни. Беренчедән, андый оешманы авыл җирендә табып булмый, тапсаң, 126 сум 70 тиенгә ул мунча салып бирәме? Ул оешмаларда да закон бар, расценкалар бар, алар расценкасы буенча мунчаның күпмегә төшәсен дөньяда яшәгән кешеләр белә. Димәк, кәгазьдә расценкалар бер, тормышта икенче. Аермалары адәм ышанмаслык.

Мин моны ни өчен язам? Мәсьәлә минем мунчада һәм аның бәясендә түгел. Мәсьәлә җитдирәк һәм куркынычрак. Бездә тормыш һәм кәгазьдәге язулар, кагыйдәләр, бәяләр арасында аерма зурайды. Тормышның ни икәнен белмәгән, яңа гына институт бетереп дәүләт учреждениеләрендә эшли башлаган мәскәүский, яки казанский, яки фәләнский «дендиләр» түшәмнән алып сан язып куялар да, без шул саннарга буйсынырга мәҗбүр булабыз. Мунча чепуха. Ә заводлар? Яки башка төзелешләр? Проект бәясе белән чын бәясенең туры килгәнен кемнең кайчан күргәне-белгәне бар? Проектта идеаль шартлар алына. Төзи башлагач, реаль чынбарлык якадан эләктерә. Китә сүгенү, китә гаеплене эзләү. Нәтиҗәдә... гаепле кеше табылмый.

Язучы тормышны белергә, өйрәнергә тиеш дигән нәрсәнең бер очы шушында да. Ниндидер иллюзияләр дөньясында яшәп, тормышны инструкцияләрдән генә укып өйрәнгән язучының әсәрен укучылар укый да мин мунча бәясеннән көлгән шикелле кычкырып көлә. Кычкырып көлү ул хәтле үк зарарлы түгелдер: алдашып язучыдан көлүнең гөнаһы юк. Ләкин тормышны белмәгән укучы тормышны бел-

мәгән язучының әсәрен укып: «Ә-ә, дөнья болай икән»,— дип куйса, шулай тормыш итәргә җыенса, монысы инде җинаять.

Язучының бурычларыннан берсе — тормышны белеп бетермәгән укучыны әдәби образлар аша тормыш чынбарлыгы белән таныштыру, үрнәкләр яки гыйбрәтләр белән аны тәбрикләү. «Кырларым-тугайларым» пьесасын караучыларның күбесе миңа рәхмәтләр әйтә, тормышны дөрес күрсәткәнсең, гыйбрәтле әсәр диләр. Ә Казаннан бер инженер һәм авылдан берәү (кайда эшләгәнен язмаган) «Социалистик Татарстан» газетасына Туфан Миңнуллин иптәш тормышны белми, исерек татар хатыннарын күрсәтә, андый исереп йөрүче татар хатыннары тормышта юк, дип хат язганнар. Җаннарым-бәгырькәйләрем, кая, кемнәр арасында яшисез? дип сорыйсым килә бу кешеләрдән. Бар шул, һәм, кызганычка каршы, аянычка каршы, шактый. Мин суд утырышчысы буларак хөкем залында 18—19—20 һәм өлкәнрәк яшьтәге алкоголик татар кызлары, татар хатыннары белән очрашам. Аларны күргәч, җаным җылый. Шул турыда әчынып яздым. Авылда аракы эчүче авыл апалары күбәйгәннән күбәя. Аларны күрми үтсәм, аларны юк дип йөрсәм, алар турында борчылып язмасам, мин мунчаны 126 сум 70 тиенгә бәяләүче ахмак бер кеше булыр идем.

*30 июль, 1981.*

## Халыклар дуслыгы

Без күп милләтле Совет дәүләтендә яшибез. Барлык милләтләр дә тигез хокуклы. Бу — Конституциябездә беркетелеп куелган.

Без, язучылар, әсәрләребезне язганда үз милләтебез белән генә чикләнеп кала алмыйбыз. Чөнки тормышта бүтән милләтләр белән көн саен аралашып яшибез. «Әдәбиятта халыклар дуслыгы» дигән төшенчә, димәк, юктан гына, кемнеңдер теләге, күрсәтмәсе буенча гына килеп чыкмаган. Ул тормышның үзеннән туган, ул — табигый. Халыклар дуслыгын сурәтләгәндә шул табигыйлык принцибыннан чыгып эш итәргә тиешбез.

Коры риторика, һәркемгә мәгълүм лозунгларны кабатлау — язучы эше түгел. Төрле милләтләрнең дуслыгын, ул дуслыкның чыганагын конкрет мисалларда тормышның үзеннән алу — безнең бурычыбыз. Ә андый мисаллар тулып ята.

Мин Кама Тамагы районында туып үскән малай. Татарлар һәм руслар районы. Әллә кайчаннан бирле бергә, кулга-кул тотынышып, ярдәмләшеп, кайгыларын, шатлыкларын бергә уртаклашып яшиләр. Аның шулай икәнен берничә мисал белән сөйләп бирергә телим.

Тенеш дигән авылның яртысы рус, яртысы татар. Берваксыт сабан туенда бер усал авылның усал егете Тенеш егетенә суга. Татарга татар суга. Кытә чәкәләшү. һәр ике егетне яклап ике егет ягыннан авылдашлары чәкәләшүгә катнаша. Ягъни Тенеш авылы белән теге усал авыл бәргәләшә. Тенеш авылының татары, русы бер булып усал авыл егетләрен тукмап ташлыйлар да бәйрәм итәләр. Янәсе, тимәгез безнең авыл егетенә. Мин монда зур мәгънә күрәм. Сабан туенда егетләнеп йодрыклар көчен сынашканда авыл даның яклаганнар, Бөек Ватан сугышында русы, татары, украины, казакъ, башкорт һәм башкалар, һәм башкалары бер булып ил даның якладылар. Кемнеңдер кушуы буенча түгел, йөрәк кушуы буенча. Димәк, милләтләр дуслыгы безнең илдә акыл дуслыгыннан йөрәк, хисләр дуслыгына әйләнгән. Язганда без моны онытмаска тиешбез. Әгәр теге яки бу язучы үз милләтен күккә чөеп, икенче милләт кешесенә тел тидерә икән, ул язучының намусына, вөҗданына шикләнеп карарга кирәк. Чөнки ул тормышның үзенә каршы бара, ялганлый.

Икенче мисал. «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасында Әлмәндәр белән рус карты Евстигней сәхнәсе бар. Анда ике дус очрашып гәпләшәләр, җырлар җырлыйлар. Шунысы кызыклы: Әлмәндәр русча, Евстигней татарча сөйлиләр. Мин моны уйлап чыгармадым, нәкъ тормыштан алып яздым. Хәтта Евстигнейның исемен дә үзгәртмәдем. Мин малай чакта әнинең әтисе ягъни бабай янына Антоновка авылыннан

Евстигней бабай килеп йөри иде. Кара-каршы утырып, бабай — русча, Евстигней бабай татарча «сыптыралар» гына иде. Нигә алай булгандыр — белмим, бәлки үзләренә шулай кызык тоелгандыр. Мәнә алар дуслар иде инчмасам. Бабайның үзебезнең авылдагы кешеләр белән алай рәхәтләнеп, җәелеп сөйләшкәнен хәтерләмим. Нидән килгән ул дуслык? Беренчедән, дошманлашырга сәбәп юк. Алар икесе дә эш кешеләре — иген игүчеләр, сөенечләре, көенечләре уртак. «Милләт мәсьәләсе»н куертып, көннәр буе коры сүз чәчеп утырырга аларның вакытлары булмаган. Икенчедән... Хәер, икенчедән дә, өченчедән дә сәбәп шул ук. Гади халык беркайчан да бер-берсеннән усал итеп көлмәгән, берсе икенчесенә кимсетеп карамаган. Үзен өстен итеп санаучылар һәрвакыт та тук корсаклар булган.

Революциягә чаклы халыкларны, политикага кушылып, дин дә аерып торган. Халыклар дуслыгын тагын да ныгытуга каршы диннең йогынтысы хәзер дә юк түгелдер. Әмма күптән түгел генә миңа кызыклы бер вакыйга сөйләделәр. Бөгелмә шәһәрендә булган бу хәл.

Бер карчык үз квартирасына дус-иш карчык-корчыкларны кунакка чакырган. Ничә еллар бергә янәшә квартирада яшәгән, бергә керешеп-чыгышып йөргән күрше карчыгын да чакырырга онытмаган, әлбәттә. Күрше карчыгы рус икән. Дөнья хәлләре сөйләшеп, ашап эчкәннән соң дога кылганда татар карчыклары кулларын мөселманча итеп амин тотканнар, рус карчыгы христианча итеп чукынган. Шундый табигый килеп чыккан бу гайре табигый хәл, берәү дә игътибар итмәгән. Димәк, мәсьәлә ничек итеп укыну яки чукынуда түгел, ә күңелләрнең бер булуында икән, син үзеңчә укы, мин үземчә укыйм, әмма укыганнарыбыз бер, теләкләребез уртак, күңелләребез бер булсын — монысы инде дуслык, туганлык билгесе. Безнеңчә итеп әйткәндә, формалары төрле-төрле, эчтәлеге бер әдәбият.

Көлсәң көл бу вакыйгадан, ышанмасаң ышанма, әмма ул булган хәл. Булмаганны уйлап чыгарып азапланганчы, шуларны күрә белергә кирәк. Менә шунда инде, без көн саен әйтә-әйтә шомарып беткән сүзләр бөтенләй яңа яктан ачыла, мәгънәләре тирәнәя, кадерләре арта. Үз күңелеңнең офыгы да киңәя төшә. Үз милләтеңне тагын да ныграк ярата башлыйсың, бүтән милләт кешесен ныграк хөрмәт итәсең. Үз милләтеңне ярату башка милләтләр бәрабәренә булмаска тиешлеген ныграк аңлыйсың. Язучыга бу бик кирәк, чөнки без — идеология хезмәткәрләре.

*29 август, 1981*

# Нәрсә ул җыр?

Җыр турында күп язылган. Аны тегеләй дә тикшергәннәр, болай да өйрәнгәннәр. Халык җырлары минем өчен — могҗизалы йомгак. Мин ул серле йомгакның очын эзлим — таба алмыйм. Тапсам, бәхетсез кеше булыр идем. Бөтен нәрсә дә (хәтта хисләр дә) фәнни аңлатылган, ачылган, шәрәләнгән бу заманда кеше өчен нинди дә булса сер калырга тиеш ләбаса. Җырның кеше күңелендә кай мизгелдә туганын төгәл белсәк, кызыксыз булыр иде. Менә тотам да тик торганнан җырлап җибәрәм. Нәкъ шул вакытта нинди җыр җырларга кирәген уйлап тормыйм — үзеннән-үзе җырлана. Көем дә әлләни түгел, беләм, әмма җырлыйм. Миңа җырның көеннән бигрәк сүзләре якын. Гап-гади, көн саен сөйләшеп йөргән сүзләр бер тәртипкә тезеләләр дә — җылата һәм юата торган җыр барлыкка килә.

**Сандугачлар гына күрде**
**Төшеп су алганымны;**
**Күрми дә калырсыз әле**
**Төшеп югалганымны.**

Нәрсә бу? Кеше күңеленең нинди хисләргә уралган чагында туган? Үлеп гашыйк булган бер егет моңлануымы, әллә үзе исән чакта кадерен белмәгән, хурланган,

җәберләнгән берәүнең ялгыз калгач сызлануымы? Бәлки моңлану, сызлану түгелдер? Киреснечә, шаярып җырлагандыр берәү — яңасе, ялындыра, үзенә күбрәк игътибар сорый.

«Кыска җырлар» дип аталган китаптагы бер җыр мине тетрәтте:

Иртән торып тышка чыксам,
Карпат тора каршымда.
Түбәтәй дип салган идем,
Картуз икән башымда.

Шушы дүртьюллык җыр әллә кайларга алып китте. Татар халкының үткән тарихындагы кайбер язмышлар күз алдыма килде. Тулы бер роман ята түгелме соң шушы дүрт юлда?

Тыныч кына җир сөреп, Миңлебикә яки Бәдриҗамал чибәргә гыйшык тотып йөргән авыл егетен патшага хезмәт итәргә дип солдатка алып китәләр. Өйләнеп, балалар үстерәм дигән хыяллары чәлпәрәмә килә егетнең. Авылдашлары, тиңдәшләре арасында телгә үткен булса да, русча белми икән егетебез. Менә аны туган-үскән җиреннән аерып еракка-еракка озаталар. Тау да тау. Карпат дип атала икән ул таулар. Таулар исә тауда яшәгәннәр өчен матур булсалар да, безнең егетебез өчен ятлар, шыксызлар. Солдат киеме дә шыксыз аның өчен. Әлбәттә, бер көн килер, егетебез русча өйрәнеп, шинель, картуз киеп авылга кайтыр, картузын кыңгыр салып, русча белгәне белән кызлар алдында мактанып йөрер. Ә хәзергә аңа ямансу. Төшләрендә авылын, сөйгән кызын күрә. Хыялында ул түбәтәен кыңгыр салып кыз янына килә. Түбәтәйне маңгайга төшереп, баш артына авыштырып, уң һәм сул якка чалшайтып кисә дә җайлы, үзенә килешеп тора. Татлы хыялын фельдфебельнең ят тавышы бүлдерә. «Гололобый! Чаплашка!» дигән сүзләрнең мәгънәсен аңламаса да, ямьсез сүзләр икәнен тоя егет. Ә башында — чигәләрне кысып торучы авыр картуз.

Бәлки кайберәүләр өчен бу җыр көлкедер. Анда-монда сугылып йөреп шомарып беткән зимагур өчен картуз булды ни, түбәтәй булды ни. Берсе дә булмаса да исе китми — яланбаш йөри. Аның җыры да бүтән. Иртән тапканын кич каба да чалкан ятып, күккә карап җырлап җибәрә:

Зимагурны шуннан таныйм
Каеш буган биленә;
Ашый калҗа, үбә марҗа —
Ник кайтсын ул иленә.

Хәер, кем белә, зимагур да бу җырны рәхәтләнеп җырламыйдыр, үзеннән-үзе көлүедер аның, моңаю, сагыну формасы шулайдыр.

Минем үземә зимагур түгел, картузын түбәтәй дип уйлаган егет якын. Аның җыры үзәкләрне өзә. Чөнки мин туган якларымнан еракка китсәм, ямансулыйм. Русча да ярыйсы гына сукалыйм, миңа «гололобый, чаплашка» дип кычкырынучылар да юк, ул сүзләрне әйтеп мыскылларга теләүчеләр очраса, җавап та бирә беләм, әмма туган ягымнан читтә миңа ямансу. Шундый чакларда туган якларын ташлап китәргә мәҗбүр булган, ностальгия чиреннән интеккән бабайларның җыры иска төшә:

Чәчәк идек илләрдә,
Сибелдек чит җирләргә;
Тагы да чәчәк булыр идек,
Кайтсак туган илләргә.

Җыр турында күп язылган. Тагын да язылыр. Минем өчен ул барыбер анализга бирелми торган, кеше күңеленең серле җимеше булып калыр.

*15 сентябрь, 1981*

# «Галиябану»

Бервакыт миңа бер егет үзе язган пьесаны укырга бирде. Укып чыктым — берни дә аңламадым. Шул турыда кулъязманың авторына әйттем. Егет бик канәгатьләнеп елмайды. «Аңламавыгыз табигый, Туфан абый, сез искечә язасыз, минем бу әсәрем яңача язылган»,— диде. Бу сүзләрен дә аңламавымны сизгәч, егетем миңа Ионеску, Сартрлар турында сөйләп китте. Мин Ионеску, Сартрларның кайбер әсәрләрен укыган булсам да, алар турында авыз тутырып сөйләрлек, бәхәсләшерлек дәрәҗәдә түгел. Мин «Галиябану»ны укып, карап үскән малай. Шул турыда әлеге яшь иптәшкә әйттем дә, егет кычкырып ук көлде. «Галиябану»лар заманы узды»,— диде. Ачуым чыкты. «Ә син, энекәем, башта «Галиябану»ны язып кара. Һәм синең язганыңны алтмыш ел буе миллионлаган кеше рәхәтләнеп карасын һәм үзе уйнасын, шул чакта сөйләшербез»,— дидем.

Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 90 ел тулган көннәрдә шушы сөйләшү искә төште. Теге егетнең яңача язылган пьесасын куйган театр юк бугай, ә «Галиябану»ны һаман уйныйлар. (Җәя эчендә әйтеп китим, бәлки егетебезнең пьесасы чынлап та яхшыдыр, гениаль әсәрдер, мин һәм минем кебек «искеләр» аңламаганга гына куелмыйдыр. Драматургиягә һәм театрга «яңалар» килгәч, куелыр. Амин, шулай булсын. Тик хәзер ул егет «искечә» яза.)

Ни өчен соң әле революциягә хәтле үк язылган әсәр бүген дә уйнала? Ничә буын үзгәрде бит инде. Спектакльне тәрҗемә белән генә карый торган татар малайлары һәм кызлары үсеп җитте. Алардагы хис безнекеннән үзгә, алардагы мәгълүмат безнекеннән күбрәк, әмма «Галиябану»ны карыйлар. Үзара сөйләшкәндә бәлки «ничего особенного, старинная вещь» дип әйтәләрдер, ләкин спектакльне карыйлар. Яңача язылган әсәрләрнең кайберләренә тамашачыны завком, фабком, местком аша мәҗбүр итеп китерәләр, ГПТУ малайларына, кызларына мәҗбүри культпоход оештыралар, ә «Галиябану»га тамашачы үзе килә. Нәрсәдә моның сере?

Мин, әлбәттә, әдәбият белгечләречә аңлатырга алынмыйм, шул хактагы кайбер фикерләремне генә язып куям.

Беренчедән, «Галиябану» — драматургия законнарының бөтен нечкәлеген белеп, тоеп язылган әсәр. Шуңа күрә ул зур ышандыру көченә ия. Әгәр әдәбият законнарына буйсынып, оста кул белән язылган булса, без язучының алдашуына да ышанабыз. Мәсәлән, Тукайның «Кисекбаш»ында Кисекбаш «Тимә хатынга!» — диеп бармак яный». Алдаша бит шагыйрь, күзгә карап алдый — соң инде, уйлап карагыз, кисекбашның бармагы буламы? Алдый безне Тукай, һәм без рәхәтләнеп алданабыз, алданганыбызны сизмибез дә. Чөнки кисекбаш безнең күз алдыбызга киселгән баш булып түгел, аяклы-куллы Кисекбаш булып килә. Тукай әдәби образ иҗат итә. Инде «Галиябану»га күз салыйк. Хәлил Галиябану янына килә. Тәрәзә аша сөйләшәләр, җырлашалар. «Сөюләрең чыннан булса, Галиябану, сылуым иркәм, тәрәзәңнән тартып ал»,— ди Хәлил. Галиябану Хәлилне тартып алмаса да, тәрәзәдән керергә рөхсәт итә. Ул замандагы урта хәлле крестьянның өен күз алдына китерик әле. Хәлил тәрәзә аша Галиябану янына керде ди, ә анда Бәдри белән Галиябануның әнисе Галимәбану да бар ләбаса. Әтисе белән әнисе янына егет кертте түгелме соң Галиябануыбыз? Моңа беркем дә ышанмый. Әйе, яза белеп язмасаң, ышанмый. Ә Мирхәйдәр Фәйзи ышандыра. Вакыйгаларның агышын шулай төзи автор, без аның «алдашуын» сизмибез. Безне Бәдри өенең зурлыгы, анда Бәдри белән Галимәбануның булуы кызыксындырмый, безне Галиябануның мәхәббәте кызыксындыра: кертерме ул Хәлилне, юкмы — менә кайда безнең игътибар. Мондый тормышчан булмаган «төгәлсезлекләр» пьесада еш очрый — ләкин без әсәрне ышанып кабул итәбез. Ышандыру көче тирәндәрәк, кешеләр характерының, аларның кылган эшләренең логик эзлеклелегендә, психологик төгәллектә. Моның өчен инде, яшь иптәш, «яңа» булу гына җитми. Моның өчен язучылык таланты кирәк. Ә талант искерми. Талант әдәбият законнарын баш белән генә түгел, күңел белән дә тоя. Бу очракта хәтта интуиция дигән сүзне куллану дөрестер.

Икенчедән, «Галиябану» — социаль әсәр. Үзәгендә егет белән кыз мәхәббәте ятса да, ул — татар халкының яшәешен, әхлак нормаларын дөрес бәяләгән әсәр.

Сафлык, гаделлек, турылык, горурлык кебек төшенчәләр беркайчан да искермиләр. Ә «Галиябану»да шуларга дан җырлана. Без Хәлилнең сафлыгы, шигъри күңеллелеге аша, Галиябануның горурлыгы, сафлыгы, турылыгы аша үзебезне тикшерәбез һәм тикшерәчәкбез.

Кайбер тәнкыйтьчеләр заманында әсәрнең социальлеген кулак малае Исмәгыйль һәм ярлы егете Хәлил арасындагы тигезсезлек аркасында туган конфликтта гына күрделәр. Пьесаны болай гына бәяләү, аны тарайтып, кечерәйтебрәк, күбрәк вульгар-социологизм күзлегеннән карау иде. Әлбәттә, әсәрнең тышкы интригасы шуңа корылган: Галиябану Хәлилгә буламы, Исмәгыйльгәме? Ләкин, әйткәнемчә, мәсьәлә тирәндә ята.

Пьесаны вульгар-социологизм карашыннан аңлау нәтиҗәсендә «Галиябану»ны сәхнәдә без гадиләштереп тә уйнадык. Кулак малае Исмәгыйльне кешедә булган табигый хисләрдән мәхрүм итеп схема ясадык. Исмәгыйльнең фаҗигасе тамашачыга барып җитмәде. Ул үтерәм, суям дип йөрүче җансыз манекенга әйләнде. Ә бит әсәрдә Исмәгыйль Галиябануны ярата һәм чынлап ярата, Хәлил кебек үк ярата. Ни өчен әле кулак малаенда мәхәббәт дигән хис булмаска тиеш? Ләкин шул замандагы тормыш шартлары Исмәгыйльнең җанын имгәнткән, аны бар нәрсәгә дә, хәтта бүтән кешенең мәхәббәтенә дә хуҗа булырга өйрәткән. Минә шушы ике арада бәргәләнә торган фаҗигале шәхес ул Исмәгыйль. Башкорт Академия театры, минемчә, Исмәгыйльне дөрес «уйнады». Мин үзем күргән спектакльләр арасында Галиябану образының трактовкасы белән риза түгел. Спектакльләрдә Галиябану чибәр, матур җырлаучы, тыйнак, ахырдан сентиментальлеккә барып җиткән кыз итеп сурәтләнә. Әлбәттә, Галиябану бу сыйфатларның барысына да ия. Ләкин Галиябанудагы горурлык, аның көчле характеры ачылып җитми. Нидән шулай? Аның мәгълүм сәбәпләре бар. Без мәкаләләребездә булсын, докладларыбызда булсын, татар хатын-кызларын изелгән, мескеннәр итеп күрсәтергә күнеккәнбез. Социаль хокуксызлыкны без әсәрләребездәге хатын-кызларның характерына да күчердек. Безнең хатын-кызларыбыз авызларын яулык чите белән томалап, почмакта посып утырган җан ияләре булып тасвирландылар... Бу — ялгыш караш. Татар хатын-кызы беркайчан да мескен булмаган. Социаль хокуктан татар хатыны гына түгел, бүтән милләтләрнең хатын-кызлары да мәхрүм булган. Социаль хокуксызлык белән характер мескенлеге — икесе ике нәрсә. Конституцион хокуксызлыкка баш имичә яшәгән татар хатын-кызларын аз беләбезме? Галиябану шундый көчле характерларның берсе. Ул яшәгән заманда тирәздән егет кертергә батырчылыгы җиткән кыз мескен буламы? Дөресен генә әйткәндә, Хәлил дә, Исмәгыйль дә Галиябануны «егетлеге» өчен яраталар. Бүтән кыз булса, Исмәгыйльнең исе дә китмәс иде бәлки, Галиябануның «егетлеге» Исмәгыйльнең җанын көйдерә. Социаль хокуксызлыкка каршы актив рәвештә баш күтәргән кыз ул Галиябану.

Хәлилне без, киресенчә, «молодец егет» итеп күрсәтәбез. Бу да дөрес түгел. Хәлил, минем аңлавымча, шигъри күңелле, йомшак табигатьле егет. Ул бары тик моңнан гына тора. «Молодец егет» булыр өчен аңа активлык җитешми. Галиябануны да ул урла мине дигәнгә генә урлый. Галиябану Хәлилне шигъри күңеле өчен ярата. Ләкин, йомшак табигатьле итәм дип, Хәлилдән «пешмәгән» малай да ясарга ярамый. Табигать аңарга моңны өеп биргән, ул дөньяны бары тик гадел итеп кенә күрә. Гаделсезлек белән очрашкач, ялгыша — алтатарны Исмәгыйль алдына ташлый.

Катлаулы пьеса «Галиябану». Шекспирның «Ромео һәм Джульетта»сы, Островскийның «Яшенле яңгыр»ына ничек сокланса, «Галиябану»ыбызга да шулай сокланасың. Ул безнең милли байлыгыбыз. Әлеге егет белән без искерербез, «Галиябану» һаман яңача яңгырар.

*20 октябрь, 1981*

## Мишәрләрдә кунакта

Күп җирләрдә булганым бар, күп кешеләр белән очрашып сөйләшкән бар. Мәҗлесләрнең дә төрлесен күрергә туры килде. Ә менә мондый мәҗлесләрне беренче күрүем. Бүтәннәр онытылган, болары, ахры, онытылмас.

Горький өлкәсендәге Зур Рбишча авылына кунакка алып кайттылар. Җиде йөз йортлы авыл. Өр-яңа мәктәбе бар. Мәчете һәм указлы мулласы да. Каралты-кура төзек, өйләр — алты почмаклы. Барысы да — шыгырдап торган нараттан. Хәзер кирпечтән сала башлаганнар. Авылда иң яшел, иң тәртипле урын — зираттыр. Кыш көне булуга карамастан күренеп, сизелеп тора. (Үлгәннәрнең кадерен белгәннәр генә исәннәрне хөрмәтли белә.)

Мине кунакка алып кайткан инженер Вәдүт Мөхетдиновның туганнары безнең хөрмәткә мәҗлес җыеп безне ашка чакыра башладылар. Өч өйдә кунакта булып өлгердек (Вәдүтнең әтиләре белән дүртәү). Дүрт табынга уртаклык — аш яки пилмән, бәрәңге белән ит яки пәрәмәч, аннан чәй. Пәрәмәч бу як өчен аеруча хөрмәтле ризык икән. Пилмән, пәрәмәчләр мине гаҗәпләндермәде — күргән бар.

Мине гаҗәпләндергән һәм аптырашта калдырганы — өстәл өстендә бер генә тамчы да аракы юк. Табынның уртасында күзләрне кызыктырып утырган аракы шешәләренә шулкадәр ияләшелгән, ризык белән тулы табын беренче карашка буш кебек күренә, мәҗлес күңелсез үтәр, эчпошыргыч булыр сыман тоела. «Очрашу хөрмәтенә» дип исәнлек-саулык теләшеп берәр чәркә күтәрмәгәч, мәҗлес була димени ул? Ашап карын туйдыру өчен нигә кунакка килергә? Валлаһи дип әйтәм, мин шулайрак уйладым. Юк, исерекбаш түгел мин, хәтта аракының зыянын, фаҗигасен үз күзләрем белән күргән кеше. Әмма мәҗлесне шешәсез күз алдына китерә алмыйм. Табынның бүтән төрлесен күргәнем юк иде.


Лакин, я хода, мәҗлесләрнең барысы да шундый күңелле үтте (мәгънәле булуын әйтеп тә тормыйм), аракысыз да яшәп була икән. Ни чуртыма дип эчәбез соң без аны? Кем өйрәтте безне бу «эшкә»?

Әнинең сөйләгәннәре искә төште. Егерме ничәнчедер елда безнең авылда бер туй булган, шунда беренче тапкыр туйда аракы эчелгән. Бер чирек (өч литр) аракы эчкәннәр туйда! Шул туйны мыскыллап бер ай сөйләгәннәр. Ә хәзер? Күпмешәр ящик аракы эчәбез? Ире-хатыны, баласы-чагасы, әбие-бабае, егете-кызы... Нишләвегез бу? Кем этәрде безне шушы әшәкелеккә? Кай арада бозылып өлгердек? Аракы катыштырмыйча әсәрләр яза алмыйбыз. Бу — табигый. Чөнки тормышны дөрес сурәтлим дисәң, аракыдан башка сурәтләү мөмкин түгел. Шунсыз укучы да, тамашачы да ышанмый. Нишләдек?

Рәхмәт, мишәр агайлар! (Агайлар гына түгел, яшьләре дә.) Сез минем күземне ачтыгыз, халкыбызның иң күркәм традицияләреннән берсен күрсәттегез. Безнең күптәнге традициябез бүгенге көндә әйтелә торган лозунгларга туры килә икән ләбаса. Без бүген аракыга каршы көрәшәбез. Дөрес, күбрәк сүз белән көрәшәбез. Ә сез — эш белән!.. Өйгә кайткач та нык уйландым бу мәсьәләдә. Мөмкин булган хәтле язган әсәрләремне аракысыз итәргә кирәк булыр. «Чуртсним» тормыш дөреслеге... Бүтән мәсьәләләрдә тормыш дөреслеге дип тормыйбыз — алдашабыз ич, нигә бу мәсьәләдә маташтырырга.

*1 декабрь, 1981*

# ҮЗГӘРДЕ РУХ, КИТТЕ ҖАН УЯНЫП...



*Бар телләрдән торган гаҗәп хорга*
*Кушыласым килә!*

...Җай гына агучы елгаларга да кискен борылышлар ясау җиңел бирелмидер. Ә иҗат лабораториясендә ниндидер реформа ясау үзенә күрә бер батырлык таләп итә, һәм аңа бары тик үзен-үзе җиңә алучы гына ирешәдер. Бүген мин әдәбият фронтында нәкъ менә шундый батырлык күрсәткән, үзенең үк сүзләрен файдаланып әйткәндә, «кысып торган ниндидер кыршауны ватып», «үз алласын җиңеп» чыккан шагыйрь Нури Арсланов иҗаты һәм шул уңайдан гомумән поэзия турындагы кайбер фикерләр белән уртаклашырга телим.

Шагыйрь Нури Арслановның иҗаттагы батырлыгын мин үз-үзен җиңә алуында, ягъни «үзгәрде рух, китте җан уянып», дигән сүзләрен чынлыкта исбатларлык көч табуда, вакыт сайланышында җиңүгә ирешүендә һәм, шулай итеп, галәмдә генә түгел, ә татар поэзиясе күгендә дә Арслан йолдызлыгы барлыгын раславында күрәм. Ә чынлыгын раслау, «үз сәләте югарылыгына» күтәрелү аңа җиңел бирелмәде.

Шагыйрь Нури Арслановның бер әсәрендә мондый «автобиографик» юллар бар.

**Таныдылар чынлап илле яшьтә,**
**Зурладылар фәкать алтмышта...**

Әлеге сүзләр авторының поэтик язмышын белмәүчеләрдә үзеннән-үзе шундый сорау туарга мөмкин: ни өчен ул илле яшендә генә таныла башлаган? Бер әдип әйткәнчә, «шагыйрьләрнең төрле сорты була». Бәлки, шагыйребез озаграк өлгерешле төргә керәдер?! Әдәбият дөньясында андыйлар да очрый ич. Күренекле рус шагыйре Иннокентий Анненский, мәсәлән, үзенең беренче китабын илле яше тулганда гына чыгарган. Ә үзебезнең балалар әдәбияты классигы Бари Рәхмәткә карагыз! Ул да бит нәкъ менә шушы яшьләрдә ачылып, балкып киткән. Юк, Нури Арслановның поэзиягә мәхәббәте соңарып уянмаган. Эш анда түгел. Ул инде биш яшендә үк үзе

гашыйк булган Нәфисәгә багышлап җырлар чыгара башлаган. Ә инде утыз яше тулганда каләмне үзенең төп коралына әверелдергән ул.

**Танылулар чынлап илле яшьтә...**

Шулай соңарып танылу сәбәбен шагыйрь, җиңелрәк хөкем өметн иткән гаепләнүчедәй, яшермичә үзе үк әйтеп бирә, кыю рәвештә турыдан-туры ярып сала:

**Шигырь дип алданып язганнарымны**
**Йомарлап ташладым — чыкканга такмак...**

Ни өчен шагыйрьнең язганнары такмак булып чыккан? Без кайчакта әдәбияттагы теге яки бу гомум житешсезлекне «чорның эстетик концепциясе»нә генә бәйләп аңлатырга яратабыз, «бередә шагыйрьнең гаебе юк» дигән төсле бөтенесен дә заманга гына аударып калдырабыз. Яшереп-нитеп торасы юк, аерым елларда безнең поэзиядә тормыш күренешләрен салкын кан белән генә иллюстрацияләүчеләр саны үсте. Күп кенә каләм ияләрен эзәрлекләүче менә шушындый чирләрнең сәбәпләрен без төрлечә аңлатып карыйбыз. Ә аның диагнозы бик гади, мондый елларда сәнгатьнең төп асылы — чынбарлыкны нәфис образлар аша чагылдыруы, дөньяны эстетик танып белү формасы булуы онытылыбрак киткән шикелле. Поэзиянең «үтмәс товарлары» белән танышканда, кайчак шулай да уйлап куясың: әллә Каюм Насыйриның беркайчан да искерми торган гап-гади киңәшләрен дә ныклап искә төшерүче юкмы соң? Ул бит болай язган:

«И угыл, әгәр шагыйрь булып шигырь әйтергә теләсәң, тырыш... Хыялсыз, тәртипсез, художествосыз шигырь сөйләмә. Метафора, чагыштыру, каршы кую һәм шуларга охшаган бик күп сурәтләү алымнары бар, шуларны куллан... Халык чәчмәдә сөйләү өчен начар дип исәпләгән сүзләрне шигырьдә сөйләмә. ...шигырь — әдәбиятның патшасы...»

Дөресен генә әйткәндә, без, угыллар, канунга әйләнергә тиешле әлеге таләпне, шигырьнең «хис белән җылытылган фикер», шагыйрьнең һәрвакыт уйлап табучы-рационализатор булырга тиешлеген бүген дә онытып җибәргәлибез.

Бүген дә поэзиядә сыйфат белән тиешле дәрәҗәдә идарә итә алмауны заманага гына сылтыйкмы? Сүз дә юк, иҗатчы үз чоры тенденцияләреннән читтә кала алмый. Әмма чын мәгънәсендәге олы талант иҗат юлында очраган шаукым һәм өянәкләргә бирелми. Әйтик, Хәсән Туфанның олы шигъриятендә төрле «изм»нар эзе бармы? Анна Ахматова, Александр Твардовский кебек шагыйрьләр иҗатында да көпшәк әсәрләрне бөтенләй диярлек очратмыйбыз. Заманны гына гаепләргә ярамый. Шагыйрьне беркем дә кулыннан тотып яздырмый.

Безнең поэзиядәге менә шушы «сөйләмчәклек» чире Нури Арсланов актив иҗат итә башлаган вакытта һәм хәтта илленче елларда да күзәтелде. «Хисләр эрозиясе»н кемнәр генә кичермәде? Бу чир кайбер талантлар иҗатына да үтеп керде. Алар арасында шагыйрь Нури Арсланов та бар иде. Нишлисең, халыкча әйткәндә, чирләү гаеп түгелдер. Иң әһәмиятлесе шул: мондый вакытлы күренеш шагыйрьдән мөтәшагыйрь ясый алмады, аны уртакул әдип итеп тә калдырмады! Талант җиңеп чыкты!

«Шигырь дип алданып» язганнарыңны инкарь итеп, «җан машинасы»н яңача кора алу һәм алга таба кискен бер сикереш ясау үзе үк фидакарьлек түгелме?! Ә беренче әсәрләрең буенча җәмәгатьчелек хәтеренә уелып калган фикерне үзгәртү һәм «атаклы исем гипнозы»на ия булу бәхетенә менә шундый иҗатчылар гына ирешә аладыр. Мин Нури Арслановның иҗат батырлыгын, әйтеп үткәнемчә, нәкъ менә шунда күрәм. Бик күпләргә менә шундый кыюлык җитешми. Әгәр иҗатта үз-үзләренә катгый хөкем чыгара алучылар күбрәк булса, әдәбиятка әллә нинди «алтын гасыр»лар килер иде! Юк шул, мондый егетлек бары тик көчлеләргә генә хас. Шул ук Пушкин кульъязмаларындагы сызып ташланган юлларга гына күз төшерик. Югыйсә бернинди дә җитешсезлек күренми шикелле. Ә шулай да аларны сызып ташлаганда шагыйрьнең куллары калтыранмаган. Безнең Такташыбыз да беренче әсәрләрен егерме ике яшенә кадәр яндыра барыр өчен үзендә көч таба алган бит.

Безгә мәгълүм булганча, Борис Пастернак та 1940 елга кадәр язылган әсәрләренә

үгисетеп карый башларга җөрьәт итә алган. Ә Сибгат Хәким... Аның үз-үзенә чыгарган хөкеме аеруча катгый: «...мин үзем дә иҗат гомеремнән алты-җиде елымны сызып ыргыттым». Үзе үк сызган да ыргыткан. Кайберәүләрчә, «шигырем — йөрәк итем» яки «бармакның кайсын киссәң дә авырта», дип, сызланып тормаган.

Иҗатчының үзе тарафыннан яндырылган яки сызып ташланган шигырьләр... Мин аларны һавадагы аэростатның тагын да югарырак күтәрелүе өчен ташлап калдырылган ком капчыкларына, җир орбитасына ыргылучы ракетаның янып юкка чыккан беренче буынына тиңлим. Вакыт дигән хөкемдар сызып ташлаганчы, үзен юкка чыгару зирәклек түгелме?

Нури Арслановның «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан «Моңсар» исемле иң калын җыентыгын укыганда шуны игътибарга алдым: андагы сайланмаларның иң зур күпчелеген шагыйрьнең илле яшьтән соң, ягъни танылгач язылган әсәрләре тәшкил итә. Аңа хәтле язылганнардан берән-сәрән генә шигырь кертелгән. Ә калганнарын автор нигәдер яңадан бастырырга теләмәгән. Бу бертомлыкта әдипнең 1942 елда язылган «Мәхәббәт» исемле беренче поэмасы да күренми. Ни өчен? Шагыйрь аларны, бәлки, сызып ташлагандыр?! Бәлки... Әйе, «язганнарымны йомарлап ташладым — чыкканга такмак», дип, тикмәгә генә әйтмәгәндер ул... Шагыйрь кичергән рухи үзгәрешнең асылы нидән гыйбарәт соң? Мондый борылыш, әлбәттә, үз сәнгатеңнең, шигъриятеңнең идея-эстетик кыйммәтен тагын да күтәрү максаты белән ясала. Әмма кайбер үзенчәлекләр турында әйтеп үтәргә кирәктер. Мәсәлән, һади Такташ поэзиясендәге борылышны, нигездә, идея эзләнүләре барлыкка китергән. Ә Нури Арслановның «яңадан тууы»н эстетик эзләнүләр белән аңлатасы килә. Сүз дә юк, рухи яңару аның дөньяга карашын да күпмедер үзгәрткәндер. Шулай да шагыйрь иҗатындагы төп үзгәрешләр нәкъ менә эстетик принципларны тирәнәйтү, сәнгатьчә фикерләү мөмкинлекләрен киңәйтү, кыскасы, поэтика камиллегенә ирешү юнәлешендә барды. һәм ул үзенең яңа «поэтик конституция»сен барлыкка китерде.

Булса синдә Әфләтүнның акылы,
Садәлеге керсез сабыйның,
Дәрвишлеге Хуҗа Насретдинның,
Исәрлеге Мәшрәп сафиның,
Телгә оста булсаң чичән кебек,
Уйга — йөгерек, дала атыдай,
Гаделлеккә Нәүширваннан гадел,
Юмартлыкта булсаң Хатәм-Тай...
Анда да син камил түгел, шагыйрь!
Җитми әле Хәйям касәсе,
һәрдәм тулы шатлык шәрабына!
Бар әле бар күкрәп-яшьнәсе,
Салават күпере салып күңелләргә
Коясың бар хисләр ләйсәнен,
Кирәк сиңа Мәҗнүн мәхәббәте
һәм илһамы гүзәл Ләйләнең!..

Син карванбаш нар дөягә охшаш —
Күпме йөкләр сиңа артыла!
Тик истә тот: иң мөкатдәс йөгең —
Тугрылыклы булу халкыңа.

Шагыйрьлек төшенчәсенә Нури Арсланов менә нинди билгеләмә бирә. һәм ул әлеге билгеләмәне мәкаләләрендә, интервью җавапларында, чыгышларында һаман сәен тулыландыра килә.

«Мин шагыйрь!» дип, күкрәк сугу бер дә килешми, чын шагыйрьне халык үзе танып ала. Шагыйрь элек-электән изге кеше, хикмәт иясе саналган. Иҗатың белән, яшәвең белән әнә шул исемне раслый алсаң гына син бәхетле»

«Эчеңдә ни яна, җаныңны ниләр борчый — фәкать шуны язарга кирәк!»

Юк, бу гади билгеләмә генә түгел, ә шагыйрьнең идея-эстетик карашларыннан

килеп чыга торган, газаплы эзләнүләр бәрабәренә табылган хакыйкать. Ул үзе нәкъ менә шундый программа буенча иҗат итә.

Мине бер сорау еш кына уйландыра: «кысып торган ниндидер кыршауны» Нури Арсланов ничек ватып чыга алды соң? Ә бит башыңнан югары сикерер өчен кемнең дә булса ярдәм итүе кирәк. Шагыйрь иҗатының кискен рәвештә сыйфат үзгәреше кичерүен, бәлки, «чорның эстетик концепциясе»нә бәйләп аңлатыргадыр?! Кешелек ирешкән идея-эстетик концепциянең бүгенге дәрәҗәсен, аерым алганда, хәзерге заманның сәнгатьчә фикерләү казанышларын тирәнтен өйрәнгән һәм үзләштергән шагыйрь генә иҗатта рекорд булырлык сикерешләр ясарга сәләтле. Ә хәзер Парнаска күтәрелү, иң биек пик Эверестка яңа юл яру кыенлашкан шикелле, һаман саен авырлаша бара. Эйе, «Заман таләбе»н Нури Арсланов та бик яхшы аңлыйдыр...

Ат аягына тай басар, дигәндәй, Нури Арслановның яңача ачылып китүе, күпмедер дәрәҗәдә татар поэзиясенә көчле агым булып «яхшы һәм төрле» шагыйрьләр килүгә дә бәйләнгән. Бу да уйлап баксаң, «чорның эстетик концепциясе»ннән килеп чыга. Үзеңнән бер көн элек туганнан акыл сора, дип халык. Ә Нури Арсланов, менә киресенчә, бүгенге заман мәктәбендә тәрбияләнгән яшьләрдән дә өйрәнүне кирәк тапкан. Мондый якынлыкка аны «Казан утлары» журналының поэзия бүлегендә озак еллар буе эшләве дә этәргәндер. Яшьләрдән үрнәк алуын шагыйрь үзе дә яшерми:

«Соңгы биш-алты ел эчендә... бик күп талантлы, өметле һәм җитди яшьләребез әдәбиятның киң һәм изге мәйданына кыю адымнар белән килеп керделәр. Аларның һәркайсының бер дә кабатланмаган үз җыры, үз моңы, үз авазы бар. Мин бу яшь шагыйрьләребезгә карап шатланам да, сокланам да. Алар безнең хакта ни уйлыйлардыр, ә менә миңа аларга карап үз тулпарымны еш чыбыркыларга туры килә».

«Яшьләрдән дә өйрәнү кирәктер, күрәсең. Аларда — дәрт, миндә — тәҗрибә. Менә шулар акрынлап икесе бергә кушылды».

«...шул сәләтле яшьләргә тәрбияче вазифасындагы кешегә — миңа алардан калышырга да ярамый иде, әлбәттә».

Ә, бәлки, Нури Арсланов иҗатының үзгәреш кичерүенә безнең тәнкыйтьчеләребез сәбәпчедер? Дөресен әйтик, элегрәк елларда Нури Арсланов иҗатын анализлауга багышланган мәкаләләр, нигездә, юбилейлар уңаеннан гына язылган. Ә юбилей язмаларының күбесе, гадәттә, дифирамб рухында була. Иҗади ел йомгаклары яки аерым проблема уңаеннан язылган кайбер мәкаләләрнең авторлары да Нури Арсланов иҗатына карата гомуми бәя генә сылап үткәннәр. Әмма күзәтүләрдән үз исемеңне эзләп табу гына шагыйрьгә әллә ни иҗат стимулы китерми шул...

Шулай да кинәт күтәрелә алуның иң яшерен серен, объектив сәбәпләрне инкарь итмәстән, шагыйрьнең үзеннән эзләргә кирәктер. Төп хикмәт анатомик-физиологик талант мөмкинлекләрендә һәм иҗатка мөнәсәбәтнең нинди булуында тора. Ә талант төрлечә ачыла. Җир астындагы хәзинәләрнең ачылуына да менә шундый төрлелек характерлы. Прогнозчы да ялгыша. Перспективасыз саналган чыганак көтмәгәндә үзенең исәпсез-хисапсыз байлыкка ия булуын күрсәтә. Шагыйрь Нури Арсланов талантында да ачылырга әзер торучы нәкъ менә шундый потенциаль ресурслар булгандыр. Һәм үз-үзеннән канәгать булып яшәргә теләмәүче, «Берәүләр бик ризалар үз-үзеннән, Ходаем, шул бәладән калчы саклап!» дигән сүзләрне кат-кат кабатлаучы, бөтен талантын тулысынча бер максатка туплый алучы иҗатчының рухи эзләнүләре буылып яткан шушы чишмәләрнең кинәт бәреп чыгуына китергән. Һәрхәлдә, шулай фараз итәсе килә.

Сәһел бине Һарун әйтте: «Каләм — күңелнең борыныдыр, кайчан канаса, серләрен чәчәр, әсәрләрен атар». Халык телендә йөри торган әлеге сөйләктә сүз художниклары иҗатының асыл сыйфатын чагылдыручы гаять тирән мәгънә бар. Исбатлап торасы да юк, үз-үзеңне кызганмыйча, янып-көеп иҗат иткәндә генә чын сәнгать әсәрләре туа. Борчылулар һәм тетрәнүләрсез гомер кичерүләрдән чын шагыйрь чыга аламы соң?! Шагыйрь Нури Арслановның иҗат үсешен күздән кичерү шундый нәтиҗәгә китерә: әлеге хакыйкать аның аңында һаман саен тирәнрәк урнаша бара. Олы сәнгатькә таба борылыш ясау сәбәпләре дә шактый дәрәҗәдә менә шушы хакыйкатьне аңлауга бәйләнгән. «Чыгам җимле, җайлы аранымнан, Далаларга иркен суларга!» «Шагыйрь чыгырдан чыга,— Шунда шигырь дә чыга». Бер матур таңда шагыйрь әнә нинди катгый фикергә килгән.

**Гамьсезлектән җырлый диләр мине,**
**Гамьсезгә соң җыр-моң ни аңа!!**
**Эчендәге сагышлары кушкач,**
**Җырлый башлый миндәй дивана.**

Чын шагыйрь менә кайчан җырлый башлый! Художник кулындагы каләм менә шундый халәттә генә «серләрен чәчәр, әсәрләрен атар!» Бөек рим шагыйре Гораций сүзләрен кулланып әйткәндә, «уртакул» уңышларга түзеп тора алмаучы» поэзия менә нинди юлдан барырга тиеш.

**Ил кайгысын бөек кайгы итеп,**
**Башын салган ата-бабамнар.**
**Дөрес иттем шул юл белән китеп**
**Мин, сагышлы, көләч ватандар.**

Халык язмышы — шагыйрь язмышы. Без бер-берсенә тыгыз бәйләнгән әлеге төшенчәләрне бик еш кабатлыйбыз. Чөнки бу төшенчәләрдә — искерүне белмәүче хакыйкать, шагыйрьлекне билгеләүче төп асыл сыйфат. Шагыйрь Нури Арсланов та, Идел төбендә агып ятучы чишмәдәй, үз язмышын халык язмышы эчендә күрә. Ә халык язмышы тоташ бәйрәмнәрдән генә тормый. Бүгенге катлаулы дөньяда исә халык язмышыннан читтә яшәү җинаятькә тиңдер. Хәзерге заманда «Кошны азык белән, кешене сүз белән аулыйлар» дигән мәкаль тагын да актуальрәк яңгырый шикелле. Сүз сәнгатендә дезертир булырга ярамый.

**Кыл өстендә тора бөтен язмыш,—**
**Я тәрәккый, яки бөлгенлек...**
**Чын хуҗа бул, Кеше, планетаңа! —**
**Син хәлифә түгел бер көнлек.**

Зурдан кубып фикер йөртүче шагыйрьнең борчылулы уйлары «урынчылык» чикләрендә генә калмый. Поэтик гомумиләштерүләр халык язмышыннан — кешелек язмышы, Ватан язмышыннан Җир язмышы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә! Минем уйлавымча, Нури Арсланов кордаш каләмдәшләре арасында дөнья масштабында фикерли алуы белән дә аерылып тора. Бу уңайдан аның соңгы елларда язылган публицистик шигырь циклларын гына искә төшерегез. Публицистика, дим, чөнки шулай әйтергә нигез бар. Соңгы вакытта Нури Арсланов иҗатындагы публицистик башлангыч көчле үсеш алды. Бу — табигый күренеш. Үсә баручы политик һәм гражданлык активлыгы, халык алдында үзеңне җаваплы итеп тою, дөнья язмышы өчен борчылу шагыйрьне үзеннән-үзе публицистик юнәлештәге тирәнәюгә этәрә. «Иҗтимагый»... «Публицистика» сүзе латинча әнә шундый мәгънәне аңлата. Ә үзен Ватанның көрәшче-гражданины итеп санаучы шагыйрь «...саф, коеп куйган поэт кына түгел, ...дипломат, политик, общественный деятель дә» булырга тиеш.

Бу очракта шагыйрь музасының публицистик аһәңе көчәюен икенче төрле дә аңлатып була. Публицистик поэзия үзенең табигате буенча вакыт эчтәлеген эмоциональ рәвештә генә түгел, ә социаль һәм философик призмадан карап концентрацияләүне таләп итә, һәм ул статик тасвирчылыкны кире кага. Ә «сөйләмчәклек»тән ваз кичкән шагыйрь иҗатында публицистик ноталарның күбәюе, димәк, көтеп алынган хәл буларак кабул ителә. Күңелле күренеш. Әмма шуны истән чыгармаска кирәктер: публицистик поэзия өлкәсендә эшләүчеләрне милли җирлектән аерылу куркынычы сагалап тора. Бездә шундый «космополитик» әсәрләр дә очраштыргалый: аларның «милләтен», «туу урынын» берничек тә белеп булмый. Ә үзләрен татар шагыйре язган. Бу сүзләр Нури Арслановның «Атлантида» кебек кристалл шигырьләренә кагылмый. Әлеге әсәрдә татар публицистик поэзиясенең чын үрнәге гәүдәләнгән. Әйтик, Сибгат Хәкимнең Җир орбитасына чыгып язылган «Әзлиләр Европа буйлап» исемле яңа поэмасында да милли җирлектән аерылу күренми. Мин бу әсәрне беренче мәртәбә радио аша рус шагыйре укыганда тыңладым. Көтмәгәндә-уйламаганда Поэтик юлларның авторын да ишетергә өлгерә алмадым. Һәм радиоалгычның Казан

яки Мәскәү дулкынына көйләнүенә дә игътибар итмәдем. Әмма поэманың татар шагыйре тарафыннан язылуы кычкырып тора, һәм монда «Фәләнneke булуы ихтимал шигырьләр», дип, икеләнеп торырга да урын калмый: авторы һәм милләте шунда ук телгә килә.

Бөтен дөньяны колачлаучы публицистик поэзиядә сәнгатьчә конкретлылыкка ирешүдә татар шагыйрьләренә әле шәхси тәҗрибә җитенкерәми шикелле. Ә дөнья турында язар өчен дөнья күрү кирәктер. Тик менә без чит илләргә чыгарга бик ук ашкынып тормыйбыз. Ә шагыйрь Байрон бу мәсьәләгә карата бөтенләй башка мөнәсәбәттә торган: «Кешелек турындагы үз фикереңне китаплар буенча түгел, шәхси тәҗрибәң буенча тупларга». Һәм ул үз вакытында Якын Көнчыгыш, көньяк Европа илләренә сәяхәткә чыгып киткән...

«Бер елны мин «Победа» корабында Кара диңгез буйлап сәяхәткә чыктым. Язмышның көлүен кара син! — минем каютам кайчандыр Гитлер сайлаган люкс булган икән...»

Менә бит, хәтта шундый юлларны язу өчен генә дә шагыйрь Нури Арслановка сәяхәткә чыгу кирәк булган. Күпме тәэсирләр! Соңыннан шигырьгә әвереләчәк күпме нюанслар!.. Шагыйрьнең дөньяга карашын киңәйтергә, язганнарның ышандыру көчен арттырырга ярдәм итүче мондый сәяхәтләр тагын да күбрәк булсын.

**Күрергә ерак Япон утрауларын,**
**Сокланырга карап Париж таңнарын,**
**Иңләргә бер Шотландия ярларын...**

Әйдә, татар шагыйре дә Җирне бер итеп йөрсен, тик «Кайда барсам да үз туфрагымда Атлап йөргән кебек хис итәм!» дигән юлларына һәрвакыт тугрылыклы булып калсын.

Сүз җаеннан тагын бер фикерем белән уртаклашып узасым килә. Бу күзәтүем Нури Арслановның кайбер поэма, әкият һәм легендаларына кагыла. Хәтерлисездер, шагыйрьнең рус, белорус, казакъ, бурят, корея, тау халыклары, кырым, Ерак Көнчыгыш әкиятләре һәм легендаларына таянып язылган күп кенә әсәрләре бар. Менә шулар белән танышканда, китап битләре читләренә кайбер сораулар язмак буласың. Чәчмә фольклор үрнәкләрен «тар шигырьләр үлчәве»нә сыйдыруның кирәге бармы? Башка халыклар иҗаты казанышларын үзәккә алып язылган әсәрләр халыкчанлык принципларына туры киләме? Минемчә, халык иҗатын интерпретацияләүгә кагылышлы әлеге сораулар буенча җиң сызганып сүз көрәштерергә була. Үзе бер сөйләшү. Әмма хәзергә Максим Горькийның мондый сүзләрен искә алу белән чикләнсәк тә җитеп торыр шикелле: «Мин татар язучыларыннан кайбер иптәшләрнең әсәрләрен укыганым бар. Алар үзләренең татар язучылары икәнлекләрен онытып ялгыш итәләр. Татар тормышына хас булган специфик моментларны художество сурәтләүләре аркылы күрсәтү, формасы белән милли, эчтәлеге белән советчыл булган татар әдәбиятын тудыру, сыйнфый әдәбият аркылы татар тормышы белән бөтен дөньяны таныштыру татар язучыларының төп бурычлары».

Халыкның шундый әйтеме бар: арслан картайса, тычкан өнен күзәтер. Әмма бу мәкальнең мәгънәсе Нури Арслановның поэтик язмышына туры килми. Бу хакта ул үзе дә искәртеп уза:

**Ә картайгач: «Бу яшәгән саен**
**Гел яшәрә бара!» — диделәр.**

«Илле яшьтә танылган» Нури Арсланов, «Бәйгеләрнең зуры алда әле. Аз вакытта күп юл үтәсе», дип, поэтик язмышын хәл итә торган яңа һөҗүмгә күчте.

**Менгән атым баткан ак күбеккә,**
**Белмим, һаман кая чабамдыр!!**
**Привал кирәк иде инде күптән,**
**Әйтерсең лә**
**Егет чагым белән чамам бер...**

Икенче сулышы ачылган шагыйрь, ал-ял белмичә, рухи хәзинәләрен мөмкин кадәр күбрәк чыгарып калдырырга ашкына. Ә цейтнот кыса. «Аз гомердә күп тәрәккый тели күңеле...» Уй-кичерешләр дәрьясы, әле генә ерып җибәрелгән буа шикелле, киңәеп-тирәнәеп киләчәккә ага. Киләчәккә!.. Шагыйрьнең танылуга ирешә алуы — вакыт сынавын уңышлы уза баруы түгелме?

Адәм сөйләр, тормыш көләр. Кайчак шигырь-ачышларга да Вакыт «патент» бирергә ашыкмый. Шулай да ул гадел хөкем итә. Галиҗәнаб Вакыт кешеләргә хас симпатия һәм антипатияләрне танымый. Шагыйрь гомере җирле вакыт белән түгел, ә Кояш вакыты белән билгеләнә. Кайчандыр «Тукаев шагыйрьме, түгелме?» диган сорауга «Буңа биреләчәк җавап төрлечә булырга мөмкин», дип икеләнү белдергәннәр. Ә менә Вакыт әлеге сорауга катгый төстә бердәнбер җавабын бирде. Әллә нинди матур исемнәр онытыла, ә билгесез шагыйрьләр һаман да яши.

Поэтик язмышлар... Бер язмыш икенчесенә охшамый. Алар гомер озынлыклары буенча да бер-берсеннән аерылып торалар. Вакыт бирәүләр өчен мәрхәмәтле, икенчеләр өчен... Гаять зур иҗат потенциалына ия булган рус шагыйре Дмитрий Веневитинов, мәсәлән, тулысынча ачыла алмыйча 22 яшендә үк үлеп китәкән.

Ә Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар шагыйрьләреннән Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Әгъзам Камал, Мансур Гаяз, Касыйм Вахит, Мифтах Вәдүт... Аларның иң яшенә 23, ә иң өлкәненә 27 яшь кенә булган. Ярты лаш та ачылмыйча янган чәчәк бөреләре!.. Менә бит ул Вакыт һәм Язмыш рәхимсезлеге! Кайчак шундый уйлар да килә: шәһит киткән талантлар бөтенләйгә юкка чыкмыйлар, ә «яңадан туган» Нури Арсланов кебек шагыйрьләр җанында берәм-берәм ачыла баралар. Мондый «стратегия» белән, әйтерсең, халык үзе җитәкчелек итә, һәм ул үзенә резерв итеп Вакыт тарафыннан сыналган ышанычлыларны гына сайлый.


«Эх, туасы иде яңадан бер мең елдан соң...» Шагыйрь Нури Арслановның бу теләге, вакытны уза алу сәбәпле, бик алдан чынга ашты. Ә бер үк шәхестәге ике «мин», ике «шагыйрь» көрәше яшәү өчен көрәшүгә тиңдер. «Бар булыргамы, юк булыргамы?» Талант җиңде: Нури Арсланов Поэзиядә барлыгын батырларча раслауга ирешә, һәм шагыйрь ир-егетләрчә әйтелгән сүзенә бүген дә турылыклы:

**Мәйдан тотсам — исемем генә түгел,**
**Бөтен рухым, җисмем арслан!..**

**ЗИННУР МАНСУРОВ.**

*«Казан утлары» журналы үзенең битләрендә балалар әдәбияты әсәрләренә һәрчак киң мәйдан биреп килде. Менә бу санда да редакция балалар әдәбиятына махсус бүлек багышлый. Укучылар аның белән кызыксынып танышырлар дип уйлыйбыз.*

# САБЫЙЛЫКТА КУНАКТА




Антология. Грек сүзе. Антос — чәчәк. Лего — җыям. Физик һәм акыл ягыннан камиллеккә омтылучы борынгы эллиннар шигъри җанлы да булганнар икән. Поэзия җәүһәрләрен туплаган җыентыкларына нинди гүзәл исем тапканнар. Гади генә китап түгел, берничә шагыйрьнең әсәрен туплаган гадәти җыентык кына да түгел, болын чәчәкләре кебек төрле-төрле, матур-ачык төсләргә бай, шигъриятнең иң яхшы үрнәге дип саналырлык әсәрләрдән торган китап. Шуны укып, мин чәчәк җыйган кебек булам, рәхәт табам, хозурланам диясе килә.

Андый антологияләр, кагыйдә буларак, тарихы тирәннән килгән, традицияләргә бай олы әдәбиятларның күрке була. Шуның өстенә, теге яисә бу халыкның культура дәрәҗәсен билгели торган бер билге дип тә карарга кирәктер аңа.

Моннан берничә дистә ел элек республикабыз китап нәшрияты «Татар поэзиясе антологиясе»н чыгарып шигърият сөючеләрне шатландырган иде. 1980 елда «Татар балалар поэзиясе антологиясе» басылып чыгу да әдәбият дөньясында зур вакыйга булды.

Милли орнаментлар белән бизәлгән, шома ак кәгазьгә басылган, зур форматлы бу калын китапны кулга алгач, һәркем үзенчә бер хис кичергәндер, тик аны берәү дә салкын кан белән генә актарып калмагандыр. Әкияттәге сихри йомгак кебек алып кереп китә дә ул сине, еллар һәм юллар буенча йөртеп, күп нәрсәләр хакында уйлата. Иң элек син үзеңнең бала чагыңа кайткандай буласың, аның сихри гүзәллегенә биреләсең. Әнгер-меңгер иңгән җылы, җәйге кич хәтергә килә. Учак төтене, яңа сауган сөт, төн гөлләренең исе аңкыган урамда бала-чага чыр-чуы. Эш бетереп чыккан агайлар бер җирдә гәп корып утыра, икенче берәүнең капка төбендә әниләр-апалар җыены. Әбәкле уйнап арыган сабыйлар, тыннары бетеп, яшел чирәм өстенә килеп утыралар да, берсеннән-берсе уздырып такмак әйтергә тотыналар.

— Песи кая барасың?
— Әбиләргә барамын.
— Анда сиңа ни тия?
— Ике кадак май тия.

Антологияне ачып җибәргән бик борынгы һәм мәңге яшь халык авыз иҗаты. Мәхәббәт кебек ул да «...үзе иске нәрсә, һәрбер буын аны яңарта». Кулымдагы шушы китапка шигырьләре кергән барлык шагыйрьләр үзләренең яшьтәшләре кебек үк, шул уеннарны уйнаганнардыр. Әле бездән соң киләчәкләре дә табышмаклар әйтешеп, әкиятләр тыңлап үсәрләр. Тик аларның уеннары да, табышмаклары да башкачарак, үз заманнарына ятышлырак

булыр. Ул заманның халкы үз авыз иҗатын тудырыр, алар башка антологияне ачып җибәрерләр. Буыннардан буыннарга килгән борынгы үрнәкләр дә шунда урын алыр.

Шигырьләрне укыганда, онытыла язган әйбәт, иске танышыңны очраткандай, тагын бер сөенеч кичерәсең. Бала чакта күп ишеткән, укып ятлаган, әдәбият дәресләрендә сөйләп күрсәткән һәм менә ничә дистә еллар инде кабатлап басылмаган шигырьләр белән очрашу ул.

**Урамда буран,**
**Мин өйдә торам.**
**Тәрәзә аша**
**Тик авыз ерам...**

Әле бу кышны гына да ике яшьлек оныгым белән тышта котырган буранны карап утырганда шушы юллар күңелемә килгән иде. Ул чагында моның авторы кем соң әле дип уйланмадым. Антологияне укыганда игътибар иттем, бик әйбәт прозаик булып хәтердә калган Гомәр Толымбайның шигыре икән ләбаса. Яки менә:

**Яфраклары яшел ак каенның**
**Хәтфә җәйгән кебек һәр ягы,**
**Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,**
**Шаулап тора һәркөн тау ягы.**

Мәктәп залларында, бәйрәмнәргә әзерләнгән чакларыбызда зәгыйфь кенә тавышларыбыз белән җырлый идек бу җырны. Авторы Зыя Ярмәки турында бернәрсә белмәсәк тә, сүзләре хәтердә калган. Еллар тузанына күмелә язып югала барган шигъри җәүһәрләрне бәрәмтекләп җыю һәм укучыга күрсәтү ягыннан да кыйммәт икән бу антология.

Сәламәт кешедән сәламәт бала туа дигән сүз бар. Бу акыллы фикерне әдәбият дөньясына күчереп карасак та шулай. Тамырлары тирәннән килгән көчле зур әдәбиятлар куенында үзәктән таза, нык булып, балалар әдәбиятларының да күтәрелүен күрәбез. Ана сөтеннән көч алган сабый кебек ул да олы әдәбияттан куәт алып үсә, ныгый, шуның хисабына туктаусыз тулыланып тора. Аның мөстәкыйль иҗат итүче, хезмәтләрен гел балалар әдәбиятына гына багышлаган язучылары да була булуын. Әмма, барыбер, теләсә генә нинди илнең, теләсә кайсы халыкның балалар әдәбиятына, күбесенчә, олы әдәбиятның иң алдынгы вәкилләре нигез салган. Алар бу әдәбиятны сан ягыннан гына үстереп калмаган, жанр һәм форма төрлелегенә, идея эчтәлегенә, фикер тирәнлегенә дә юнәлеш биргәннәр. Балалар өчен бер генә юл булса да әсәр язмаган классик язучы дөньяда юктыр ул, булса да бик сирәк булыр.

«Татар балалар поэзиясе антологиясе»нең дә үзәгендә Г. Тукай, М. Җәлил кебек олы шәхесләр иҗаты тора. Шуның белән бергә, М. Гафури, һ. Такташ, Х. Туфан, Ф. Кәрим, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, С. Хәким, Н. Арсланов кебек шагыйрьләр иҗатына зур урын бирү дә сөендерә. Иҗат байлыклары, үткән тормыш юллары белән гаять кызыклы, олы буын шагыйрьләр алар.

Билгеле, татар балалар поэзиясе бу антологиягә кергән авторлар белән генә чикләнмидер. Бигрәк тә аның элеккерәк чоры, «Татар шагыйрьләре» дигән бүлеге саранрак бирелгән, азрак өйрәнелгән кебек тәэсир калдыра. Шулай да, җыйналган кадәресен генә күзәтеп чыкканда да, аның үсеш юлларын күзалларга мөмкинлек туа.

Антологиянең икенче бүлеге XIX йөз ахырларында иҗат иткән шагыйрьләр белән башлана. Бу шигырьләрдә күбрәк табигать күренешләрен сурәтләү — таң ату, яз көннәре, гөрләвекләр агу, туган авыл һ. б. матурлыгын күрсәтү яки балаларны эшкә, укырга өндәү кебек мотивлар өстенлек ала.

Ни гаҗәптер, бала кеше элек-электән үгет-нәсихәтне яратмаган. Әмма шул фикерләрне читләтеп әйткәндә, яки матур сүзле шигырь юлларын тыңлаганда, аңар колак салган, игътибар иткән, хәтта тәэсирләнеп тә куйган. Мөгаллимнәр сабый психикасының бу үзенчәлеген яхшы белгәннәр, бала тәрбиясенең үтемле коралы итеп шигъриятне сайлаганнар. Габделмәннан Рахманколый, Нәҗип Думави, Миргазиз Укмаси кебек мәгърифәтче шагыйрьләрнең, дин сабакларына каршы чыгып, мәктәп-мәдрәсәләрдә яңача укыту өчен янып-көеп яшәгән чаклары булган. Торабара алар шагыйрьлекне төп хезмәтләре итеп сайлаганнар һәм яңача, дөньяви дәреслекләр төзеп, шул дәреслекләр өчен үзләре дә күп кенә шигырьләр иҗат иткәннәр. Шигырьләрнең теге яки бу күренешне сурәтләүгә корылулары һәм беркадәр дидактик тонда булулары аларның авторларының мөгаллимлекләреннән дә киләдер, бәлки.

Поэзиягә актив геройларны без беренче тапкыр Тукай иҗатында очратабыз.

Олылар сөйләгәнне авыз ачып тыңлап утыручы балалар өчен язылмаган инде алар. Шагыйрь баланың үз образын тудыра, алар шигырьдә хәрәкәт итәләр, шатланалар, кайгыралар, без аларның буй-сыннарын, яшьләрен, характерларын чамалыйбыз, хәтта исемнәрен дә беләбез. Менә аның бер сабые кәҗәне «...чирәм белән кунак итә». «— Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың белән тор», — дип, икенчесе Акбаен өйрәтә. Алар сөйкемле, эшлекле, тик тормас, шаян, хәйләкәр, изге күңелле. Шушы образлар аша Г. Тукай балаларны тормышка актив мөнәсәбәттә булырга чакыра, үз карашларын якларга өйрәтә.

Сабый күңеленең сафлыгын ул табигать күренешләренә бәйләп ача. Этләрне, куяннарны, күбәләкләрне, сандугачларны җанландырып, бала белән сөйләштерә, кеше һәм табигать арасындагы каршылыкларны, табигатьнең үз законачалыкларын алар аңларлык итеп сөйләп бирә. Балалар моңа сәерсенмиләр, шагыйрьгә ышаналар. Алар үзләре дә бит курчакларын сөйләштереп уйныйлар, талчыбыкка атланып чапканда бахбай булып кешнәп куялар. Табигатьнең тереклек иярәрен үзләре кебек җанлы, телле, акыллы итеп күрергә өйрәнгәннәр.

Шигырьләрнең күбесенең аерым бер сюжетка корылуы да бала күңеленә тәэсир итү көчен арттыра. Мең кат сөйләгәнче бер кат эшләп күрсәт, дигән мәкаль бар. Тукайның шигырьләре әнә шул «эшләп күрсәтүләре» белән дә көчле.

Г. Тукай шигырьләренең тагын бер хасиятен әйтми калу мөмкин түгел, ул — баланың шуклыгы. Шагыйрьнең үзенең матур бала чагы да булмаган югыйсә! Ә шигырьләрендә никадәр шаянлык, җылы юмор.

«Эттән күп дошманнары» белән тарткалаша-тарткалаша иҗат иткән шагыйрьнең балалар өчен **нәрсәләр** язу мәсьәләсен куеп торып, **ничек** язуы хакында гына уйлансаң да — таң калырлык. Балалар поэзиясендә беренче булып, сабыйларның җанлы образына мөрәҗәгать итү, сюжет, динамика кебек хәрәкәтчән пружиналардан файдалану, кош-кортларны җанландырып, шигырьләрдә әкият алымнарын куллану, бала юморына юл ачу, җен-парйләргә каршы куелган чын халыкчан әкиятләр иҗат итү... Шагыйрьнең кыска гына гомере өчен хәтта күбрәк тә шикелле болар...

Октябрь революциясеннән соң әдәбиятка килгән шагыйрьләр әр-яңа дөнья ачтылар. Революцион пафос, социалистик яшәеш күренешләре, Тукайлар хыяллана гына алган яңа кешеләр... Поэзиядә генә түгел, прозада, бигрәк тә ул елларны шактый җанланып киткән балалар драматургиясендә дә шундый ук хәл. Яңа илнең яңа гражданы белемле, физик яктан көчле, туган илен нык яраткан кеше булырга тиеш. Шуның өчен туган ил, дошманнарга каршы көрәш, физкультурачылар турында шигырьләр, дәртле җырлар күп языла. Әдәбиятка кыюлыгы, җитезлеге, үткенлеге, тик тормаслыгы, дошманнарга каршы нәфрәте белән пионер образы килеп керде.

Антологиянең соңгы битләрендә балалар әдәбияты тәнкыйтьчесе Равил Кукушкин 20-50 еллар поэзиясен характерлаганда: «... тематик дәреслеге белән генә түгел, бала психологиясен бирү үзенчәлеге һәм шигъри яңгырашы белән дә аерылып тора. Әйтик, бу чорда иҗат ителгән күпчелек әсәрләр, нинди генә темага язылмасын, уртак өч үзенчәлек — күмәк тормыш, оптимистлык һәм патриотизм тойгысы белән сугарылган»,— дип язды. Яңа тормыш тудырган психологик үзенчәлек, кеше характерындагы яңарыш иде бу. Бу үзгәрешне без антологиягә кергән шигырьләрдән ачык күрәбез.

Утызынчы еллар әдәбияты өчен тагын бер яңалык шул булды, ул елларда балалар өчен генә язган әдипләр мәйданга килде. Мәктәп балалары Абдулла Алиш әкиятләрен, Гариф Гобәй повестьларын, Абдулла Әхмәт пьесаларын йотлыгып укыган кебек, Әминә Бикчәнтәева, Җәвад Тәрҗеманов, Нур Гайсиннәрнең дә шигъри китапларын көтеп алалар иде. Сугыштан соңгы елларда балалар шагыйрьләренең сафы тагын да ишәйде. Бари Рәхмәт, Зәкия Туфайлова, Шәүкәт Галиев, Хакимҗан Халиков, Роберт Миңнуллин кебек бик үзенчәлекле шагыйрьләр иҗатларын бары тик балаларга гына багышладылар.

Бөек Ватан сугышы күп кенә язучыларыбызның гомерен кисте. Әнә шушы югалтуны, бушлыкны тутыландырырга телэгәндәй, сугыштан соңгы елларда бөтен язучылар да балалар өчен әсәрләр яза башладылар. Бу күп санлы әдипләр төркемендә өлкәннәр дә, утны-суны кичеп кайткан урта буын да, әдәбиятта беренче адымнарын атлаган яшьләр дә бар. Шулар арасында кояшлы алан кебек ялтырып, Бари Рәхмәт иҗаты күренеп тора иде. Га-

җәп йомшак күңелле, балаларча самими, сабыр холыклы, әкрен тавышлы бу кеше шигърият дөньясына тавышсыз-тынсыз гына килеп керде дә тиз арада барыбызның да мәхәббәтен яулап алды. Артык игътибарга, мактауга дәгъва итми иде ул. Дан аңа үзе килде. Әмма Бари абыйның аңар да исе китмәде. Аның иң бәхетле сәгатьләре балалар алдына чыгып, йомшак кына тавышы белән шигырь уку иде. Балалар белән сөйләшә белә иде Бари Рәхмәт. Дөресрәге, ул үзе түгел, шигырьләре сөйләшә иде аның.

— Сыерчыгым, нигә китәсең!
Сагынырмын сине, киткәчтен.
— Көз җитте бит инде, мин туңам,
Килгән идем җәйге костюмнан.

Гади дә, хикмәтле дә. Бер генә дә артык сүз юк. Фикер җыйнак кына шигырь юлларына сыеп беткән. Ә хикмәте — авторның дөньяга бала күзе белән карavында, чынбарлыкны бала фантазиясе аркылы ачуда.

Бари Рәхмәттәге гадилек һәм тирәнлек гармониясен Хәсән Туфан иҗаты белән чагыштырасы килә. Хәсән ага да бит фикерләрен шигырь кысасына көчләп кертмичә, җанга рәхәт итеп, үзәк өзгеч моң, я җиңелчә бер шаяру белән сөйләп тора кебек. Әмма һәр юлында афоризм итеп алырлык акыллы уй ята.

Поэзиядә «лидер» сүзен куллану урынлы да түгелдер, бәлки. Поэзия ул спорт мәйданы түгел. Шулай да инглиз теленнән кергән бу сүзнең «әйдәп баручы» дигән мәгънәсен күз алдында тотсак, илленче еллар поэзиясендә Б. Рәхмәтнә, алтмыш-җитмешенче елларда Ш. Галиевнә шулай дип атыйсы килә.

Бу ике шагыйрь сугыштан соңгы балалар поэзиясенең үсешенә, сыйфат ягыннан күтәрелешенә, форма төрләнешенә бик зур йогынты ясадылар. Хәтта бәр төркем яшь язучылар нәкъ Рәхмәтчә, нәкъ Шәүкәтчә язарга омтылдылар. Аларның кайберләре, зур агач төбендә корыган үлән кебек, шулай югалып та калдылар. Әмма талантлылары соңыннан үз юлларын табып, үз тавышларын ишеттерә алдылар.

Ш. Галиев Г. Тукай, Б. Рәхмәттән үк килгән көлкеле шигырьләр язу традициясен дәвам итсә дә, остазларын кабатлау юлыннан бармады. Аның да геройлары яшь ягыннан Г. Тукай һәм Б. Рәхмәт геройлары белән бер чамадарак иде. Ләкин акыл ягыннан алар үскәнрәк, алар белән җитди мәсьәләләр турында да сөйләшеп була. Заман сүзе белән әйткәндә, менә дигән акселератлар. Шулай да алар әле барыбер бала. Бар нәрсәгә бала күзеннән карыйлар, иң элек теге яки бу нәрсәнең кызык ягын күрәләр.

Шәүкәт Галиев шигырьләрендә техника заманасы алып килгән яңалыклар күп. Витамин, пластмасс, магнитофон, парикмахерская кебек артык прозаик сүзләрне дә ул шигъри калыпка җиңел сыйдыра. Бу яңалыклар аерым сүзләргә генә дә кайтып калмый. Йорт-җир әйберләреннән башлап бала тормышының аерым күренешләре турындагы шигырьләренең барысында да бүгенге көн сулышын сизәбез.

Алтмышынчы-җитмешенче еллар балалар поэзиясе, гомумән, кызыклы. Авторларның бик күбесе яшьләр, югары белемлеләр, заманча кыюлар. Үз-үзләреннән канәгать булмау, туктаусыз эзләнү, рус, хәтта дөнья әдәбияты үрнәкләренә тыңлашырга тырышу хас аларга. Характердагы бу активлык, билгеле, поэзиядә чагылмый калмый. Берберенә һич тә охшамаган әнә шундый бик әйбәт шагыйрьләр бүген дә нәниләр поэзиясендә эшләп килә. «Барлык талантлы язучылар төрле-төрлә, талантсызлары гына бер төрле яза»,— ди Илья Ильф. Соңгы ун елларның балалар поэзиясе дә төрлелек белән интегә дип әйтеп булмый. Роберт Миңнуллин һәм Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалимов һәм Хәкимҗан Халиков, Гәрәй Рахим һәм Фәнис Яруллин — никадәр төрлелек, үзенчәлек, аерымлык бар аларда.

Бу антология татар балалар поэзиясенең зурлыгын, байлыгын кулга тотып карарга, акылыбыз, йөрәгебез аша үткәрергә мөмкинлек бирә. Тәнкыйтьче Равил Кукушкинның китапка язылган җитди мәкаләсе әдәбиятның бу өлкәсендәге уңышларны күрсәтеп бирергә тырышкан. «Татар балалар поэзиясе антологиясе»н төзүчеләр дә, аның редколлегия әгъзалары да көчләрен, белемнәрен генә түгел, җан җылысын да биреп эшләгәннәр.

Татарстан китап нәшрияты әдәбиятыбызның, шулай ук нәшриятның үз тарихында да калырлык зур хезмәт чыгарган.

Шушында барысына да рәхмәт белән сүзне дә бетерергә мөмкин булыр иде, ләкин бер-ике теләкне әйтмичә каласы килми. Антология элек чыккан «Татар поэзиясе антологиясенә» охшатып бизәлгән. Бәлки, икесе бер стильдә эшләнсен дип уйланылгандыр. Шулай да балалар

антологиясе үзенә хас рәсемнәр белән бизәлсә, мәсәлән, балалар кулыннан ясалган кояш, кош, чәчәк элементларыннан да файдаланылса, уңышлырак булыр иде кебек. Ул вакытны язучының биографик белешмәсе бирелгән бит иркенрәк калыр һәм авторлар турында күбрәк сүз әйтеп булыр иде.

Ниһаять, антологиянең тиражы бик кечкенә булуын да искә алыйк. Ул инде сатылып та бетте, шулай булгач, кабатлап чыгару турында да уйларга кирәк түгелме икән?

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА.

# ДӘҮ КИТАП

Безнең өйдә хәзер шөгыльсез-нисез утырулар бетте. Әз генә буш вакытың бар икәнен күрдеме, кечкенә улым «Татар балалар поэзиясе антологиясе»н китереп тоттыра да: «Әти, укы әле миңа тагын шушы дәү китапны», — дип тыкырдата башлый. «Дәү китап» аркасында «тынычлыгын югалткан» ата-аналар бер без генә түгелдер, мөгаен...

Сөенечле хәл, 1980 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан бу шигъри тупланма тиз арада сатылып бетте дә, балаларның яраткан китабына, тәрбиячеләрнең иң кирәкле кулланмасына әйләнде. Бу — антологияне хәзерләп бастырып чыгаручыларның хезмәтенә иң объектив, иң гадел бәя.

«Балалар поэзиясе антологиясе» басылып чыгу культурабыз тарихында олы вакыйга. Ул «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», «Татар поэзиясе антологиясе» белән тиңләшерлек зур хезмәт. Борынгы чордан алып хәзерге заман шагыйрьләре иҗатыннан иң яхшы әсәрләрне генә алып та 368 битлек олы бер поэтик тупланма төзергә мөмкин булган икән, без балалар поэзиясе өлкәсендәге бай мирасыбыз белән хаклы рәвештә горурлана алабыз.

Балалар өчен әдәби тупланмалар чыгару эше бездә XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башларында ук күренә башлый. Бу нәүбәттән М. Иванов, Т. Яхин, К. Насыйри һ.б. кебек мәгърифәтчеләр һәм Г. Тукай тарафыннан чыгарылган җыентыкларны күрсәтергә була. Аларны антология төзүдәге беренче тәҗрибәләр дип атарга мөмкин. Совет власте елларында басылган «Балалар календаре», «Нәниләргә бүләк», «Нәниләр китабы» кебек тупланмалар да шул эшнең дәвамы булдылар. Әмма Тукайлар заманыннан ук әдипләрнең һәм педагогларның хыялында яшәп килгән «Татар балалар поэзиясе антологиясе»н дөньяга чыгару теләге озак еллар гамәлгә ашырыла алмыйча торды. Аны тормышка ашыру күренекле әдип һәм галим Н. Исәнбәт, шагыйрь Г. Рәхим, әдәбият белгече Р. Кукушкиннарга насыйп булган икән.

Табигый ки, антологиянең гамәли әһәмиятеннән тыш, фәнни кыйммәте дә булырга тиеш. Бу яктан караганда, китапка шулай ук тел-теш тидерерлек түгел. Шагыйрьләрнең әсәрләре югары эстетик зәвык белән сайланып, хронологик бер эзлеклелек белән урнаштырылганнар һәм шуның өчен китап, тулаем алганда, татар балалар поэзиясенең үсеш эволюциясен чагылдыра. Бу исә әдәбиятчыларга балалар поэзиясенең тарихы турында фикер йөртергә һәм нәтиҗәләр чыгарырга мөмкинлек бирә.

Антологияне башыннан ахырына кадәр укып чыккач, шул күзгә ачык бәрелә: XIX гасырдан алып шушы көнгә кадәр татар балалар поэзиясе озын юл үткән. Бу юлны балалар поэзиясендә шигъри осталыкка, камиллеккә илтүче юл дип атарга мөмкин булыр иде. Чыннан да, китапка кертелгән шагыйрьләрнең иҗат үрнәкләрен бер эзлеклелек белән укып бару дәвамында, безнең заманга якынлашкан саен, балалар шигъриятенең нәниләр күңеленә, аларның эстетик зәвыгына якыная барганлыгын сиземләргә була. Әйтик, безнең гасыр башларында иҗат иткән Г. Рахманкулый, Дәрдмәнд, М. Укмаси әсәрләрендә әле «чын балалар шигыре» юк. Ул әле балаларга багышланган шигырьләр генә. Аларда әсәрнең лирик герое өлкән кеше һәм ул, өлкән кеше буларак, нәниләрне тормыш-көнкүреш, әйләнә-тирәлек белән таныштыра. Шагыйрьләр, шулай итеп, әйләнә-тирәлекне поэтик тасвирлаулар аша балалар күңеленә матурлык тойгысы иңдерүне максат итеп куялар. Аларның шигырьләре кайчакта дидактик форма да алалар. Балалар поэзиясенең башлангыч чорына хас булган бу үзенчәлекләр соңга таба

Г. Тукай иҗатында, мәсәлән, яңа сыйфат үзгәрешләре кичерә. Дөрес, әле Г. Тукай иҗатында да балаларга «өлкән кеше булараҡ» мәрәҗәгать итү, тормыш-көнкүрешне аның күзлегеннән тасвирлау традициясе яшәп килә. Әмма ул «өлкән кешенең» күңеле балалар җаны кебек саф һәм садә булуы, әсәрнең мавыктыргыч һәм аңлаешлы тел белән язылуы аркасында балалар йөрәгенә үтеп керә ала.

Г. Тукай балалар поэзиясенә күзгә күренерлек олы бер яңалык алып килде. Ул лирик герое бала булган чын нәниләр поэзиясенең тәүге үрнәкләрен бирде. Поэзиянең Тукайдан соңгы чоры әнә шундый — чын балалар шигъриятенең үсеш еллары булып күзаллана. Дөрес, ул үсеш тигез юлдан гына бармады. 20 — 30 елларда, мәсәлән ,балалар шигърияте тасвири әсәрләр дә басып киткәләде. 40 — 50 елларда исә ул тагын тернәкләнеп китте. Б. Рәхмәт, Н. Исәнбәт иҗатларында үсеш кичереп, Ш. Галиев иҗатында югары ноктага ирешә. Хәзерге урта һәм яшь буын шагыйрьләре Җ. Тәрҗеманов, М. Фәйзуллина, Р. Валиев, Р. Миңгалимов, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Р. Миңнуллин, Җ. Дәрзаманов, М. Әгъләмов, Р. Бәшәров һ. б. иҗатында без аның алга таба уңышлы дәвам иттерелүен күрәбез. Бу шагыйрьләргә бала психологиясен нечкә тоеп, аларның «үз эчләренә кереп» уйлый һәм сөйли белү хас. Бөек Тукай иҗатында яралган бу асыл сыйфат хәзерге көнгәчә дәвам иттерелә.

Китапта Р. Кукушкинның «Җирдә яңа кеше өчен» дигән күләмле генә мәкаләсе урнаштырылган. Автор балалар поэзиясенең башлангычын хаклы рәвештә нәниләр фольклорында күрә һәм аның нәниләр шигърияген сугарып торучы матурлык чишмәсе булуын дәлилләп аңлата. Ә язма балалар поэзиясенең тарихын ул борынгы чор шагыйрьләре Кол Гали, С. Сараи, Мөхәммәдъяр һ.б. иҗатыннан башлый. Әмма, кызганычка каршы, авторның соңгы фикерләре коры сүз булып кына кала, чөнки антологиягә борынгы шагыйрьләрнең иҗатыннан үрнәкләр кертелмәгән.

Балалар поэзиясе 1905 елдагы буржуаз-демократик революциядән соң зур күтәрелеш кичерә. Монда «Тәрбиятел әтфаль», «Якты юл» кебек балалар журналлары, мөгаллимнәр өчен чыгарылган «Шура» журналларының әһәмияте гаять зур була. Балалар поэзиясенең XX йөз башындагы үсешен тасвирлаганда миңа калса, 1905 елгы революция тудырган демократик хәрәкәт һәм балалар өчен журналлар чыга башлау, аларның әһәмиятен ассызыклап күрсәтү житенкерәмәгән төсле.

Революциягә кадәрге чор балалар поэзиясен анализлаганда автор Г. Тукай иҗатына киң тукталган, аның хезмәтләрен һәм балалар поэзиясенә алып килгән яңалыгын тулысынча ачып бирә алган. Шулай ук мәкаләнең революциядән соңгы чор балалар поэзиясе тарихын ачыклауга багышланган бүлеге дә һәръяклап мактауга лаек. Анда балалар поэзиясе үткән юл ачык күзаллана, теге яки бу шагыйрьнең балалар шигъриятендә тоткан урыны, роле дөрес билгеләнә.

Китапның төп бүлеге — текстлар бүлеге балалар поэзиясенең нигезе булган фольклор үрнәкләреннән башланып китә. Анда нәниләр өчен башкарыла торган һәм балаларның үз мохитендә яшәүче халык иҗаты үрнәкләре китерелгән. Әмма, әйтергә кирәк, алар жанрларга бүленеп түгел, ә «Бишек янында», «Табигать белән сөйләшү», «Тел шомарткычлар», «Такмак-такмазалар» кебек гомуми бүлекчәләргә аерып кына урнаштырылганнар. Бу, әлбәттә, төзүчеләрнең генә гаебе түгел. Ул балалар фольклорының әлегә кадәр фәнни яктан өйрәнелеп бетмәвеннән, жанрларның ачыкланмавыннан килә торган җитешсезлек.

Китапның «Татар шагыйрьләре» дип аталган бүлегендә революциягә кадәр иҗат иткән унсигез шагыйрьнең биографик белешмәсе һәм әсәрләре бирелгән. Минемчә, бу сан азрак. Мең еллык әдәби мираска ия халыкның 1917 елга кадәр унсигез генә балалар шагыйре булуына ышанасы килми. Борынгы чорда иҗат иткән шагыйрьләрнең әсәрләреннән аерым үрнәкләрне сайлап алу мөмкинлеген искәртеп узу белән бергә, XIX гасыр шагыйрьләре К. Бикколов, Г. Чокрый, Я. Емельянов һәм башкаларның балалар өчен язган шигырьләре бар икәнлеген әйтеп узарга була. Кызганычка каршы, алардан үрнәкләр китерелмәгән. Шулай ук совет чорында яшәгән һәм иҗат иткән С. Миңлекәй, Г. Мөхәммәтшин һәм башкаларның да балалар өчен язылган шигырьләре байтак. Шигъри антологиягә аларның да керергә тулы хокуклары бар иде. Хәзерге яшь шагыйрьләрнең әсәрләре кертелсә дә зыян булмас иде.

Антологиягә керә алмыйча калган һәм исемнәре онытыла башлаган борынгы ав-

торлар булуы мөнәсәбәтендә шуны әйтәсе килә: бу очраклы гына килеп чыккан хата түгел. Төзүчеләр кулларыннан килгәнне эшләгәннәр — эзләнгәннәр, тапканнар, китапка урнаштырганнар. Төп бәла шунда: бу антологиягә керергә лаек булган күп кенә шагыйрьләрнең мирасы (бигрәк тә революциягә кадәрге шагыйрьләрнеке) әле тулысынча барланмаган. Алар төрле газет-журнал битләрендә, хәзер сирәк очрый торган китапларда, кайберләре исә кульъязма килеш фәнни учреждениеләрдә, шәхси архивларда яталар. Аларның барлыгын белүче әдәбият белгечләре никтер бу шигъри тупланманы төзү эшенә тартылмаганнар. Нәтиҗәдә, исемнәре онытыла башлаган күп кенә шагыйрьләр уникаль басмага керә алмыйча калган.

Сүз дә юк, бай культура традицияләре булган халыкның поэтик мирасын кузаллап чыгу һәм шуннан сөземтәләр алу гаять катлаулы эш. Монда кайбер вак-төяк чатаклыклар китүе дә табигый хәл. Төзүчеләр җибәргән җитешсезлекләрнең бер өлеше шагыйрьләр турында бирелгән биографик белешмәләргә карый. Алар, нигездә, күп эзләнүләр нәтиҗәсендә туган язмалар. Әмма аларда стилистик чуарлык күзгә бәрелә, биографияләр барысы да бер төрле генә язылмаганнар. Кайберләрендә шагыйрь тормышы һәм иҗатындагы вак-төяк вакыйгаларны, фактларны күрсәтүләр очрый. Кыскасы, биографик белешмәләргә фәннилек җитенкерәмәгән.

Китапның техника ягына караган җитди бер тәгәлсезлекне дә күрсәтеп узмыйча ярамый. Мәсәлән, антологиянең 241—256 битләрендә (бәлки ул аерым нөсхәләрдә генә шулайдыр) бирелгән тугыз шагыйрьнең әсәрләре һәм биографик белешмәләре кабат килеп «кунаклаган».

Мондый хаталар бу уникаль басманың беркадәр ямен җибәрсәләр дә, китапның гамәли һәм фәнни әһәмиятен кулэгали алмыйлар. Күп хезмәт түгеп, озак эзләнүләр аша туган бу китап балаларга, тәрбиячеләргә һәм, гомумән, әдәбият сөючеләргә олы бүләк. Ул чыннан да, культурабыз тарихында зур казаныш булырлык «дәү» китап.

**РӘШИТ ЯГЪФӘРОВ.**

# НӘНИЛӘРНЕ ОНЫТМАГЫЗ!

Бүгенге укучыбызның ни дәрәҗәдә хәзерлекле һәм туган телебез гүзәллекләренә никадәр сизгер булуы өчен без, әлбәттә, үзебездән элгәрге язучыларга бурычлы. Тукайның балаларга атап язылган якты шигырьләре, Галимҗан Ибраһимовның йөгерек хикәяләре, Такташ иҗаты тудырган «Караборынның дусты», Мирсәй Әмирнең «Батыр малай турында хикәяләр»е, Туфанның «Юкмыш бабай» әкияте, Җәлил,Фатих Кәримнең нәниләргә багышлап язылган онытылмас шигырьләре...

**Урамнар бүген сөенгән,**
**Ап-ак карга киенгән.**
**Ләйлә чанасын күтәреп**
**Чыгып китте өеннән.**

Бу — Такташ. Бер мәртәбә ишетүгә күңелгә сеңеп кала. Шушы юлларны ятлап үскән ничәнче буын укучылар бүген татар китабын кулына ала икән?!

Муса Җәлилнең моннан илле еллар элек Татарстан язучыларының I съездына хәзерләнү уңае белән язылган мәкаләсе бар. Ул «Балалар әдәбиятына иң нык игътибар!» дип атала. Шуннан бер-ике өзек китереп үтик.

«Татар совет әдәбиятында зур ук урын тоткан язучыларыбызның бик күбесе әле балалар әдәбиятыннан әсәр биргәннәре юк...» «Балалар драматургиясен һәм балалар җыр-музыкасын үстерүне бөтен кискенлеге белән куярга кирәк булыр. Музыка-балет театрын төзү процессында балалар өчен музыкалы сәхнә әсәрләре һәм балетлар язуны да куярга кирәк...» Гыйльми критика институты аркылы балалар әдәбиятына тулы күзәтү үткәрү һәм, гомумән, тәнкыйтьне юлга кую эшен эшләргә кирәк...»

Күргәнебезчә, безнең классикларыбыз яшь буынны тәрбияләүгә, яңа укучыны булдыруга әнә шулайрак килгәннәр.

Без, язучы яки аның китабы турында сөйләгәндә «аның үз укучысы бар», «аның бу китабы үз укучысын тапты» кебек тәгъбирләрне еш кулланабыз. Ә менә үз укучысын тәрбияләү, аны үзенә якынайту өчен язучы нәрсә эшләвен беркайчан да куз-

гатканыбыз юк. Балаларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, аларны батырлыкка, тапкырлыкка өйрәтү, матурлыкка соклану хисенә яңа юнәлешләр бирү — һәрбер язучының изге бурычы. Шушы җәһәттән нәниләр өчен соңгы вакытта чыгарылган берничә китапны күзәтеп үтик.

**Гәрәй Рәхим. «Чәчәк тәкыя». Татарстан китап нәшрияты, 1981. Рәссамы В. Малякин.**

Сүзне китапның бизәлешеннән башлыйсы килә. Рәссам автордагы юморны оста тотып алган. Шаян, тапкыр, кулыннан эш килә торган малай образы тышлыктагы рәсемдә үк күренә.

**Кибеттән чиләк сатып ал диеп**
**Борчып тормадым әле әнине.**
**Каен тузыннан үрдем бер тырыс**
**Ярдәмгә дәштем бары әбине.**

Шуннан соң безнең тырыш малаебыз нәрсә эшләгән дип беләсез? Соң, әлбәттә, ул тырысны матурлык өчен, мактанып өчен генә ясамаган, урманга җиләккә киткән. Җиләкләр дә аның осталыгына сокланганнар һәм аларның әнә шул матур тырыска утырып карыйсылары килгән. Алар «мине өз» диеп, яфрак астыннан йөгереп чыга торганнар, тырыска сикереп менә торганнар. Шундый оста куллы малайны кем яратмасын соң? Тырыш малай күз ачып йомганчы тырысын түбәләмә тутырган да, өйдәгеләрне сыйларга кайтып киткән.

**Каен тырыста каен җиләге,**
**Көнләшеп калсын кибет чиләге.**

Кулыннан бер эш килгәннең һәммәсе килә инде. Менә ул калайдан кисеп әтәч ясаган. Хәзер моны нишләтергә? һәрбер ясалган әйбер ,нинди дә булса эшкә яраргa тиеш ләбаса! Башыңны гына эшләтергә кирәк, тырыш малай үзенең калай әтәченә дә эш таба. Аңа җилләр телен өйрәтә. Ул хәтта болында йөргәндә дә «бу — егет кеше эше түгел» дип тормаган, тәкыяләр үргән. Нигә гаҗәпләнергә, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз! Әнисенә дә үргән ул, әтисенә дә үргән ул, дусларына да үргән ул — һәммәсенә дә үргән ул. Тырыш, оста куллы малайның теләге дә изге. һәрбер баланы сокландырырлык.

Китапның исеме дә әнә шул шигырьдән алынып «Чәчәк тәкыя» дип аталган. Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең өлкәннәр өчен язылган шигъри әсәрләрендәге стиль үзенчәлеге, авазларның салмак, ышанычлы агышы бирегә дә сакланган. Бу шигырьләрне укып үскән балалар, һичшиксез, шагыйрьнең өлкәннәргә язылган китапларына да хәзерлекле рәвештә киләчәкләр.

Шагыйрь бу әйбәт китабында бер тырыш малай хакында гына язмаган. Бу юнәлеш китапның үзәген генә тәшкил итә. «Чәчәк тәкыя»да башка малайлар да бар. «Бер ялгышу — мең ялгышу» балладасында ул «Ташавыл Әрчүгенең моннан унбиш еллар элек нәрсәләр кичерүен» сөйли. Әйе, Әрчүк үзе әйбәт кенә малай. Ләкин һич кенә дә ялгышын төзәтергә теләми. Менә ул ялгышып тоньякны көньяк дип күрсәтә, әмма үзенең хатасын һич кенә дә таныйсы килми, һәм үз күзләре белән күреп кайтырга теләп Әрчүк майкадан, шорттан гына көньяк дип тоньякка чыгып китә. Шуннан соң нәрсә булганы авторга хас юмор белән тасвир ителгән... Әйе, мондый балладалар, әкиятләр, хикәятләр бик тә кирәк. Алар гыйбрәтле булудан тыш та күп мәгълүмат бирәләр, балалар хәтерен тирәнәйтүдә, чыныктыруда аларның файдасы бәхәссез.

Шагыйрь берничә генә юл белән балада елмаю һәм уйлану тудырырдай матур сурәтләр дә ясый ала.

**Юл өстендә тузан уйный —**
**Ике яшь әтәч талаша.**
**— Безнең әтәч җиңә, — ди-ди**
**Ике малай якалаша.**

Китапның бер кимчелегенә тукталып китмичә булмый. Дөресен генә әйткәндә, бу кимчелек соңгы елларда басылып чыккан бик күп китапларыбызга хас. Эш шунда: китапларыбыз нәкъ менә җыентыкны хәтерләтә. Ә бит китап — тематик бер бөтен үзәге булган, тормышны төрле ноктадан килеп өйрәнүләрдән торган камил формалы һәм эчтәлекле тепләмә булырга тиеш. Юк, бер җыентыкларга каршы түгел. Әдәби мирасларны да җыеп чыгарырга кирәк. Ләкин бүгенге тормыш эчендә кайнаган, кулында каләме уйнап торган иҗат кешесенә сокландыргыч муенса-сәйләнтезү үзе бер сөенеч булырга тиеш. Әнә бит Г. Рәхимнең үз герое да тәкыя үргән. Шуңа күрә дә «Туган ягым», «Кызыл», «Якты аланда» кебек шигырьләр, аерым алганда матур гына булсалар да, «безнең ни гаебебез бар» дигәндәй, башларын иеп торалар төсле...

**Әхмәт Рәшитов. Кояшлы ил — бәхет иле». Татарстан китап нәшрияты, 1981. Рәссамы Р. Төхвәтуллин.**

Китапка барысы 13 шигырь кертелгән. Биредә, Гәрәй Рәхим китабыннан аермалы буларак, иң нәниләргә язылган шигырьләр тупланган. Шулай булуына карамастан, китап төсле рәсемнәр белән түгел, ә акка каралы сурәтләр белән генә чыгарылган. Бүгенге бала ике телдә дә чатнатып укый, аның кулына илебезнең төрле шәһәрләрендә чыгарылган матур-матур рәсемле китаплар керә. Китап, һичшиксез, күп төс белән чыгарылырга тиеш иде. Шулай ук тышкы битендә авторы да куелмаган. Монысы инде бигрәк тә сәер.

**Кояшлы ил — безнең ил,**
**Күге аның гел аяз.**
**Кыш китерсә Кыш бабай,**
**Чәчәк алып килә яз.**

Китап шулай башлана. Ул йөгерек тел белән язылган. Шигырьләрне хәтердә калдыру да бик җиңел.

**Бу ил безгә булсын, дип,**
**Кояш балкып торсын, дип,**
**Бабайлар яулап алган,**
**Әтиләр саклап калган.**

Шагыйрьнең зурлар өчен язылган шигъри әсәрләрен яхшы белгәнгә, әнә шундый героик пафослы, бәйрәмчә рухлы шигырьләр күбрәк көтелгән иде.

Китап тематик яктан киң, шигырьләр вакыйгалы. Бүгенге балалар тормышы анда төрле яклары белән күрсәтелгән. Әтисе белән абыйсының уракны бетереп кайтуларына сөенгән малай («Игеннәр өлгергәч»), алдашу уеныңда көлкегә калган Гөлсинә («Алдашу уены»), өлкәннәргә хөрмәт белән эндәшә белмәгән Кави («Агач авыз»), су коенганда Әминә исемле кызны коткарган Мәмәт («Медальле малай») һ. б. кызлар һәм малайлар һәммәсе дә тормыштан, балаларның үз араларыннан.

Малайга әтисе Казаннан татарча китаплар алып кайта. Китаплар эчендә Шәүкәт Галиевнең Шәвәлие, Тукайның Шүрәлесе, халыкның тапкыр Шомбае.

**Тиз генә укып чыгыйм да,**
**Белим дә үзем барын,**
**Саша белән Наташага**
**Сөйләрмен кызыкларын.**

Төрле милләт балаларының дуслыгын чагылдырган бик тә гыйбрәтле шигырь бу. Китапның эчтәлеге дә исеменә тиң. Әгәр алда әйткән кимчелекләре дә булмаса, икеләтә әйбәт тоелыр иде.

**Марсель Галиев. «Җиңәсем килде». Татарстан китап нәшрияты, 1981.**

Марсель Галиев чәчмә һәм тезмә әсәрләрдән төзелгән берничә китап авторы. Алары өлкәннәр өчен иде. Шуңа күрә Марсель Галиевнең балалар өчен беренче булган китабын хуплап каршыларга кирәк. Китапта 6 хикәя, 2 парча урнаштырылган. Хикәяләрнең һәрберсендә үз формасы табылган. Автор һәрбер вакыйгада эчке пружина булган детальне табарга тырыша.

«Утыз тиен генә» хикәясендә Данилның күгәрченнәргә ваклап сипкән йөземле күмәче, «Үпкәләү»дәге ертылган рәсем», «Ак парашют»та очучы әтисен югалткан Маратның төшендә әтисеннән бүләккә ак парашют алуы — болар һәммәсе дә үзенә күрә бер табыш. Алар вакыйгаларны бер теземгә җыйган муенса җепләре. Гомумән, Марсель Галиевнең хикәяләре баланы дөнья хакында киңрәк уйланырга, фикер йөртергә өйрәтәләр. Һәм алар һәммәсе дә гыйбрәтле вакыйгалар аша бирелгәннәр. Китапка исем булган «Җиңәсем килде» хикәясендәге Илгиз бакчада шахмат уйнаганда сукыр абзыйсының бер фигурасын алып куя. Бер уйласаң, балалык беркатлылыгы гына. Хикәягә нигез булып яткан шул кечкенә генә детальдән олы гомумиләштерү ясала.

Безнең балаларыбыз Марсель Галиевтән киләчәктә дә шундый гыйбрәтле әсәрләр көтәләр.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: безнең язучыларыбыз әнә шулай сирәк кенә булса да нәниләребезне сөендерә торалар. Әмма бу аз, хәтта бик аз. Кабатлап әйтик — нәниләр безнең киләчәктәге укучыларыбыз. Шушы хакыйкатьне без беркайчан да онытырга тиеш түгелбез.

**МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ.**

# ҖАНГА ШИФА



...Вәлкәхмәт агай төпчек буласы улына исем эзли. Мулла-мазар чакырып түгел, үзе кушарга була исемне. Ак биләүгә биләнгән бер атналык малайны кояш ягына каратып сала да колагына: «Исемең Ирәк булсын, улым,— дип пышылдый.— Ирәк булса, илдә тынычлык булыр. Илдә тынычлык булса, бар да булыр!»

Ел артыннан ел үтә. Ирекнең киң күңелле, алдынгы фикерле, ил кайгысын үз кайгысы итеп уйлана, көрәшә белүчә әтисе 1946 елда дөнья куя. Әмма алты баласының алтысына да үз кыйблаларын күрсәтеп, хезмәт сөяргә, кешеләрне яратырга, авырлыкларга бирешмичә дөньяда җыр белән яшәргә өйрәтеп калдыра ул. Алтысының да гармун уйнарга өйрәнүләре белән дә балалары әтиләренә бурычлы.

Бервакыт әнисе Фатыйманың: «Әтиегезнең дә йолдызы сүнде»,— дип елаганын күрә Ирек. «...Күктә күпме йолдыз. Һәркайсының иясе бар, имеш. Кеше җирдән киткәч, аңа аталган йолдыз да сүнә икән»,— дип уйлый ул. Шул чак Ирекнәң тылсым көчә белән зәңгәр күккә ашасы, кулына очкын алып, сүнгән йолдызларга ут тергезәсе килә. Җырлый-җырлый ут тергезәсе... Йолдызларын кабызып, кешеләрнә кабат тормышка кайтарасы килә аның.

«Хыялыңны тормышка ашырасың, олы эшләр майтарасың килсә, укырга кирәк»,— ди торган иде бит аның әтисе!

Ирек башта урта белем ала. Аннары, Төньяк флотта крейсерда хезмәт итеп, туган якларына әйләнеп кайткач, нефть чыгаручы оператор булып эшли. Техник училищены тәмамлап, Казандагы тимер-бетон заводында эшли башлагач, егет балачактан ук канына сеңеп калган икенче бер омтылыш белән яши башлый. 1957 елда В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры каршында ачылган театр студиясенә укырга килә ул. Тормышның серле, шул ук вакытта авыр, җаваплы яңа мәйданына аяк басканда, икеләнүләр, шик-шөбһәләр дә борчый, әлбәттә, егетнең күңелен. Заяга гомер уздыру булмасмы бу? Инде өйрәнгән һөнәренә, эшенә хыянәт итү булмасмы? Алай дисәң, ни өчен сәхнә тынгылык бирми соң аңа? Ни өчен күңеленнән чайпалып моң түгелергә тора? Ни өчен аяклары үзләреннән-үзләре көн саен театрга илтә? Юкка түгелдер бу! Сәнгать аңа канатлар бирергә тиеш. Шул канатларда очып, сүнгән йолдызларны кабызачак, туңган җаннарны җылытачак әле Ирек. Тәвәккәлләргә, укырга, өйрәнергә кирәк!

Егет әнә шулай уйлый һәм ялгышмый. Бу адымны Татарстанның халык артисты, авылдашы Касыйм Шамилнең зур йогынтысы тәэсирендә ясамады микән Ирек?

Казанга килүенең беренче көннәреннән ук К. Шамил җитәкчелек иткән драма түгәрәгенә йөри башлый ул. Профессиональ сәнгатькә омтыла, укырга керә. Һәм театр студиясендә зур сәнгать белән очраша. Тормышында җуелмас эз калдырган

һәркайсы дөнья бәясе кешеләр — Хәлил Әбҗәлилов, Хөсәен Уразиков, Габдулла Шамуков, Шәукәт Биктимеров, Празат Исәнбәт, Шириәздан Сарымсаков, Марсель Сәлимҗанов белән якыннан танышла. Сәнгатьне яратулары, кешеләргә булган яхшы мөгамәләләре, эчке культуралары, ихласлыклары белән җәлеп итә алар Ирекнең күңелен. Әлеге мәшһүр кешеләргә тырыш, сабыр егет үзе дә ошый, алар арасында бик тиз үз кеше булып китә. Әнә бит, кем белән генә очрашып, кем белән генә сөйләшмә И. Баһмановның үтә тыйнак, кешелекле, эш сөючән, туры сүзле булуына басым ясыйлар. «Артист — хезмәтчән ул,— дип сөйләргә ярата, мәсәлән, актерның беренче укытучысы, режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе П. Исәнбәт.— Ирекка тапшырылган эшнең һәрвакыт җиренә җиткерелеп, намус белән үтәләчәгенә, иптәшләрен, театрны кыен хәлдә калдырмаячагына үз-үзенә ышангандай ышанасың. Аңа таянып була».

«Таянып була. Вәгъдәсендә нык тора. Искиткеч әдәпле, объектив, тагы бер тапкыр кешелекле! — дип өсти СССРның халык артисты Ш. Биктимеров.— Ирекнең театрда эштән бәхете бар. Бүгенге көндә театр репертуарын төпкә җигелеп тартучы иҗат көчләренең берсе ул».

Р. Ишморатның «Шаулыйлар дулкыннар»ында, А. Гыйләҗевнең «Әңгер-меңгер»ендә, Ш. Хөсәеновның «Әни килде»сендә, Н. Погодинның «Баһадирлар»ында һәм башка әсәрләрдә И. Баһмановка күп тапкырлар Ш. Биктимеровның партнеры булып уйнарга туры килде.

«Баһадирлар» дигәннән, И. Баһманов иҗатында аерым игътибарга лаек бу спектакль. Әлеге киң полотнолы әсәрдә инженер-металлург Ипполит образын тудырды ул.

Революцияне беренче көннәреннән үк кабул иткән, ләкин политик яктан әзерлексез булуы аркасында еш кына икеләнеп, шик-шөбһәгә калучы Ипполит Кремльгә кила. «Әгәр?..— дигән уй борчый Ирек Баһмановны.— Әгәр үзе юлбашчы белән очрашса, нинди хисләр кичерер иде коммунист Баһманов? Ничегрәк сөйләшер, нинди позада калыр, ничек мөрәҗәгать итәр иде икән?..»— Вакыйганың асылына төшенеп, аналитик уйлап, фәнни нигезләп уйнарга кирәк монда. Әсәрне җентекләп, кат-кат укый Ирек. Тамашачыга әйтеләсе фикернең асылына төшәргә тырыша. Образның язучы тудырган чаклысын гына үзләштереп калмый, аңа үзеннән дә матур буяулар өсти, заманча төсмерләр белән баета. Кыскасы, бу спектакльдә революция солдатының тамашачы күңелен дулкынландырырлык якты образын иҗат итте.

Гражданлык хисе белән сугарылган, патриотик рухлы, революция ялкыны дөрләп торган әсәрләрдә беренче генә мәйдан тотуы түгел И. Баһмановның. Әйтик, А. Гыйләҗев һәм А. Яхинның «Шамил Усманов» әсәрендәге моряк Каюм образы. Оста һәм уңышлы иҗат иткән иде ул аны. Үзе дә биш ел буе Төньяк флотта хезмәт итеп кайткан егет өчен табигый, якын образ иде кырыс матрос образы. И. Баһманов әлеге героен Аврора, Балтика, Кронштадт морякларының революцион вәкиле дәрәҗәсенә күтәрде. Шул роль өчен ул Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгына багышланган Бөтенсоюз конкурсында икенче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Бу — олы юлга аяк басу чорындагы тәүге хезмәтләренең берсе иде.

И. Баһманов рольне әзерләгәндә, бай тәҗрибәсенә генә таянып, интуиция белән генә эш итми. Геройларның эресенә-вагына карамый, һәркайсына зур җаваплылык, таләпчәнлек хисе белән алына.

Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»ен генә искә төшерик. Беренче пәрдәдә туксан яшен тутырган әтисе бер чынаяк чәй эчкәнче генә сәхнәгә чыгып керә Искәндәр-Ирек. Әмма тамашачыга никадәр гыйбрәт бирә, аның эчке дөньясын күзгата. Өстендә калын сырма, башында кәләпүш, аягында киез ката, билендә кат-кат итеп уралган мамык шәл. Үзе буылып-буылып ютәлли.

— Нәрсә инде бу, әти? Иркенләп ятарга да бирмисең,— ди ул, тирләп-пешеп чәй эчеп утыручы әтисе янына көч-хәл белән чыгып утыргач.— Шул чәеңне өйгә кереп эчсәң булмыйммы?!

Шат күңелле, сәламәт, дәртле һәм дәрманлы ата алдында искиткеч мескен кыяфәттә, үзеннән егерме яшькә кече улы басып тора. Кулына тоткан чынаяклары шалтыр-шолтыр шалтырый.

— Әнекәем, шифаханә койкасыннан чын хастаны китереп утыртсалар да бу кадәр



килештерә алмас иде,— дип пышылдый тамаша залыннан берәү, Искәндәрне чын күңелдән кызганып.

Шул чак РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы Гөлсем Болгарская истәлекләреннән бер өзек хәтергә килә: «Күтәрелеп Сиражетдин-Г. Кариевка караган идем, йөрәгем жу-у итеп китте. Каршымда чын-чынлап юләр кешә басып тора. Бу хәл үземә дә файда бирде, нәкъ җүләрләргә булган мөнәсәбәт белән сөйләшә башладым...»

Чынлап та, артист халыкны сәхнәдәге тормышына ышандыра, йөрәк түренә кайнар дулкын булып кагыла ала икән — бу, һичшиксез, аның иҗат уңышы, иҗади бәхете.

Әгәр Искәндәрнең күзләрендә яшәү нуры сүнә баруы күренмәсә, кыяфәтендә тирән битарафлык күләгәсе ятмаса, хәрәкәтләрендә өметсезлек, дөньядан ваз кичү сизелмәсә, Әлмәндәрнең «яшьлеге», җорлыгы, оптимистлыгы шул кадәр үк калку булып күренер иде микән?! Кечкенә — эче төш кенә, диләр чикләвек турында. Спектакльдәге әлеге роль турында да шундый сүз әйтәсе килә. Геройның сәхнәдә күп сүз сөйләп, күп хәрәкәт ясавында түгел икән хикмәт. Хикмәт — актер иҗат иткән характерның көтелмәгәнчә, яңача, үзенчә ялтырап балкып алуында, бер бөтен булуында, максатка ирешүендә.

«Мин сүзләрдән бары юллар тездем, юл арасы тулы хисләрем»,— ди шагыйрь. Чын артист та нәкъ әнә шулай драматургның «юл арасында калган» фикерен укый. Шул фикерне сәнгать кануннары аша ача. Мондый сәхнәләрдә И. Баһмановка тирән мәгънә салынган паузалары гына түгел, чиста, ачык дикциясе, яңгыравыклы тавышы, табигый сөйләм теле белән сәнгатьчә эш итә белүе дә ярдәмгә киләдер, әлбәттә.

Гадәттә тамашачылар да, театр белгечләре дә спектакльдәге төп образга зуррак игътибар бирәләр. Бу аңлашыла да. Сәхнә уены күпмедер дәрәҗәдә күк җисемнәре хәрәкәтен хәтерләтә: үзәктә торган геройлар тирәсендә башкалары әйләнә. Тик бу системада иң кечкенә генә җисем юлыннан тайпылсын — шунда ук коточкыч гарасат кубачак. Спектакльдә дә шулай. Берәр артист нярчен рольне күңел биреп, талантын, тырышлыгын салып уйнамаса — бөтен тамашаның яме китә.

Ирек Баһманов башкарган рольләр арасында да бар андый ярдәмче образлар. Ләкин алар, бәхеткә каршы, спектакльдән соң да онытылмый, төп герой белән бер дәрәҗәдә истә калалар, уйландыралар, дулкынландыралар. Мондый геройларның

күбесе аз сүзле, тормышта алар кирәксә-кирәкмәсә дә чәчрәп алга чыкмый. Дөньяда гаделлекне яклап, хакыйкать сагында гомер итсәләр дә, кайчагында кадерен белеп бетермиләр андый кешеләрнең. Ләкин алар халык күңелендә яшәп кала. Һәрхәлдә И. Бәһманов андый геройларны образ буларак шулай иҗат итә, шулай башкара. Мәсәлән, күпләр хыялый дип йөртүче Түрәй (А. Гыйләҗев. «Тургайлар килгән»), кайберәүләр сәламен дә алмый торган Челем картны үз итә алучы Шәйхел (Г. Ибраһимов. «Татар хатыны ниләр күрми»), башы больницадан чыкмаса да, йөрәге дөнья борчулары белән тулы Инсаф (Ш. Хөсәенов. «Әни килде») һ. б. бик күпләр...

И. Бәһманов тудырган образлар бергәйле итеп уйналулары белән истә кала. Аларның эчке матурлыгы, рухи сафлыгы нәкъ әнә шундый тыгыз, киеренке, халәтләрдә ачылып китә. Мондый минутларда И. Бәһманов персонажларының гомер буе җаннарын кимереп, эрәкләрен әрнетеп килгән газаплы хисләре кайнар чишмә кебек өскә бәреп чыга. Чыга да тамашачыларны тетрәндереп куя, кичерешләрен тирәнәйтә, уй-фикерләрен бөтереп ала.

Шундый уеннарның берсеннән соң, урамда:

— Гафу итегез,— дип туктаталар Ирекне.— Сез әле генә мине уйнадыгыз бит. Протезларыма кадәр Инсафныкына охшаган,— ди бер агай «тезләр»ен шакылдатып.— Ләкин хикмәт аякта түгел, менә монда — күңелдә!.. Эх, Ирек туган, рәхмәт сезгә. Һәр сүзегез җанга шифа булды. Кешеләргә бөтен эч серемне әйтеп бирдегез. Хәзер үземне ничектер бушанып, борчуларымнан арынып калгандай тоям. Рәхмәт!

Ирек Бәһманов өчен вак роль юк дигән идек. Аны иҗатында тискәре яки уңай герой дигән чикләү дә юк. Әллә нинди холыксыз, мәкерле, әхлакый бозык, тискәре геройларны тамашачы ышанырлык, тормышчан итеп уйный белә ул. Мәсәлән, Б. Горбатовның «Бер төн» әсәреннән Новожилов образы кеше бәхетсезлегеннән файдаланып мал җыярга омтылучы комсыз бәндә булып күз алдында кала. Н. Островскийның «Агай-эне ак мыек» әсәрендә акча бәрабәренә теләсә нинди кабахәтлеккә әзер торучы адвокат Рисположинский, Л. Леоновның «Ябырылу»ында Ватанын сатучы куркак Массалский. Анарның «Шәһәрдә җәй көннәре» әсәрендә акчага, байлыкка күзе кызган әрәмтамак Фирүз. Т. Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» спектаклендә (талантын ташка үлчим) композитор Фәһим. Шул ук авторның «Адәм баласына ял кирәк» әсәрендә салмыш Касыйм образы һәм башкалар.

Куллары алтын икән Касыймның. Җырлый-җырлый җыр кебек матур койма кора ул. Бу катлаулы персонажның да эчке халәтен ачу бурычы И. Бәһмановка йөкләнгән. Артист бөтен осталыгын, актерлык талантын эшкә җигә. Әгәр ул сәхнәдә тамашачыны уйландырган, аның күңелендә нәфрәт кабызган, хәтта геройны куралмас дәрәҗәгә җиткергән икән, димәк, ул образының психологиясен аңлап, фаҗигасен тоеп эш итә. Бер такта кагуны ун сумга исәпләп, ике метр чамасы коймасына мең дә егерме сум акча сорый Касыйм. Үзе көрәктәй куллары белән ап-ак чәчле профессорның үпкә-бавырларын селкетерлек итеп аркасына суга. Тамашачы Касыймның суга алуына ышана һәм тагын да ныграк нәфрәтләнә төшә.

Мария белән Кузьма башына (В. Распутин. «Авылдашлар, акча кирәк») олы хәсрәт килгән. Мария эшләгән кибеттә ревизиядән соң бик күп акча җитмәвә билгеле була. Бу хәл дүрт балалы гаиләне куркыныч астына куя. Бәладән бары тик бер генә юл белән котылырга мөмкин. Авылдашлардан мең сум акча җыеп, җитешмәүчелекне капларга кирәк. Нужа Кузьманы укытучы Евгений Петрович (Ирек Бәһманов) янына китерә. Евгений Петрович саклык кассасыннан алып, йөз сум акча бирергә вәгъдә итә. Әмма Кузьмалар гаиләсенең фаҗигасен аңлап, ярдәм итү максаты белән түгел, бәлки үзенең «әйбәт» кеше булуын күрсәтү өчен. Акча сорап керүченең тәмам җелегенә төшеп, акча мәсьәләсенең җитди икәнлеге турында шактый вәгазь укыганнан соң, үзенең кешеләргә игелек эшләвенә кат-кат басым ясаганнан һәм шуны Кузьмадан кат-кат раслатканнан соң гына вәгъдә итә әле ул акчаны.

Тискәре геройларны бер-бер артлы күз алдына китергәннән соң сорау туа. Тамашачы алдында еш кына шундый кыяфәттә чыгу артист өчен куркыныч түгелме? Юкса кайчагында йөзләренә төкерердәй булып нәфрәтләнә ич халык. «Юк»,— дип җавап бирә куелган сорауга театр фәне. Киресенчә, бу — артистның иҗат мөмкинлекләрен киңәйтүче, реаль фантазиясенә зур юл ачучы сыйфатлар икән, Ирек Бәһманов мисалында без моңа тагын бер мәртәбә ышанабыз.

Йөзгә якын образ иҗат иткән И. Баһманов коеп куйган сәхнә артисты гына түгел. Театр репертуарын төпкә җигелеп тартуы өстенә радио, телевидениедән дә шактый еш чыгыш ясый ул. Мәсәлән, М. Хәбибуллинның «Чоңгыллар» романы буенча эшләнгән телевидение спектаклендә без аны төп герой — Гайзулла ролендә күрдек. Күңел күзе томаланып, кешеләрдән читләшеп тәмам сырхауга сабышкан, гомере буе мәгънәсез тормыш кичергән кешенең бөтен фаҗигасен ачып салды артист.

Гаиләсендә тынычлык юк Гайзулланың. Иң мөһиме — мәхәббәт юк. Еллар, чорлар болганган вакытта бик җиңел генә кулына төшкән алтыннар тынгы бирми. Шуларны яшерә-яшерә үзе дә кырыс, шикчел, җинаятьче кешегә әверелә. Соңгы кадрларда чүлмәге белән алтынын кочаклаган, кая барып бәрелергә белмәгән хәлдә күрәбез без Гайзулла-Баһмановны. Калтыранган тавышы белән кешеләргә алтын тәкъдим итеп йөри ул. Бер генә кеше дә кул сузып, алтын акчаларны алмый. Менә кайда ул чоңгыл, мөнә кайда ул трагедия! Әнә шул трагедияне, гомерен заяга үткәргән картның эче җан газабын бөтен тирәнлеге белән күз алдына бастыра алды Ирек Баһманов.

Белгәнебезчә, нәфис фильмнарны татарчалаштырудан тыш, кино сәнгатендә дә көчен сынап карады Ирек. Казан киностудиясендә Г. Камал әсәрләре буенча эшләнгән нәфис фильмда Вәли ролен башкарды.

Совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен И. Баһманов Татарстанның атказанган артисты дигән исемгә лаек булды. Ә иң мөһиме — кешеләр күңелен, тамашачы мәхәббәтен яулады ул. Тәнгә сихәт, җанга шифа бирә торган саф суын кешеләргә өләшә-өләшә агучы кайнар чишмәдәй, халык алдындагы изге бурычын үти тынгысыз артист. Сәләтен, көч-куәтен, җылы хисләрен һич кызганмыйча туган халкына бүләк итә.

**ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНА.**

# БЕР ЙОЛДЫЗЫҢ МИННӘН БУЛЫР...



Һәр иҗат кешесе хыялы белән күкләргә менә, җир читенә китә, иксез-чиксез далаларда йөри, узган белән киләчәк арасын бәр дәрвиш булып сәяхәт кыла. Адашмый. Яшәешебезнең иң кадерле терәклегә, шигърияткә булган Кеше янына әйләнеп кайта. Аның рухи матурлыгына, кылган эшләрә зурлыгына сокланып илһамлана, иҗат итә. Әгәр шулай булмаса, бөек Заманга яңа бизәкләр, яңа төсләр өсти алмас идә иҗатчы. Дөнья элеккечә калыр иде, иске төсләре үзгәрмәс идә. Яңа көннәрнең, гомерләрнең кадере кешә иҗаты белән генә арта...

Мин шул уйларым бәлән халык артисткасы Гәүһәр Камалова өенә якынлашам. Ишекне бөтенләй таныш булмаган кыз бала ачты. Түргә уздым. Гәүһәр апа өйдә икән. Кухня тәрәзәсенең тышкы ягына асылган җим савытына җим сиба. Ул бу эш белән шулкадәр мавыккан ки, миңа аның тәрәзәсе янына җыелган кошлар белән сөйләшкәнен шактый озак тыңлап торырга туры килде.

— Дусларымны сыйлыйм әле,— диде ул тыныч кына.— Кошларда да кешеләрдә булган гадәт-холыклар бар. Карагыз әле, нинди «көрәш» бара!— дип тәрәзәгә ымлады.

Сүзебез әнә шулай кошлардан башланып китте.

Кеше барыбер кошлар нәселеннән!
Төшләремдә очам кош булып.
Нича очып, нича мәтәлсә дә,
Кеше барыбер сайлый кош юлын,—

дип, онытылмас шагыйрәбез Саҗидә Сөләйманова шигырен сөйләп киттем. Урамда яз иде. Кошларның җылы яктан кайтып килгән көннәре. Гәүһәр апа тыныч кына үз фикерен белдерде:

— Кошлар туган җирләренә кайткан чакта ашкыналар, көне-төне очалар икән,— диде ул,— төнлә юлдан язмас өчен йолдызларга карап очалар. Һәм үзләренә изге саналган җиргә кайтып җитәләр. Көчсезләре генә һәлак була юлда...

Гәүһәр Камалова турында язуы җиңел түгел. Ул сәнгать дөньясында бик тә танылган кеше. Тормышта да, матбугатта да үз иҗатына күптәннән инде бәя алган иҗатчы. Шуның өстәвенә әтисе Габдулла Камал I — классик драматург Г. Камалның иң олы энесе. Урта Азия республикаларында, Оренбургта, үзебезнең Әгерҗедә, Буада беренче милли театрларны оештыручы күренекле татар артисты, режиссер, гомумән, сәнгать дөньясында якты эз калдырган театр эшлеклесе. Әнисе Фатыйма Камалова — Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы, татар театр сәнгатенең нигез ташларын үз йөрәгендә, үз иңендә күтәрешкән фидакарь кеше. Гәүһәр ана шул гаиләдә 1922 елда Ташкент шәһәрендә туа. Бу вакытта Г. Камал I үзбәк театрында режиссер, ә Ф. Камалова артистка булып эшлиләр. Яңа үзбәк театрын тудыруда башлап янып йөрүчеләр арасында атаклы шагыйрь-революционер Хәмзә Хәкимзадә Ниязи да була. Камалларның яңа туган кызларына Гәүһәр дигән исемне дә ул табып бирә. Шулай итеп кечкенә Гәүһәр язмышы белән сәхнә кешесе булып туа, сәхнә артында үсә.

1935 еллар. Ф. Камалова Оренбург колхоз-совхоз театрында эшли. Әтисез калган 12—13 яшьлек Гәүһәр дә аның белән бергә сәхнәгә чыга, концертларда катнаша (әтисе 1933 елда каты авырудан соң үлә). Менә еллар үтү белән сары иңә башлаган бер фоторәсем. Күбәләк булып киенгән Гәүһәр сәхнәдә Г. Тукайның «Бала белән күбәләк» шигырен сөйли. Бу рәсемгә карагач, Оренбург далаларында чәчелеп утырган иске авылларның берсендә — тузанга баткан иске мәчеттә барган концерт күз алдына килә, тамашачыларның алкышлары ишетелгәндәй була.

Шул елларда Оренбург театры репертуарында нык урын алган «Бердәнбер бала», «Булат бабай гаиләсе», «Зәңгәр шәл» спектакльләрендә Гәүһәр малайлар ролен башкарып, тамашачылар арасында «кечкенә артистка» дигән матур исем казана.

Еллар үтә. Гәүһәр Камалова да юллар буйлап бара-бара иң изге саналган газиз җирен таба. Ул изге урын — халык йөрәге. Ул бүген зур хөрмәт казанган кеше — Татарстанның халык артисткасы. Адашмас өчен төнлә йолдызларга карап очкан кошларны бүген ул юкка гына искә алмагандыр, күрәсең. Бик күп якты йолдызларга карап адашмыйча юллар узды ул. Аның тормышта да, иҗатында төп таянычы әнисе булды. Ә инде Бөек Ватан сугышының иң авыр көннәрендә Мәскәүдә А. В. Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) драма студиясендә укыганда ул турыдан-туры сәнгать йолдызлары арасында яши, алардан белем ала. Студиянең җитәкчесе К. С. Станиславскийның талантлы шәкерте О. И. Пыжова һәм башкалар ярдәмендә Гәүһәр бөтендөнья классик әсәрләрендә тамашачыны сокландыра алган образлар иҗат итә алырлык артистка булып җитешә. Моңа аның гел эзләнүчән тынгысыз характеры, табигать мул итеп биргән матур буй-сын, беркемдә дә кабатланмаган үзенчәлекле тавышы нур өстенә нур булып ярдәмгә килә.

Менә Гәүһәр Казанда. Яшь артистка тамашачылар алдында иҗади имтихан тота. ГИТИСның драма студиясен тәмамлаучы яшьләр үзләренең диплом спектаклен — А. М. Горькийның «Васса Железнова» әсәрен Казан тамашачыларына күрсәтәләр. Васса ролендә Г. Камалова. Буржуаз сыйныфның череп таркалуын, һәлакәтен шушы образ аша онытмаслык итеп күрсәтә ала яшь артистка. Театр белгече Х. Кумысников

Г. Камалованың Вассасы турында: «Ул гаҗәеп көчле, нык ихтыярлы, үз дигәнен эшләмичә, теләгенә ирешмичә калмый торган акыллы хатын. Аның байлыкка гына омтылмыйча, балалары, ире, үзе турында төпле уйлары, һичшиксез, тамашачының игътибарын үзенә җәлеп итә. Тамашачы аның фикер агышын, эзлекле рәвештә, эчке каршылыклар аша үсконнән-үсә баруын күрә. Тыштан караганда героиня һаман да әле үзенең ныклыгын саклый. Аның фаҗигасе — җаны-тәне белән алга этәргән эшнең чәлпәрәмә киләчәген сизүдә»,— дип яза.

Бу спектакльне күп кенә тамашачылар хәзер дә хәтерли. Иске дөнья белән җир өстенә мәңгелеккә киләчәк яңаның үзара көрәшендә Васса — юкка чыгачак сыйныф вәкиле. Җиңелергә теләмәү аны ерткычка әйләндергән. Менә ул агу эчереп ирен үтерә. Васса-Камалованың һәр хәрәкәте аерым тормыш детальләреннән тора, тамашачыны ышандыра. Артистка үз уены белән тамашачылар алдында Вассаны үлемгә хөкем итә.



*Н. Исәнбәт. «Миркәй белән Айсылу». Г. Камалова Ләйли ролендә*

Шунысы кызык: әлеге образны татар сәхнәсендә иң беренче булып Фатыйма Камалова иҗат итә. Ул гынамы әле, иҗат гомерендә Гәүһәр апага әнисе тудырган байтак образларны сәхнәдә уйнарга туры килә. Әнисе иҗатына олы хөрмәт белән караган артисткага бик күп иҗади газаплар кичерергә туры килә. Ул яңа образлар иҗат итә. Үзенекеләрне. Шундый образлардан бигрәк тә Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясендәге Гөлбану, «Зифа»сындагы Әйшүкне калку төстә билгеләп үтәргә мөмкин.

Бөтен илгә танылган атаклы Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Г. Камалова сиксәннән артык образ иҗат итте. Бу бит театр сәнгатенә булган гомерлек мәхәббәтнең сиксән биеклеге, төрле төстәге сиксән балкышы. Артистка меңнәрчә тапкыр тамашачылар алдына чыккан, меңнәрчә тапкыр үз образлары белән елаган-көлгән, яшәгән-үлгән. Мәхәббәт һәм нәфрәт көче белән кешеләрне яшәргә, киләчәккә чакырган. Менә ул образларның кайберләре: А. М. Горькийның «Дошманнар»ында бөтен яшәеше гамьсезлектән торган икейөзле Полина, «Соңгылар» әсәрендә революционер егетне тәрбияләп үстергән курку белмәс, батыр рухлы Соколова, Т. Гыйззәтнең «Чаткылар» әсәрендәге изге күңелле Газизә, М. Брэндлиның «Килен кайтты» әсәрендәге шәфкатьсез Амелия Гамельтоны, Х. Вахитның «Күк капусы ачылса» водевилендәге тамашачыны бертуктаусыз көлдерүче Шәмсия, Т. Миңнуллинның «Ир-егетләр»ендәге табигатьнең үзе кебек бай күңелле Гашия, Х. Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» әсәрендәге ил анасы дип атарлык укытучы Хәят Газизовна, «Ике килен-килендәш»ендә Бибигайшә, С. Шакуровның «Туган туфрак» әсәрендәге илкорткыч Маргаретбану, Г. Ибраһимовның «Татар хатыны нилэр күрми» әсәрендәге коточкыч явыз, кансыз Сабира, Ч. Айтматовның «Анам кыры»ндагы сәхнә поэмасы дәрәҗәсенә җиткән Тулганай һәм тагын уннарча образлар. Беркатлылар, явызлар, хәйләкәрләр, фидакарьләр, алдаучы-алданучылар, илгә-көнгә тугры булу өчен, якты киләчәк өчен һәлак булучылар... Артистка боларны барысын да бер максатка буйсындыра — дөнья матур булсын, дөнья пакьлансын, кешеләрнең җаны иркенлектә-иректә булсын.

Сүзебез дөнья хәлләре турында барды. Үз иҗаты турында Гәүһәрападан таки сөйләтеп булмады. Чираттагы спектакльләрен әзерләүдә киңәшләре белән ярдәм итүен үтенеп Гәүһәр апага Чирмешән районыннан килгән кунак кызы да күңеленнән моңа риза түгел. Бәлки артистка хаклыдыр. Һәр иҗат үзе балкырга тиеш бит, нәкъ аныкы кебек. Иҗатың үзе синең турыда сөйләсен.

Халык артисткасының кошларны ятарканын белә идем. Ә менә кошлар турында язылган шигырьләрне яттан сөйләвен ишеткәч, яңа бер спектакль күргән кебек булдым. Күптәннән таныш тавышы бу юлы язгы җил кебек йомшак иде:

**Яшер, күгем, син кошлардан давылыңны,**
**Миңа калдыр, җыры итеп гомеремнең.**
**Син юлдашы, дусты булсаң гомеремнең —**
**Бер йолдызың миннән булыр — мин бирермен...**

**РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ.**

# УКУЧЫНЫҢ КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕНӘ

**Монгол мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Чиста үләндә барча ат ауный, дөреслек сүзен һәр кеше тыңлый.*
*Ялган артыннан күләгә йөри.*
*Карак ачкыч яраштыра, ә алдакчы ялганлый.*
*Хакыйкать сүзе гел алда, ә ялган сүз — гел артта.*
*Пычак аулак җирдә кадала, сүз мәйданда үтерә.*
*Фикерле зат сүзгә таяна.*
*Йомшак тел каты чага.*
*Хәйләкәр төлке койрыгын болгый, хәйләкәр кеше — алдалап сөйли.*
*Үгез адымы — йөрү түгел, мыгырдау сүз булалмый.*
*Бардыр дип тә санамаган үлән аркамны чәнечте.*
*Гадел булмаган табыштан гадел зыяның артык.*
*Арт аяклар алгыга ияра.*
*Шеше уеның катламы җирдән калынрак була.*
*Яр ишелә, кеше ялгыша.*
*Халык белән дус булсаң, халык сүзенә колак сал.*
*Галимнәр күп, иҗатчылар аз.*
*Яхшы ат та мөгри алмый.*
*Нинди үткен пычак та үз сабын үзе кисми.*
*Ике этка бер сөяк.*
*Ничек озын булса да, өзәңге җиргә тими.*
*Пошыйга төбәгән угы тычканга барып тигән.*
*Таяк булса, арка табыла.*
*Саесканнар бердәм булса, юлбарысны җиңәләр.*
*Кешегә булышкан кеше үзенә ярдәм итә.*
*Дусын алдаган кеше үзен үзе алдалый.*
*Кипкән күлдә үрдәк булмый, усаллардан дус кача.*

# БАРЫЙ ТАРХАНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Барый Шиһап улы Тарханов 1892 елның октябрь аенда Сембер шәһәрендә вак сәүдәгәр гаиләсендә туа. Бирედә беренче татар спектакле 1907 елның җәендә куела. Сәхнәгә куелган әсәр «Наданнар һәм галимнәр» дигән пьеса була. Икенче спектакль 1908 елның җәендә куела. Бу вакыт «Сәйяр» труппасы килеп, «Оят яки күз яше» дигән драманы уйный. Драма Сембер губернасында булган вакыйгадан алынып язылганга, шәһәр халкына бик мәгълүм була. Кадимчеләр ни кадәр куйдырмаска йөрсәләр дә, Кариев һәм Мортазин кебек артистларның мондый эшләрдә халык белән аңлашуда аерым осталыклары булу аркасында, спектакль куела.

Б. Тархановка «Сәйяр»ның шушы спектаклендә катнашырга туры килә. Шуннан соң Сембернең үз һәвәскәрләре дә активлашып китә.

1912 елда шәһәргә тагын «Сәйяр» килә һәм «Ачлык кушты»ны, ә 1913 елны «Яшә, Зөбәйдә — яшим мин»не куя. Шулай итеп бу чорда Сембердә театр эшләре уңышлы гына бара. 1914 елның җәендә «Нур» труппасы да килеп чыга. Б. Тарханов бу труппа белән Оренбургка даими эшләргә китә. Ә 1917 елгы февраль революциясеннән соң Тарханов Сембердә «Ирек» труппасы оештыра, соңрак бу труппаның исеме «Кызыл йолдыз»га алмаштырыла.

Гражданнар сугышы елларында Сембер шәһәрендә Бәкер Бәлоусов, Сибгат Гафуров һәм драматург Фәтхи Бурнаш җитәкчелегендә һәвәскәр труппа төзелеп, ул шәһәр хезмәт ияләренә, сукно фабрикасы эшчеләренә, кызыл гаскәрләргә концерт-спектакльләр куя башлый.

«Сембер сәхнәсе электән үк әкренләп эшләп килсә дә, февраль революциясе соңында артист Барый Тарханов кул астында һәвәскәрләр хәзерләнәп, ике атнага бер мәртәбә генә театр вә әдәбият кичәләрә ясап килделәр. Бу ел гаири рус милләтләр эше бүлегенең мөселманнар сәкциясе хозурында татарларга махсус «Театральная секция» ачылып, җирле артистлардан гыйбарәт бер труппа төзелде. Уйнаучыларга яхшы вазифа түләнелә. Яңадан-яңа пьесалар куеп киләләр. Халык күп була»,— дип яза «Яшь көч» газетасы үзенең 1919 ел, 16 июнь санында.

Гражданнар сугышы беткәннән соң, Б. Тарханов Казанга Татар дәүләт театрына чакырыла. Бирედә аның таланты чын мәгънәсендә чәчәк ата башлый. Ул Гогольнең «Ревизор»ында Осип, М. Фәйзинең «Галиябану»ында Бәдри, Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт»ендә Миллер, «Юлбасарлар»ында Моор, Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә»сендә вәзир, Х. Хаҗибәкевнең «Аршин мал алан»ында Рөстәмбәк, Г. Камалның «Банкрот»ында Сираҗетдин һәм башка рольләрне иҗат итә.

1924—1925 елларда Б. Тарханов Буа шәһәр театрында эшли, театрның яңа бинасын салдыра.

1926—1930 елларда Б. Тарханов Ф. Бурнашның «Камали карт»ында Камали карт, «Адашкан кыз»ында мужик, «Хөсәен мирза»да Гаскәр, драматург Генның «Трибун»енда Цвингали, «Җинаятьче гаиләсе»ндә Коррадо, К. Тинчуринның «Казан сөлгесе»ндә мәзин h. б. рольләрне иҗат итә.

1930 елның язында Б. Тарханов Троицк шәһәренә урындагы труппа белән җитәкчелек итү өчен чакырыла. Аңа кадәр Троицкида профессиональ татар театры булмый, һәвәскәрләр труппасы гына эшләп килә. Б. Тарханов килү белән бу труппа бердән һәм оешкан профессиональ театр булып китә. Б. Тарханов белән күп кенә артистлар да бергә килә.

Б. Тархановның Троицк театрында уйнаган рольләреннән: К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр»ендә Мисбах хаҗи, «Зәңгәр шәл»ендә Шәйхи бабай, «Ил кучкәндә»сендә Әсад карт рольләрен күрсәтергә кирәк.

1931 елның җәендә артист Свердловск шәһәренә күчә һәм татар-башкорт театрында эшли башлый.

Бу урында бер нәрсәгә игътибар итеп үтәргә кирәк. Г. Камал үзенең кайбер пьесаларын Г. Кариевка атап язса, Ф. Бурнаш та байтак пьесаларын Б. Тархановка атап, ягъни аның иҗат мөмкинлекләрен искә алып язган: «Адашкан кыз»да мужик, «Хөсәен мирза»да дивана Гаскәр әнә шундый рольләр. Әлбәттә, бу дуслык аларны зур иҗади уңышка ирештерә. «Камали карт роле — Тархановның үзенә карап тегелгән кием шикелле матур»,— дип яза Г. Кутуй заманында.

Б. Тарханов иҗатында берничә теманы күзәтергә була. Көлке образлар (Кәрим бай, Мисбах хаҗи, мәзин һ. б. шундыйлар) белән рәттән, драматик образларны иҗат итүдә дә артист зур осталык күрсәтә. Моңа Гаскәр, Цвингали, Коррадо, Моор һ. б. образлар ныклы дәлил. Күрәсез, артистның иҗат диапазоны бик киң булган.

Рольләрне югары сәнгатьле итеп башкару өчен артист бик күп сыйфатларга ия булырга тиеш. Б. Тархановның килеш-килбәте, сәхнә күркәмлеге булу, көр тавыш һәм ачык дикциясе — болар барысы да аңа иҗатта ярдәм иткәннәр. Б. Тарханов олы артист буларак, табигать биргән күркәмлеген, кешелеклеген, үзенең иң саф хисләрен сәхнәгә алып менә. Аның онытылмаслык образлары әнә шулай туганнар.

**ХӘСӘН ГОБӘЙДУЛЛИН.**

# УКУЧЫНЫҢ КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕНӘ

### Монгол мәкальләре һәм әйтемнәре

*Вак таш булып таралганчы, кыя булып кинәт ау.*

*Угын аткач, җәясен яшерә.*

*Ат яхшылыгы иярдән түгел, кешене кием күркәм итәлми.*

*Бер утлы кисәү янганнан салкын су кайнап чыкмый.*

*Мал үлсә — этләр җыйнала, кайгылы җиргә муллалар килә.*

*Ана сөте — изге су.*

*Гаебе булган кеше яктыдан курка.*

*Эткә бәйләнсәң, итәгең булмас, байга бәйләнсәң, башсыз калырсың.*

*Күрмисең икән, нигә карыйсың.*

*Үзе өйдә, уе дәрьяда.*

*Сусыз җирдә көймә кирәкми.*

*Үләсе килгән тычкан мәче койрыгын тартыр.*

*Тукмак — казыкка башлык.*

*Татлыны әче итүе җиңел, әчене татлы итүе кыен.*

*Авыр чакта ныклык кирәк, җиңел көндә — сак булу.*

*Күк күкрәвен һәм халык шаулавын һич тыеп булмый.*

*Ике бердәм ике дистә ялгызны ега ала.*

*Пычак белән борчага яный.*

*Үтелгән юл җиңел юл була.*

*Кояш бер кайчан сүнми дә халык бер кайчан җиңелми.*

*Һәр үрнең — үз сөзәге, һәр кешенең — үз холкы.*

*Дусы күп кеше — дала кебек киң, дусы юк кеше — уч төбедәй тар.*

# ТЕЛДӘН-ТЕЛГӘ КҮЧӘ КӨЛКЕ СҮЗ

*Төрле халыклар иҗатыннан*

* * *

— Зират капкасы янында торган ул велосипедны ник урладың?
— Мин аның иясе үлгәндер дип уйладым.

* * *

— Сез телевизордан чыгышлар ясый башлаганнан бирле алар күбрәк сатыла башлады!
— Әйе, дөрестер бу. Мин дә үз телевизорымны саттым.

* * *

— Хәзер безгә берәр айнылткыч нәрсә бирсәгез иде, официант!
— Рәхим итегез, менә сез түләргә тиешле акчаның суммасы язылган кәгазь!

* * *

— Доктор, йоклаганда саташып сөйләшәм икән.
— Ә моның ни куркынычы бар?
— Мин эшләгән бүлекнең бөтен хезмәткәрләре бик каты көләләр дә йокымнан уяталар мине.

* * *

— Ирем командировкада йөргән арада мин яхшы итеп аш-су әзерләргә өйрәндем.
— Кайткач ни диде соң ул үзе?
— Тагын командировкага чыгып китте.

* * *

— Синең әбиең таеп егылган икән дә уң кулының өч бармагын имгәткән, имеш. Алар хәзер бөтенләй бөгелми диләр. Дөресме?
— Чеп-чи ялган бу. Әле кичә генә ул миңа нәкъ шул өч бармагы белән кукиш күрсәтте!

* * *

Берәүнең хатыны бик лыгырдык була һәм теләсә нәрсә турында туктаусыз текелдәп иренә һич тынгылык бирми икән.
Көннәрнең берендә ире джаз музыкасы концертына китәргә җыенгач, сорый аңардан шул ханым:
— Шул дөбердәвек концерттан нинди тәм табасың икән син?
— Анда тыныч була,— ди ире.

* * *

— Хәлләр ничек? — дип сорый берәү үзенең ахирәт дустыннан. Балаларың да бардыр инде, шәт?
— Бар.
— Ничәү соң?
— Эш хакымның өчтән бере хәтле...

* * *

Аудиториядән чыккан бер студентны дуслары урап ала.
— Я, ничек? Тапшырдыңмы?
— Булды бугай.
— Укытучы нинди сораулар бирде соң?
— Кем белгән аны!.. Ул бит инглизчә сөйләшә.

* * *

— Карчыгың ни хәлдә?
— Коточкыч яман! Аңарда невралгия, неврит, неврастения бар дип тапканнар... Һәм тиздән невроз да башланачак икән...
— Гафу итегез, мондый симптомнарны берьюлы тоеп-белеп булмыйдыр кебек?
— Мөмкин! Әнисе аңа медицина сүзлеге бүләк иткән, һәм ул хәзер шуның «Н» хәрефенә башланган төшенчәләрен җентекләп өйрәнә...

* * *

— Әгәр без өйләнешмәгән булсак, син минем белән тагын никахлашырга теләр идеңме, иркәм?
— Зинһар өчен, иске җәнҗалларны яңадан башламыйк әле!

* * *

— Хатыныгыз белән шулай бик озак сөйләшми торуны нәрсә белән аңлатырга мөмкин?
— Барысы тик минем тәрбиям белән.
— Ә нинди тәрбия соң ул?
— Мин хатын-кыз башлаган сүзне бүлдерергә яратмыйм.

* * *

— Бу чыннан да балык шулпасымы?
— Һич тә шикләнмәгез, поварның аңа суны аквариумнан салганын үзем күрдем.

* * *

— Өйләнгәнсең икән дип ишеттем? Ник шулай бик ашыктың?
— Ашханәләргә йөрүдән бик туйган идем.
— Ә хәзер?
— Ашханәләрне бик яратам һәм бик теләп йөрим.

* * *

— Ник болай, улым, бик кыйммәтле сигаретлар гына тартасың әле син? Менә мин гел арзанлыны гына суырам!
— Синеке кебек биш балам булса, мин бөтенләй тартмас идем, әги!

* * *

— Иптәш милиционер, әнә тегендә күптән инде кешеләр әүмәкләшеп кыйнаша!
— Ә ник син моны элегрәк килеп әйтмәдең?
— Чөнки моңарчы минем әти өстә иде...

* * *

— Кичә мәрхүм картымның өебезгә кайтып кергән шәүләсен күрдем.
— Нәкъ ул үзе булганын каян беләсең?
— Чөнки, гадәттәгечә, ярты төннән соң гына кайтты.

* * *

Иртә таңда берәүнең үз өенә тәрәзәдән кереп маташканын күрә бер милиционер.
— Нишләвегез бу, гражданин?
— Фатирыма керәм.
— Ә ник тәрәзәдән?
— Чөнки... ишек төбендә хатыным тора.

* * *

— Син, картым, кичә тагын эчкәнсең бит.
— Каян белдең?

— Үзең шулай дидең бит кайткач.
— Исерек баш нинди юләр сүз әйтмәс...

* * *

— Нишләп бүген болай бик боек утырасың әле син?
— Бер нәрсәне һич хәтерли алмыйм — хатын миңа кайсын әйтте икән: бер савыт сыра эчеп, кичке сәгать унга кайтыргамы, әллә ун савыт эчкәч, төнге бердә өйдә булыргамы?

* * *

— Миңа яңа тарак алырга кирәк. Искесенең теше сынды.
— Ник акчаны шулай күп тотарга? Сынык бер теш өчен яңа тарак ал, имеш...
— Ул бит иң соңгы теш иде.

* * *

— Авыруыгызның сәбәбен әйтә алмыйм, әмма хикмәт эчемлектәдер дип беләм.
— Алайса, доктор, Сез мине бүтән чакта, үзегез айныгач, карарсыз...

* * *

Юлбарыслар читлеге каршында торганда, зоопарк хезмәтчесе үз хатынына әйтә икән:
— Бик үтенеп сорыйм, кадерлем, бу җанварлар алдында минем белән, зинһар дим, талаша башлама: авторитетым бөтенләй төшәчәк бит...

* * *

— Миңа әзмәвердәй өч ир һөҗүм итте, дисез. Алар сезне канга батырып кыйнаганнар һәм киемегезне дә салдырганнар... Ә ник бернинди каршылык күрсәтмәдегез?
— Шул кара эшкә катнашасым килмәде.

* * *

Кияүгә чыккан кызга әнисе киңәш бирә:
— Шуны исеңдә тот, балам: беркайчан да ирең белән бәхәскә керmә! Беренче сүз ишетүгә үк үзең җылый башла!

* * *

— Мин кичә өч кило чамалы бер балык эләктердем!
— Ә минеке ике килога артыграк иде!
— Әллә үлчәдеңме?
— Юк, кибетче үлчәде. Зур балыкны мин үземә алдым, ә кечерәген сиңа дип калдырдым.

* * *

— Кызыгыз пианинода ничек уйный?
— Инде халыкара уңышка иреште — аның аркасында ике күршебез Австралиягә күчеп китте.

* * *

— Мин төн буе Сезнең турыда уйладым, доктор?
— Чынлапмы?
— Әйе, доктор, ниндидер ярамаган әйбер ашаганмын, ахры...

* * *

— Карале, улым, чакырам-дәшәм, ә син һаман ишетмисең-килмисең. Белмим, синнән кем генә чыгар икән үскәч.
— Официант чыгардыр, ахры, әнкәй.

* * *

— Ник шулкадәр күп мәче асрыйсың?
— Күршеләр хакына.
— Алар мәче яраталармыни?
— Яратсалар, асрамас та идем.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### КПСС ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА КИҢӘШМӘ

КПСС өлкә комитетында республика һәм район газеталары, журналлар, нәшриятлар, телевидение һәм радиотапшырулар, идеология учреждениеләре хезмәткәрләре, иҗат оешмалары вәкилләренең киңәшмәсе булды. Анда «КПСС Үзәк комитетының май (1982 ел) Пленумы йомгаклары һәм 1990 елга кадәрге чорга СССРның Азык-төлек программасын аңлату һәм пропагандалау буенча республиканың массовый информация средстволарының бурычлары» дигән доклад белән КПСС өлкә комитеты секретаре Ф. А. Садыйков чыкты.

Киңәшмә эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзының чираттагы ачык партия җыелышы КПСС Үзәк Комитетының май Пленумы карарларын тормышка ашыруга багышланды. Аны кереш сүз белән партоешма секретаре Ринат Мөхәммәдиев ачып җибәрде. Аннары бүгенге авыл турында иң актив иҗат итүче язучылар Мөсәгыйть Хәбибуллин һәм Мөхәммәт Мәһдиев сүз алды. Алар бүгенге авыл тормышы өчен бик мөһим булган социаль, экономик һәм әхлак мәсьәләләре турында сөйләделәр. Г. Ахунов, З. Нури, Р. Мостафин, Т. Миңнуллин, Б. Камалов, Р. Мингалимов, М. Галиев, Ә. Гаффар язучылар алдында торган конкрет бурычларга тукталдылар.

### РЕДАКЦИЯДӘ СӨЙЛӘШҮ

КПССның 1982 елгы май Пленумы карарлары буенча ТАССР Язучылар союзы белән «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе оештырган «Түгәрәк өстәл» янында сөйләшү уздырылды. Очрашуда язучылардан Г. Ахунов, Г. Минский, М. Садри, Л. Ихсанова, М. Зарипов, Ф. Миңнуллин, Ф. Мусин, Р. Мөхәммәдиев, Б. Камалов, Р. Фәйзуллин, Р. Кәрами, М. Вәлиев, Г. Кашапов һ. б. катнашты. Сөйләшүдә катнашучыларның чыгышларында СССРның Азык-төлек программасын тормышка ашыруда язучылар алдында да зур бурычлар торуы, авыл тормышының тирән гомумиләштерүләр таләп итә торган күп кенә җитди проблемалары турында сүз барды.

### ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ БӨТЕНСОЮЗ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Чаллы шәһәрендә «Социалистик яшәү рәвеше, яшь шәһәрләр һәм хәзерге заман әдәбияты» дигән мөһим темага язучыларның Бөтенсоюз иҗат конференциясе үткәрелде. Конференцияне СССР һәм Татарстан Язучылар союзлары, «Новый мир» журналы редакциясе һәм КПССның Чаллы шәһәре комитеты оештырды. СССРның 60 еллыгына багышлап үткәрелгән бу бәйрәмдә Мәскәүдән, РСФСР, Украина, Белоруссия, Казагыстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Литва, Эстония һәм Татарстаннан барлыгы 40 тан артык язучы катнашты. Конференцияне КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты. Аннары СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев һәм партиянең Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. К. Беляев чыгыш ясады.

Язучылар хезмәт һәм көнкүреш шартларын камилләштерү өлкәсендә Чаллыда алып барыла торган зур эшләр белән таныштылар, яңа төзелешләрне, спорт корылмаларын, балалар, культура-агарту учреждениеләрен карадылар. Автомобиль комплексында булып, эшчеләр белән кызыклы әңгәмәләр үткәрделәр. Чыгыш ясаучылар арасында СССР Язучылар Союзы идарәсе секретаре Ю. Суровцев, РСФСР Язучылар Союзы идарәсе секретаре М. Шевченко, шагыйрьләр Лев Ошанин, Александр Преловский, Людмила Шаменкова кебек танылган язучылар булды. Кичәләрдә шулай ук Казаннан Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов, язучылар Сибгат Хәким, Диас Вәлиев, Чаллы Язучылар союзы оешмасы секретаре Разил Вәлиев, Әхәт Гаффар һ. б. катнашты.

### ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ

Вильнюс шәһәрендә үткәрелгән Бөтенсоюз семинарының көн тәртибе әнә шундый иде. Анда Татарстаннан тәнкыйтьче Мансур Вәлиев катнашты һәм «Соңгы еллар әдәби тәнкыйтендә кайбер яңа тенденцияләр» дигән темага чыгыш ясады.

### МУСА ҖӘЛИЛ ШИГЫРЬЛӘРЕ ИНГЛИЗ ТЕЛЕНДӘ

Патриот-шагыйрь Муса Җәлил шигырьләре инглиз телендә басылып чыкты. Бу китапны Мәскәүнең «Прогресс» нәшрияты 94 мең тираж белән чыгарган. һәм ул «Сайланма лирика», «Моабит дәфтәреннән» дигән ике бүлектән тора. Шигырьләр ике телдә — инглиз һәм рус телләрендә, иллюстрация белән бирелгәннәр.

Китапка кереш мәкаләне Рафаэль Мостафин язган.

### ДРАМАТУРГЛАР КИНОСТУДИЯДӘ

Казан киностудиясендә драматурглар Д. Вәлиев, Р. Батулла, Р. Мингалим белән

кызыклы очрашу булды. Аларга студия төшергән берничә документаль фильм күрсәтелде. Соңыннан шул фильмнар турында фикер алышуда Татарстан киностудиясе алдында торган конкрет бурычлар, мөһим мәсьәләләр турында сүз барды.

## «КЕШЕЛӘР һӘМ КИТАПЛАР»

Сергей Баруздинның «Советский писатель» нәшрияты чыгарган «Кешеләр һәм китаплар» исемле җыентыгында 60 тан артык әдипнең портреты бирелгән. Алар — илебез укучылары күңеленә киң юл тапкан авторлар — төрле милләт вәкилләре, төрле буын кешеләре. Татар совет әдәбияты осталарыннан берсе Гомәр Бәшировның иҗатына багышланган язмада автор әлеге иҗатка яшәү көче биргән чыганаклар белән таныштыра, аның илебез әдәбияты хәзинәсенә керткән өлешен югары бәяли. Бирелә шулай ук М. Фәйзуллина турында да язма бар.

## ӘДИПКӘ 90 ЯШЬ

15 июньдә С. Радзиевскаяга 90 яшь тулу уңае белән язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында тантаналы кичә үткәрелде. Әдипнең иҗат юлы турында доклад белән Н. Орешина чыкты. Кичәне Г. Ахунов алып барды.

* * *

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм туксан яше тулу уңае белән С. Б. Радзиевскаяны хөкүмәтебез Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләде.

* * *

Республика балалар китапханәсендә язучы С. Радзиевскаяга 90 яшь тулуга багышланган кичә үткәрелде. Әдипнең иҗаты турында кереш сүз белән Н. Орешина чыкты. Аннары С. Радзиевская мәктәп укучыларына үзенең әсәрләренең язылу тарихын, бай тормыш биографиясеннән кызыклы вакыйгалар сөйләде, сорауларга җавап бирде.

## КАЗАН КУРЧАКЛАРЫ ИЛ ГИЗӘ...

Моннан ун еллар элек драматург Р. Батулланың «Әбугалисина» пьесасы Казан, Саратов, Кемерово, Барнаул шәһәрләре курчак театрларында куелган иде. Быел драматургның ике яңа пьеса-әкияте («Төш вакытындагы могҗиза», «Курай уйный торган бер малай») Омск, Томск, Кострома, Липецк, Нижний Тагил курчак театрларында зур уңыш белән бара.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Оешмада КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумы карарлары уңаеннан язучыларның бурычларына багышланган җыелыш булды. Җыелышта язучы Р. Төхфәтуллин доклады тыңланды. Доклад буенча фикер алышуларда Г. Афзал, Ә. Маликов, Ж. Рәхимов, Ш. Бикчурин, Э. Мөэминова, А. Хәсәнов, К. Булатова, Н. Әхмәдиев, Ә. Габиди һәм Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре Әхәт Гаффар катнашты.

* * *

Сарман районында әдәбият һәм сәнгать атналыгы үткәрелде. Очрашуларда Ш. Бикчурин, Э. Мөэминова, К. Булатова, Ә. Гаффар, Ә. Габиди, А. Хәсәнов, Д. Гарифуллин, Ф. Галиева һәм И. Кушаев катнашты.

Оешмада танылган әдипләрнең иҗат кичәләрен уздыру традициягә әйләнеп бара. Күптән түгел Әлмәтнең почетлы нефтьчесе әдип Гариф Ахуновның, шулай ук язучы Аяз Гыйләҗевның иҗат кичәләре булды. Г. Ахунов Һиндстан һәм Нигериягә бару истәлекләре белән уртаклашты. А. Гыйләҗев нефтькә кагылышлы проблемалар турында сөйләде. Язучылар әдәбият сөючеләрне иҗат планнары белән таныштырдылар, күп санлы сорауларга җавап бирделәр.

Иҗат кичәләрен язучы Әхәт Гаффар алып барды.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Оешмада матур әдәбиятны пропагандалау эше көннән-көн көчәйтелә. Күптән түгел Чаллы язучылары Кама автомеханика техникумында, сәнгать училищесында, Алабуга педагогия институтында һәм Чаллының культура сарайларында әдәби очрашулар уздырдылар. Анда Разил Вәлиев, Эдуард Касыймов, Нәҗип Мадьяров, Тәлгать Галиуллин, Газиз Кашапов, Мансур Сафин, Евгений Кувайцев, Казаннан Мөхәммәт Мәһдиев катнашты.

## ЯҢА БЕРЛӘШМӘ

Балтач районының «Хезмәт» газетасы каршында «Янар чәчәк» дигән яңа иҗат берләшмәсе ачылды. Аның җитәкчесе итеп Әхәт Фазылҗанов сайланды. Күпләгән авторларны, җырчыларны һәм композиторларны туплаган әлеге әдәбият һәм сәнгать берләшмәсенең беренче утырышында, ук унбишләп авторның иҗатына күзәтү ясалды. Утырыш эшендә Илдар Юзеев белән Шәүкәт Галиев катнашты.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Июнь ахырында Пермь өлкәсендә совет әдәбияты көннәре булып узды. СССРның 60 еллыгы уңае белән уздырылган бәйрәмдә илебезнең төрле республикаларында яшәүче совет язучылары катнашты. Татарстан вәкиле Равил Фәйзуллин делегация әгъзалары белән бергә Пермь, Чайковский, Оса, Воткинск шәһәрләрендә, Оханск, Частые, Барда районнарында булды, укучылар алдында чыгышлар ясады.

*
* *

Илдар Юзеев Башкортстанның Яңавыл эшчеләр поселогында «Замандаш» әдәби берләшмәсе әгъзалары белән очрашты. Ул бүгенге татар совет әдәбиятының торышы, республикадагы әдәби берләшмәләр һәм яшь көчләр белән эшләү тәҗрибәсе хакында сөйләде.

*
* *

Язучылар М. Хәбибуллин һәм М. Скороходов Түбән Кама шәһәренең предприятиеләрендә, профессиональ-техник училищеларда һәм мәктәпләрдә очрашулар үткәрделәр. Алар әдәбият сөючеләрне бүгенге әдәби хәрәкәтнең торышы һәм үзләренең иҗади планнары белән таныштырдылар, әсәрләрен укыдылар.

*
* *

Казанның текстиль-галантерея фабрикасында шагыйрь М. Хөсәен чыгыш ясады. Ул эшчеләргә үзенең соңгы вакытта иҗат иткән шигырьләрен һәм сонетларын укыды.

*
* *

Югары Ослан район культура йортында язучы А. Расихның «Ямашев» романы буенча китап укучылар конференциясе үткәрелде. Анда автор әдәбият сөючеләрнең күпсанлы сорауларына җаваплар бирде һәм әсәренең язылу тарихын сөйләде.

Республикабызның Минзәлә, Әлмәт, Балык Бистәсе h. б. районнарында язучылар Р. Ишморат, Р. Ишморатова, М. Хөсәен, Р. Гәрәй, Г. Зәйнәшева, Р. Кәрами, Рәшит Әхмәтҗанов, Ә. Гадел, Ж. Дәрзаман, К. Кәримов, композиторлар Сара Садыйкова, Риф Гатауллин, җырчы М. Галиев һәм башкалар булып кайтты.

*
* *

Шагыйрьләр И. Юзеев, Р. Гатауллин, тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев Мамадыш районында булып кайттылар. Район хезмәт ияләре һәм игенчеләр, терлекчеләр белән очраштылар, КПСС Үзәк Комитетының май Пленумы (1982 ел) карарларының әһәмияте хакында әңгәмәләр уздырдылар, яңа әсәрләре белән таныштырдылар. Район газетасы каршындагы «Агымсу» әдәбият берләшмәсенә йөрүчеләрнең яңа әсәрләре тикшерелде.

*
* *

Чиләбе өлкәсендә әдәби атналык уздырылды. Бу әдәби бәйрәмдә Татарстаннан Равил Фәйзуллин һәм Газиз Кашапов катнаштылар. Алар Чиләбе әдипләре белән бергә Златоуст, Миасс шәһәрләрендә, Кунашак районы авылларында да, телевидение буенча махсус оештырылган тапшыруда да чыгыш ясадылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет сынлы сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен художник Бакый Идрисович Урманчега, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1982 ел, 28 июнь Указы белән «РСФСРның халык художнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Ринат Арифжанович Тажетдиновка РСФСР Верховный Советы Президиумының 1982 ел, 3 июнь Указы нигезендә «РСФСРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

# Социалистик Татарстан

**Хөрмәтле иптәш!**

КПССның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Министрлар Советы органы — «Социалистик Татарстан» газетасы әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрен яктырту өлкәсендә дә бай традициягә ия. Һәр атнаның якшәмбесендә аның өченче бите махсус әдәбият һәм сәнгатькә генә багышлап чыгарыла. Анда күренекле әдипләребезнең мәкаләләре, яңа әсәрләре урнаштырыла, шулай ук яшь һәм башлап язучылар иҗатына да зур игътибар бирелә.

Газета театр, музыка, рәсем сәнгате, әдәбият һәм сәнгать проблемалары турында тирән анализлы мәкаләләргә дә урынны кызганмый. Шулай ук яңа спектакльләргә, китапларга рецензияләр бастырып чыгарыла, тугандаш әдәбиятлар дуслыгы темасы киң яктыртыла. Моннан тыш «Авылым таңнары» исемле махсус сәхифәләрдә дә әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре еш катнаша, СССРның Азык-төлек программасын тормышка ашыруга кагылышлы мәкаләләр белән чыгыш ясый.

«Социалистик Татарстан» газетасына язылу һәркайда, шул исәптән Татарстаннан читтәге өлкәләрдә һәм республикаларда да берниндн чикләүсез кабул ителә. «Социалистик Татарстан» газетасы Бөтенсоюз каталогына (2 нче кушымта) кертелде. Индексы — 54123. Язылу бәясе: бер елга — 7 сум 80 тиен.

# АЗАТ ХАТЫН

**«Азат хатын» журналын** илебезнең төрле өлкәләрендә яшәүче хатын-кызлар ай саен көтеп алалар. Хәер, нигә хатын-кызлар гына? Бу журналны ир-егетләр дә бик яратып укый. Шулай булмый мөмкин дә түгел: журнал битләрендә авыл хуҗалыгының һәм промышленностьның мөһим мәсьәләләре күтәрелә, культура, фән, сәнгать яңалыклары яктыртыла, тарихи сәхифәләргә киң урын бирелә. Әдипләребезнең, шагыйрьләребезнең күп кенә яңа әсәрләре иң беренче булып шушы журналда дөнья күрә.

Мәхәббәт, гаилә төзү, бала тәрбияләү мәсьәләләре дә журналда мөһим урын алып тора.

Кыскасы, журнал күтәргән темаларны санап чыгу да җиңел түгел. Иң яхшысы — аны даими алып, укып бару. Журнал Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Индексы — 73002. Аңа илебезнең барлык почта бүлекләрендә чикләнмәгән рәвештә язылырга мөмкин. Язылу бәясе — елга 3 сум.

әясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!**

Безнең халык кунак ярата. Кем килсә дә, ишекләре ачык аның. Шундый кунакларның берсе — «Казан утлары» журналы. Ул — айга бер генә килә торган мавыктыргыч, тыйнак кунак. Аны һәр өйдә көтеп алалар, яратып укыйлар. Без, редакция хезмәткәрләре, укучыларыбызның күп булуы белән чиксез горурланабыз һәм, әлбәттә, аларның ышанычларын аклар өчен бөтен көчебезне куябыз. Бу максатка безне КПСС Үзәк Комитетының «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик тәзелеш практикасы белән иҗади бәйләнеше турында»гы карары да рухландыра.

60 яшьлек журналыбыз үзенең әсәрләрен һәрвакыт киң катлам укучыларга дип чыгара. Журнал битләреннән сез әдәбиятыбыз, культурабыз тарихына караган, шулай ук әдәбият белеме, бүгенге татар совет әдәбияты алдындагы проблемаларны күтәргән материаллар таба аласыз. Үзешчән сәнгатьтә катнашучылар, культура-агарту өлкәсендә эшләүчеләр өчен яңа пьесалар, яңа җырлар дөнья күрә.

КПССның Май Пленумы карарларын, СССРның Азык-төлек программасын тормышка ашыру йөзеннән, журнал редакциясе иң яхшы очеркларга конкурс игълан итә. Күренекле язучылар, танылган журналистлар язачак конкурс очерклары авыл хезмәтчәннәре тормышын яктыртып барачак. Сез алардан үз арагызда яшәүче хезмәт батырларын да, күренекле якташларыгызны да табарсыз. Шулай ук журналның һәр санында бүгенге әдәби процесс, республикабызның культура тормышы киң яктыртылып барачак.

«Казан утлары» журналы Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Индексы — 73210. Язылу барлык элемтә бүлекчәләрендә, хат ташучылар, җәмәгать башлангычында матбугат таратучылар тарафыннан чикләүсез кабул ителә. Журналга үзегез язылу белән генә чикләнмәгез, бергә эшләгән иптәшләрегезнең, якыннарыгызның, туганнарыгызның һәм күршеләрегезнең дә исләренә төшерегез! **Әгәр ниндидер тоткарлыклар килеп чыкса, еллык язылу хакын төгәл адресыгыз белән редакциягә җибәрә аласыз.** Безнең адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2, редакция журнала «Казан утлары».

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии